# казан утлары

2
ФЕВРАЛЬ • 1978




# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**2**

ФЕВРАЛЬ
1978

## Бу санда

С. ХӘКИМ. Кырның бер төшендә кояш. Шигырьләр . . . 3
Г. ӘПСӘЛӘМОВ. Агыла болыт. Роман . . . . 9
Р. ХАРИС. Бәхетлерәк кем бар бездән! Шигырьләр . . . 90

Ф. ХӨСНИГӘ 70 ЯШЬ

Ф. ХӨСНИ. Картая белмәс картлык. Повесть . . 96

С. БАТТАЛ. «Татарлар елмаеп үлделәр». Шигырь . 142
Ә. АТНАБАЕВ. Сау булыгыз. Шигырьләр . . . 144

М. И. УЛЬЯНОВАНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Н. КРУПСКАЯ. Владимир Ильичның сеңелесе . . 147
Е. СТАСОВА. Ульяновлар гаиләсе хатын-кызлары 149
В. КАРПИНСКИЙ. Каһарманлык . . . . . . . 150

СОВЕТ АРМИЯСЕНЕҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

М. ГАЛИЕВ. Җиңүчеләр мәрхәмәте . . . . . 151
С. КАЛЬМЕТОВ. Хурлык тамгасы . . . . . . 159

СӘНГАТЬ

Б. УРМАНЧЕ. Архитектор Исмәгыйль Гайнетдинов 160

ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

В. ВОЗДВИЖЕНСКИЙ, М. МАННУРОВА. Муса Җәлил һәм Каршылык хәрәкәте поэзиясе . . 167

КИТАП КҮЗӘТҮ

Р. НИЗАМИЕВ. Мәңгелек сәяхәт . . . . . . . 173
Р. МОСТАФИН. Хис һәм фикер берлеге . . . 176

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**Ә. Камалга 70 яшь** . . . . . . . . . . . . . . 181
**В. Воздвиженскийга 50 яшь** . . . . . . . . . 182
**М. Шәрифуллинның туууына 50 ел** . . . . . . 183

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**ГӨР-ГӨРИ. Пародияләр һәм эпиграммалар** . . . 184
**А. ЯХИН. Күргәзмә әсбап.** Хикәя . . . . . . . 186

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . . 189

Редакциянең адресы: Казан, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов** (баш редактор урынбасары), **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

---

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

---

Производствога бирелде 14/XI-1977 ел. Басарга кул куелды 10/I-1978 ел. ПФ 07005. Кәгазь форматы 70×108[1]/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 94 544 экз. Заказ Б-405. Бәясе 50 тиен.

---

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1978 ел.

## Сибгат Хәким

# КЫРНЫҢ БЕР ТӨШЕНДӘ КОЯШ

### Павлов йорты...

Павлов йорты... Утырмаган кеше
Монда роман язып,
Кычкырды кук шул йорт подвалыннан
Миңа Рамазанов.
Кинәт шунда куркынычны тойдым
Минем өскә килгән,
Кычкырды кук Сталинградча усал:
Саклан снайпердан.
Павлов йорты. Йөрмә герой эзләп
Монда син әсәргә,
Кешелегең өчен сөенәсең
Кая сөялсәң дә.

### Шәһәр паркы, аерым кабер...

Шәһәр паркы, аерым кабер, һәйкәл.
Илләр урый-урый,
Сталинград өчен һәлак булган
Рубен Ибаррури.
Куңел өчен сынап, Сталинградның
Җирен карыйм чукып:
Шул кабердә бергә рус солдаты —
Ята Каменщиков.
Көттең, ана, айлар, еллар көттең,
Хаттан-хатка көттең,
Шул кабердә, шунда рухы татар
Фәттахетдиновның.
Парк. Кабер. Идел буйларының
Моңсу искән җиле.
Шул җил белән килә ераклардан
Моңсу испан җыры.

●

Данлы Курган. Тып-тын торасыңмы,
Ятып елыйсыңмы...
Сталинградка кушып булмый бутән
Шуннан зур исемне.

●

Зират өстендә иртә-кич
Тора кошлар чыр-чуы,
Кешенең җаны, күрәсең,
Мәңге шулай борчулы.

## Көтүче

Яшел тугае, болыны,
Дөньясы бер җыр кебек,
Баскан ул көтү алдына
Бөек дирижер кебек.

●

*Казан дәүләт педагогия
институтының 100 еллыгына.*

Әй, мәһабәт бина, сиңа карыйм,
Караган күк гашыйк көнче кыз,
Кайнап, шаулап синдә булып узды
Ким дигәндә ярты көнчыгыш.

Хәтерлимен синең ишегеңнән
Курка-курка кергән чакларны,
Каршылады залларыңда түрдә
Толстойлар — көрәк сакаллы.

Буразнадан — сиңа, изге йортка,
Тышта калды гүя гөнаһлар.
Язу өлкәсендә Толстойлар
Әле һаман миңа графлар.

Әй, мәһабәт бина, изге нигез,
Калын ишек, калын таш идән.
Әле һаман мин шул графларның
Алларына килеп баш иям.

Яшьлегемдә минем фатихалар
Бик күп иде, тоттым имтихан,
Гомерлеккә бары берсе калды:
Җырларыма биргән фатихаң.

●

Русның танылган шагыйре
Михаил Львов белән
Очраштык, татар икәне
Күзеннән беленеп тора.

Мавзолей ишеге төбендә
Очраштык, йөз шат аның,
Гүя бер тапкыр югалтып,
Шушында үз татарын
Яңадан тапкан шикелле,
Үскәнбез аерым, ләкин
Бер тигез хезмәт итәбез:
Ул-дәүләт, ә мин-хәким.
Ул баксаң, Дәүләт [1] малае,
Гап-гади Рәфкать икән!
Әйләнеп кайтсаң аслыңа,
Үзеңә рәхәт икән.
Очраштык, изге минутлар
Нигә икән аз була?
Ленин алдында кешеләр
Кайта кинәт аслына.
Яшибез ватанлы, илле
Һәм төрле телле булып,
Нигәдер Ленин алдында
Калабыз милли булып.
Очраштык, бер-беребезне
Шушында аңлый төштек,
Сүз бирдек татарча, телне
Сакларга ант итештек.

## Сусау

Күңелгә минем, туган як,
Бигрәк тә якын шул син,
Кырларың өстеннән искән
Җилләргә хәтле сусыйм.
Туктаусыз янган җанымда
Калды тик сусау гына,
Мин бит бәхетле бары син
Бәхетле булсаң гына.
Ник болай сагышлы иттең
Бу кадәр мине соң син?
Аерылып бер көн дә узмый,
Яңадан сиңа сусыйм.
Бу нинди гомерем буена
Бетмәгән сусау икән?
Үлгәндә башым очында
Су салып торсаң икән.

## Бер авыл каен утырткан

Бер авыл каен утырткан,
Полосада гел каен,
Гел каен, шаулый көн саен,
Бер каен һәр тол саен.
Сөйли кайгысын үзенчә
Шул каеннар толларга,
Толлар — каеннарга... авыр
Бар да тып-тын торганда.

[1] М. Львовның отисе — Дәүләтша. Дәүләтша Шаһи улы Габитов.

## Тукай дәфтәреннән

●

Кирәк түгел төрле афишалар,
Кирәк түгел төрле игъланнар,
Бәйрәм икән, юбилее икән
Тукай үзе йөри иң алдан.

Көе, моңы — бар да үзенеке,
Хәсрәтләнмә: каян җыр алыйк?
Тукай диден: хәрәкәткә килә
Халык үзе, үзе зур тарих.

●

Татарлары, белмим, кая киткән?
Зурмы, кинме, тап-тар гынамы,
Анда түгел хикмәт, килгән яшәп
Җаекта бер татар урамы.

Тора-бара барыбер бетәр иде;
Башка исем белән аталды:
Хәзер — Тукай, гомер буе шулай
Саклап калган Тукай татарны.

## Бәрәңге төбе өям

Син шигырь язарга өйрән,
Баланның телен өйрән,
Ә мин көрәгем алам да
Бәрәңге төбе өям.

Өям уртасында торып
Үзем сызган сызыкның,
Талый газабы үземнән
Үзем ризасызлыкның.

Әйтерсең бүген күңелгә
Бар әрнү туры килгән,
Онытылып, башым күтәрми,
Бәрәңге төбе өям.

●

Безгә хәтле йөз мәртәбә сынап,
Кулы белән капшап йөз кабат,
Дәрдмәнднең шигырьләрен Вакыт
Җыйган юллап, җыйган мыскаллап.

Үлчәр өчен бизмән алган Вакыт,
Вакыт — Судья, Вакыт хәл итә,
Тоткан, үлчи, кыл уртада бизмән,
Ике якта — ике тәлинкә.

Бер ягында — шигырь, бер ягында
Алъяпкычы тулы, ал тулы
Дәрдмәнднең Урал тауларыннан —
Комнан арчып алган алтыны.

Китерә, сала, алтын баса кайчак,
Карап торган кебек ул моны,
Очып килеп шунда тәлинкәгә
Дәрдмәнднең куна былбылы.

Тигезләнә үлчәү, алтыннарга
Шигырьләре аның бәрабәр,
Уза еллар, төшми бәяләре,
Заман белән бергә баралар.

●

Юк гамем гүя бу җирдә,
Юк гүя бала-чагам,
Яшь вакыттагы шикелле
Барамын полосадан.

Күкри күк, саламын колак
Ерак алкышларга мин,
Барамын кебек алданып,
Төрле ал төсләргә мин.

## Арышның саргылт серкәсе

Арышның саргылт серкәсе
Ябышкан да арышка,
Селкенә иртәнге җилдә
Күнеп көткән язмышка.

Мин дә бу җирнең вакытлы
Кунагы, иркәсе күк,
Торам әз генә эләгеп,
Арышның серкәсе күк.

## Артта җәй

*Шакир Нигъмәтҗановка*

Печәннәрне ерып йөреп,
Җиргә тараласың да,
Ятасың, ятасың җәйнең
Яшел тарамасында.

Кайный чәй, ташый болыннар,
Дүрт якта дүрт көтүче,
Уртада һаман да тормыш,
Гел дөнья — көтү эше.

Кайный чәй, кайный тормышым,
Кайный йөрәккәемнең
Хисләре, хисләре кайный
Каен җиләкләренең.

Артта җәй, артта хуш исле
Җиләкле тарамалар,
Уйларым тарамалар күк
Бу җиргә таралганнар.

●

Кайтуым сезнең якларга
Бераз кунак булыйм дип,
Әйтсәләр: Хәким малае
Үлде, вафат, кулыйн [1] дип,
Ышанма, белеш, мари дус,
Селтә бары кулыңны,
Миңа син, беләм, беркайчан
Теләмәссең кулыйнны.
Беркайчан сезнең урманны
Төнлә урлап кисмәдем,
Җырладым ике халыкның
Фәкать уртак хисләрен.
Урманнар белән сөйләшкән
Телеңне тыңлап куныйм,
Кардәшлек, дуслык хакына
Кичерер бәлки кулыйн.

## Кырның бер төшендә кояш

Кырның бер төшендә кояш,
Күләгә бер төшендә,
Уйнады шулай ике төс
Минем гомер эчендә.
Шул кырларында гомернең
Тынмый көрәште җаным,
Сайлады үзенә бу җирнең
Мәңге кояшлы ягын.

*1976—1977.*

[1] Кулыйн — марича, үлде.

Габдрахман Әпсәләмов

# АГЫЛА БОЛЫТ

РОМАН

**18**



Май бездә генә түгел, Германия белән Польшада да май инде — табигатьнең иң ямьле чагы. Бөтен җирдә сагынып көтелгән яңарыш, саф яшеллек, кырларда, болыннарда чәчәкләр, игеннәр шаулап үсә. Табигать бит кайдадыр туплар гөрселди дип үзенең барышын туктатып тормый, вакытында бөреләре ачыла, вакытында куе яшел яфраклары ялтырый, кояш көннән-көн юмартлана бара. Тик әсирләр генә моны күрми кебек. Аларның йөзләре һаман сүрән, ә сагышлары шул хәтле тирәнәйгән, күктә торналар күрсәләр дә, күзләреннән яшь атылып чыга.

Муса шагыйрь кеше — ул бигрәк тә табигать кочагына ыргыла иде. Әмма күңел чәбәләнүләрен ул шәфкатьсез рәвештә басарга тырыша. Дөрес, ул Берлинда гына ябылып ятмады. Аны әле Радомда, әле Познаньда, әле Крушинода, әле Дрезденда һәм башка җирләрдә урнашкан лагерьларда күрделәр. Аның ашыгып барган юлында һәр җирдә дуслары очрады. Әле татарлар, әле руслар, әле әрмәннәр, әле поляклар килеп чыкты.

Үзе элек яшәгән лагерьларга Муса еш рак бара, монда аның дуслары да күбрәк иде.

Демблин лагеренда әсирләрне зур бер баракка җыйдылар, «концерт була», диделәр. Моны ишеткәч, күпләр ачы итеп көлемсерәде генә. «Тапканнар күңел ачар чак!» диләр иде шикелле аларның сүрән күз карашлары. Билгеле, тел белән ачыктан-ачык әйтмиләр, әмма хисләрен бөтенләй яшерә дә алмыйлар. Ак эмигрантларның нәрсә сайраулары аларны аз гына да кызыксындырмый, ә алардан башка бу җәһәннәм базында кемнең җырларга күңеле күтәрелсен. Шуңа күрә сәхнәгә урта буйлы, кара костюмлы, чәчен кыекка тараган бер кеше чыккач, рәтләп кул да чапмадылар. Концертны алып баручы, — әсирләр аны шунда ук танып алды, — ул кухняда эшләүче әсир Гайнан Кормаш иде, «Гумеров шигырьләр укый дигәч» тә, «залда» җанлану сизелмәде, гүя аларның җаннарын салкын боз зынҗырлаган иде. Беренче шигырьләрдән соң да күңелдәге кара боз эремәде.

---

Ахыры. Башы журналыбызның беренче санында.

Муса лагерьдан киткәннән бирле әсирләр составы бөтенләй диярлек үзгәргән. Яңа әсирләр Мусаны күреп белми, ә Гумеров дигән фамилия аларга гомумән бер нәрсә әйтми иде. Шигырьләре болай ярый кебек, азатлыкны, ирекне җырлый, Иделне, Уралны сагына, туган илгә турылыклы булырга, дошманга буйсынмаска чакыра. Тик нинди дошманга буйсынмаска, кемнәр иленә кайтырга чакыра. Әнә бит фашистлар да үзләренең батальоннарын «Идел-Урал» диләр, газеталарын да шулай...

Туган як моңнары, халык җырлары яңгырый башлагач кына әсирләр әкренләп җанланып китте, йөзләре яктыра төште, сүнгән күзләрендә очкын күренде. Алар ак эмигрант артистларны көткән иде, ә сәхнәгә һаман үз иптәшләре чыга торды. Зиннәт Хәсәнов Сарман җырлары белән үзәкләрне өзде, Фәрит Солтанов халыкчан итеп мандолина чиертте. Аннары пәрдә артыннан озын буйлы, киң җилкәле әсир чыкты. Кемнәрдер аны да танып алдылар. Бу — Дим Алишев иде. Аны «Казан филармониясенең артисты» диделәр, ләкин Димнең Казанда булганы да юк иде.

— Кайту маршы!

Дим, «зал»ның тынычланганын береаз көтеп, чын артистларча бик ягымлы тавыш белән сузып җибәрде:

Без — җиңелмәс данлы ил батыры,
Һич какшамас безнең изге антыбыз.
Зур давыллар һәм даулар аркылы,
Таң аттырып бер көн илгә кайтырбыз.

Алга, алга, якты таңга йөрәк ашкына,
Безне анда көчле дауга Ватан чакыра.
Әй, егетләр, әйдә, алга атлагыз,
Дошманнардан туган илне саклагыз.

Муса, сәхнә артыннан «зал»га карап, бу җырны аеруча дулкынланып тыңлады. Бу аның сүзләре иде. Күр, фикерләре әсирләргә барып җитә, әнә ничек алкышлыйлар!

Дим инде яңа җыр башлады. Дәртле, тыелгысыз көй яңгырады. Муса чак кына көлемсерәде.

Без кайтырбыз туган илгә,
Таулар-сулар аша,
Я җиңәрбез шушы елда,
Я үләрбез шушы юлда,
Я ясарбыз тамаша!

Шуннан соң бер «артист» бик моңлы итеп скрипка сыздырды, гүя барысын үзе белән әллә кайларга — ямьле сахраларга алып китте.

«Танылган артист» Шәриф Әмировка сүз биргәч, ул бер дә көчәнмичә, нәкъ айлы төндә авыл урамындагыча, борынгы озын көйгә калын тавыш белән җырлый башлады:

Ай-һай да гына дими көйләр килми,
Кайгылар ук күрми ир булмый.
Нинди генә итеп сөйләсәң дә,
Чит-ят илләр туган ил булмый.

Шәрифнең икенче җыры да шул ук рухта булып, тик көе генә башка иде.

Сахраларга чыксам ялгыз башым,
Чулпан йолдыз минем юлдашым.
Чулпан йолдыз булса, һай, юлдашым,
Мең дошманга торыр бу башым.

Әмиров күбесенчә халык җырларын башкарды. Туган ил, үзенең сөекле уллары белән җыр ярдәмендә ихлас күңелдән сөйләште кебек.

Ул аларны, әсирлеккә төшкән өчен, каһәрләмәгән, каргамаган, читкә какмаган, аларга әүвәлгечә ышана, дошманны үз өнендә тукмагыз, шуннан соң гына туган илгә якты йөз белән кайтырсыз дия кебек.

Җырның шундый хасияте барлыгын, җыр кайчакта тыңлаучыларга бик күп нәрсә әйтүен, аларның йөрәк түрендә яткан яшерен уйларын дәррәү кузгатуын гитлерчылар әллә белми, әллә «бу азиатлар җырында андый бөек нәрсәләр булмаска тиеш» дип исәплиләр инде, югыйсә, болай җырларга рөхсәт итмәсләр иде. Әйе, туган җыр үзенең сөекле улларына турылыклы хезмәт итә, аның чын мәгънәсен үз балалары гына аңлый иде.

Сәхнә артына баскан Мусаның шатлыгы минут саен арта барды. Ул шундый җырлар иҗат иткәне өчен газиз халкына, аның искитмәле бай теленә, җәүһәрдәй саф моңнарына күңеленнән мең рәхмәт укыды. Бу минутта аның белән янәшә Ясәви бабай басып торса, үз халкының бинниһая кодрәтенә таянып, дөрес эшлисең, улым, халык үз балалары белән ничек сөйләшергә кирәклеген белә ул. Аның һәр сүзе улларының күңелендә фәкать үзенчә генә яңгырый бит. Читләргә ул мәгънәсез булып тоелса, көзге җил тавышы гына булып ишетелсә, үзенекеләргә кадерле бернинди алтыннарга сатып алгысыз кыйммәт, дияр иде.

Муса үзен баштa салкын каршы алуларына һич үпкәләмәде, хәтта сызгырып сәхнәдән кусалар да рәнҗемәс иде. Чөнки ул үз фикерләрен ачыктан-ачык әйтә алмый, ә ымын тиз генә төшенеп җиткермәделәр, дөресрәге, мондый ымны аңардан көтмәгәннәр иде.

Шуның белән бергә Муса репертуар сайлауга җитди игътибар кирәклегенә инанды. Монда өстән-өстән генә эш итәргә ярамый. Бердән, әсирлектә легионерларның күңелләре йомыклана төшкән, күп нәрсәгә ышанмыйлар да бугай, ә гитлерчылар көн саен аларның акылларын чуалта торган нинди генә мәгънәсез сүзләр лыгырдамыйлар. Аннары немец цензурасы иртәме-соңмы үзенең беренче ялгышын аңлар. Аның шымчылары, сәрхушләре бу «залда» да, мөгаен, утыра торганнардыр. Алар хуҗаларына барысын җиткерерләрдер.

Мусаның Демблинга килеп чыгуының төп сәбәбе, билгеле, шигырь уку түгел иде. Моннан соң ул үз шигырьләрен гомумән укымастыр бәлки, чөнки монда чын шигырьләргә урын юк, кинаяләләрен дә рөхсәт итмәсләр, ә буш шигырьләр укуда ни мәгънә? Ул җыр-музыка капелласына артистлар сайлап алырга килде. Бу эшкә беренче килүләрендә үк тотынган иде. Шунысын әйтергә кирәк, легионда бер генә чын артист та юк иде. Гомумән әсирләрне «артистлыкка» өндәү җиңел булмады, күпләр бу турыда сөйләшә башлау белән үк сүгенеп, кул гына селтәделәр, ә чын максатны аңлатырга иртә иде. Аннары биредә «артистларны» талантына карап алмадылар, ә бөтенләй башканы күздә тотып сайладылар.

Бүгенге концерт шул сайлап алынган «артистларга» үзенә күрә бер смотр булды. Иң элек концертны алып баручы — аның художество житәкчесе Гайнан Кормаш һәр яктан уңай тәэсир калдырды: кайчандыр, әле армиягә кадәр, илдә үзешчәннәр белән эшләве, анда алган тәҗрибәсе биредә дә үзен нык сиздерә. Сәхнәдә ул үзен иркен тота, һич каушамый, еш кына декламатор булып та чыгышлар ясый. Бүген ул аеруча бер осталык белән Җәлилнең «Урман», «Кошчык», «Мәхәббәт һәм томау» һәм тагын башка көлкеле шигырьләрен укыды. Тыңлаучыларның йөзләрендә әле сагыш, әле тәвәккәллек, әле елмаю күренде. Шаркылдап көлүчеләр дә булды. Лагерь шартларында бу әйтеп бетергесез уңай күренеш иде. Димәк, шигырьләр әсирләрдә кешелек тойгыларын уята. Ә кеше үзен кеше итеп сизсә, ул инде икенче адымын атларга да әзер. Ихтимал, монда Гайнанның «артистлыгыннан» тыш Җәлилнең үзенең биредә булуы, аның нинди хисләр белән януын белү дә декламаторга ярдәм иткәндер. Шигырь уку гади әйбер генә уку түгел бит.

Мусаның һәм иптәшләренең ышанычын һәрьяклап казанган, иптәшлеге, турылыклыгы хәтәр эшләрдә сыналган шул Гайнан Кормаш «Җыр-музыка капелласына» язылуга иң нык каршы торучыларның берсе булды.

— Чыпчык башы хәтле талантым белән дә черчетларга хезмәт итмәскәме тагы! — диде ачудан буылып.

— Черчетларгамы, үзебезнекеләргәме! — диде Муса тыныч кына. Ләкин барлык төшендерү чаралары белән дә Гайнанны җиңә алмагач, Муса актыккысына ябышты — аңа ничек кенә булса да Гайнанны «капеллага» тарту кирәк иде, чөнки художество җитәкчесе итеп аңардан да кулай кешене күрмәде.

— Бәлки, Гайнан болай уйлый торгандыр, — диде Муса кыза төшеп, — мин кухняда, ачка үлмим әле, сугыш беткәнче шул җылы урында посып ятармын, ә башкалар туган ил өчен башларын салалар икән, салсыннар, анда минем ни эшем бар!

Бу бик каты, шул ук вакытта зур ышаныч белән әйтелгән сүзләр иде. Гайнанның ябык йөзенә кан йөгерде.

— Муса абый, — диде ул, тынын чак кына алып, — сез мине шул хәтле түбән җан дип уйлыйсызмы? Ил язмышы турында сүз барганда мин үземнең мескен гомерем турында гына кайгыртаммы?

— Нишлисең, шундый рәхимсез нәтиҗә ясарга да туры килә, Гайнан, — диде Муса. — Без гадәттән тыш шартларга куелган, безнең күп сөйләп торырга мөмкинлегебез юк: яки, яки!

Шуннан соң гына Гайнан капеллага язылырга, аның җитәкчесе булырга ризалык бирде...

Әле үткән килүләрендә үк Муса Гайнанга «артистларны» сайлауда таләпчән булырга задание биреп калдырган иде. Бу эшне Гайнан бик тырышып үтәгән, ул сайлаган кешеләрнең Муса һичбересен кире какмады. Фәрит Солтановны госпитальдән барып алдылар, «шәп артист» Рушат Хисаметдиновны башка лагерьга күчергәннәр икән. Едлинода очрашабызмы дип калдылар.

— Рәхмәт, егетләр, — диде Муса, концерт беткәч, — шатландырдыгыз. Иртәгә Едлинога чыгабыз. Төп тору урыныгыз анда булыр. Сезне, ягъни барлык «артистларны», дүртенче батальонның культвзводына билгеләячәкләр. Аның бер яхшы ягы шунда — сез строевой занятиеләргә йөрмәссез, каравыл нарядларында тормассыз. Художество җитәкчегез итеп Гайнан Кормаш билгеләнә. Ул — командир, аның сүзе—закон.

Таралышкан чакта Муса, Гайнанны читкә дәшеп:

— Мин хәзер госпитальгә керәм, аннары тагын очрашырбыз, — диде.

Шул ук бүлмә, беренче очрашулардан соң монда бернәрсә диярлек үзгәрмәгән, тик ярдәмче генә юкка чыккан, врач бер үзе. Ул тагы ябыга төшкән. Мусаны күрүгә бик шатланды, хәл-әхвәл сорашты. Муса аңа барысын сөйләп бирде.

— Яхшы булган. Дәвам итегез. Иптәшләрнең сүзе шул. Бирелә без шулай әкрен генә кыймылдыйбыз, — диде врач.

Икенче көнне инде Мусалар Едлинода иде. Демблинда сәләмәләрдән генә йөргән әсирләрне легион формасында күргәч, Фәритнең йөрәге өзелеп төшкәндәй булды. Башка иптәшләренең йөзләрендә әллә ни үзгәреш күренмәгәч, мөгаен, госпитальдә тәмам җебегәнмен, дип уйлады ул.

«Артистларга» да шундый ук форма бирделәр. Күңел һич тартмаса да, кулыңны өзеп ташлый алмыйсың, беләктә шул нәләтләнгән «Идел-Урал» эмблемасы. Шунысы гаҗәп, аерым-аерым алсаң, Иделе дә, Уралы да җанга газиз, әти-әниең кебек якын, алар татар-башкортларның күңелләрендә сүз белән әйтеп бирә алмаслык татлы сагыну хисе уята,

ә менә шул ук сүзләр яшел нашивка эчендә нәкъ камышлар арасыннан шуышып баручы зәһәр еланга охшый — күр дә тор чагып егар.

«Артистларны», Муса әйткәнчә, IV батальонның эшче ротасына — культвзводка билгеләделәр, строевой подготовкадан, каравыл хезмәтеннән азат иттеләр, аның каравы, репетицияләр көн саен, атнага бер тапкыр — легионерларга концерт бирергә, ягъни аларның боек күңелләрен күтәрергә приказ алдылар. Моны рота командиры — немец офицеры строй алдында әйтте. Аннары өстәде: «Ышанам, — диде, — намус белән хезмәт итәрсез».

Берлинга кайтып китәр алдыннан Муса «артистларны» җыеп, үзенең соңгы күрсәтмәләрен бирде: репертуарга күбрәк халык җырларын кертегез, Тукай, Такташ шигырьләрен укыгыз. Алар һәр легионерның җанына үтемле. Шулай икәненә ныграк ышанасыгыз килсә, аларны укыганда легионерларның күзләренә карагыз, барысын үзегез күрерсез, диде.

Гайнан Кормаш белән Муса аерым, күзгә-күз карашып сөйләште, аеруча уяу булырга кушты, аннары Фәрит Солтанов белән икесен якын арада Берлинга «кунакка» чакырды.

Едлинодан Муса бик канәгать булып кайтты. Димәк, музыкаль взвод бар инде. Ләкин бу — зур эшнең башы гына. Асылда бит Мусаны музыкаль капелла үзе кызыксындырмый, ул ярдәмче чара гына, аның исеме артына яшеренеп меңләгән әсирләрне, беренче батальондагыча, аңлы көрәшкә күтәрерлек, нык дисциплинага корылган яшерен оешма төзү. Билгеле, капеллага кергән барлык «артистлар да» ул яшерен оешмага катнаша алмый, чөнки берәү бик яхшы «артист» булып та башка ягы туры килмәскә мөмкин.

Берлинга кайткач та Муса бу турыда кат-кат уйланды. Иң ышанычлы иптәшләрдән ант алырга кирәк. Моңа гади бер нәрсәгә караган шикелле карарга ярамый, кешеләрнең моңа йөрәге җитәрме, калтырамасларны? Яшерен оешмага керү — ул инде үз гомереңне кызганмау дигән сүз.

Билгеле, «кунаклар» чакырганда иң элек кемнәрне өндәү турында да Муса алдан уйланды. Гайнан Кормаштан башлау аңа беренче чиратта кирәк иде. Икенчесен кемне алырга? Яңа оешкан капелланы аз вакытка булса да җитәкчесез калдырырга ярамый. Гайнан булмаганда дилбегәне нык тотарлык кешеләр капеллада калырга тиеш. Күп уйлангач, ул Гайнан белән бергә Фәрит Солтановны чакырды. Фәриткә репетицияләр әллә ни кирәкми, ул кылларны болай да ярыйсы оста чиертә.

Бер атнадан Муса Гайнан белән Фәритне Берлинда каршы алды. Вокзал тирәләрендәге бер тыкрыкта, ярым подвалда урнашкан бер ашханәдә тамак туйдырдылар — Муса алдан талоннар алып куйган иде. Шунда ук лагерь хәлләрен сорашып өлгерде. «Артистлар» концерт биргәннәр икән инде. Болай уңышлы гына чыккан шикелле. Иптәшләр тырыша, үзләренең «чын» артист икәнен күрсәтергә омтылалар, «филармония солисты» Дим Алишев бигрәк ашкына икән. «Миңа бу егетлегем өчен атказанган дигән мактаулы исем бирсәләр ярамый микәнни», — ди. Гайнан аңа шаяртып: «Яңак төбеңә берне бирермен», — дигән. Дим анысына да канәгать. Бер көнне ул Гайнанны аптыратып бетергән:

— Гайнан, син безнең андый-мондый гына җитәкче имәс, ә худжитәкче, — дигән. — Синең кодрәтеңнән барысы килә. Өйрәт мине уйнамый уйный торган артист булырга.

Гайнан күз кырыйлары белән аңа бик озак карап торган. Юк, Дим Алишев, мәзәк ятратучы Габдулла Баттал кебек, юри шаярмый, йөзе

житди, хәтта бераз аптыраулы, мөгаен, аның чын артист буласы бик киләдер.

Ахырда Гайнан шаркылдап көлеп җибәргән.

— Юләр, уйнамый уйный торган артист буламыни?

— Ник булмасын, — дигән Дим Алишев, — менә син бер дә уйнамыйсың кебек, ә үзең сәхнәдә кем генә булмыйсың! Әле томаулы хәчтерүш гашыйк, әле үләргә җыенган, әмма матур кыз күргәч, җан бирергә оныткан, берьюлы терелеп, яшәреп киткән әкәмәт карт... Мин уйнаган булам, үрле-кырлы сикерәм, кыланам, ләкин миннән берни чыкмый, миңа карап беркем көлми, юләр, идәнне җимерәсең ич дип кенә кычкыралар, ә син кыланмыйсың да — барысының авызы ерык.

— Юләр, мин үзешчән артист мәктәбеннән ләбаса,— дигән Гайнан,— акылың булса, күп фәлсәфә сатма, кыланма, чәчең коелыр, лучше ике күзеңне дүрт итеп иптәшләреңә бак: яхшы якларын үзеңә күчер, начар якларын кабатлама. Кеше өйрәткәннән генә филармония артисты булып булмый. Яңак төбеңә бирсәләр дә рәт чыкмас.

— Юкәдә икән чикләвек,— дигән Дим күңелсез генә.

— Юкәдә шул! — дип кабатлаган Гайнан. — Әллә яңа гына беләңме?

Боларны тыңлагач, Муса рәхәтләнеп көлде. Димәк, «артистлар» чынлап тырыша. Бу — яхшы, бик яхшы.

Тамакларын туйдыргач, Муса аларны «Татар комитетына» алып барды, ә көннең бер вакытында Тиргартында — зоопаркта булдылар. Зоопарк бик зур, монда әйтерсең кара урман. Тамаша кылып йөрүче кешеләрдән бер читтәрәк, читлек янында туктадылар.

— Шул кара маймылларга караган булыгыз, ә үзегез мине игътибар белән тыңлагыз, — диде Муса иптәшләренә шыпырт кына. — Ватанга турылыклы булырга ант итәргә хәзерме? Гайнан син? Фәрит? Алайса, минем арттан кабатлый барыгыз.

Муса антларын пышылдый башлады:

— Яшерен оешмага кергән чакта, мин, явыз дошманга каршы соңгы сулышыма кадәр көрәшергә, группаның өлкәне кушканнарны берсүзсез үтәргә, туган Ватаныбызга һәрьяклап ярдәм итәргә тантаналы сүз бирәм. Әгәр кирәк була калса, туган Илем өчен гомеремне дә кызганмам. Дошман кулына төшсәм, бернинди газаплаулар-җәзалауларга карамастан, яшерен оешма һәм дуслар турында бер сүз әйтмәскә ант итәм. Әгәр бу тантаналы антымны бозсам, мине Ватан дошманы, фашистлар лакее дип санагыз...

Бер минут эчендә әйтелгән гади генә сүзләр кебек, ә эчләренә кешенең бөтен героик гомерен ала.

Зоопаркта йөренгән чит кешеләрдә бернинди шик уятмас өчен, ант биргәннән соң, Муса иптәшләрен тәбрикләп кулларын кысмады, бүгеннән яшерен оешмага рәсми керүләре белән котламады, читлек яныннан берни булмаган кебек киттеләр. Алар читлек янына килгәнче дә дуслар иде, киткәндә исә гади дуслыктан югары күтәрелгәннәр — алар ант иткән көрәшче дуслар иде. Тик бик үткен күзәтүче генә бу минутта якында пәйда булса, Гайнан белән Фәрит бу мизгелдән соң бөтән кешеләр булып житлеккәнлеген, күңелләре ныгуын абайлар иде. Әмма андый гайре табигый күзәтчеләр адым саен очрамый шул.

— Бүтән иптәшләрдән дә вакыты белән ант алырбыз, — дип пышылдады Муса. — Без ирекле лэр төркеме түгел, аңлы көрәшчеләр. Безнең өчен шул көрәштән дә изгерәк эш юк.

Ниһаять, көннең бер вакытында Муса белән Гайнан икәү генә калдылар. Фәрит Солтанов якташы Гариф Шабаевка иярде. Алар икесе дә Үзбәкстаннан, сөйләшер сүзләре күп.

— Безнең дә, Гайнан, күзгә-күз карап гәпләшәсебез бар, — диде Муса.— Музыкаль капелла инде яши, үзәге — яшерен оешма — көч туп-

лый. Бу яхшы, бик яхшы. Ләкин бу безнең тулы максат түгел әле... Син айсбергларның ни икәнен беләсеңме?

Гайнан аңа гаҗәпләнеп карады.

— Әллә тагы. Ишеткәнем бар, күргәнем булмады. Зур диңгезләрдә йөзә торган пар тауларымы, боз тауларымы шунда.

— Мин дә аларны кинода гына күрдем. Ә китапларда алар турында күп укыдым. Айсбергларның су өстендә йөзә торган өлеше артык зур булмый икән, ә су астындагы күзгә күренми торган өлеше, киресенчә, бик зур була... Менә без дә шулай, туган. Су өстендә йөзә торган өлешебез — музыкаль капелла — бәләкәй, ә су астындагысы — сугышчан подразделениеләр, сугышчан бишлекләр — Алып батыр...

— Фу, бу шагыйрьләрне, берьюлы төшенмисең дә.

— Ашыкма, Гайнан, хәзер аңлатам. Моны мин куктән алып әйтмим, бу шагыйрьләр хыялы гына түгел. Совет-герман фронтына җибәрелгән беренче «Идел-Урал» батальонының язмышы сиңа билгеле. Алар подразделениеләрдә сугышчан бишлекләр оештырган булганнар, шул нәрсә взводларны, роталарны цементтай беректергән. Кыскасы, практика моның безнең шартларда дөрес икәнен раслаган. Безгә менә шул тәҗрибәне файдаланырга кирәк. Ләкин сугышчан бишлекләрне оештырганда үтә саклык таләп ителә. Алар бер-берсен вакыты-сәгате җиткәнче белмәсеннәр. Әгәр провал-фәлән — моны да күздә тотарга тиешбез — шул бишлек кенә сафтан чыга. Төшенәсеңме?

— Төшенәм.

— Хәзер безнең төп эшебез — шул бишлекләрне оештыру. Бер үк вакытта взвод, рота, батальон командиры да булырдай кешеләрне исәпкә алу. Саклык өчен аларны сугышчан бишлекләргә кертмәү яхшы булыр шикелле. Бу соңрак эшләнер... Синең Зиннәт Хәсәнов ничек?

— Боевой командир.

— Син аны сакла. Кирәк чагы булыр.

Алар сугышчан бишлекләрне оештыру, подразделениеләргә кемнәрне командирлар итеп сайлау турында байтак сөйләштеләр. Муса бер нәрсәгә бик шат иде: Гайнан барысын бик тиз төшенде, аңа бәйнә-бәйнә аңлатырга кирәкми иде. Аннары ул бик күп әсирләрне белә икән, аларның кылларын тартып-тартып карарга өлгергән.

— Әлбәттә, тормышта әллә нинди көтелмәгән хәлләр килеп чыгуы мөмкин,— дип дәвам итте Муса.— Киңәшергә кирәк була. Мин һәр вакыт синең янда була алмыйм. Бу эшкә, минемчә, Зиннәтне тарт. Аңа кайбер нәрсәләрне ачарга мөмкин. Аннары Демблиндагы врачны күрергә тырыш. Ул сиңа ышанычлы кешеләрне әйтер, кайбер нәрсәләрдә ярдәм дә итәр. Синең турыңда ул белә. Сөйләшер алдыннан миннән сәлам тапшырырсың.

— Булды, Муса абый.

— Мондагы иптәшләр мине Мөршид дип йөртә. Син дә, кирәк булганда, шул исемне куллан.

— Төшендем.

— Алайса, шуның белән түгәрәклик. Мин Едлинога ешрак барырга тырышырмын. Онытма, синең көндәлек доган — айсберг. Тик моны хәзергә икәү генә белик.

Үзенең эчке дулкынлануын Муса иптәшләренә күрсәтмәскә тырышты. Берлин урамнарында да, «Татар комитетында» да аларга бик игътибарлы булды. Ниһаять, иптәшләре кайтып киткәч тә аның рухи халәтендә әллә ни үзгәреш күренмәде шикелле.

Шулай берничә көн үтте. Инде тәмам тынычланам дигәндә Берлин зоопаркында күреп калган кара маймыллар Мусаның төшенә кереп йөдәтә башлады. Башта алар читлекләре янына килгән Мусаларга кур-

кып, шыпырт кына читтән карап тордылар, аннары, нәрсәдер сизенеп, пошынырга, чинарга, үкерешергә, үрле-кырлы сикереп мәтәлчек атынырга керештеләр. Шуннан соңгы төннәрдә читлекләреннән сикереп чыгып, дүрт аякланып, парк буйлап җан-фәрман чабыша башладылар, гүя патшалыкларына рөхсәтсез-нисез килеп кергән Муса белән аның иптәшләренә бармак янап: «Яшерен серегезне беләбез, беләбез!» — дип акырыштылар. Аннары бөтен көтүләре белән каядыр чабып киттеләр, агач башларына үрмәләп менделәр, тагын бирегә килеп җиттеләр, җыйнаулашып, Мусаларны үзләрен читлеккә ябарга маташа башладылар...

Мондый төннәрдә Муса кара тиргә батып уяна иде.

## 19

Әллә совет авиациясе, әллә союзникларныкы Берлинны бер өзлексез бомбага тота. Кап-кара күктә самолетлар үкерә, аэростатлар чайкала, зенит снарядлары шартлап ярыла, прожектор кылычлары айкала. Совет авиациясе тарафыннан әле 1941 елның августында ук караңгылыкка чумарга мәҗбүр ителә башлаган фашист башкаласы хәзер бу дәһшәтне бик еш татый. Таш шәһәр кинәт нигезенәчә дереләдәп, урыныннан купкандай була, аннары бар авырлыгы белән җәһәннәмгә убылып төшә кебек. Бомбоубежищеда болай да тоныклана янган электр утлары, сүнәм-сүнәм дигәндәй, селкенеп китә. Куркынган, нәрсәдер пышылдаган немецларның җансыз, кансыз чырайлары күренә. Ул да булмый, баягыдан да дәһшәтлерәк итеп, бөтенләй якында гына тагын бомба шартлый, шәһәр ухылдап ала.

— И мәрхәмәтле хода! — дип илерә язып кычкыра карт немка. Башкалар эндәшми, авыз эчләреннән дога укынып, түшәмгә карыйлар.

Бер гомер вакыт үтте кебек, отбой булып убежищедан кайтканнан соң сәгатенә карагач, Шәфи Алмас үз күзләренә үзе ышанмый торды: нибары ике сәгать узган. Ул инде үзенең алты катлы йортын тыштан да, эчтән дә карап чыгарга өлгергән иде: исән-имин, ватылган җире күренми, бомбалар читтәрәк төшкән, ахрысы. Аннары Шәфи Алмас, яңадан эшли башлаган редакциягә дә туктамыйча, өскә, кабинетына узды, шкафтан шнапс алып, бер-бер артлы ике рюмка эчеп җибәрде. Немец аракысы аның салкыная башлаган кан тамырларын аз җылытты. Ул башын ике кулы белән кысып, киң өстәленә таянган хәлдә озак утырды. Хәзер Шәфи Алмас корбаны өстенә сикерергә җыенучы әлсерәгән карт ерткычка охшый иде — теләге зур, көче чамалы. Йөзе кыйшайган, күзләрен кан баскан, куллары калтырый, бөтен тәнендә ниндидер әшәке көчсезлек. Койрыгын ике бот арасына кысып чапкан эт кебек каядыр күз күрмәгән якка шыңшый-шыңшый йөгерер иде, аннары я үкереп уларга, я, тәвә кошы кебек, башын канат астына яшереп, аякларе белән тиберченергә тотынырер иде. Күрәсең, убежищедагы куркулары әле узмаган аның.

Тагын берничә рюмка аракы эчкәч кенә ул яңадан «Идел-Урал» газетасы турында уйлый башлады. Шәфи Алмас үз кул астындагы кешеләр алдында чын фикерләрен яшереп тормады, моны кирәк дип тә санамады. Редакция белән бөтен «Идел-Урал» комитетын, аның төрле бүлекләре белән бергә, ул инде яулап алынган җирләр итеп карады, ә яулап алынган җирләрдә җиңүчеләр теләсә нәрсә эшләргә хаклы. Бу, билгеле, аның үз фәлсәфәсе түгел, хуҗаларныкы, ләкин Шәфи Алмасның шашкан хыялларына да туры килә. Дөрес, канатны киң җәяргә гитлерчылар аңа ирек бирмәсләр, аның белән әллә ни санашып та тормаслар, чөнки Шәфи Алмас алар каршында бары тик сатлык эмигрант

кына. Ул моны бик яхшы аңлый. Шуңа күрә эченнән еш кына сыкрана. Югары үреләсе бик килә, буе кәрлә.

Рәхим Саттарны редакциядә Шәфи Алмас башта ук яратып бетермәде. Ул немец унтер-офицеры формасын йөртсә дә, Шәфи Алмас аңа ышанмады. Рәхимнең әрсез кара күзләре, кәкре борыны, әллә нәрсәләр яшергән сыман күренгән буйсынмас көлүе, ирекле холкы — ул гел үзенчә эшләргә тырыша — баш мөхәррирнең җан ачуларын чыгара иде. Ул Рәхимнең газетадагы мәкаләләрен аеруча шикләнеп укыды, юл араларында бер-бер нәрсә юкмы дигәндәй, кайта-кайта карады, күңеленә чак кына ошамаган урыннарый рәхимсез рәвештә сызды, я бөтенләй ерткалап кәрзингә атты. Ләкин шул ук мәкаләләр, берникадәр үзгәртелеп, яңадан полосаларда күренәләр иде. Кайчагында Шәфи Алмас аларның астыртын зәһәрен сизми кала, я аракыдан башы чатнаган чагы була, я алдым-бирдемнәр белән әвәрә килгән, чуалган көннәре була, — җибәрә, ә газета басылгач күрсә дә, эчтән көеп, тыштан дау күтәрми, чөнки хуҗаларыннан эләгүдән курка — газета басылганчы ни карадың дип муеныңны борырга күп алмаслар. Мондый минутларда Шәфи абзаңның бөтен тәне эсселе-суыклы булып китә, ул мөхәррирлек эшенә ризалык бирүенә үз-үзен тирги. Төрле Ишбулмаслардан, Сәрхушләрдән бик курка. Аларның да башны ашавы мөмкин. Бераздан тагын уйлап куя: ул бит немецларны да шактый шәп алдый: газета кирәк-яракларына дип билгеләнгән акчаның күп өлеше Шәфинең үз кесәсенә кереп кала. Шулай булгач...

Бер фикер Шәфи Алмасның башына торган саен ешрак килә: аңа калса, совет командованиесе Рәхим Саттарны немецларның гомуми эшенә күбрәк зыян китерү максаты белән герман тылына махсус җибәргән булса кирәк. Менә шуны гестапога тотып бирсәң иде! Ул чагында алар Шәфинең вак-төягенә күз йомарлар иде. Саттар гомумән үз фикерләре белән герман дәүләтенә зарарлы кеше, редакция эшенә һич мәгъкуль имәс, дип кайта-кайта уйлады редактор. Ул чегән токымыннан нәрсә көтәсең, үзе дә юньләп эшләми, башкаларны да котырта...

Мәсьүл редакторның бу фикер-зарлары бер вакыт ачыктан-ачык донос төсен алачак, әмма хәзергә әле кайбер нәрсәләр аның кулын тотып тора. Иң мөһиме — исбаты азрак. Шәфи Алмас тәҗрибә буенча яхшы белә: мондый чакта гестапо төгәл сорый, аларга ярылып яткан фактлар булсын, синең алай-болай уйлануларың, шикләнүләрең аларны кызыксындырмый, алар үзләре уйлый белә. Һәр совет кешесе — әсирме ул, түгелме — барыбер алар каршында потенциаль дошман. Бу — Адольф Гитлер тәгълимәте!

Монда тагын четерекле як шунда: Рәхим Саттарны редакциягә алырга тәкъдим иткән беренче кеше — Шәфи Алмас үзе булды. Дөрес, аңарчы немецлар аны тикшергән, ләкин кирәк чакта алар киресен дә әйтә беләләр ич. Бу вакытта «Идел-Урал»ның хәле аеруча мөшкел булуын, каләм тотып эшләрлек кешеләр житешмәвен кемгә сөйлисең? Үзен шагыйрь дип тәкъдим иткән, бик һаваланган Ишбулмаслар бушбугаз гына булып чыкты, тәтәйләргә йөрүне белә дә аракы чөмерә.

Шәхси җаваплылык Шәфи Алмасны һәр вакыт акылдан язарлык дәрәҗәдә тетрәтә иде. Болай чакта теләсә нинди явызлыктан, теләсә нинди мәкердән тартынып тормаган, курыкмаган, киресенчә, моны сәүдәгәрлек җорлыгы итеп санаган, иң четерекле хәлләрдән дә шома чыга белгән Шәфи Алмас асылда вак һәм куркак җан иде. Менә шул ваклыгын, шул куркаклыгын башкаларга күрсәтмәс өчен ул үч алырга ярата. Үзенә аз гына да зыян килмәвен сизгәндә ул бигрәк тә зәһәрләнә.

Теге вакытта ул Рәхим Саттарның бер мәкаләсен газетага керттермәгән иде. Менә шул мәкаләдәге фикерләр легионерлар арасында йөргән бер листовкада тагын да ачыграк төстә кабатлана икән, хәтта рус-татар дуслыгы турында Тукайдан китерелгән юллар да бар.

Моны Шәфи Алмаска шымчылары хәбәр итте. Бу бик җитди сигнал иде, абзаң хәтта урыныннан сикереп торды, кыйшайган йөзенә явыз тантана билгесе чыкты. «Әһә, элэктеңме, чегән!» диде кулларын тырпайтып. Аннары уйга калды: юньсезләр, листовканың үзен җибәрә белмәгәннәр. Болай синең коры сүзләреңә кем ышансын, үз бәяңне күтәрер өчен уйлап чыгаргансың диячәкләр әле тагын.

Шәфи Алмас шул ук көнне лагерьга үзенең махсус кешесен җибәрде, аннары Ишбулмасны да шунда озатты.

— Менә нәрсә, кәгазь сандугачы,— диде ул аңа турыдан-туры,— бүгенгә хәтле синең кулыңнан эш килгәне юк. Болай булгач, шигырьләр китабыңны чыгаруны да туктатырга туры килер. Сөйләмә! — дип кычкырды Шәфи Алмас бүртенеп, — синең буш вәгъдәләреңне күп ишеттек, ә үзең тәтәйләрне генә беләсең, дуңгыз кебек...

— Хөрмәтле Шәфи әфәнде, мин бөтен көчем белән тырышам бит...

— Тырышасың!.. Менә соңгы мәртәбә кисәтәм, аннары миңа үпкәләмә. Бүген үк Едлинога кит. Анда, легионерлар арасында, яшерен листовкалар йөри башлаган ди. Шуларның берсен таш астыннан табып булса да кулыңа төшереп кайт. Кисәтәм, нинди эш белән йөрүеңне берәү дә сизмәсен! Лыгырдасаң, муеныңны өзәрбез! Төшендеңме?

— Төшендем, Шәфи абзыкаем! Җанымны фида итеп үтәргә тырышырмын сезнең боерыкны.

— Бар!

Әмма Шәфи Алмасның махсус кешесе дә, хәсрәт шагыйрь дә буш кул белән кайттылар — листовка юкка чыккан. Шәфи Алмаска сүгенергә генә калды. Агарынган, дер-дер калтыраган Ишбулмасны кабинетыннан артына тибеп чыгарды. Эх, нинди козырьны кулдан ычкындырганнар, ахмаклар!

Бераз суына башлагач, шиккә төште: шаяртмадыларммы икән карт исәрне? Ул тешләрен шыгырдатты. Әгәр кулына эләксәләр, Коръән үбеп ант итә ала, менә шулай өзгәләр иде ул аларны! — ул кулларын да бутап алды.

Ярсуы басыла төшкәч, аеграк акыл белән болай уйлады: юк, монда шаярту булмаска тиеш, ник дисәң, картага артык зур нәрсәләр куела. Әсирләр булса да башлары бер генә бит.

Шәфи Алмас әзрәк тынычлана башлады. Тагын бер рюмканы әйләндереп каплады. Шунда «Идел-Урал»ның беренче батальонында булган үтә күңелсез хәлләр исенә төште. Алар совет-герман фронтына җибәрелгән батальонның шанлы җиңүләре турында шатлыклы хәбәрләр көтеп торганда шундый удар булды, Шәфи Алмасны гына түгел, бөтен Гитлер командованиесен шаккатырды — аяз көндә яшен сукты диярсең: бөтен бер батальон, барлык коралларын алып, совет партизаннары ягына чыга!

Ахыр килеп, сүз бер батальон турында гына барса, сугыш вакытында каян килеп кая китмәс иде, монда зуррак нәрсә: нацистларның мәкерле планы — СССР халыкларын үзара бәрелештерү планы челпәрәмә килә бит. Аннары начар үрнәк аеруча зарарлы ул, башка милли легионнарның да татарлардан өлге алуы бар. Татар легионының бәясе гомумән төште. Эх, татар барда хәтәр бар, дип юкка гына әйтмәгәннәр шул! Бу күптән онытылган әйтем кинәттән генә Шәфи Алмас күңеленә килеп, бөтен тәнен чемердәтеп алды. Дөрес, беренче батальонда булган хәлләрне Гитлер командованиесе йомарга тырышты, ләкин... без капчыкта ятмый бит.

Карт бүренең маңгае тирләп китте. Ул киң өстәлгә ныграк иелде, гүя аны сытарга, изәргә теләде. Иреннәре кыйшайды, күзләре тәмам кечерәеп, тар ярыклар сыман гына калды, аларда зәһәрле ут ялтырады.

Котыртучыларның эзенә төшәр өчен легион командиры белән берлектә Шәфи Алмас бар чараларны күрергә тырышты. Фетнәчеләрнең

барысы беренче батальон белән китеп бетмәгәндер бит. Эх, табасы иде шуларны, тотасы, эләктерәсе иде, аннары Шәфи Алмас тантана итә белер иде! Монда инде ул хуҗаларыннан арттырып җибәрергә дә тартынмас иде. Бу бер Шәфи Алмаска гына түгел, гомумән, барлык куркак, барлык сатлык җаннарга диярлек хас нәрсә. Аларны ниндидер әхлакый чикләрдә тотып тора торган бернәрсә дә юк бит. Алар бәйдән ычкынган, шашынган явызлыкның үзе.

Лагерьдан буш кул белән кайткан шәхси вәкиле, әллә чыннан, әллә үзенең булдыксызлыгын яшерер өчен, яңа әләкчеләр таптым, дип әйтте. Шәфи Алмас, аны тыңлагач, иреннәрен кыйшайтты. Бер-ике әләкче белән нәрсә эшләп була! Ул каһәр суккан большевиклар үлсә үләләр, әмма үзләре урынына яңа батырлар калдырып. Каян таба торганнардыр шундый каһарманнарны. Менә синең дә шундый шоңкар егетләрең булса иде! дип, Шәфи Алмас ихтыярсыздан дошманнарына сокланып куйды. Кем үстерә аларны, кем тәрбияли диген!

Шунда Шәфи Алмас яңадан Рәхим Саттар турында уйлый башлады. Фетнәчеләр башында шул егәт егете тормыймы икән? Вакыт-вакыт Шәфи Алмас: шул, нәкъ үзе! — дип әйтергә әзер тора, әмма аеграк уйлангач, карт доносчы бу фикереннән кире кайта: нигезсез! Рәхим Саттар ваграк эшләргә ярар, ә җитәкчелеккә батмас, үзен артык әрсез тота, акылы, хәйләсе җитешми. Большевиклар мондый кешене башлык итмәс, алар акыллырагын, хәйләкәррәген тапканнардыр. Алайса, кемне? Монысын инде Шәфи Алмас тәгаен белми, уйлап-уйлап та башына китерә алмый. Каян белергә икән? Моны абвер ялчылары гына белсә белер. Солтан Гарип? Ул баш мөхәррирне дә төпсез иләккә утыртырга күп алмас, ул үзе хуҗаларның табанын ялый бит. Аңа әле тырышырга да тырышырга кирәк. Юк, хәзергә Солтан Гариплар үз юлларында йөреп торсын, ә җае чыкса, Шәфи аңардан да файдаланыр, ләкин вакыт барда үзенә тырышырга кирәк... Әйе, ул фетнәче, мөгаен, кайда булса башка төштәдер, күрер күздән ераграк, ышанычлырак урынга оялагандыр. «Идел-Урал»да булса, Шәфи аны бер күрмәсә бер күрер иде. Мондый нәрсәләргә аның күзе, иншалла, үткен, борыны сизгер. Андый явызның редакциядә булмавына ул янә бер шатланып, мөселман алласына да, немец алласына да мең кәррә шөкерләр укыды. Аннары уйлап куйды: аллалар алар еракта, күктә, җирдәге хәлләрне барысын күрми калулары мөмкин бит. Һәм ул редакциядәге һәр сотрудник артыннан күзәтүне бермә-бер көчәйтергә булды. Моңарчы да андый күзәтү булды, шайтан дигән каһәр җитмеш җиде төскә керә ди бит, ул, теләсә, хәтта үз хатынынны үзенә сата ала.

Шәфи Алмас айнып киткәндәй булды, кара, көчсез минутлар узды, ул инде эшкә тотыныр алдыннан була торган күтәренке бер дәрт белән тагын бер рюмканы тотты, иреннәрен бөрештереп кысты, аракының бөтен сихәтен эченә сеңдергәндәй булды. Инде редакциягә төшәр өчен урыныннан кузгалды. Каһәр генә суксын! Ишек төбенә барып җитмәде, тагын, җан өзгеч тавыш белән, һава тревогасы сиренасы үкерергә тотынды. Шәфи Алмас, акны, караны күрмичә, түбәнгә — подвалга ыргылды.

Ул бункерның авыр ишеген япканда, өстә беренче бомбалар гөрселдәп ярыла башлады. Сүнәм-сүнәм дип җемелдәгән электр утлары яктырып киткән генә иде, кинәт яңа, әүвәлгеләреннән бермә-бер көчлерәк гөрселдәү ишетелде. Кинәт дөм караңгы булып китте, утлар сүнде. Ниндидер хатын-кыз, акылдан язып, нечкә тавыш белән илерергә тотынды.

Шәфи Алмас үзен-үзе белештермәде. Ул әллә бар, әллә инде җәһәннәмгә очты. Күлмәк якасын өзеп бугазын капшады. Ниндидер әби, барлык изгеләрне шаһитлыкка чакырып, нацистларга нәләт укый башлады. Аның тавышы ярты сүздә өзелде, яңа гөрселдәүләр ишетелде. Аларның бетәсе юк иде шикелле.

Муса бүлмәсендә ут караңгы, җитмәсә, тышта яңгыр коя. Һава тревогасы юк-югын да, аның бит һәр минут яңгыравы мөмкин. Шагыйрь аны шатланып та, борчылып та көтә.

Ут караңгы, әмма дала егетенең күзләре әле яхшы күрә, кара мәрҗәннәрдәй вак-вак хәрефләр юлларга бик тигез яталар, ул ашыга. Кайчак тынып кала, карашын каядыр караңгы почмакка теки, гүя ул әллә ничә мең чакрымнан туган илен күрә, дуслары белән көлеп, сөйләшеп йөри, кадерле Әминәсен, сөекле Чулпанын иркәли, аларга иң йомшак, иң гүзәл сүзләрен әйтә кебек: «Миннән сезгә хәбәр китерсәләр, минем турыда әллә нәрсәләр сөйләсәләр, Муса илен алмаштырган дисәләр, ышанмагыз. Сезгә һәм илемә мин беркайчан хыянәт итмәм. Илемә фәкать күбрәк файда китерер өчен, үзем теләп, шөпшә оясына кердем. Моннан исән-имин котылу ихтималым юктыр да бугай. Бар җырымны илгә багышладым...»

Муса тирән хыялларыннан аерылып башын күтәрде. Шигъри юллар, ерак йолдызлар кебек, бер җемелдәделәр дә сүнделәр. Алар әле кәгазьгә түгелер дәрәҗәдә өлгереп җитмәгән иде. Килер бер көн, алар күкрәктән ташып, ургылып чыгарлар, шагыйрьнең мөкатдәс васыяте булып буыннарга калырлар, аларга чикләр дә, киртәләр дә, төрмәләр дә булмас, туган илгә барып җитәрләр, аннары тагын мәңгелек сәяхәткә чыгып китәрләр. Алар бөтен дөньяга яңгырар, шагыйрь сүзе шундый канатлы ул, йөрүдән мәңге-мәңге туктамас, кешелек аларны һичкайчан онытмас, иң пакь, иң нечкә хисләр белән төрле телләрдә кабатлар...

Мусаның шигърият дәрьясына чумган мондый тылсымлы-борчулы төннәре Берлин шәһәрендә бер генә булмады, бакчаларда яки су буенда сирәк-мирәк йөргәндә дә күңелендә шигърият нурланды, ә кайчакта төн йокысыннан кинәт уянып, кәгазь-карандаш алды. Шагыйрь илһамы, бигрәк тә көрәшче-шагыйрь илһамы, назлы иркә түгел, махсус вакыт сорамый, ул гүя күк күгәрчен — бер дә көтмәгәндә тәрәзә төбенә килеп куна, сыйларга җимең бармы дип сорамый, гөрләргә тотына. Ишетәсеңме, юкмы — бусы инде синең эш. Иренмәсәң, вакытында кәгазьгә төшерсәң, син бәхетле, чөнки икенче тапкыр, иңәлеп чакырсаң да, тәрәзәң төбенә килеп кунмый ул.

Кайчагында тылсымлы илһам да килми, кул каләмгә үрелми. Андый чакта Мусаны кешенең мәңгелек юлдашы — истәлекләр били. Ул дөньяда күп яшәмәсә дә, истәлекләре гаҗәп бай иде аның. Тик уйлары ни өчендер һаман-һаман яшьлек елларына кайтты. Күрәсең, кеше гомерендә бу чор — дөньяны беренче ачу чоры — аеруча матур, хәтердә аеруча нык уелып кала. Ул туган авылы Мостафаны күңеленнән бер генә буйламады. Комсомолда эшләгән Орск өяз комитеты, Мәскәүдә ВЛКСМ Үзәк Комитетының татар-башкорт секциясе, Мәскәү дәүләт университеты, «Кечкенә иптәшләр», «Октябрь баласы» журналлары редакцияләре, каләмдәш дуслары исеннән чыкмады. Болар барысы да аның иҗат биографиясе белән үрелеп барды. Ул аеруча бер дәрт белән МОПР оешмасында Александр Фадеев белән бергә эшләде, халыкара революцион хәрәкәтне өйрәнде, аның беренче шигырьләр җыентыгы — «Барабыз» 1925 елда МОПР көтепханәсендә басылып чыкты. Анда «Кисәкләр» поэмасы бар. Поэма 1923 елда Германиядә булган тарихи-революцион вакыйгаларны чагылдыра. Рур эшчесе белән рус эшчесенең дуслыгын, көрәш хисләрен җырлый... Билгеле, әгәр хәзер ул поэмага кабат кайтып эшләргә мөмкинлек булса, Муса күп нәрсәне өстәр, күп нәрсәне үзгәртер, яшьлек беркатлылыкларын алып ташлар иде — хәзер бит ул чын Германияне белә! Шунысы тагын бик характерлы: Германия татар шагыйренең иҗатында шактый урын ала, гүя аның бүгенге көненә басма булып сузыла...

Ә тышта һаман яңгыр коя, вакыт-вакыт яшен яшьни, күк күкри. Мусага исә дәһшәтле туплар тавышы ишелгәндәй тоела. Ул, сагаеп, башын күтәрә, сулыш та алмыйча диярлек тыңлый...

Иртә белән ялтырап кояш чыкты, төнге яшенле яңгыр әйтерсең булмаган да. Муса, плащын беләгенә салып, башына эшләпәсен киеп, Берлинның Штеттин вокзалына төште. Бүген Едлинодан Берлинга — экскурсиягә «артистлар» килергә тиеш. Билгеле, алар үз теләкләре белән килми, аларны чакырганнар. Каршы алырга, Мусадан тыш, немецлардан һәм «Идел-Урал» комитетыннан вәкилләр килгән иде.

Кунаклар, Мусаны вагон тәрәзәсеннән үк күреп, шатланып кул болгый башладылар. Аларның кайберләре Мусаны Демблин буенча гына хәтерли. Шагыйрь аруланган, өсте-башы шомарган — костюм, галстук, эшләпәдән.

Муса иптәшләре белән үз итеп күрешсә, немецлар исә салкын, тәкәббер исәнләште, «комитетчылар» төче елмайган булып кыланды.

Вокзалдан «артистларны» шәһәр уртасындагы «Александрплац» гостиницасына алып киттеләр. Биредә алар урнашкан арада Муса әле берсе, әле икенчесе белән сөйләшеп өлгерде. Дим Алишевка күчтәнәч әзерләгән иде — берничә җыр тексты бирде.

— Берсе, Дим, синең ятратканың — «Казан сөлгесе» көенә җырлана. Әйттерерсең дә инде, — диде Муса, үзе шунда ук көйли башлаган Димгә сокланып карап торды. Гайнан Кормаш шәп өйрәткән икән бу пәһлеван егетне «уйнамый уйнарга», карасана, чын артист кебек кылана бит, бахыр!

— Ә моның көе бармы? — дип сорады Дим, икенче кәгазьне кулына алып. Муса җавап биргәнче, күңелендә кинәт туган көйгә әкренгенә көйли дә башлады:

Әй, батырым, яуга бар,
Шуның өчен бүген ал.
Ил Юлайның баласы син,
Дошманыңны кыр да сал,
Сал, сал, сал!!

— Менә үзең дә таба яздың ич көен, — диде Муса көлеп. — «Башкорт маршы» бу. Синең чын башкорт җырларын ишеткәнең бардыр ич. Шәп җырлар! Көйләре — алтын. Ир-егетләр моңы.

Бераздан кунакларны сәяхәткә — Берлин шәһәрен карарга алып чыктылар. Алар шәһәр күрке — Тиргартенда да булдылар.

— Капеллага килеп кушылуыңа чын күңелдән шатмын, Рушат, — диде Муса Хисаметдиновка, зоопарк урманы буйлап бара-бара. Төрле җәнлекләр, ерткыч хайваннар, гаҗәеп кошлар урнашкан читлекләргә, вольерларга «артистлар» кызыксынып карады, Рушатны алар әллә ни җәлеп итмәде. Муса сорауларын дәвам иттерде. — Кайларда, нинди лагерьларда булдың, агай-эне арасында кыю егетләр бармы?

Рушат Демблиннан соң кайсы лагерьларда булуын, андагы хәлләр, «кыю егетләр» турында Мусага, җаелмичә, мөмкин кадәр кыска итеп сөйләп бирде.

— Ә безнең хатлар анда күренәме? — дип сорады Муса.

— Күренгәли. Егетләр аларны кызыксынып укый. Берсе миннән вәгъдәләр алгач кына күрсәтте үземә. Бөти бу, диде.

Бер аулаграк урында Муса, бармагы белән ымлап, Гайнан Кормашны да үз яннарына чакырды. Аннары төшенә кереп йөдәткән кара маймылларга күрсәтеп:

— Сез шул кара шайтаннарга багып, мине игътибар белән тыңлагыз, — дип пышылдады. Ул Совет Армиясенең бик каты һөҗүмгә күчүен әйтте. — Дошман хәзер үзенең агитациясен тагын да көчәйтәчәк. Анд

каршы үз сүзебезне ныграк әйтергә кирәк. Бу эштә җыр-музыка капелласыннан тулырак файдаланырга, төрле чаралар уйлап табарга. Исегездә тотыгыз: без үзебезнең концертларда күңел ачу максатын куймыйбыз, бусы тышкы кабык кына...

«Артистлар» Берлинда ике көн «кунак» булды. Ике көн буена Муса алар яныннан китмәде, үзенә кирәкле кешеләрнең барысы белән аерым-аерым сөйләшергә өлгерде, кайберләреннән ант та алды. Кыскасы, бу ике көннең һәр минутын ул зур эш өчен файдаланырга тырышты.

Ниһаять, пропаганда министрлыгындагы махсус очрашуга бардылар. Түрәләр «коллары» алдында үзләрен бик эре тотты, үгет-нәсихәтләрен теш арасыннан гына сиптеләр. Кайберләре, тавышларын күтәреп, бармак янап та алды. Аларның тәкәббер мин-минлеге исә «артистлар»ның эчке горурлыгын гына арттырды.

Шәһәр урамнарында, музей залларында йөргәндә «артистлар» үзләрен иркенрәк хис итте. Немец халкының гасырлар буе ургып торган талантына, сәләтенә, эш сөючәнлегенә чын күңелдән сокландылар. Бу халыкның сәламәт тәнендә фашизм бары тик яман шеш кенә. Музейда бу күзгә аеруча нык бәрелә. Ләкин бу яман чирне алар үзләре генә җиңеп чыга алмас, ул бик тирәнгә киткән. Монда «үткен пычаклы хирурглар» кирәк. Эх, әгәр шул көннәргә кадәр исән-имин яши алсалар, «артистлар» да бер-бер эшкә ярап куярлар, Берлин урамнарында гаҗәеп зур «концерт», Дим җырлаганча әйтсәк, «тамаша» бирерләр иде.

Рушатның йөзе уйчан. Гайнан Кормаш моны күреп:

— Рушат абый, күңелне төшерергә ярамый, мөкаддәрдә язылган шатлыклы көнгә ерак калмый инде, — диде елмаеп. — Мөкаддәре нидер тагы, белмим, безнең әби шулай әйтә торган иде. Тик әбиләр ялган сөйләмәс, чөнки алар ялганны зур гөнаһка санаган.

— Әкият дигәндә безнең Ош карчыклары да төшеп калганнардан түгел иде,— диде Рушат күңелсез генә.

— Ә мондагы әбикош ничек синенчә?

Рушат төшенеп җитмәде.

— Әбикош? Нинди әбикош тагы ул?

— Комитетта утырды ич, күрмәдеңмени?

— Матур немканы әйтәсеңме?

Гайнан көлеп куйды.

— Рәтең беткән икән, Рушат абый! Үз милләтең кешесен танымыйсың.

— Кит аннан!

— Менә шул чибәрне инде мондагы бер егет үзләренчә «әбикош» дип атый икән. Могҗизамы?

— Аңа ук барып җитмәсә дә, кызык. Кәләпүшле әфәнделәр булгач, калфаклы мадамнар да бардыр, — диде Рушат сүрән генә.

Экскурсиядән китәр алдыннан Муса Гайнан Кормаш белән Рушат Хисаметдиновка бер-әр пачка «күчтәнәч» бирде. Болар Совинформбюроның соңгы сводкалары, легионнарга дип аталган махсус листовкалар иде. Листовкалар латин хәрефләре белән типографиядә басылган. Өстә ятканына Гайнан күз кырыйлары белән карап алды:

«Хөрмәтле иптәшләр! Без ничек кенә җәфа чиксәк тә, Туган ил безне онытмас. Фашистларның алдауларына ышанмагыз, алар барыбер җиңеләчәк. Менә, мәсәлән, Совинформбюро үзенең соңгы көннәрдәге белдерүендә болай дип яза...»

— Рәхмәт, — диде Кормаш Мусага, — болар легионерларга икмәк кебек кирәк. Хәтта икмәктән дә битәр, хәзер инде әсирләр карын турында гына уйламыйлар.

— Шулай булуы бик һәйбәт. Тик серне йөрәктә саклагыз,— дип кисәтте Муса иптәшләрен.— Беренче уңышлардан башыгыз әйләнмәсен. Сабан туе алда әле, аңа әзерләнәсе дә әзерләнәсе. Яшерен оешмага яңа

членнар алырга бик үк ашыкмагыз. Без оешманың составын киңәйтү бурычын гына куймыйбыз. Ватан өчен, халык өчен җанын корбан итәргә курыкмаган егетләр генә бу оешмага керергә хаклы. Безне һәр җирдә бик нык эзлиләр. Арага провокатор керүдән сак булыгыз. Курыкмагыз да, гамьсезлеккә дә юл куймагыз.

Элемтәчеләр, конспирация шартлары буенча, үзләренә беркетелгән биш-алты кешене генә белә, алар белән генә эш итә. Гайнан Кормаш исә, Җәлилнең ике кулының берсе буларак, лагерьлардагы хәлләрдән күбрәк хәбәрдар. Муса аның белән сөйләшкәндә, нәкъ Абдулла Алиш белән сөйләшкәндәге кебек иркенрәк җәелсә дә, Рушат алдында алай итми иде. Бу Рушатка ышанып бетмәүдән түгел, бәлки шул ук конспирация шартларын күздә тотудан килә. Аннары Муса үзе дә бар нәрсәне белми, аны кайбер немец антифашистлары һәм башка милли легион вәкилләре белән генә бәйләнешкә керттеләр. Яшерен шартларда бу инде бик күп нәрсә.

Муса инде Гайнан Кормаштан айсбергтагы хәлләр турында, нәрсәләр эшләргә өлгерүен сүз арасында сораштырган иде. Гайнан, гадәтенчә, кыска-кыска гына җаваплар бирде. Госпитальдәге табибны да күргән. Уңышлы.

Иркенләп сөйләшергә вакыт тимәгән иде, менә хәзер генә икәүдәникәү калдылар. Гайнан аңа сугышчан бишлекләрне оештыруның барышы турында тулырак сөйләде. Табиб әйтеп биргән кешеләрнең кайберләре белән күрешеп сөйләшкән дә. Ярыйсы егетләр.

— Уңышлы башлагансың, тик кабаланма гына.

— Беләм. Мин бит егетләргә күптән күз сала киләм. Аннары Зиннәт булыша.

— Ничек, каршы сүз әйтмәдеме?

— Юк, хуплады гына.

— Син аңа командир күзлегеннән караганың бар идеме?

— Монда, Муса абый, бер түгел, биш карыйсың.

— Үзеңә бер-бер нәрсә сиздереп куймадыңмы?

— Юк, Муса абый. Дуслык — дуслык белән, сер — сер белән.

— Дөрес, бу турыда «хәрби советта» киңәшербез. Гомумән, командирлар мәсьәләсен «хәрби совет» карар. Монда башбаштаклык һич ярамый, Гайнан.

— Төшендем. Күрсәтмәдән бер адым читкә китмәм.

— Бик яхшы. Аннары шуны да исеңдә тот, Гайнан: хәзер сезгә элеккедән күп кыенрак шартларда эшләргә туры килә. Гитлерчылар легионерларга аз гына да ышаныч юк икәнен төшенделәр инде. Батальоннарда әләкчеләр санын арттырганнар дигән хәбәр бар. Сез аларны белергә тырышыгыз. Сездә ниндидер Исхаков дигән бер әшәке бәндә бар икән...

— Беләбез, фельдшер. Әшәкенең әшәкесе.

— Тагын бардыр. Уяу булыгыз! Сездәге батальон тулысынча әзер бугай?

— Әйе. Иптәшләр тизрәк фронтка озатсыннар дип көтәләр. Беренче батальоннан кимен эшләмәбез диләр.

— Юк, Гайнан, бездә булган мәгълүматларга караганда, әзер батальоннарны хәзер фронтка җибәрмәячәкләр. Мөгаен, тылда файдаланырлардыр. Мондый шартларда безнең төп бурыч — батальоннарда восстание күтәреп, аларны поляк партизаннары белән кушу. Әрмән легионы да шулай эшләргә җыена. Бу — беренче чиратта, аннары инде нәрсә кирәген вакыйгалар үзе күрсәтер. Хәзер барыннан да бигрәк уяулык кирәк. Тагын менә нәрсә. Лагерьларда черчетлар кайбер легионерларны кулга ала башлаган. Берничәсен, большевик агитаторлары дип, строй алдында атканнар да. Алар арасында безнең кешеләр юк. Димәк,

гитлерчылар яшерен оешманың барлыгын сизенәләр, тик анык белмиләр генә. Шуңа күрә «җәтмә» салалар.

Муса берничә минут уйланып торды, аннары Гайнанның күзләренә туры карап:

— Тагын бер ашыгыч эш бар, дускай, — диде. — Үтә ышанычлы дүрт кеше хәзерлә. Кимендә икесе шофер, берсе радист булсын. Картаны яхшы белсеннәр. Немецча яки полякча сөйләшсәләр бигрәк яхшы. Тагын нәрсә? Бу эшкә аеруча батыр кешеләр кирәген аңлыйсыңдыр. Алар һәр минут әзер булсыннар. Башкаларга бу турыда сер итеп тә сөйләмә... Миңа сорауларың бармы?

— Аңлашыла, Муса абый.

— Едлинога кайтып кергәндә аеруча сак булыгыз. Сез юкта әллә нинди провокация оештырулары мөмкин. Гомумән, артны-алны карап йөрергә кирәк. Рота яки батальон командиры кайларда булдыгыз, нишләдегез дип сораулары мөмкин. Каушамыйча җавап бирегез.

«Артистлар» Едлинога кайтып кергәндә анда тыныч, бернинди хәвеф-хәтәр сизелми иде. Бары тик моның шулай икәненә тулысынча ышангач кына Гайнан Мусаның заданиесен үтәргә кереште. Әгәр аның алдан бернинди әзерлеге булмаса, кешеләрне яхшы белмәсә, бу эш чиксез авыр булыр иде. Ул юлда ук кемнәр белән сөйләшә башларга кирәклеген күңеленнән билгеләде. Соңыннан аларның берәвен генә кире какты, чөнки ул госпитальдә булып, заданиегә әзер түгел иде.

Берлиннан кайткач, «артистларны» төрле лагерьларга концертлар белән еш йөртә башладылар. Алар Радомда, Крушинода, Демблинда, Узидомда, Дрезденда булдылар. Концертлар һәр җирдә ярыйсы уңышлы үтте. Дим үзенең яңа җыры — «Башкорт маршы» белән шаулады, «Казан сөлгесе» көенә җырланган җыры да тыңлаучылар күңеленә хуш килде. Зиннәт Хәсәнов Сарман яклары көйләре белән дан алды. Шәриф Әмиров борынгы җырларны бик оста, үзенчәлекле башкарды. Музыкантлар — Фәрит Солтанов, Рушат Хисаметдинов мандолина чиртте, скрипачлар үзәкләрне өзеп скрипка сыздырдылар.

«Артистларның» һәр адымын Муса бик яхшы белеп тора иде. Маршрутларны һәр вакыт министрлык билгеләде. Еш кына Муса үзе дә алар белән бергә йөрде. Шундый очрашуларның берсендә Гайнан Кормаш аңа заданиенең үтәлүен, дүрт кешенең әзерләнүен әйтте.

— Бик яхшы булган, — диде Муса. — Озакламыйча безне Едлинода «кунакка» көт.— Һәм бераз уйлап торгач өстәде:— Хәзер, дус, иң мөһиме — айсберг, айсберг. Бигрәк тә аның күзгә күренми торган өлеше!

## 21

Бүген Шәфи Алмас йортында зур мәҗлес — хуҗа үзенең илле яшь тулган көне һәм «Идел-Урал» штатының президенты» итеп сайлануы хөрмәтенә мәҗлес үткәрә. Аның өе зыялы кунаклар белән тулы. Сугыш вакытында мондый туйлар гадәти булмаса да, югары катлау өчен, аерым тантаналы очракларда, ярый, күрәсең. Зур залның ишекләре киң ачык, төрле зиннәтләрнең күбесе җыеп алынган булса да — шәһәрне бомбага тоталар ич — стеналар, шкафлар бөтенләй шәрә димәссең, барысы шәрык рухы белән сулый. Савыт-сабалар, төрле хикмәтле вазалар, келәмнәр, тагын әллә нинди затлы зиннәтләр — бар да Төркиядән, гарәп илләреннән килгән. Шунда ук көнчыгышның атаклы мәчетләре, Мәккә вә Мәдинә сурәтләре. Әллә кайдан әкрен генә шәрык музыкасы

да сибелә. Шәфи Алмас үзе дә баштанаяк мөселманча киенгән — ул төрек подданные ич — «бондый мыз-мезләрне» унга-сулга чәчә, җитмәсә, мәҗлестә берничә төрек журналисты да бар.

Залда кунаклар тула барган саен шәрык рухы, нацистлар рухы белән аралашып, тагын арта төште. Ирләр хәтфә түбәтәйдән, фәстән, хатын-кызлар энҗеле калфаклардан, Шәмсинур баштанаяк милли киемнән.

Залда Познань фабриканты Мөхәммәт Кәмал Яушев күренде. Күкрәгендә нацистларның алтын значогы ялт-йолт итә. Күргәч, кунакларның күпчелеге аңа таба омтылды, ихтирам күрсәтеп, күрешә, саулык сораша башладылар. Шәфи Алмас та түбәнчелек белән каршы алды, кунакның мөбарәкләүләрен илтифат белән тыңлады. Аннары яңа кунакларны каршыларга ашыкты.

— Мәрхабә, хуш киләсез. Боерыгыз, боерыгыз.

Ул алтын алма кебек балкый, тик күзләре генә тынычсыз. Ихтимал, ул үз иминлеге өчен күбрәк борчыла торгандыр, ихтимал, бу сәүдәгәрлек гадәтедер. Капитал дөньясында шунсыз ярамый, йоклап ятсаң, «президент» дип тормаслар, авызыңдагыны тартып алырлар.

Фабрикант Мөхәммәт Кәмал Яушев Шәфи Алмасның күптәнге дусты һәм көндәше. Ул Яушевның һаман тауга үрмәләвен, үз фабрикаларында бик төшемле сугыш кирәк-яраклары җитештерүен, бер галәмәт баюын көнләшеп күзәтә. Соңгы вакытларда Яушев Познаньда тагын бер кәрханәнең — радиоаппаратлар эшләп чыгара торган заводның хуҗасы булып алган. Фюрерның чикләнмәгән мәрхәмәтеннән файдалана шул ул. Ачык авыз булсаң, «Идел-Урал» нәшерене дә умырыр. Аңардан барысын көтәргә була — карчыга! Тырнаклары үткен!

Ишектә профессор фон Менде күренде.

— Көтәмез, көтәмез, хөрмәтле профессор. Боерыгыз. Рәхмәт, рәхмәт, фон Менде әфәнде. Кая ул йөз яшькә хәтле яшәү. Картаябыз шул. Рәхмәт, әлегә бирешергә исәп юк, милләт юлында... — Ул күзләре белән хатынын эзләде, күрмәде. Тапкан кәҗәләнер вакыт. — Аһ, әнә Шәмсинур ханым, сезнең уңган шәкертегез. Мин бер генә минутка сезне аның карамагына калдырам, хөрмәтле профессор, мең кәррә гафу, кунаклар.

Шәфи Алмас тагын кемнәрнеңдер ягына атлады. Ишек артында бер яшь егет белән сөйләшеп торучы шагыйрь Муса Җәлил күзенә чалынса да, анда ул туктамады.

— Исегез китмәсен, Муса әфәнде, болар эмиграциянең коела башлаган чәчәге, сугышка кадәр алар күбрәк, ыгы-зыгылырак иде. Хәзер әкренләп башка илләргә сызалар, — диде башына хәтфә түбәтәй кигән яшь егет. Бу — Шәмсинурның улы Илдархан иде.

Бүген генә Польшадан командировкадан кайткан Муса юлда әзрәк арган-талган булса да, шеф чакыргач килми калырга ярамый иде. Мондагы кешеләрнең күбесен, «Идел-Урал» комитеты, Розенберг министрлыгы тирәсендә чуалучылардан башкаларын, ул белми иде. Илдарханның туры килүе шәп булды, сорашты да, залны да күзәтте.

Муса бик сак иде. Ул күзләре белән Сәрхушне эзләде. Сайлау кампаниясе вакытында бик тырышып йөргән иде, хәзер нигәдер күренми. Әллә ерактан күзәтәме, әллә берәр яры китеп барганмы? Ваграк чукмарбашлары — Әхмәт Симай шулай диган иде бит — биредә булырга тиеш. Мондый мәҗлесне алар күз-колаксыз калдырмас.

— Әтиегез биредә нигә юк? — дип сорады Муса Илдарханнан, ә күзләре һаман зур зал буйлап йөрде. Кунаклар артканнан-арта бара иде.

— Әти мондый мәҗлесләрне яратып бетерми, аларга йөрү — бушка вакыт үткәрү, ди.

— Президент мәҗлесе ич бу!

— Булса ни, безнең эти ул политикага катнашмый.

Илдархан үзе энисе килгәнгә килгән, ә энисенә килми калырга ярамый икән.

«Кызык та икән боларда семья мөнәсәбәтләре», дип уйлады Муса. Аның күзләре, зал уртасында кунаклар белән камалган хәлдә, бик эре, мәгърур басып торган фабрикант Яушевка текәлде. Яушевлар турында аның ишеткәне бар иде, менә бүген аларның берсен күрергә дә туры килде. Чыннан да ач сөякле карчыгага охшаган икән, күзләре үткен, башы кечкенә, кыска чәче агара башлаган. Кыяфәтендә эрелек, кәперәйгәнлек.

— «Идел-Урал»дан кешеләр алырга килгән ул, — диде Илдархан фабрикантка ымлап, — полякларга ышаныч юк ди, мөселман агай-энеләрне өсләреннән караучы итеп куймакчы икән. Мәһабәт гәүдәлеләрен генә сайлаган, күргәч ук котлары алынсын дип әйтә икән.

...Берлин туфрагына аяк басканнан бирле әллә ни күп вакыт үтмәсә дә, Муса эмигрантларның табигатен бераз аера башлаган иде. Ул эш арасында аларның әле берсе, әле икенчесе белән сөйләште, бигрәк тә Шәмсинур Идриси белән сөйләшүләр аңа күп нәрсә бирде. Ул эмигрантлар белән һәр вакыт аралашып яшәгән. Эмигрантлар монда төп ике төркемгә бүленә: бер ишеләре совет властена каршы, әмма Россияне үз ватаннары итеп саный, алар Россияне советлардан азат ителгән килеш күрергә тели; икенчеләре — киребеткәннәр, ягъни гражданнар сугышы елларындагыча катып калганнар. Алар большевизм белән агуланган бөтен Россияне җир йөзеннән юк итү ягында торалар, ике йөз миллион кеше бетсә бетәр, аның каравы, «азат дөнья» иркен сулыш алыр дип фараз итәләр. Беренчеләре совет властена, коммунизмга каршы каһарманнарча «көрәшүче», «изге коткаручы» итеп Гитлерга мәдхия укый, әмма аның Россия кешеләренә карата аеруча кансызлыгын өнәп бетерми; икенчеләре, киресенчә, нацистларның ерткычлыгына кинәнеп кул чабалар, афарин дип акыралар.

Татар эмигрантлары, билгеле, үзләренә аерым төркем тәшкил итми, алар әлеге шул гомуми ике төркемнең я тегесенә, я монысына якын торалар. Баштарак алар: «Рус̆сия халкы кулына корал алса, советларга каршы күтәрелер»,— дип лаф орды. Әмма бу хәл булмагач, татар эмигрантлары үзләренә аерылып: «Каферләргә ышаныч юк, менә мөселманнар изге бурычларын үтәми калмаслар»,— дип, төкерек чәчәргә тотындылар. Беренче татар легионы батальонында булган мәгълүм хәлләрне ишеткәч, аларның да күзләре шар булды.

Эмигрантларны болай ике төркемгә бүлү хакыйкатькә бөтен яктан туры килеп бетмәсә дә, хәзергә Муса шул кадәресен генә белеп өлгерде. Менә Шәмсинур Идрисине һәм аның ирен кайсы якка кертергә — ул аптыраган. Шәмсинур гитлерчылар органы «Идел-Урал»да эшли, ләкин аның юлын, Шәфи Алмас кебек, бәхәссез кабул итәме, әллә кабул иткән булып кылана гынамы? Шәмсинурның бердәнбер улы Илдархан бер тапкыр Мусага әйтеп ташлады: «Гитлер-югенд сафларына кермәс идем дә, аннан башка югары мәктәпкә укырга алмыйлар бит». Бу зур мәсьәлә буенча семья эчендә сүз булмый калмагандыр, әлбәттә. Менә шул нәрсә Мусаны еш кына уйландыра. Аннары ул үз-үзенә әйтеп куя: ярар, тормыш бер ачыклык кертер әле, уйлап кына моның очына чыга алмассың. Әмма бер нәрсә шактый ачык: Шәмсинурга серләреңне чишәргә ярамый, шулай ук аңардан бөтенләй кул селтәү дә акыллы булмас. Әхмәт Симай аны әбикош дип бер сүзсез дошман санаса да, хәзергә Шәмсинур Мусаларга ачыктан-ачык каршы килеп маташмый бит. Шәмсинур үткен акыллы хатын, теләгәндә ул бик күп зыян итә алыр иде.

Шәфи Алмас алар каршында туктаган иде инде.

— Бәрәкалла, мин сезне күрми дә торам, Муса әфәнде, — диде, ниһаять, хуҗа. — Түргә боерыңыз, хәзер утырта башлыймыз. Тагын берничә кунакны гына көтәсе калды. Безнең мөселман кардәшләр, борынгы гадәт буенча, көттерергә ярата, ә немецлар, мәдәниятле халык, бик төгәл, минуты илә килеп җитәләр.

Ниһаять, кунакларны, дәрәҗәләренә карап, утырта башладылар — урыннар алдан язып куелган иде. Түрдә фон Менде һәм башка немецлар, алар белән янәшә фабрикант Мөхәммәт Кемал Яушев, бүтән дәрәҗәле кунаклар. Алар уртасында, йөзек кашы кебек ялтырап, доктор Шәмсинур Идриси утыра. Каршы якка шагыйрь Муса Җәлилгә урын билгеләнгән. Шәфи Алмас барысын алдан уйлап эшләгән. Яушев мәҗлесләрдә мактанырга ярата, ә Муса әче телле, түзмәс, теге борчак сибә башлагач, берничә сүз белән авызын каплар. Монда Шәфи Алмас үзенең куптәнге көндәше Яушевтан үч алмакчы иде.

Мәҗлеснең рәсми өлеше — Шәфи Алмасның туган көне, «Идел-Урал» штатының президенты» итеп сайлануы уңае белән котлаулар, милләт юлында илаһи уңышлар теләүләр, аннары мөхтәрәм Шәфи әфәндене купшы җавап сүзен тыңлаулар беткәч, тостлар күтәрелгәч, ниһаять, Яушев поляк эшчеләреннән көләргә тотынды: янәсе ахмаклар алар, бүгенгәчә фюрерның бөек идеалларын аңламыйлар, мәгънәсез саботаж ясамакчы булалар, туң башлар! Яушев аларны берьюлы акылга утыртырга булган: «Идел-Урал»дан егерме биш татар ала да, кулларына камчы тоттырып, поляклар өстеннән сакка куя, имеш.

— У-у-ухх! дип бер кычкырып җибәрсәләр, һы! — диде Яушев калын тавыш белән. Бөтен мәҗлеснең игътибар итүен күргәч, шаркылдап көлеп җибәрде.

— Афарин, Мөхәммәт Кемал әфәнде! — дип кычкырды кемдер.

— Болай булгач, башларына кызыл фәс тә кирәк бит, мыек чылгыйлары бер аршын булсын — Карәхмәт! — диде Муса елмаеп.

Әле революциягә кадәр Оренбурда Яушевларның галәмәт зур кибетенә бер кергән иде ул. Әллә этисе, әллә башка бер кеше сөйләгән иде: «Яушевлар акчаны көрәп кенә алалар. Аларның кибетләре бер Оренбурда гына түгел, Ташкентта, Симипалатта, Казанда, тагын әллә кайларда гөрли. Әшне зур колач белән алып баралар, эре сәүдәгәрләр алар, безнең кебек тегенди-мондый вак кәсепчеләр түгел».

Ул чакта Муса кайчан да булса Яушевларның берсен очратырмын, яңа пешкән «президент» өендә аның белән бер өстәл янында кара-каршы утырырмын дип уйламаган иде. Дөнья булгач, утырырга туры килә икән.

Баштарак Яушев Мусаның ачы кинаясен төшенеп бетермәде, дөресрәге, мондый җөрьәт әсир шагыйрьдә булыр дип башына китермәде.

— Карәхмәт! — диде ул көр тавыш белән. — Казанлылар Карәхмәт дип үлә инде. Ләкин үзләре үк аны Кабан күленә батырганнар. Ха-ха-ха!

— Ул, мөгаен, батып үк бетмәгәндер, югыйсә, Яушев әфәнде биредә аны үзенә ялчы итеп алмас иде.

— Ә нигә алмаска, әйдә безгә дә хезмәт итсен, фәсен дә киертермез, мыек та үстертермез. Безнең кодрәттән килә ул.

— Шамакайлар кия торган кызыл фәсләргә кодрәтегез житсә дә...

— Нәрсә, нәрсә әйттегез?!

— Бик арзанлы хезмәтчеләр сайлыйбыз түгелме, Яушев әфәнде? Андыйларны безнең милләт кешеләре арасыннан табу, ай-һай, җиңел булырмы икән? — диде Муса бик җитди итеп.

— Карарбыз! Сез шагыйрь булсагыз да, алтынның бинниһая көчен белмисез әле.

— Минем каршымда ул сары шайтан гына.

— Боны башка берәү әйткән инде, чөнки үз кесәсендә шомарып беткән бакыры да булмаган!

Шәфи Алмас, тавышның зурга китүеннән куркып, сүзне гади шаяруга борды, аннары бөтенләй йомды. Ул үзенекен эшләде, артыгы аңа кирәкми, хәтта зарарлы иде. Ул белә: кунаклар аны яратып бетермиләр, түрендә утырсалар да, эчтән көләләр, күптән түгел булган «президент» сайлаулары моны бик ачык күрсәтте.

Яушевның йөзе пешкән чөгендер кебек бүрткән иде. Шәмсинур Идриси, өстәл астыннан аның кулын кысып, күзләре белән фон Мендегә ымлады. Яушев барысын аңлады, яңадан шагыйрь белән бәрелешеп кузгатмады. Ләкин үз дигәнен барыбер эшләде, «Идел-Урал» комитетыннан үзенә кирәкле кешеләрне сайлап алып китте. Шагыйрьгә кешеләр аша әйтеп калдырган:

— Авызында ана сөте кипмәгән әле шагыйрь әфәндене, шул да Яушев белән чәкәшергә маташа. Фон Мендегә рәхмәт укысын, югыйсә, кемлеген йөзенә чәпәп әйтеп биргән булыр идем.

## 22

Әхмәт Симай, билгеле, Шәфи Алмасның мәҗлесендә булмады. Аңа бу өйгә ара-тирә килгәләп йөрергә рөхсәт ителсә дә, «мәрхәмәт» шуннан артыкка узмады. Аннары һәр килгәндә Әхмәтнең нинди дә булса яңа сәбәбе әзер булырга тиеш иде.

Муса белән фабрикант Яушевның чәкәшеп алу хәбәре эмигрантлар арасында шактый киң таралып өлгергән иде. Шунысы кызык, эмилар — Әхмәт эмигрантларны шулай атый иде — Мусаны артык гаепләми, мәсьәләнең политик ягы бөтенләй күрсәтелми, янәсе ике кеше, башларына киткәч, мәҗлестә бераз бәрелешеп алган — шул гына. Артык һаваланырга яраткан Яушев оттырган. Күрәсең, кемнәргәдер ниндидер сәбәпләр аркасында фабрикантка күләгә төшерергә кирәк, менә уңай очрактан файдаланып авыз чайкыйлар, хәтта Яушевның националь-социалистлар партиясе вәкиле булуына карамыйча. Димәк, үзара ызгышлар!

Әхмәт Симай үзенең очкырлыгы аркасында менә шуны белә алды. Аннары тагын бер нәрсәгә инанды — монысы аны шактый борчуга да төшерде — шау-шулы мәҗлес арасында яңа пешкән «президент», «тәхеткә» утыргач беренче зур хезмәте итеп булса кирәк, гестапога Рәхим Саттар өстеннән шым язган. Әхмәт Симай моның барлык якларын төбенәчә ачыклый алмады. Бәлки карт төлке шушы юл белән гомумән яшерен оешмага кармак сала торгандыр. Ни генә булмасын, Әхмәт бу турыда бик ышанычлы кешедән ишетте һәм кичекмәстән Мөршидкә хәбәр итәргә кирәк дип тапты.

Бу вакытта Әхмәтнең кәефе гомумән яхшы иде. Яшерен оешманың йомышларын Голландиядә уңышлы башкарып кайтканга, вак-төяккә борчылырга аның нигезе дә юк иде кебек. Тормыш исә алга яңа мәсьәләләр куя тора, гамьсезлеккә чумарга ирек бирми.

Бер көнне радиостудиядә чираттагы тапшыруларга хәзерләнеп утырганда аның янына Ишбулмас килеп керде. Авызы тузган чабата башы кебек ерылган иде.

— Ну, малай, котла абзаңны! — диде ул, кесәсеннән уч төбе хәтле китап чыгарып.— Менә нинди зур бәхеткә ирештем: шигыр мәҗмугам чыккан, типографиядән кереп алдым, кәтә-кәтә йөрәк түзмәде. Күпме тырыштым, Казанда чыгармадылар, ә монда... рәхим ит! Шатлыктан юарга булдым. Син килерсең бит.

— Командировкага китеп калмасам...

— Радиода бер тапшыру оештырсагыз иде шул турыда, ә?

— Башта хуҗалар карасыннар, рөхсәт булса, бездән эш тормас. Ярый, минем вакыт бик тыгыз, «президентның» мәкаләсен хәзерлим.

— Син инде килми калма. Муса ничек, килерме?
— Кеше өчен әйтә алмыйм — ну, килмәс дип уйлыйм.
— Ә мин аңа китабымны автограф язып бирсәм?
— Анысы синең эш. Бигайбә. — Әхмәт кәгазьләренә төртелде.
Ишбулмас башкалар янына күчеп утырды. Әхмәт аның китабын кулына алып та карамады.
Әхмәт Мусаны күрергә ашыга иде. Турыдан-туры күрә алмаганга, кич белән Алиш квартирасына барды, барлык борчылуларын аңа сөйләп бирде. Бигрәк тә Шәфи Алмасның Рәхим Саттар өстеннән язган шымы турында борчылып сөйләде. «Боларны тиз генә Мөршидкә житкер», диде, «Очкыр бик борчыла диген», диде.
— Тагын бер яңалык, Абдулла абзый: Сәрхуш мәләвен кайткан. Соңгы вакытларда югалып торуының сәбәбе шул — Австриядә булган икән. Көч жыйган, имеш. Хәзер эшкә тотынып инде. Бу турыда Мөршидкә аерым әйт, үзе шулай кушкан иде. Тагын шуны белдем: «мыз-мез» мәжлесендә ваграк чукмарбашлардан берәү бер тәтәй белән булган... Бүген генә яныма Ишбулмас кергән иде. Китабы чыккан, мәжлес оештырырга йөри. Радиода шул турыда тапшыруны сорады. Сасысы борынга бәреп тора. Кабәхәт!
Шуннан соң Әхмәт радиостудиягә кайтты һәм иртәгәге тапшыруларга мәкалә язарга утырганда башына кызыклы бер уй килде: яңа пешкән «президенттан» юл күрсәтмәле берәр кәлжемә яздырып алып булмасмы икән. Аның кәефе хәзер шәп булырга тиеш, үзен чын тәхеттә сизеп, берәр мөһим нәрсә ычкындырып ташламасмы?
Әхмәт шунда ук Шәфи Алмаска шалтыратты, үзенең бик шатланганын әйтте: жәмәгатьчелек аның сайлауларда жиңеп чыгуын алкышлый, янәсе. Аңа әллә ничә жирдән шалтыратканнар, эфирга хәбәр итүен сорыйлар — татар милләтенең гүзәл уңышын дөнья белсен, диләр.
— Шул уңай белән берәр житәкче рисалә язсагыз бик яхшы булыр иде, президент әфәнде. Без аны бик зурлап тапшырыр идек.
— Тапшырдыгыз бит инде, — диде Шәфи Алмас, тыйнаклык саклаган булып.
— Хәзер жәмәгатьчелек сезнең олы сүзне һәр көн көтә.
— Ярый, уйлап карармын. Барып чыга торган булса...
Әхмәт «президент» кеше бик назланыр дип көткән иде, Шәфинең вәгъдә бирә язып куюын ишеткәч, шөһрәткә сусаган икән абзаң, дип уйлады.
Студиядән чыкканда Әхмәт, башка вакытлардагыча, кесәсенә берничә вак радиодеталь салды.
Вакыт-вакыт такылдаудан баш тартмаган Әхмәт кайбер нәрсәләр турында авыз да ачмый. Ул әбикошның үзен күзәтүен белә, хәтта Шәфи Алмас өен дә тыныч калдырмый, «президентның» башын әйләндерер дип куркамы икән әллә? Һәрхәлдә, Әхмәтнең бу өйгә бушка килеп йөрмәвен сизә булса кирәк.
Ике көннән соң, алдан телефонда шалтыратып, ул Шәфи Алмасларга тагын керде. Керсә, әбикош анда утыра инде!
— О, Шәмсинур ханым,— диде Әхмәт, бернәрсә белмәгәнгә салынып, — сез бу араларда студиядә нигәдер күренми тордыгыз. Авырмадыгызмы?
— Доктор авырса да белмиләр улыр, башкалар авырмасын.
— Анысы табигыйдер, Шәфи әфәндегә шалтыраткан идем — зарланмады. Тик бераз томау төшкән, ахрысы, борыным сызгыра, диде.
Шәмсинур Әхмәтнең ирониясен ачык сизсә дә, берни әйтмәде, аңа күз читләре белән генә сәер карап алды.
— Кыен сезнең һөнәр, Шәмсинур ханым, — диде Әхмәт, һаман берни күрмәмешкә салынып. — Кеше сыкрамый торамы соң.

— Әйе шул. Адәмнәр авырмаса, мәдәниятле илләр докторлар хәзерләмәс иде.

Шәмсинурның гаҗәпләнүен бик ачык сизеп, Әхмәт шаяртыбрак сөйләшүен туктатты. Бу әбикош үзенең яшерен уйларын башкалар белеп алудан бик курка булса кирәк. Ара-тирә аның теленнән милләттәшләренә карата уңай сүзләр ычкынгалый, әмма, Әхмәт фикеренчә, болар бары тик сүзләр генә, ул үз милләтен белми, аның уй-фикерләрен төшенми. Шәмсинур буржуаз җәмгыять кешесе, ә биредә барысы да акчага корылган. Гитлерчылар бүген аңа яхшы түлиләр, ул аларга гадел хезмәт итә һәм күз йома. Түләми башласалар — икенче хуҗаларга ялланыр, аларга да гадел хезмәт итәр. Карт әнисеме, әбисеме бала чагында аңа туган телен аз-маз өйрәткән, бәлки җырлар җырлап, экиятләр дә сөйләгәндер, әмма Ватан хисен алар аның йөрәгенә тирән сала алмаганнар, балалары җыры юк сандугач булып үскән...

Әхмәт тирән көрсенүен чак баса алды. Туган җирләреннән аерылган кешеләрнең аяныч язмышлары турында аның болай ук тирән уйланганы юк иде. Дөресен әйткәндә, ул аларны кызганмый, аның фикеренчә, монда бары тик алар үзләре генә гаепле. Шулай да бу тормыш кешене шул хәтле гарипләндерер дип күз алдына китермәгән иде. Әбикош кешечә йөри, кешечә сөйләшә, хәтта ачулана ала, ә рухы...

Шәмсинур гаҗәпләнүен тиз генә яшереп өлгерде.

— Сезнең эшләр бара ничек, Әхмәт әфәнде? — дип сорады ул.

— Радиодамы? Ал да гөл, — Әхмәт үзенең гадәти мактанчык тонына күчте. — Немец сводкаларын беренче чиратта шаулатабыз. — Доктор ханымның шикле карашын сизеп исә өстәде: — Профессор фон Менде шулай куша.

— Тыңлаучыларыгыз ышанамы?

— Башларына тай типкәнме әллә... фюрер сүзенә ышанмаска!

Шәмсинур тагын, күз читләре белән генә Әхмәткә карап, сорады:

— Т-тай типкән... була ни?

Әхмәт көлеп җибәрде. Күр, әбикош аның каһкаһәсен тотып алды бугай. Инде кыен хәлдән ничек чыгарга, ничек җавап бирергә?!

— Сез бу уенчак тәгъбирнең мәгънәсен бик яхшы аңлыйсыз, Шәмсинур ханым. — Ышанычлырак булсын өчен Әхмәт салпы якка салам да кыстырды. — Сез татар телен миннән яхшырак беләсез. Мин прастуй халык сүзләрен генә беләм, сез китап сүзләрен дә...

— Шулай да, Әхмәт әфәнде, тай була ни?

— Тай тай була инде... Ничек әйтергә, бала атмы, бәләкәй атмы.

— Ә кемнең башына типкән?

«Бик дөрес аңлагансың, браво, майкушым әбикош» дип әйтәсе килде Әхмәтнең. Ләкин соңгы минутта фикерен үзгәртте.

— Әлбәттә, юләр әсирләрнең!

Сорау белән җавап арасында бер мизгел пауза бар иде. Шул нәрсә акыллы Шәмсинурны сагайтты. Әхмәт тә, уйламыйчарак кулланган халык сүзе өчен, дөресрәге, аңа тиз генә аңлатма таба алмавына үкенеп куйды. Башыбыз әйләнә башлаган бугай. Әбикош студия тапшыруларын өендә тыңламый димә. Татарчаны да ул ярыйсы яхшы белә бугай, ә кайбер буташтыруларны юри эшләмиме икән? Әхмәтләр немец сводкаларындагы аерым атамаларны еш кына я бозып, я ике мәгънәлерәк итеп бирәләр, янәсе татарчаны монда кем аңлый, кем төшенә. Әнә Шәмсинур нинди нечкә әйберләрне әләктергән бит! Дошманны юләрсетеп карау — ул үзеңне дә түбәнәйтү. Ничек моңарчы шуны аңламады, Очкыр! Разведчик бит аерым-аерым вак кына детальләрне дә бергә җыя, шулай җыйгач, алар бөтенләй башка төс ала. Әйтик, җитәкче мәкаләләрдә юри катлаулы әйләнмәләр кулланулар, хәзерге укучыга мәгънәләре аңлашылып бетми яки бөтенләй кире мәгънәле иске сүзләр кыстырулар — Әхмәт үзе дә аларны аңлап бетермим диген иде бит — радио тапшыру-

ларда күпме була. Шуның өстенә укыганда бутаулар, ялгыш әйтеп җибәрүләр, тотлыгулар нихәтле тагы. Никадәр ачык авызлык! Имеш, газетаның подшивкасы кала, радиотапшыруларныкы калмый, янәсе? Телләгәндә һәр радиотапшыруны магнитофон тасмасына язып алып булмыймыни. Немецларда бу яңалык инде бар ич.

Шәфи Алмас бу якка чыгуга барысы да аякка бастылар, баш иеп исәнләштеләр. Шефның йөзе таушала төшкән, күз кабаклары шешенгән, борыны калынайганрак шикелле һәм нindидер шәмәхә төскә кергән. Мәҗлестән соң аның тиешенчә айнып җиткәне юк иде әле, ахрысы.

— Шәфи әфәнде, сезне авырый дип шалтыраттылар, — диде Шәмсинур борчылып.

— Зарар юк, — «президент» мәгънәсез генә кулын селтәде, — утырыгыз. Картлар шыгырдый инде ул, менә сез, яшьләр, бирешмәгез. Әхмәт әфәнде, сезне бик озак көттергәндермен, ахрысы. Чак язып бетердем. Башка бер әйбәт уй килеп мәмнүн иткән иде, кәгазьгә төшергәнче онытылды, каһәр. Әйтегез, әле, илһам дигәнең шундый назлы нәмәстәкәймени ул?

— Шагыйрьләр шулайрак диләр, журналистның илһамы — аның аякларында,— диде Симай каламбур сымаграк итеп.

Шәфи Алмас көлеп җибәрде:

— Бурзайлыкка дисәгез мин инде карт.

— Бур-зай була ни?— дип тиз генә сорады Шәмсинур. Бу сүздә дә ул нидер сизде кебек.

— Бурзаймы? Әхмәт әфәнде, әйтеп бир әле доктор ханымга шул Рәсәй сүзенең мәгънәсен.

— Йөгерчек эт, ау эте.

Шәмсинур буялган иреннәрен тешләде. Шәфи Алмас аның чырае үзгәрүен күрде бугай, авыр сулап, сүзне бүтәнгә борды.

— Ярар, бәлки уңышлырак сүз дә табармыз. Аякларның дәгел, каләменең бераз җитезрәк булуы кирәк иде дә, нишлисең... Бәлки Шәмсинур ханым булышыр. Акыл өстенә акыл — куш беләзек диләр иде борын.

— Сезнең үзегезгә тагын күрсәтергә кирәкме, президент әфәнде?

— Шәмсинур ханым карап чыкса, шул җитәр.

— Баш өсте.

Әхмәт саубуллашып чыгып китте.

— Нинди рисалә ул? — дип сорады Шәмсинур.

— Гадәти. Президент буларак кайбер күрсәтмәләр бирдем.

— Профессор фон Менде карап чыктымы?

— Президент рисаләсенә...

Шәфи Алмас «цензура кирәкме?» дип әйтмәкче булган иде, ләкин актык секундта тел төбендәгене әйтми калды, сиңмез йөзе кызарды.

— Җитәкче рисаләләрне профессор мәҗбүри карарга тиеш бит.

— Һай, алла! Шундый кечкенә нәрсә... Минем үз башым юкмыни.

— Шәфи әфәнде, язманы редакция мөхәррирләре кулына биргәнче фон Менденең рөхсәте булырга тиеш бит. Редакция аның бер хәрефен дә үзгәртми була. Моны сез беләсез. Бу тәртипнең үзгәргәне юк.

Шәфи Алмас тирләгән маңгаен сөртеп алды. Һай, нихәтле җыерчык икән маңгаенда!

— Ярар, Шәмсинур ханым, шауламыйк, үзегез караңыз да...

Шәмсинур үзенекен кабатлады:

— Юк, Шәфи әфәнде, бик зур күңелсезлек бар була.

— Нишләргә соң? — диде «президент» бик зәгыйфь тавыш белән.

— Кире алыгыз!

«Шәфкатьсез!» дип чак кычкырып җибәрмәде Шәфи һәм тамагын кыргалап телефонга үрелде:

— Әхмәт әфәнде, сезме? Рисаләне кире кертеңез әле. Бер фикер онытылган.

— Мәкаләгез бик шәп бит. Бигрәк тә бер шалапай турында. Шәфинең күңеле күтәрелде.

— Ха-ха! Шалапай...— Шәмсинурның сытылган чыраен күреп, ул тиз генә өстәде: — Шулай да кире кертеңез әле.

— Аларга ошаса, бигрәк тә! — диде Шәмсинур каты итеп. Аннары йомшаграк тавыш белән сорады: — Ша... ша... була кем?

— Ша?.. Ә, шалапаймы? Шул инде, чегән малае.

— Эфирга тапшырасы рисаләдә... редакция мөхәррире турында... Бу... Рөхсәт булмый торып...

Шәфи Алмас берни әйтмәде, ул курчак президентның ни бәя торганын бу минутта бик яхшы аңлады булса кирәк. Сайлаулардан соң беренче мәртәбә үзенең аяныч хәленә әрнеде.

— Башына... тай типсә була ни? — дип кинәт сорады Шәмсинур.

— Кемнең, минекенәме?! — дип кычкырды Шәфи Алмас, артына капыл борылып. — Юләр, ахмак була!

Шул секундта ачы тавыш белән сирена үкерә башлады — һава тревогасы. Хәзер ул торган саен ешрак кабатлана. Гитлерчылар инде сугышның беренче айларындагыча совет авиациясен тар-мар иттек дип шапырынмыйлар, киресенчә, үзләре бункер юлын такырайтып бетерде.

— Шәмсинур ханым, тизрәк бу-бу... бункерга! — дип калтыранган тавыш белән кычкырды Шәфи Алмас. Үзе, йөгереп килеп, өстәл тартмаларыннан бик кабаланып нидер эзли башлады. Тапмады, ишеккә йөгерде. Идән уртасында туктап калды. Тагын өстәле янына атылды, тартмаларны шалт-шолт ачып япкалый башлады.

— Шәмсинур ханым, Шәм!..

Шәмсинур күптән инде бүлмәдән чыгып киткән иде. Кинәт бөтен җирдә утлар сүнде. Шәфи Алмас дөм караңгыда калды. Анда атласа да, монда сугылса да — бары тик таш стенага килеп төртелде...

## 23

Болытларга тигән Колама тау башлары...

Бала чакта Муса ул тау башына менәргә, кояшта җылынган үлән арасына чалкан ятып зәңгәр күккә, тау-тау күчмә ак болытларга әсәрләнеп карарга бик ярата торган иде. Күпме шигырьләр чыгарды ул шунда! Шигырьләр аның яшь күңеленнән тау елгасыдай шаулап агалар иде кебек. Аннары ул күзләрен йома, яңагына кунган, җиңелчә кытыклаган бөҗәкне кулы белән сыпырып төшерә, нәрсәгәдер елмая, битендә кояш җылысын тоя, аңа рәхәт булып китә. Янындагы чәчәкләрне исни, күңелендә шигырь ургыла башлый: «Чәчәкләр, үсегез, чәчәкләр...» Кинәт төртелеп кала, өлгереп җитмәгән, ахрысы, әле.

Бервакыт Колама тау башында Муса куркыныч кара болытлар да күрде. Алар бер-берсе белән бәрелешә, сугыша, ачулы ишеләләр иде кебек. Муса, гаҗәпләнеп, аларга озак карап торды. Болытлар инде таралышып беткән чагында, кинәт яшен яшьнәп китте. Менә бүген дә, Берлин өстендә, нәкъ ул чактагы кебек, чалт аяз күктә яшен яшьнәмәсенме! Бәлки бу яшен дә булмагандыр, тәрәзәдән карап алган Мусаның күзенә генә кинәт шулай чагылып киткәндер. Бәлки...

— Рәхим, яхшы тыңла,— диде Муса, карашын биек тә, тар да тәрәзәдән алып Саттарның каратут йөзенә текәлде.— Без сиңа бик зур, үтә җаваплы задание бирергә уйлыйбыз. Син шуңа ризамы?

Алар Муса Җәлилнең Шарлотенбург урамындагы бүлмәсендә сөйләшеп утыралар иде. Муса яшь шагыйрь Рәхим Саттарга нинди тәвәккәл адым атларга кирәк икәнен ахырынача аңлый, ләкин башка чара юк. Рәхим исә эшнең никадәр җитдилеген төшенеп җитми бугай.

— Ике куллап,— диде ул, уйлап та тормастан.

— Тукта, Рәхим, ашыкма. Йомыш дигәнебез бик хәтәр, бик...

— Солдат фәкать шундый заданиене үтәргә күнеккән, Муса абый. Мин тынлыйм, — диде Саттар, Мусаның күзләренә керердәй булып.

— Мин синнән бүтән җавап көтмәгән идем, Рәхим. Без уйлаштык, бу эшкә синнән дә кулай кеше юк кебек. Синең акылыңа, батырлыгыңа тулысынча ышанабыз...

Рәхим ялтырап торган күзләрен Мусадан алмады. Гаҗәп бер нәрсә, Казандагы әдәби кичәләрдә алар күп мәртәбәләр бергә шигырь укыдылар. Гадәттә Муса, Татарстан Язучылар союзы җитәкчесе буларак, шагыйрьләргә бер-бер артлы сүз бирә торган иде. Яшьләр, билгеле, дулкынлана, кабалана. Җитәкче исә сүз бирер алдыннан аларның күзләренә карый: әзерләрме? Әзер булмасалар, беразга кичектереп тора. Ләкин кайчан да булса яшь шагыйрьгә менә хәзергечә үтә җаваплы сүз бирермен, дулкынланганын ачык күрермен, әмма сабыр итеп торырга һичбер әмәл булмаячагын әйтермен дип уена да китермәгән иде Муса ул чакта.

— Чама белән август урталарында Едлинода «Идел-Урал» легионының икенче батальоны баш күтәрергә тиеш, — диде ул. — Аннары, шулай ук баш күтәргән күрше әрмән батальоны белән кушылып, поляк партизаннары ягына чыга, шуннан обстановкага карап, сугыша-сугыша, Польша җирен, Белоруссиянең оккупацияләнгән өлешен үтеп Кызыл Армиягә кушыла... Шул турыда безнең командованиегә алдан хәбәр итәргә кирәк. Аңлашыламы?

— Артыгы белән! Горький дөрес әйткән: без кыюларның шашкынлыгын мактап җырлыйбыз! — диде Рәхим, чиксез дәртләнеп.

— Бүлдермә, Рәхим. Тыңла. Әрмән батальоны белән дә, поляк партизаннары белән дә бәйләнеш бар. Едлинода тагын дүрт иптәш сиңа кушылыр: икесе шофер, берсе радист. Юлда ярдәмче булырлар. Карта, компас, корал һәм тиешле документларны Едлинода алырсыз. Рацияне бирердә табып булмады. Бәлки юлда табарсыз... Менә шул. Бу задание — хәрби сер. Тулы инструкция Едлинода бирелер. Аңлашыламы?

— Кем, кайда бирер?

— Ашыкма. Едлинога мин үзем дә барам. Иртәгә юлга чыгабыз. Мин, гадәттәгечә, культвзводка репетицияләр үткәрү сылтавы белән, ә син — «Идел-Урал» газетасының махсус хәбәрчесе сыйфатында. Юлда безгә бергә барырга, сөйләшергә ярамый. Мине ялгызымны җибәрмиләр, һәр вакыттагыча, кемне дә булса, әлбәттә, тагарлар. Бәлки Едлинода да турыдан-туры сөйләшергә мөмкинлек булмас. Хәбәрләшү — Кормаш аша. Син чемодан ал, чемоданга — «Идел-Урал» газеталарын, арага листовкалар салырсың. Аларны Алиш бирер. Листовкаларны Кормашкамы, Солтановкамы тапшырырсың.

Алар беравык сүзсез торды. Боерык инде бирелгән. Тагын нәрсә? Шәфи Алмасның доносы турында Муса Рәхим Саттарга әлегрәк сөйләгән иде инде, бүген моны кабат кузгатып тормады. Рәхимнең кандидатурасын сайлаганда бу момент, билгеле, бик нык искә алынды. Иптәшләре аны коткарып калу өчен кулларыннан килгәннең барысын эшләргә тырыштылар.

— Хәзер саубуллашабыз, Рәхим. Һәр җәһәттән сиңа уңыш телим. Кыюлык шәп нәрсә, әмма сак бул, күрәләтә утка кермә, акыл кирәк чакта акылны тыңла. Калганын,— Муса елмайды,— Казанда, Матбугат йортында бергә утырып сөйләшергә насыйп булсын.

Рәхим Саттар киткәч, Муса беркадәр вакыт уйланып торды. Шунда яшь шагыйрь Шамун Фидаи кылт итеп аның исенә төште. Муса белән Фидаи бер әдәби түгәрәктән — ягъни бер оядан чыккан бөркетләр иде. Яшьлекләрендә алар комсомол җырчылары дип дан алдылар. Егерменче елда комсомолның тарихи өченче съездына барганда, юлда дошман-

нар Шамун Фидаине ерткычларча үтерәләр. Бу хәл Мусаны тетрәтә. Ул Фидаига багышлап үзенең нәфрәт белән тулып ташыган дүрт юллык шигырен яза:

Ил ирке өчен сугышып, ил юлында
Җанкайларын фида иттеләр.
Ирек өчен көрәш дулкынында
Фидаилар корбан киттеләр.

Тукта, ни өчен Фидаи һәм бу беркайда да басылмаган дүрт юллык шигырь кинәттән генә Мусаның исенә төште әле? Аның алдан сизенә белү хасияте бар иде. Әллә бу юлы да шундый фаҗига булачакмы? Яшь шагыйрь Рәхим Саттар да, Фидаи кебек, ирек юлында башын салырмы? Йөгереп барып туктатыргамы әллә? Юк, Рәхимне туктатып булмас, ул юлда булачак. Әнә ничек куанып кабул кылды бит бу хәтәр заданиене. Аннары Муса үзе дә бу бер минутлык йомшаклыгыннан оялды. Рәхим урынында әгәр ул үзе булса, хәтәр юлдан куркыр идеме? Һичкайчан!

Күптән инде, әле Орск шәһәрендә комсомолда эшләгәндә, бервакыт аны татар, башкорт, казакъ авылларына җибәрергә карар чыгаралар. Утырыш барганда коточкыч буран кузгала. Бу якларда ул бер башланса атна-ун көнсез туктамый. Командировканы кичектерергә булалар. Эш өчен янып торган Муса моның белән килешми, котырынган буранга карамастан, чаңгыга басып юлга чыга. Өяз комитетында Мусаның бу тәвәккәллеген белеп алгач, артыннан бүтән чаңгычыларны җибәрәләр. Алар берничә көннән соң гына Мусаны бер казакъ авылында эзләп табалар. Ул анда комсомол ячейкасы оештыра башлаган була инде...

Яшьлек еллары, яшьлек тәвәккәллеге. Подпольеда да Муса көн саен диярлек шундый киеренке көннәр кичерә иде. Тик чиксез борчылып иптәшләрендә шик уятырга гына аның хакы юк. Чөнки дуслары да шулай яшиләр бит.

Актык минутта үзе белән Едлинога Шәфи Алмасның барасын белгәч тә Муса тыштан үзгәрмәде, сабыр калды. Тик эченнән генә уйлап алды: «Рәхим турында бер-бер нәрсә сизделәрме икән әллә? Егетне кисәтергә кирәк булыр. Ә бәлки Шәфи Алмас культвзводтагы эшләрне үз күзе белән карарга тели торгандыр — «президент» бит!» Радиога язган теге мәкаләсен бөтенләй бирдермәделәр, Әхмәт Симай бөтен очкырлыгын куеп тырышса да, сәбәбен аныклый алмады. Үзе генә шундый нәтиҗә ясады: Шәфи Алмас үз уйларын артык туры әйткән, хуҗаларының рөхсәтен сорамаган, «президент», имеш! Бу гитлерчыларга ошап бетмәгән булса кирәк. Алар аның борынына чиерткәннәр.

Бөтенләй икенче бер чыганактан Әхмәт тагын бер хәбәр ишетте: «Татар комитеты» Яушевка биреп җибәргән «ышанычлы» егерме биш кешенең берсе заводның зур гына цехын яндырган. Пожарный команда берни сизми калган, алар үз бүлмәләрендә әллә карта уйнап утырган, әллә йоклап ятканнар, ишекләр өстән бикле булган. Яушев Шәфи Алмасны да нәрсәдәдер гаепләмәкче була ди.

Әхмәт шул көннәрдә Шәфи Алмасны үзе күргән булган. Йөзе кар болыты кебек кап-кара. Әхмәт бернәрсә дә белмәгәнгә салынып, кәефен сорагач, Шәфи сүгенгән генә: «Син иманлы булган саен үз агай-энең сине иблис-шайтан итәргә маташа», дигән.

— Президент абзаң беренче бүләкләрне җыя — куллары куырыла, ахрысы, — диде Әхмәт Симай Мусага һәм юк сакалын сыпырды.

Моны ишетеп Муса бик шатланды. Иптәшләр тик ятмый, яшерен оешманың заданиеләрен бик төгәл үтиләр. Шулай куанып ул юлга чыкты.

Юлда Шәфи Алмас гомумән аз сөйләшә иде, бу юлы исә авызын бөтенләй диярлек ачмады. Тик немец аракысы чөмерүен генә белде.

Йөзе чөгендер сыман кызыл-көрән төскә керде. Ул йокымсыраган урман мәчесенә охшый: болай төрле тавышларга да әллә ни игътибар итми кебек, әмма «тычкан» шытырдаса, ялт итеп күзләрен ача, алар рәхимсез яшькелт ут шикелле ялтырап китәләр.

Тарихның шаярулары кайчак акылга сыймаслык гаҗәп була. Менә бу юлы да ул ике Оренбург кешесен бер вагонда, бер купеда герман җире буйлап алып бара, тәгәрмәчләр поляк юлларында тәгәри. Ә бу кешеләрнең уйлары һаман капма-каршы. Кем белә, бәлки винтовкасының приклады җиргә тия язган бәләкәй Муса революция елларында артын-алдын күрмичә табан ялтыраткан нәкъ менә шушы буржуйны дала буйлап куа баргандыр. Унтугызынчы елда «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыганда Муса комсомолга керә, ә егерменче-егерме беренче елларда Оренбург тирәсендәге авылларда кулак бунтлары күтәрелгәч, Муса аларга каршы ирекле коммунарлар отрядларында көрәшеп йөри. Колама тау итәгендә сәнәкчеләр кулына эләгә яза, тик яшьлек зирәклеге һәм тәвәккәллек кенә коткарып кала аны. Абыйсы Ибраһимнар отрядына килеп кушыла.

— Нигә килдең? — дип сорый абыйсы.

— Син монда коммунар булып сугышып йөр дә, ә мин бандалар килеп үтергәнне өйдә көтеп ятыйммы? — дип җавап кайтара Муса үсзүләнеп.

Эх, нинди дәртле чаклар бар иде! Ә хәзер рольләр алмашынган. Алар куеп йөргән балалар спектакльләрендә дә мондый хәтәр борылмалар булмый торган иде бугай. Урман мәчесенә охшаган ата буржуй, тырнагына эләккән кош белән уйнаган сыман, Мусаның үзе белән дә уйный шикелле — бугазын чәйнәр алдыннан уйный. Белә, кошның канаты сынган, теге вакыттагы кебек аңа ярдәмгә коммунарлар отряды да килеп җитә алмый. Шәфи Алмасның күзләрендә яшькелт ут: «Бәйрәм ашы — кара каршы, онытмадыңмы, егетем?!» — дия кебек.

Тәгәрмәчләрнең тигез тавышы тора-бара Шәфи Алмасны йокымсырата башлады. Ул сискәнеп күзләрен ача, «Муса мондамы?» дип карап ала, аннары күзләр тагын йомыла.

Төнлә дә рәтләп йокламаган Мусаның исә керфекләренә йокы эленми. Аның башы авыр уйлардан иелгән. Нәрсә соң ул башта? Бәлки Шәфи Алмасның ник тагылуы турында уйлый торгандыр. Башка чакларда Шәфи Алмас күбрәк поляк самогоны белән әвәрә була иде, чөнки самогон аңа әллә никадәр табыш китерә, ул һәр җәһәттән үтемле товар. Бу юлы ничек? Бәлки икенче вагонда баручы Рәхим Саттар турында уйлый торгандыр?.. Бер кулы белән донос, икенче кулы белән командировка кәгазе язарга Шәфи Алмас юләрме әллә. Кеше уйларын белү ансат түгел шул, бигрәк тә гомер буе алдарга, чын йөзен яшерергә күнеккән бәндәнең уен. Бәлки үзе монда булмаса да, Шәфинең фикерләрен Солтан Гарип биләгәндер. Бу Сәрхуш белән алар рухи кардәш, сүзләре туры килә, тик моны башкаларга белдерергә теләмиләр.

Соңгы вакытта Солтан Гарип тагын юкка чыкты. Кая китте? Легионга юл алмадымы? Муса ул явызның эзгә басып йөргәнен сизенә иде. Әхмәт Симайга, Сәрхушның кая киткәнен белергә тырыш, дип махсус әйтте. Әхмәт бөтен өчкырлыгын эшкә җигеп тырышса да, бернәрсә белә алмады. Бу хәл Мусаны шактый борчыды. Ул барысын ныклап уйларга тырышты, әмма аның уйлары эзлекле акмады, каршылыклы булды, күз алдына әле Рәхим Саттар, әле Солтан Гарип, әле Шәфи Алмас килде. Монда тагын Муса үзе дә бар иде, әмма ул ничектер икенче планга кала килде. Кайчакта Абдулла Алиш, Рәхим Саттар, Әхмәт Симай күренеп китә. Күр, Казанда гына түгел, Берлинда да бөтен бер Татарстан Язучылар союзы бүлеге тупланган диярлек. Тагын Гайнан Кормашны да кушарга кирәк. Димәк, алар үзләре өчен дә, Татарстанның бөтен язучылары өчен дә эшлиләр. Начар эшләсәләр — иптәшләре

аларны гафу итмәс. Муса үзләренә тарих тарафыннан зур җаваплылык йөкләнгәнен тагын бер тапкыр тирәнтен хис итте.

Язучылар — алдынгы идеология отрядларының берсе. Дошман ул отрядны һәр вакыт эчтән йомшартырга маташып килде. Туган илдә дә черек бәндәләр аңа сырышып карады, ләкин анда аларга юл бикле иде, ә монда шуларның берсе — нииндидер Ишбулмас, Шәфи Алмас канаты астында, аның нәшриятында үзенең мөнәҗәтләрен аерым китап итеп бастырып чыгарган, Муса ул китапчыкны кулына тотып караган иде. Сәдакага биргән шомарып беткән тиен кебек кызганыч, төссез, мәгънәсез китап. Илен алмаштырган, дошман багында сайраган сатлык җан күңеленнән нинди юньле шигырь чыксын ди. Аннан бары тик мәет исе генә килә. Муса ул китапны шунда ук җирәнеп кулыннан ташлады.

Хәзер исенә төшкәч тә ул мескен шагыйрь кисәге аңарда ачы җирәнү хисеннән башка бер тойгы уятмады. Ул, Ишбулмасны тизрәк оныторга теләп, вагон тәрәзәсеннән тышка карады: анда да җанга якын бер нәрсә юк иде. Муса күзләрен йомды, үзе белән бер поездда баручы яшь патриот шагыйрь Рәхим Саттар турында уйлый башлады. Рәхим хәтәр давылларга каршы чыгып китәргә җыена. Муса, билгеле, аның сәфәре җиңел булуын тели. Ләкин әсирлектә үзенең җәяү үткән канлы юлы, шул юлда үлеп калган асыл ирләр күз алдына килеп киткәч, ул көрсенүен чак тыеп кала. Нигәдер, аеруча ачык булып үзе белән бергә атлаган, аннары авып калган Лёнинград эшчесе исенә төшә. Ул гүя әйтә: «Мин егылдым, бу була торган хәл, ә син исән, син бирешмә, туган, безнең өчен дә тырыш. Исән булсак, нәрсә эшләячәгебез сиңа билгеле бит».

Ниһаять, Едлинога килеп җиткәч, иптәшләре арасында Муса беркадәр тынычланды. Шәфи Алмас шунда ук легион командиры янына китеп барды. Алар анда бер сәгать чамасы сөйләшеп утырдылар. Аннары командир машинасына утырып, каядыр чыгып киттеләр.

— Алмас алдым-бирдемгә китте — иң зур түрә белән! — диде Гайнан Кормаш Муса янына килеп.

— Юлда муеннары сынса, тагы да әйбәтрәк булыр иде, — диде Муса. — Ләкин шулаймы икән? — Бераз эндәшми торгач, Кормашка Рәхим Саттарның монда икәнен әйтте. — Ул синең арысланнарыңны үзе белән алып китәр. Алар әзерме?

— Күптән әзер.

— Яхшы. — Гайнанның күзләрендә сорау галәмәте күреп өстәде: — Кичен сөйләшербез, барысын аңлатырмын. Аннары Рәхимне күрерсең. Иртәгә иртән алар юлга чыга. Кирәк-яракларның барысы да бармы?

— Бар.

— Кәгазьләр?

— Фамилияләрен генә куясы калды.

— Аларын минем белән сөйләшкәч куярсыз. Рәхимдә сезгә күчтәнәчләр бар. Солтанов барып алсын. Ә син албастының ник килгәнен белергә тырыш. Бу бик мөһим.

— Эшләрмен.

Муса музыкаль капелла белән мәш килде, репетицияләрен карады, якшәмбе көнгә легионерларга концерт оештырды. Шунда ул яннарында бөтерелүче ач яңаклы бер легионерга игътибар итте. Бу кешене ул монарчы күргәне юк иде. Кирәксезгә кабалана, бер дә юкка ыгы-зыгы килә кебек. Әйтерсең бик кирәкле эш башкара.

— Кем? — дип сорады Муса Гайнан Кормаштан, аны бер үзен туры китереп һәм күзләре белән ач яңаклы, тар йөзле легионерга күрсәтте.

— Яңа легионер, пропагандист.

— Фамилиясе?
— Мәхмүт Ямалетдинов,— һәм көлемсери төшеп өстәде: — легионерлар Мәхмү диләр.
— Мәхмү?!
Кешеләрнең исемнәрен бозу яхшы нәрсә түгел, моны бигрәк тә балаларга әйтәләр. Ләкин монда балалар юк бит. Ә зурлар шаярып исем бозмый инде. Кайчагында моның өчен бик җитди сәбәпләре булса гына...
Муса бармагын иреннәренә куйды, бу аның иптәшләрен кисәтүе иде. Ул, әлбәттә, берни белми, бу бәндәнең Солтан Гарип белән бергә абвер агенты икәнен башына китерми. Бары тик, саклыкка өндәп, иптәшләрен генә кисәтте.
Кич булды. Муса, Гайнан Кормашны чакырып, Рәхим Саттарларның эше турында сөйләште. Мәхмү бу хакта бернәрсә дә белмиме дип кайта-кайта сорашты — күңеле тынычланмады, ахрысы. Гайнан йомышларны үтәргә җыенгач та аны туктатты.
— Сабыр, туган,— диде уйланып кына. Аның күз алдыннан ач яңаклы Мәхмү китмәде. Нигә аның исемен шулай бозганнар: Мәхмү!
Мондый чакта Муса үз күңеленә каршы бара алмый иде.
— Өстәмә шик уятмас өчен мин аларны кабат күрә алмам. Минем һәр адымны күзәтәләр булса кирәк. Син дә сак бул. Минем исемемнән Рәхимнәрнең кулын кыс, уңыш телә. Ышанабыз, диген. — Тагын бераз уйланып торгач сорады:— Мин бая әйткәннәрне үти алдыңмы? Нигәдер әйтмәдең.
— Тулысынча үти алмадым әле, Муса абый, — диде Гайнан туп-туры итеп. — Түрә белән албастының нәрсә турында сөйләшкәнен белеп булмады. Ә барулары поляк спекулянтларына булган. Шофер минем таныш, ул әйтте. Анда тагын бер мөһим нәрсә ишетеп кайткан: Познаньда подпольщиклар бер заводны яндырганнар ди. Икенче заводтанмы, икенче цехтанмы — яхшы гына белми — татар егетләре полякларга пулемет частьлары алып чыгарга булышканнар. Соңыннан бер сатлык җан шунда татар белән полякны гестапога тоттырган. Албасты хәзер түрә өендә лаякыл исерек ята.
— Рәхмәт, — диде Муса, Шәфинең үзасыл табигатенә турылыклы булуы турында уйлап.— Моннан соң да белгәләп тор. Безнең тирәдә козгыннар еш ишелә. Сак булыгыз.
Заданиене тулы үти алмавы өчен Мусадан кимендә шелтә көткән Гайнан, аның рәхмәт сүзен ишеткәч, аптырый төшеп калды. Шулай да куркынычның зурлыгын төшенде. Ләкин моны бары тик Рәхим группасы өчен борчылу дип кенә уйлады.
— Сез артык хафаланмагыз, Муса абый, без аңлыйбыз, барысын җиренә җиткереп эшләргә тырышабыз.
Төнлә Муса айсберг мәсьәләләре белән шөгыльләнде, күрәсе кешеләрен күрде, кирәкле күрсәтмәләрен бирде. Ул иптәшләренең эшеннән ярыйсы канәгать иде. Алар мәсьәләнең җитдилеген аңлыйлар. Барысын хәрбиләрчә төгәл үтәргә тырышалар, җиңел караш, ваемсызлык юк.
Икенче көнне, инде бераз айный башлаган Шәфи Алмасны күреп, Муса:
— Кайтмыйбызмы, Шәфи әфәнде,— диде.— Монда хәзергә минем эшләрем бетте. Ә Берлинда эш өелеп ята.
— Үзем дә шуны әйтергә дип чыккан идем, — диде Шәфи карлыккан тавыш белән. — һай, башым... Тик, чиркәүгә барып та попны күрмәгән кафер шикелле, артистларыгызны күрми китү килешмәс. Бер ярты сәгатьтән мин килермен, артистларыгызны җыегыз, — диде һәм икенче ишектән чыккан немец офицеры янына юргалап китте. Аннары, култыклашып,ниндидер бүтән ишеккә кереп югалдылар. «Президентның» кыланышына карап Мусаның төкерәсе килде.

Шул ук ишектән, кызарып-бүртенеп, Ямалетдинов атылып чыкты. Күрәсең, әле яңарак кына аны бик каты пешергәннәр, кулындагы кәгазьләре идәнгә төшеп чәчелеп китте. Ул, куркып, як-ягына карана-карана, калтыранган куллары белән аларны җыйды да ялт итеп коридордан чыгып китте. Үзенә карап торган Мусаны күрмәде дә бугай.

Муса «артистлар» янына кайтты, озакламый Шәфинең киләсен әйтте. Гайнан, Мусаны читкә чакырып алып, Рәхимнәрнең исән-сау килеш Едлинодан чыгып киткәннәрен пышылдады. Лагерь тыныч.

— Яхшы булган, — диде Муса. — Шеф алдында «артистлар» кулларында «Идел-Урал» газетасын тотсыннар. Шәфи алай-болай сораша калса, газета турында бары тик уңай җавап кына бирсеннәр. Сорашмаса да, кулыгызда үз газетасын күргәч, күңеле булыр. Күрү бит кайчагында сүзгә караганда күбрәкне әйтә.

Шәфи Алмас «артистларга» бер сәгать чамасы үгет-нәсихәт укыды, аларны бөек фюрер эше өчен бөтен көчләрен, талантларын кызганмаска чакырды. Репетицияләрендә булды. Күз чите белән «артистларның» кулларындагы газетага карап-карап алды.

Аннары Шәфи Алмас белән Муса Берлинга кайтып киттеләр.

## 24

Ниһаять, «Идел-Урал» батальоннарында восстание күтәрү үзенең төгәлләнү чорына керде. Бу аерата җаваплы, хәтәр эшкә ахырынача җитәкчелек итүне дә яшерен оешма Муса Җәлилгә тапшырды. «Идел-Урал» легионындагы хәлләрне бүтәннәргә караганда яхшырак белә, андагы кешеләр, командирлар, восстаниенең яшерен пружиналары белән таныш, әрмән батальоны һәм поляк партизаннары белән бергәләп эш итү планнары турында мәгълүмат бар. Ул бит лагерьларга берничә тапкыр барып кайтты, «хәрби совет» киңәшмәләре үткәрде. Шунда восстание планы каралды. Билгеле, боларны шартлы рәвештә генә «киңәшмә» дип атарга мөмкин иде, чөнки анда бик аз кеше катнашты. Ләкин көне-сәгате җиткәч, әлеге айсбергның күзгә күренмәгән өлеше дә өскә калыкмыйча калмас. Әмма хәзергә әле боларны бары тик күңел күзе генә күрә.

Берлинда Мусаның нинди юлга әзерләнүен бары ике кеше — Абдулла Алиш белән Әхмәт Симай гына белә иде. Алар Мусага иң яхшы теләктә иделәр, кулларыннан килгән барлык чаралар белән аңа булыштылар. Аларны бер нәрсә аеруча шатландырды: яшерен оешма шагыйрьнең үз гомерен саклап калу турында да кайгырта иде. Восстаниедән соң гитлерчылар Җәлилне барыбер тыныч калдырмаячаклар, бу көн кебек ачык. Шулай булгач, оешма бик авыр хәлдә калса да, шагыйрьнең баш күтәрүчеләр белән китүе хәерлерәк.

Муса Берлиндагы эшләрен дә түгәрәкләргә кирәште, күрәсе кешеләрен күрде, сөйләшәсе кешеләр белән сөйләште. Хәзер тизрәк легионга китәргә кирәк. Командировкасы мөмкин кадәр озынрак сроклы булырга тиеш. Моның өчен бик ышанычлы сәбәп табарга кирәк, ул бер яктан да шик уятырлык булмасын. Югыйсә, гитлерчыларның, бер-бер нәрсә сизеп алсалар, Мусаны бөтенләй легионга җибәрмәүләре мөмкин. Ул чагында бөтен эш тоткарланачак, хәтта җимерелүе мөмкин. Ә «Идел-Урал» легионында обстановка шактый катлаулы. Рәхим Саттарның юкка чыгуы — аңа бер айдан артык вакыт үткән иде инде — гестапочыларны аякка бастырырга тиеш, бигрәк тә кулларында Шәфи Алмас кебек турылыклы агентларының доносы булгач. Соңгы вакытларда тагын бер нәрсә мәгълүм булды: гитлерчылар «Идел-Урал»ның әзер батальонын, взводларга бүлгәләп, төрлесен төрле җиргә җибәрергә приказ әзерлиләр икән. Димәк, легионны түгел, батальонны да бөтен килеш саклау-

ның гаять хәтәр икәнен сизенәләр. Алар үзләренең бу мәкерле планнарын бик тиз тормышка ашырып куюлары бар. Мондый чакта алар йокламый. Аннары әсирләр арасында әледән-әле күренә торган листовкаларның берәр данәсе булса да алар кулына эләкми калмас. Соңгы вакытларда шымчыларның күбәюе дә шуның белән бәйледер, әлбәттә. Ни әйтсәң дә, яшерен оешма үзенең эшен бик берьяклы алып барган, оешманың иң мөһим бүлеге — куркынычсызлык бүлеге төзелмәгән, барысын бергә бер үк кешеләр башкарган. Хәтта тормыш үзе кисәтә башлагач та тиешенчә игътибар ителмәгән. «Очкырны куркынычсызлык бүлеге башлыгы итәсе калган», дип ачынып уйлады Муса. Менә кайда сизелә икән ул тәҗрибә җитешмәү! Хәзер инде боларны төзәтергә дә вакыт калмаган.

Ихтимал, бүтән кимчелекләр дә ачылыр әле. Ләкин ни булса да туарылырга ярамый, югыйсә, бөтенесен харап итәргә мөмкин. Нишлисең, кайда егыласыңны белсәң, салам җәеп куяр идең, ди халык.

Мусаның күптән яза башлап та тәмамланмаган «Шүрәле» исемле либреттосы бар иде. Шуны тизрәк тәмамлап, постановкасы өчен Шәрык министрлыгыннан рөхсәт алырга кирәк. Вакыт аз калган калуын, тырышканда... Бу Радомга бару өчен дә шәп сылтау булачак.

Муса шуны бөтен көчен биреп, бик тырышып төннәр йокламыйча язган чакта яңа хәтәр хәбәр алынды. Моны аңа поляк дуслары җиткерде: Рәхим Саттар группасы уңышсызлыкка очраган, алар немецлар тырнагына эләккән. Хәзер исәннәрме-юкмы — билгесез.

Шушы аерата кискен бер вакытта Муса аптырап калмады, күңелендәге батыр көрәшче сыйфатлары өстенлек алды. Рәхим Саттар һәм яшерен оешманың язмышы өчен тирән борчылуларын эчкә йотты, һич кичекмәстән дублер группа турында уйлый башлады. Әле Рәхимнәр киткәч үк, юлда ул-бу була калса дип, шул ук максат белән икенче группа төзегәннәр иде. Җитәкчесе итеп Седльце лагереннан яшерен оешма члены Ян Габдуллин билгеләнде. Ул утны-суны кичкән кыю егет, Совет Армиясе офицеры, тәвәккәл. Муса аңа Рәхимгә ышанган кебек ышана — үлсә үләр, ләкин хәрби серне йөрәктә саклар. Гайнан Кормаш та аның бу фикеренә тулысынча кушылды.

Берничә көннән Муса үзе дә лагерьда иде инде. Аның йөзе шат, кәефе гүя әйбәт, беркем дә аның үтә киеренке уйлар кичергәнен башына китермәс. Хәтта шагыйрьнең кыяфәте күпне күргән Гайнан Кормашны да башта аптыратты. Седльцега концерт куярга килгәннәр иде.

Муса бик эшчән кыяфәттә лагерь начальнигы янында булды, музыкаль капелланың якын атнадагы эше турында сөйләде. «Шүрәле»не әзерли башлауларын әйтте, министрлыкның рөхсәтен генә көтәләр. Лагерь командованиесе музыкантларның эшеннән гомумән канәгать икән. Муса алардан тагын чәрсәләр эшләргә кирәк дип киңәш тә сораган булды.

Бирелә барысы тыныч иде. Рәхимнәр турында читләтеп тә сорашмадылар. Шуннан соң гына Муса капеллага юнәлде, Гайнанга Рәхимнәр турындагы хәвефле хәбәрне әйтте, ашыгыч рәвештә «Ян операциясен» әзерли башларга кушты. Аннары сорап куйды: «Мәхмү үзен ничек тота?»

— Бутала шунда. Без аны күзәтәбез. Андый-мондый начар ягы сизелми шикелле.

— Бүген син мине Ян белән очраштыр. Безнең сөйләшкәнне һичкем күрмәсен һәм белмәсен.

— Эшләрмен.

Бер сәгать, сәгать ярым үттеме икән, Муса инде Ян Габдуллин белән кара-каршы утыра иде. Янның йөзе ябык, күзләре кыю карый, берниндн каушау юк. Ул Мусаның сүзләрен игътибар белән тыңлады да:

— Мин әзер, — диде.

— Иртән мин кайтып китәм. Ике-өч көннән син дә юлга чыгарсың. Миңа сүзләрең бармы? Соңгы күрсәтмәләрне Кормаш әйтер. Я, уңыш телим.

Икенче көнне Муса Берлинда иде инде. Шәрык министрлыгында булды, күрәсе кешеләрен күрде, аннары, вакытын әрәм итмичә, бүленгән «Шүрәле»сен язарга утырды. Көннәр бик санаулы калып бара, шулай да тырышырга кирәк.

Атна-ун көннән Гайнан Кормаштан хәбәр килде: бөркет очкан, оясында тыныч. Муса җиңел сулап куйды. Тик гамьсезлеккә бирелергә ярамый иде.

Ниһаять, «Шүрәле» тәмамланды. Министрлыкта аны нигездә кабул иттеләр, постановкасына рөхсәтне сәхнәдә карагач бирербез диделәр. Бу өстәмә кыенлыклар тудыра иде. Муса постановкага күз буяр өчен хәзерләнгән булып, төп игътибарны восстание оештыруга бирергә булган иде, болай булгач...

Үтә ашыгыч эшләрдән тагын яшерен оешма членнарына хат язасы калды.

Муса чиксез борчылган иде. Соңгы вакыттагы чамасыз киеренкелек үзен сиздерә башлады. Ул начар йоклады, тамагына аш үтмәде, ябыкты. Әмма хатта бары тик корыч ныклык, какшамас ышаныч кына булырга тиеш.

«Иптәшләр!

Легион һәм лагерьлар арасында ныклы элемтә булдырылды... Партизаннар белән хәбәрләштек. Эшче лагерьларда һәм легионерлар арасында күтәренке боевой рух. Легионерлар фронтка җибәрелә икән, үзебезнекеләр ягына чыгып, немецның коралын аның үзенә каршы төбәячәкләр.

Милли комитетта безнең оешманың барлыгын сизделәр, бөтен җирдә иснәнеп йөриләр. Шуның өчен **САК БУЛЫРГА, ОСТА ЭШ ИТӘРГӘ...»**

Соңгы сүзләр астына Муса ике тапкыр сызды. Аннары тагын язып китте, беткәнче башын күтәрмәде.

Берничә көннән Муса, зур чемоданын алып, якын дуслары белән саубуллашып, министрлык вәкиле белән юлга чыкты. Радомга маҗараларсыз, һичбер хәвеф-хәтәргә очрамыйча барып җиттеләр. Дуслары арасында Мусаның күңеле күтәрелеп китте. Белмәгән кешеләргә бу беркадәр сәеррәк тоелды, ник шул хәтле тырыша Муса, репетицияләрне бүген үткәрмәсә, иртәгә соң буламы әллә, монда бит көн үтүе кыйммәт, ә концерты... Әмма эшнең асылын белгән кешеләр — алар бик аз иде — аңа кулларыннан килгәнчә булышырга, ярдәм итәргә тырышалар.

Восстаниегә соңгы әзерлек эшләре «Шүрәле»гә репетицияләр белән бергә алып барылды. Репетицияләр көн саен булды. Алар уенча, «Шүрәле» бер үк вакытта «опера» һәм «балет» булырга тиеш. Аның үз көйләре шактый, Сәйдәш көйләрен, халык моңнарын нык файдаландылар. Әле «Салкын чишмә», «Печән өсте», «Дисәнә», «Дүдәк» көйләре яңгырады, әле үзләре чыгарган «Таң», «Кайту» маршлары сызылып китте. Барысы күтәренке рухта иде.

Репетицияләрне якындагы урманда, эчкәрәк кереп ясый башладылар. Немецларга «Шүрәле» өчен урман кирәк, урмансыз булмый, дип аңлаттылар. Алар моңа ышандымы? Бу бик сай яшерелгән хәйлә түгел идеме? Һәрхәлдә, легион командованиесе каршы да килмәде, үзенең күзәтчеләрен «артистларга» тагылып йөрүдән дә туктатмады, һич югында, бер унтер-офицер белән әлеге министрлык вәкиле аларга иярә торган иде.

Генеральный репетициягә кадәр әле берничә көн вакыт бар. Шул кыска вакытны Муса төп эш өчен минутына кадәр файдаланырга тырышты. Ул бик күп кешеләр белән сөйләште, аның янына боевой под-

разделениеләрдән вәкилләр килеп йөрде. Ул өч-дүрт кеше катнашы белән генә яшерен киңәшмәләр үткәрде. Бер ышанычлы кеше сакта торды, андый-мондый шикле кеше күренсә, ул шунда ук махсус сигнал бирергә, ә тыныч булса, әкрен генә «Күгәрчен» көен көйләргә тиеш:

Күк күгәрчен җиргә төшә
Бергәләп гөрләшергә...

Ерактан ук ишетелеп торган бу җыр Мусаны да бер кадәр тынычландыра иде, югыйсә аның күңеле бер дә урынында түгел: ул бит иптәшләре белән соңгы очрашуга бара! Барысы да әзерме? Иң кирәклесе оныталмаганмы?

Кинәт Муса туктап калды: аның алдында гаҗәеп матур чәчәкләр иде! Вакыты никадәр тар, эше никадәр тыгыз, ашыгыч булмасын, шагыйрь шагыйрь инде, ул матур чәчәкләр алдында бер генә секундка булса да туктамыйча түзмәде — матурлык кайда гына, нинди генә шартларда очрамасын, нечкә күңелне дулкынландырмыйча калмый бит ул. «Эһ» дигәнче бала чагы, Саелмыш болыннары, Колама тау итәкләре, Казан янындагы чәчәкле урманнар күз алдына килде. Ул чәчәкләрне иелеп өзеп алды да иснәде. Алардан бик нәфис хуш ис аңкый иде. Тагын аларда сүз белән әйтеп биреп булмый торган бер гүзәллек бар иде: әллә кайдан, бик ерактан, сагындырган ирек җиле исә иде кебек.

Муса, шул хуш исне тойган хәлдә, иптәшләре янына ашыкты. Дүрт легионер, юан агач кәүсәләренә сөялеп, аны көтәләр иде инде. Муса алар янына утырды да, бар киеренкелеген эчкә йотып, сөйли башлады:

— Партизаннар һәм әрмәннәр белән бәйләнеш кабат тикшерелде, иптәшләр. Тулы тәртип. Шулай итеп, спектакльгә хәзерлек тәгәлләнде дияргә ярый. Инде Гайнан, Сәйфелмөлек һәм Рушат әйтсеннәр: барлык тиешле урыннарга, участокларга кыю егетләр куелганмы, алар хәрәкәткә әзерме?

— Куелган, әзер, — диделәр барысы бертавыштан.

— Иблисләрен кемнәр чәнчелдерә — билгелеме?

— Билгеле, билгеле.

— Элемтәне кисүчеләр, сакчыларны алып ташлаучылар? Спектакль вакытында кемнең кайда булуы, кемнең кем артыннан чыгасы?

— Барысы генеральный планда каралганча.

Муса иптәшләренең күзләренә берәм-берәм карады. Берәү дә карашын яшермәде, һәммәсе туры, кыю карап торды, аларда тәвәккәллек үтә күренә иде, бердәм сулый.

— Иптәшләр, тагын бер тапкыр кисәтәм, — диде Муса бераз эндәшми торганнан соң, — барлык звенолар да сәгать механизмы кебек төгәл эшләгәндә генә постановканың уңышы тәэмин ителүе мөмкин. Һәркем үзенә йөкләтелгән бурычларны тагын бер тапкыр уеннан кичерсен. Генеральный репетициягә хәтле хәл ителмәгән бер генә вак-төяк тә калмасын. Кормаш, Сәйфелмөлеков, сезнең участоклар аеруча мөһим һәм җаваплы, моны исегездә тотыгыз. Сакчылар, иблисләр, элемтә — үзәктә. Спектакльнең «кендеге» шуларга тоташа. Рушат, син үзеннең төкерткечләреңне зур юлга алып чыгасың. Атларга солы бирелгәндер бит? Я, егетләр, андый-мондый үзгәрешләр юкмы?

— Юк, юк,— диде барысы өчен Кормаш, хәрбиләрчә кыска, төгәл итеп. — Минем соңгы сорау: боевой подразделениеләр ничек?

— Айсберг өчен борчылмаска мөмкин, анда хәзерлек бетте инде, — диде Муса тирән ышаныч белән. — Я, егетләр, спектакль башланырга команда булыр, барыгыз, минутына әзер булыгыз. Бутафория мәсьәләсе дә хәл ителгән. Күршедәге эшчеләр батальоны безнең спектакльгә кушылырга әзер — сигнал гына көтәләр...

Шулай итеп, «Шүрәлегә» соңгы репетициягә барысы да әзер иде. Урман эченнән хор башкаруында дәртле җыр яңгырады:

Безнең йөрәкләр утта яналар,
Утта яналар азатлык өчен,
Үлем — дошманга, ирек — дусларга,
Соңгы көрәшкә чыгабыз бүген![1]

## 25

Культвзводтан Берлинга бер кеше җибәрү турында Гайнан Кормаш Муса Җәлилдән күрсәтмә алган иде. Ул гадәти фашистик агитация материаллары белән бергә тагын кайбер нәрсәләр алып кайтырга тиеш.

— Бу кайбер нәрсәләр безгә «Шүрәле» өчен бик кирәк. Кара, егет вакытында кайтып җитсен, — диде Муса. — Күчтәнәчләрне Алиш бирер, алар әзер.

Бу җаваплы эшкә Кормаш батырлыгы, турылыклыгы күп мәртәбәләр сыналган, лагерьда әле хәзергә артык кирәге булмаган Габдулла Батталны билгеләде. Һичбер вакытта төшенкелеккә бирелми торган, теләсә нинди кыенлыктан исән-имин чыга белгән, мәзәк, үткен сүз яратучы Габдулла Баттал яшерен оешманың бу йомышын да җиренә җиткереп үтәр шикелле тоелды. Берлинга аның беренче баруы түгел иде. Бер үк вакытта мондый хәтәр эшне үтәүченең башка сыйфатлары да искә алынырга тиеш булган. Әмма бу ахырынача уйлап эшләнмәгән. Әлеге дә баягы, тагын шул тәҗрибә җитенкерәмәү бәласе. Шәхси батырлык, илгә, яшерен эшкә турылыклы булу подпольщикларның һәрберсендә җитәрлек. Кирәк чакта алар утка да, суга да керә, хәтта бер сүзсез үлә беләләр. Әмма яшерен оешма кешеләреннән, аерым заданиеләрне үтәгәндә, күбрәк нәрсә сорала икән!

Габдулла Баттал туры, хәйлә-мазар белми торган ачык холыклы егет иде. Кешегә ул бик тиз ышана, үзе һичкайчан, һичкемне алдамагач, башкалар да нәкъ шундый дип уйлый. Явыз дошманнар итеп ул бары тик фашистларны гына саный, алар белән сөйләшә дә белә иде. Аның киң холкындагы шул якларны иптәшләре ахыргача белеп бетермәделәрме, тиешенчә исәпкә алмадылармы, Кормаш аңа бу турыда ләммим димичә, Берлинда Абдулла Алишны күрергә, аңа «Шүрәле»гә, ягъни восстаниегә хәзерлекнең уңышлы баруы турында сөйләргә, аңардан берничә мең русча, татарча, полякча листовкалар алырга да, тизрәк легионга әйләнеп кайтырга кушты.

Соңгы минутта батальон командиры Габдулла Батталга ярдәмгә легионер Мәхмүт Ямалетдиновны билгеләгән. Батальон командиры белән, билгеле, сүзгә кереп булмый, аның кушканын карусыз үтиләр. Моңа да тиешле игътибар ителмәгән, ахры. Габдулла Баттал, икәү булгач, юл кыскара дип, хәтта шатланган. Гайнан Кормаш аны инде кабат күрә алмаган, аның белән Мәхмүт Ямалетдиновның да баруын белгәч, иптәшен, «Мәхмүдән сак бул» дип, махсус кисәтергә өлгермәгән.

Вагонда Ямалетдинов белән Баттал сөйләшеп китәләр. Хәйлә-мазарсыз кешегә гади генә гәпләшү кебек, ә чынында Мәхмү еракка селтәнеп кармак сала. Ул үзенең Үзбәкстаннан икәнен әйтә, элек комсомолец булуын, үзешчән түгәрәкләргә катнашуын сөйли.

— Эх, бар иде рәхәт көннәр, Абдилдә абый. Хәзер бер кычкырып җырларга тартыныпсың... — Ул Батталга күз читләре белән карап алды: бер җөмләдә ике тапкыр казакъча сүз! Һәм, түзмәде, сорап куйды: — Абдилдә... Габдулла абый, — тиз генә төзәтте үзенең хатасын, — сезнең Урта Азиядә булганыгыз бармы?

---

[1] Романдагы җырларның күбесен Ташкенттан Исхак Зәбиров җибәрде. Ул җәлилче Гарәф Фәхретдиновның архивыннан күчереп алган. Гарәф Фәхретдиновның әйтүенә караганда, бу җырларның күбесенең авторы Муса Җәлил икән. (Г. Ә.)

Баттал Татарстан егете, Урта Азия халыкларының тел үзенчәлекләрен белеп бетерми. Ул Фоат Сәйфелмөлеков кына бер тапкыр Мәхмүгә: «Үзең мин Үзбәкстаннан дигән буласың, үзең казакъчалап җибәрәсең», — дигән булган.

— Юк, Биләр турында җыр ишеткәнең бармы? Без менә шул җырларда җырланган гүзәл якныкы булабыз инде, — диде Баттал горурланып.

— Габдулла абый, — диде Ямалетдинов җиңел сулап, — вакыты белән миңа Биләр җырларын бер өйрәтерсең әле. Туган илләр искә төшкәндә, бер әйттерәсе килә.

Мәхмүт Габдуллага минут саен күбрәк ошый барды.

— Тиздән, туган, бичуралар кая кирәргә тишек тапмас. Без дә үзебезнең Казаныбызга кайтырбыз. Менә кайда ул җырларның асыллары, җаның күпме тели, шул хәтле тыңла, — диде.

— Ул изге сәгатьне кул кушырып көтеп тору килешмәстер, Абдилдә абый, — диде Мәхмү һәм тагын төртелеп калды. Ләкин үзен бик тиз кулга алды. — Көтеп торулары да туйдырды. Ничәнче ел инде интегәбез. Меңләгән әсирләрне күрәшкә күтәрүче яшерен оешма юкмыни? Безгә элек гел әйтәләр иде: фирка барысын да булдыра дип.

«Кара, бу Мәхмү шактый кыю сөйләшә бит, курыкмый да. Мөгаен, чын комсомолец булгандыр», — дип уйлады Габдулла Баттал эченнән, әмма яшерен оешма, аның кешеләре турында юлдашына бер сүз әйтмәде.

— Мин, брат, үзем фиркасыз идем, андый зур нәрсәләр турында уйларга минем баш җитми. Аннары шунысы да бар: азрак уйласаң, баш азрак авырта.

Берлинда Ямалетдинов Габдулла Батталдан бер адым калмады, итәгенә тагылып йөргәндәй йөрде.

— Мондый галәмәт каланы мин, Габдулла абый, төштә дә күрмәдем. Кара урмандагы кебек икән. Күз ачып йомганчы адашырсың. Син, Абдилдә абый, зинһар дип әйтәм, мине үзеңнән калдырмапсың инде. Яхшылыгыңны үлгәнче онытмам.

— Солдат бул, солдат шыңшымый, — диде Баттал, шулай да Ямалетдиновны үзеннән калдырмады, аңа көчсезгә ярдәм итү ошый иде.

Алиш «Шүрәле»гә әзерлекнең уңышлы баруына эченнән бик шатланса да, тыштан берни сиздермәде. Берни булмаган кебек, «Идел-Урал» плакатларын ачып күрсәтеп бирде, арага шпагат белән бәйләнгән берничә пачка листовка салды. Батталга аларны күзләре белән генә күрсәтте. Баттал аңлаганлыгын белдереп баш какты.

— Ярар, егетләр, — диде Алиш кырыс кына, — юл кешеләрен тотмыйм, аннары үземнең дә эшем күп: газета чыгарабыз. Хушыгыз, исән-сау кайтыгыз.

— Абдулла абый, — диде Ямалетдинов Батталга, янадан поездга утыргач, — теге калын кашлы, көмеш тешле абый кем булды? Бик коры сүләште.

— Кәнфитләнеп тормас инде безнең белән. Ни өчен килгәнне белә ич. Үзең күрдең — безгә нинди плакатлар бирде. Аннары, брат, шунысы да бар: редакциягә простой кешене алмаслар. Ул без генә синең белән тегесен илтергә, монысын китерергә ярыйбыз. Мәхмүләр без.

Ямалетдинов турсайган булды. Байтак вакыт эндәшми барды. Хәтта күз төпләрен сөртеп алды.

— Үз иптәшләреңә үзең ышанмагач... Әйтерсең мин...

— Әйттем бит, солдат бул, шыңшыма. Юләр, күп белгән кешенең башы таз була, — диде Баттал көлеп. — Әгәр тегеләр килеп алай-болай тенти башласалар, менә бу пачкаларны сиздерми генә тәрәзәдән ат. Шуңа күрә капчыкның авызын бәйләмәдем, тәрәзәгә якын куйдым.

— Легионерлар өчен ич болар, ничек инде тәрәзәдән атарга? — диде Ямалетдинов.

— Их син, Мәхмү. Менә кара,— Баттал шпагат белән бәйләгән листовканың кире ягын ача төшеп күрсәтте. Аның беренче сүзе зур хәрефләр белән: **«ИПТӘШЛӘР!»** дип басылган иде. — Аңладыңмы?

— Абдиллә абый, җаным, без шундый әйберләр дә алып кайтабызмыни? — дип пышылдады Ямалетдинов. — Ай, нинди бәхеткә ирештем мин!

Радомга кайткач, Баттал листовкаларны Гайнан Кормашка бирде. Гайнан күзләре белән Ямалетдиновка күрсәтте.

— Ул хәзер үзебезнеке инде... Курыкма, — диде Габдулла.

Шулай итеп, Гайнан факт алдында калды. Билгеле, әгәр ул Ямалетдиновның кемлеген белсә, актыкка чарадан тартынып тормас иде. Әмма «үзебезнеке» булгач, ничек кул күтәрелсен. Шулай да полякча листовкаларны, җырчы Шәриф Әмировка биреп, ераграк яшерергә кушты. Татарча листовкаларның бер өлешен Ямалетдиновның үз матрацы эченә яшертте. «Ул-бу булса, үзе эләгә», дип уйлады Гайнан.

Ямалетдинов барактан беркая чыкмады. Төнлә Гайнан аны күзәтеп ятты. Бераз тынычлангач кына йоклап китте. Төн урталарында ул кинәттән уянды. Караса, Мәхмүтнең койкасы буш! Гайнан сикереп торам дигәндә генә ишектә ике кулы белән эчен тоткан Ямалетдинов үзе күренде. Гайнанның йокламавын күргәч, бер секунд эчендә үлек кебек агарды.

— Үләм, Гайнан абый, җаным! — диде ул еламсырап. — Эчем борып-борып кисә. Лазарет ачылганчы чыдый аламмы, юкмы?

Эч авырту әсирләр арасында гади бер күренеш, аңа ничек ышанмыйсың. Шулай авыр, газаплы төн үтте, ә иртә белән йомышчы солдат килеп музыкантлар взводын инструментларын алып ашханәгә барырга чакырды. Командир репетициягезне үзе карамак була, диде.

Ашханәгә якынлашу белән үк «артистлар» аның солдатлар белән уратып алынуына игътибар иттеләр. Ә ашханәдә музыкантларны разведка начальнигы каршы алуын күргәч, Гайнанның шиге калмады: провал! Ул күзләре белән Ямалетдиновны эзләде: «пропагандист» иң арткы рәттә калтыранып басып тора иде. Гайнан берьюлы төшенде, бу фашистлардан куркудан түгел, бу башкадан... Эх, ник төнлә бумады шул Мәхмү көчекне?!

Болар барысы Гайнанның башыннан яшен тизлеге белән узды һәм шундый ук тизлек белән карар да кабул итте ул: бар гаепне үз өстенә алырга, мөмкин булса, взводны коткарырга, Мусаны бутамаска. Хәзер ул ашханәдә күренми. Бәлки аңа тимәгәннәрдер, Ямалетдинов аны белми ич...

Габдулла Баттал да нәкъ шул турыда уйлана. Аның уйлары әле Гайнанныкы төсле кискен түгел иде: ул Ямалетдиновны баштан ахыргача гаепләүдән ерак тора. Әнә юлда нинди сүзләр сөйләде бит. Шуның өстенә комсомолец булган...

Баттал, күзләре белән Ямалетдиновны эзләп, күңелен күтәрергә теләде. Бер генә секундка аларның күзләре очрашты. Мәхмү шунда ук читкә борылды. Баттал аңа күпме карарга тырышмасын, Ямалетдинов башын күтәрмәде. Шунда Габдулланың күңелендә дә шик уянды, беренче тапкыр ул иптәшләре алдында үзенең гаебен таныды.

Разведка начальнигы, кәгазьгә карап, кулга алынган кешеләрнең фамилияләрен төртелә-төртелә кычкыра башлады. Иң элек Гайнан Кормашның фамилиясен әйтте. Аны шунда ук каядыр алып киттеләр.

Ул көнне кулга алынган легионерларның саны утызлап булып, алар арасында Ямалетдинов та бар иде.

Радомдагы «Идел-Урал» батальонында восстание кутәрү ундүртенче августка билгеләнгән булган, ә унынчы августта җәлилчеләрне кулга ала башлыйлар. Бу эш бер үк вакытта диярлек Берлинда, Радомда, Познань һәм башка җирләрдә үткәрелә. Димәк, восстание планы гестапога алдан билгеле булган. Кемнәр эшләгән бу кара хыянәтне? Мәхмүт Ямалетдиновмы? Ул күп нәрсәне белмәгән булса кирәк. Восстание планын абвер өстәленә Солтан Гарип китереп сала, ләкин ул да ялгызярым эш итмәгән, әлбәттә.

Иң элек Муса Җәлилне кулга алалар. Кайда, кайчан, ничек — моны якын иптәшләреннән берәү дә белми калган. Мусаны Варшавадамы, Радомдамы тотканнар, имеш, дип әйтәләр. Бәлки шулайдыр, бәлки...

Башта Мусаның якын иптәшләре үзләрен кеше ышанмастай нәрсәләргә ышандырып караганнар: бөтен музыкаль взводны хәбес итсәләр итсеннәр, әмма Муса иректә йөри торгандыр, ул бәлагә эләккән иптәшләренә ярдәм кулын сузарга мөмкинлек табар кебек. Хәлбуки, чынбарлык аяусыз, ул буш хыялларда йөзәргә күп вакыт бирми, Варшава төрмәсенә барып җиткү белән үк тоткын «артистларның» бу алсу хыяллары челпәрәмә килә. Алар менә нәрсә күрәләр: төрмә ишегалдында ике стражник инде бирегә алдан китерелгән Муса Җәлилне ерткычларча кыйнап торалар, тимер дагалы итекләре белән типкәлиләр иде... Шагыйрьнең йөзе кан эчендә...

Төрмәчеләр жаргонында бу — «профилактика» дип атала икән, яңа тоткынның язмышы фашист тырнагында шулай башланып китә. Мусаны төрмә ишегалдында — кеше күзе алдында кыйнап аның иптәшләренең дә ихтыярын берьюлы сындырырга уйлыйлар гитлерчылар. Гүя алдан әйтеп куялар: акыллы булмасагыз, барыгызны да шул язмыш көтә. Монда ике сүзнең буласы юк.

«Артистларны» һәркайсын бер кешелек камераларга ябалар. Бу камералар нәкъ таш табут кебек — кысан, караңгы, суларга һавасы җитми. Сорау алуга барганда кулларны артка каерып богаулыйлар, сорауларга кирәкле җавап бирмәсә, тоткынны икенче бүлмәгә алып чыгалар да, аяктан егып, төрмәчеләрнең берсе башына, икенчесе аякларына атланып утырып, резин шланглар белән алмаш-тилмәш дөмбәсли башлый. Һуштан язгач, башына салкын су коялар, айныгач, тагын сорау: яшерен оешманың максаты нәрсәдә, җитәкчеләре кемнәр, җинаятьчел листовкаларны кайда бастыра идегез, кемнәр аларны яза иде. Белмим, дигәч, тагын кыйныйлар. Һуштан язса, тагын салкын су сибәләр, аягына басып тора алмаса гына камерага илтеп ташлыйлар...

Төрмәчеләр бик яхшы белә: алар кулына эләккән тоткыннарның күбесенең теле тиз генә ачылмый. «Артистлар» исә тагын да ныграк булып чыкты. Шуңа күрә аларга «акылга утыртуның» тулы бер системасын куллана башладылар.

Шул газаплар эчендә күпме вакыт үткәндәр, әйтүе кыен, «артистлар» көн исәбен югалтты, караңгы камера эчләре тагын да караңгылана төште кебек — гүя кара төн башланды.

Ниһаять, аларның кайберләрен гомуми камераларга күчерә башладылар, ләкин, тел белмәгәч, барыбер, бередә дә алар үзләрен ялгыз хис итте. Аннары төрмәдә теләсә кемгә сер ачарга ярамый, гитлерчылар тоткыннар янына юри үз кешеләрен утырта. Монысын инде һәр тоткын белә иде.

Төрмәдә бары тик Мәхмүт Ямалетдинов кына күренмәде. Бергә кулга алдылар, бергә Варшавага китерделәр, аннары аның белән ни булгандыр — билгесез. Башка иптәшләрен Гайнан я сорау алуга барганда, я һава суларга чыгарылганда күргәли иде, ә Ямалетдинов күзгә чалынмады. «Ник мин сине теге төнне буып үтермәдем!» дип янә бер тапкыр

үкенде Кормаш. Гитлерчыларның аны башка легионерлар арасына да иснәнергә җибәрүләре мөмкин бит. Дөрес, сугышчан бишлекләр турында ул берни белми шикелле, шулай да... Ичмаса, ничек тә булса Мусага хәбәр итәсе иде. Иптәшләре дә Мәхмүтнең чын йөзен беләләрме икән?

Төрмәдә тагын Фәрит Солтанов белән Дим Алишев юк иде. Димне нигәдер бөтенләй кулга алмадылар, ә Фәритне иптәшләре бер скрипач белән икесен легионерларның ял йорты дип аталган Узидомга концертлар куярга җибәргәннәр иде. Узидом ял итәр өчен матур гына почмак, сихәтле диңгез һавасы, яшеллеге бар. Әмма Фәриткә моның ләззәтен татырга туры килмәде. Югыйсә, Кормаш әйтеп куйган иде: «Син, Фәрит, бераз гына ял итеп сәламәтлегеңне ныгыт. Булмады. Чираттагы концерт бетмәс борын ук бер гестапо офицеры килеп аңа: «Сине Муса Җәлил чакыра», диде. Шуннан аны алып та киттеләр. Фәритнең йөрәгенә ут төште, юл буе уйланды: «Ахрысы, эләктерделәр. Кайдадыр, нәрсәдер булган...» Ул яшерен оешмага биргән анты турында борчылды. Саклый алырмы? Юк, ни генә булса да антны бозмас, тап төшермәс...

Кайтышлый Фәрит Берлинга кагылырга, Алишны күреп, сөйләшергә, ул биргән «күчтәнәчләрне» алырга тиеш иде. Алиш аны бәлки көтәдер, ә Фәрит инде аны күрә алмас. Ул кайгыра, ниндидер моңсу бер караш белән тирә-ягына күз сала. Ят кешеләрнең ят йортлары, ят урамнар бүген аеруча ямьсез кебек, бер якты карашны очратмассың, сак астында булмаган кешеләр дә ничектер йомыкланып калган, яшеренгән кебек. Җанга якын бер нәрсә очрамый. Ичмаса, бала елмаюы булсачы! Фәрит укытучы бит, ул эчкерсез бала елмаюының самимилеген аңлап, ичмаса, бер куаныр иде.

Берлинда, пересыльный төрмәдә утырганда, Фәрит Солтанов, тәмам аңга килә. Беренче тетрәү, беренче каушау үтә. Ул үз-үзенә читтән, салкын акыл белән карарга тырыша. Берлинга китергәннәр икән, димәк, Берлин группасында нәрсәдер булган. Фәритнең үзе янында бер нәрсә тапмадылар, концертында шулай ук шикле нәрсә юк иде. Ни булсын, мандолинада халык көйләрен чирттергән...

Көтмәгәндә аны түбәнгә, көтеп тору бүлмәсенә төшерделәр. Бирегә ул, гимнастеркасы ерткаланган, бил каешы салдырып алынган Мәхмүт Ямалетдиновны күреп туктап калды.

— Сине дә эләктерделәрмени... — диде Ямалетдинов калтыранган тавыш белән һәм күз төпләрен сөртеп алды. Аннары ашыгып-кабаланып пышылдарга тотынды. Лагерьда кулга алулар булган, бөтен музыкаль взводны төрмәгә япканнар, Мәхмүтне үзен менә аннан ары, моннан бире тинтерәтеп йөртәләр.

— Без бит, Фәрит абый, бер начар эш тә эшләмәдек, нигә безне?.. — диде Ямалетдинов еламсырап.

Озак сөйләшергә ирек бирмәделәр, аларны, өсте ачык машинага утыртып, каядыр алып киттеләр. Берлин артта калды. Машина җил кебек оча. Сакчы нидер мырлап бара, автоматын әсирләргә төбәгән. Бер тапкыр ул, сул күзен кысып, автоматына күрсәтте, бармак янады, янәсе, шаярмагыз. Кая алып баралар? Бераздан Польша җире башланды. Димәк, Радомга?

Юлда Фәрит уйлады: димәк, бөтен «артистларны»... Болай булгач, эш җитдиләнә, күрәсең, кемдер саткан...

Шунда ул Ямалетдиновка карап алды, Гайнан Кормашның сүзләре кылт итеп исенә төште. Гайнан: «Бу Мәхмү белән саграк булыгыз, аның алдында капчыгыгызны ашыгып чишмәгез», дигән иде бит. Бу ач яңаклы адәм Фәритнең үз күңеленә дә нигәдер ятып бетми иде. Тотып яманларлык начар ягы да юк шикелле — әзрәк шыңшый, мескенләнә — анысы бар. Шуның өчен генә күңел үз итмиме?

Ямалетдиновның барлык сорауларына Фәрит бары тик бер генә сүз белән җавап бирде:

— Белмим.

Мәхмүт сагыз кебек ябышты, Солтановның сөйләшергә теләмәвен күрә торып, бер үк сорауны төрле яктан китереп бирде.

— Нинди гаебебез өчен безне кулга алдылар? Ни дип инде җавап бирергә?

Ниһаять, Фәрит түзмәде, шактый тупас итеп өзде:

— Лыгырдама әле, Мәхмү. Гаебең бар икән, җавабың үзең бир. Минем — юк.

Ямалетдинов барысын төшенде булса кирәк, авыр сулый башлады. Синең белән бергә бәлагә эләккән иптәшеңне чамасыз җәберсетү — әйтеп бетергесез зур тупаслык. Әмма бу очракта Солтанов үзендә андый күңел кыйналу газабын нигәдер сизмәде, хәтта бу турыда уйлап та карамады. Ул бөтенләй икенче нәрсә белән мәшгуль иде. Ямалетдиновның «бөтен музыкаль капелланы сыпырдылар» дигән сүзләре дөрес булса кирәк. Югыйсә, Фәритнең бер үзен Узидомга барып кулга алмаслар иде. Ә ни өчен Ямалетдиновны Берлинга китергәннәр? — дип кинәт үз-үзеннән сорады Фәрит.

Ул Ямалетдиновның Габдулла Баттал белән Берлинда булуын, Абдулла Алишны да сатканлыгын белми иде.

Солтанов керфекләрен күтәрмичә генә Ямалетдиновка карады. Йөзендә таплар бар барын, ләкин чынлап кыйналганныкына охшамый, әбил каешын салдырырга, гимнастеркасын ерткаларга күп вакыт кирәкми.

— Нәрсә болай йөземә багасың, Фәрит абый, — дип сорады Ямалетдинов әкрен генә.— Матурладылар шул, уңнан да салалар, сулдан да. Күздән утлар оча!

Солтанов иреннәрен кыйшайтты:

— Ничек түздең?

Аның тавышында мыскыллау ярылып ята иде. Ямалетдинов моны әллә сизмәде, әллә сизүен бик тирән яшерде:

— Түздем инде... Бусы бит аның башы гына әле.

Варшава төрмәсе ишегалдында Фәрит Солтановны, машинадан төшереп, эчкә алып киттеләр. Тимер ишекләр, озын һәм ярым караңгы тар коридорлар. Бер кеше юк, монда җан иясе дә калмаган кебек. Фәритнең күңелендә шом туды, бөтен тәне өши башлады.

Ямалетдинов машинада калды...

Камерадагы беренче минутларны Фәритнең һич онытасы юк. Салкын, җепшек таш төрбә, ярым караңгы — почмакларда өрәкләр посып утыра сыман. Кабер тынлыгы шундый була торгандыр инде, Солтановка ул кинәт чукракланды кебек тоелды. Шылт иткән тавыш ишетелми, гүя бу тынлык мәңгегә урнашкан. Фәрит дер-дер килеп калтырана.

Кемнәр монда икән, берсен генә бер күз белән күрсәң иде, дип уйлады ул аннары. Нәрсә турында сорыйлар икән, нәрсәдән, кемнән сакланырга?

Шушы бетмәс-төкәнмәс уйлар белән күпме вакыт үткәндер, ул белмәде. Хәзер кичме, иртәме, көндезме — анысын шулай ук тәгаен генә чамалый алмый. Аңа калса, вакыт туктаган иде кебек, җиһаннан ниндидер коточкыч зилзилә шаулап, үкереп үткән дә, хәзер барысы, шул исәптән Фәрит үзе дә, хәрабәләр астында калган шикелле, тик моннан чыгу, котылу гына юк сыман.

Шулай оеп утырганда — бу мең елдан соң булды кебек,— ишек ачылды, сакчылар кереп, Фәритнең кулларын артка каерып богауладылар, аннары каядыр түбәнгә алып төшеп киттеләр. «Допроска... Антны онытма» — Фәритнең башында шул гына иде.

Беренче рәсми сораулар бик җиңел үтте. Солтанов аларга җавап бирде. Аннары төп сораулар башланды: нинди яшерен оешма сезгә күрсәтмәләр биреп торды, кемнәр җитәкчелек итте, җинаятьчел листовкаларны кайдан ала идегез?..

— Белмим, мин бер нәрсә белмим,— диде Фәрит.

Дүрткел күзлекле, чандыр йөзле тикшерүче, тылмач аркылы:

— Тагын бер тапкыр әйтәм, дөресен генә сөйләгез. Бу сезнең язмышыгызны җиңеләйтәчәк,— диде.

— Мин бары тик дөресен генә сөйлим: мин бер нәрсә белмим,— диде Фәрит.

— Сез югары белемле укытучы, яшь кеше — уйлагыз. Мин сезне кызганам...— Тикшерүче йомшак кына сөйләште, мәкерлелеген һич күрсәтмәде, ул гүя Фәритнең ышанычын яуларга тели иде.

— Белмим, мин бер нәрсә белмим.

— Белмисез?— тикшерүченең тавышында янау яңгырады.

— Белмим...

Шуннан соң Фәритне, икенче бүлмәгә алып чыгып, аяктан бәреп ектылар... Һуштан язгач, салкын су сибеп, аңына китерделәр.

— Я, хәзер сөйлисеңме?

— Мин бер нәрсә...— дип пышылдады Фәрит канлы иреннәрен көчкә кыймылдатып.

— Аз булган икән.

Фәритне ярым үлек хәлендә камерага китереп ташладылар.

Иртәгесен инде ул берничә минутлык прогулкага чыга алмады. Аннары тагын сорау алдылар, тагын эштән чыгарып кыйнаулар китте, аңын җуйгач кына камерага илтеп ташладылар.

Шулай хәтсез көннәр үткәч, кыйнаулар нигәдер туктатылды. Фәритне һава суларга чыгара башладылар. Бер вакыт ул Гайнан Кормашны күреп калды. Көч-хәл белән таныды. Гайнан да аны күрде. Күзләре очраштылар. Ә икенче көнне шул ук урында Гайнан бөтерелгән кәгазь кисәге ташлады. Фәрит күреп калды, прогулка вакытында, ботинкасының бавын бәйләгән булып, кәгазьне сиздерми генә күтәрде. Аның йөрәге дулап тибә башлады. Нәрсә әйтә иптәше? Бу бит беренче хәбәр.

Камерага кайткач кына Фәрит язуны укый алды. Анда бары бер генә сүз: «Мәхмү...» Ә янында фашист билгесе.

Солтанов барысын аңлады, сизенүләре дөрес булган икән.

Бик озак оеп утырганнан соң гына Фәрит үзенең йомарланган кулларына карый алды. Алар күгәреп чыкканнар, катканнар иде. Ачып карады — бармаклары кыймылдамый. Уйлары да өшегән иде шикелле аның. Ул берни турында да эзлекле фикер йөртә алмады.

— Сатлык җан!— дип кенә пышылдады ахырда.

## 27

Әллә кайдан ерактан тонык кына җыр, моңлы татар җыры ишетелә. Күпме әсирләрнең күңелләрен җылыткан, никадәр өметләндергән ул аларны чит-ят җирләрдә! «Артистлары» тагы... Аларның берсе дә профессиональ түгел, әмма алар җырлый яки музыка чиртә башласа, кырык үлемне күргән йөзләгән, меңләгән әсирләрнең күзләреннән кайнар яшь атылып чыга торган булган. Ә хәзер менә шул «артистларның» берсе — бер кешелек камерада ялгызы моңаеп утыра. Аның киң далаларга, иркен Урал тау үзәннәренә күнеккән моңлы тавышына төрмә камерасы чиксез кысан, күкрәгән тутырып сулар өчен һава җитешми, ә тыңлаучылары күзгә күренми. Ләкин ул бернигә карамыйча, надзирательләрнең сүгенүләренә, карцер белән янауларына игътибар итмичә, җырлый да җырлый. Ул белә һәм күңел күзе белән күрә: кайсыдыр

камераларда, колакларын стенага куеп, иптәшләре тыңлый аны. Ул аларга өмет сандугачы җибәрә, белсеннәр, биредә алар ялгыз түгел. Элек җыр — канатлы җыр — әсирләрнең боек күңеленә өмет чаткысы салып килгән булса, хәзер «артистларның» үзләренең күңелен юата. Өметсезләнмә, бел: бүген көн караңгы, иртәгә ялтырап кояш чыгар!..

Талгын гына ага, һич туктамый,
Ярларында бөек Идел-су-у.
Кайлардадыр, зәңгәр урманнарда
Безгә дәшә кәккүк: ку-ку-ку-у!
Кайлардадыр, зәңгәр урманнарда
Тәсбих әйтә кәккүк: ку-ку-ку-у!

Әсирләр моны бик яхшы аңлый иде: карурманнарда кәккүк тавышы — ул партизаннар өндәве. Алар кемне куарга, кемнән үч алырга кирәген белә.

Иптәшләренең кайберләрен прогулкаларда гына күргән, кайберләрен бөтенләй күрмәгән Фәрит Солтанов, тыны кысылып, тыңлап торгач, кинәт үз-үзенә сер ачкан кебек:

— Бу безнең җырчыбыз Шәриф Әмиров ич! — диде, күкрәгендә дуслык тойгылары ташыды. Мондый тирән кичерешне аның беркайчан татыганы юк иде әле.

Бу төнне Фәрит, чамасыз йончыган булуына карамастан, бик озак йоклый алмады, бөтен гомере күз алдыннан үтте. Күпме генә нәрсә күрергә өлгергән иде соң бу егерме биш яшьлек егет? Еракта калган кояшлы Үзбәкстан, сөекле җанашы яшен тизлеге белән күз алдыннан үтеп китте. Көн саен бара торган мәктәбе томан эчендә күренеп калды. Кичләрен, буш вакытларында, челтерәп аккан арык янында, чинар төбенә утырып, мандолина чиртә торган иде. Күңеле теләгәндә генә уйнап, кайчагында атналар буе сорнаен кулына алмады. Шул һөнәре ерак илләрдә, әсирлектә бер килеп ярап куяр дип кем уйлаган ул чакта? Артист булу аның хыялында да һич юк иде. Башына төшкәч, башмакчы буласың икән.

Фәрит, ниһаять, йокымсырады, ул инде төш күрә иде... Ә йокыдан ул кара тиргә батып уянды. Дөм караңгы иде. Бик әкертенлек белән зиһене ачылды Фәритнең, ул үзенең аяныч хәле турында тагын уйлана башлады.

Гайнан Кормашка рәхәт, ул бер сүз белән күп нәрсә аңлатырлык хәбәр бирде, аңа ышаныч белдерде. Монда бит «ышану» сүзенең мәгънәсе бермә-бер зур, тирән, хәтта изге. Кормаш инде төрмәнең ачы чынбарлыгын татыган кеше, ихтимал, аңа Фәриттән күбрәк эләгә торгандыр.

Шуннан соң, берничә көн үткәч, төрмә душында юынган чагында, Солтанов Гайнанның үзен очратты. Бу юлы кешечә сөйләшә алдылар.

— Тикшерүчеләр төрле провокацияләр куллана, ул алай әйтте, бу болай әйтте, диләр,— диде Гайнан.— Ышанма, барысы да ялган.— Җавапларны ничегрәк бирергә кирәген әйтте. Иң мөһиме — бер яңа фамилия атамаска. Син бер нәрсә белмисең, сиңа бер нәрсә әйтмәделәр.

— Ә Мәхмү — сволочь! Аңа берни сөйләмичә дөрес иткәнсең.

Нибары берничә минут, шул берничә минут эчендә Кормаш Фәрит Солтановка киләчәк өчен гүя бөтен бер программа сызып бирде. Соыннан коточкыч сорау алулар, әллә нинди провокацияләр, син — яшерен оешманың иң актив члены булгансың дигән ялганнар вакытында Гайнанның киңәшләре Фәритнең исеннән чыкмады. Аның югалтып егылганда да аның канга баткан иреннәре: «Мин бер нәрсә белмим» дип пышылдады.

Бер вакыт яңадан йөри алырлык хәлгә килгәч, Фәрит ишегалдындагы агач башларыннан сары яфрак коелганын күрде. «Хәзер сентябрьме, октябрьме?— дип уйлады Фәрит. Аннары ишегалды үзе дә

үзгәргән кебек. Мөгаен, аны башка камерага күчергәннәрдер, ә ул берни хәтерләми!

Бер тапкыр ул төрмә ишегалдында Зиннәт Хәсәновны күреп калды. Аны танырлык түгел иде: кара чәче агарган, гәүдәсе, бабайларныкы кебек, бөкрәйгән.

«Нишләткәннәр ерткычлар!» дип уйлады Фәрит. Икенче тапкыр бәлки күз карашлары белән алмашырлар. Фәритнең иптәшен сәламлисе килде. Ләкин ул аны кабат нигәдер күрә алмады. Әмма төрмәнең хәтсез күп баскычларының берсендә Рушат Хисаметдинов белән йөзгә-йөз очрашкач, чак кычкырып җибәрмәде. Билгеле, туктап сөйләшергә ярамый иде. Кинәт нурланып киткән күзләре генә бер-берсенә текәлделәр. Әйтелмәгән күпме серләр, моңнар бар иде аларда!

Варшава төрмәсендә Фәритнең Муса Җәлилне дә күргәне юк иде. Гестапо аның группа җитәкчесе икәнен белә булса кирәк, югыйсә, һәр вакыт диярлек аның турында сорамаслар иде. Ә бүген тикшерүче үзе әйтте: «Сезнең Мусагызны Берлинга алып киттеләр инде, сезне дә тиздән анда озатачаклар. Анда сөйләрсез, анда сөйләтә беләләр», диде.

Бу чираттагы янау, куркыту иде бугай. Чын булса, монда яңалык та бар: аларны Берлинга күчерәләр икән, димәк, аларның эшенә киңрәк төс бирәләр. Бу инде аерым батальонда, аерым кешеләр тарафыннан котыртып эшләнгән бер «фетнә» генә имәс, бу инде гомум Германия күләмендә алып барылган, нацистларның төп нигезләренә сугып, аны дер селкеткән, аның яшәвенә куркыныч тудырган шаў-шулы политик процесс. Гитлерчылар аны никадәр кечерәйтергә, гади бер «корткычлык» итеп, ә аңа катнашучыларны «гади» агентлар итеп күрсәтергә тырышмасыннар, эшнең әнә шулай зурга китүе, җитмәсә, Геббельс-Розенберг ведомстволары — ягъни фашизмның йөрәгенә якын җирдә алып барылуы аның гадәти нәрсә түгеллеген белдерә иде. Гитлерчыларның «легионерларга» карата чиксез каты кылanulары да шуның белән аңлатыла торгандыр.

Шунысы гаҗәп, хәзер Фәрит беренче көннәрдәгечә курыкмый, калтырамый башлады. Фашистларның ерткычлыкларын татып өлгергәнгәме, әллә киләчәктә дәһшәтлерәкләрен көткәнгәме, үзен ныграк тотты. Әлбәттә, ул күнекте дип әйтеп булмый, киресенчә, хәзер артык каты булмаган бәрү-сугу да аның бөтен тәнендә сүз белән аңлатып булмаслык авырту, сызлану уята иде. Ләкин ни өчен бу газапларны кичерүен аңлаган кеше чыдамас җирдән чыдый икән, гүя эшләгән эшенең максаты аңа түземлек бирә.

Үзе күреп белгән, йомшак холыклы, кешеләр белән көлеп-елмаеп кына сөйләшә торган Абдулла Алиш турында камерада Фәрит еш уйлый башлады. Ул кай ягы беләндер аңа охшый, күңеленә хуш килә иде. Алар асылда икесе дә бер профессия кешеләре, дөньяга карашлары да бер төстә бугай. Шундый хәтәр эшкә тотынуларының төбендә дә бер нәрсә — балаларга булган чиксез мәхәббәт ята булса кирәк. Бары тик шул олы мәхәббәт хакына гына булмастайны эшләргә, күп авырлыкларга түзәргә мөмкин.

Шуннан Фәритнең уйлары тагын үзеннән-үзе Мәхмүт Ямалетдиновка күчте. Бу хәчтерүш бәндәне дә укытучылар тәрбияләгән бит. Ул да, башкалар кебек, китаплар укып соклангандыр, алар кебек, зур эшләр турында хыялланагандыр, тумыштан берәү дә явыз җан булып дөньяга килми. Күрәсең, барысы формаль эшләнгән, укытучылары йомыкый бала җанына тирәнтен үтеп керә алмаган, ә кемнәрдер аңа юл тапкан, эчтә йомылып яткан «нәни шайтан»га азык биргән — ул үскән дә үскән. Мөгаен, башка профессия кешеләре, ялгышларының тирән тамырларын эзләгәндә, үзләренең эштәге кимчелекләрен, кайдадыр күрсәткән гамьсезлекләрен укытучы кебек үк ачык күрми торганнардыр.

Шундый каршылыклы, чишеп булмастай катлаулы, үкенечле уйлар эчендә үтә иде Фәритнең төрмәдәге көннәре. Кешене уттан алып суга сала торган газаплар бетәсе юк сыман тоелган бер көнне Фәриткә, кулларына богау салдылар да, камерадан чыгарга куштылар. «Тагын допроска» дип уйлады Фәрит. Тәне, алдагы газапларны тоеп, ихтыярсыз бөреште.

Конвой аны сансыз коридорларда туктатмыйча ишегалдына ук алып чыкты. Тонык ут яктысында «кара козгын» — фашистларның үлем автомашинасы күренде.

Фәрит кинәт туктады. «Атарга алып баралар икән!» дип уйлады. Саубуллашкандай, кара күктә анда-санда җемелдәшкән йолдызларга чиксез сызлану белән карап алды.

Машинада Фәрит үз күзләренә үзе ышанмыйча торды: өнме, төшме? Әллә шулай күренә генәме? Машинада бер-берсенә сыенып Гайнан Кормаш, Зиннәт Хәсәнов һәм Габдулла Баттал утыра иде. Әллә каяндыр ут яктысы төшкәнгәме, әллә тоткыннарның йөзләре эчке нурдан яктырып торгангамы, Фәрит өчесен дә ап-ачык күрде, хәтта тере, җанлы күз алмалары ялтырый иде. Әгәр шул мизгелдә биредә мәшһүр художник булса, бу күзләрне сурәтләми һич түзмәс иде! Нихәтле газаплы көннәрдән соң шундый аяныч урында очрашу! Бу минутта Фәрит белән дусларының күңелләрендә ташыган тойгыларны ничек сурәтләргә?! Бер-берсен кочарлар иде — куллары богаулы, бер-берсенең исемнәрен кычкырырлар иде — эндәшергә ярамый. Мөмкин булса, бер-берсен күрмәсен өчен, гитлерчылар аларның күзләрен дә чукып алырлар иде. Бу күзләрдә дөньядагы бар яхшылык, беренче чиратта, бинһая кайнар дуслык бар иде. Сугышчан дуслык!

Кем белә, бәлки нәкъ менә шул кичтә Фәрит Солтановның язмышы хәл ителгәндер. Иптәшләре аның бар гаебен үз өсләренә алып, «юк, ул катнашмады, моны мин генә эшләдем!» диделәр.



## 28

Гестапо, нихәтле тырышмасын, яшерен листовкаларның кайларда басылуын башта тәгаен белә алмады. Листовкалар я типографиядә, я стеклографта басылган, я кулдан язылган, я машинкада сугылган була иде. Шундыйларның берсен гестапо Едлинода кулга төшерде. Җентекләп өйрәнә башлагач, машинканың бер хәрефе бозык икәнлеге беленде. Шуннан бозык хәрефле язу машинкасын Польша белән Германиядә эзләү башланды. Бер кибән эченнән бер энәне эзләү никадәр читен булса, бу да шуның шикелле зур мәшәкать иде. Дөрес, рус хәрефле машинкалар Польшада яки Германиядә шулай да чикле, аларның кайларда булу ихтималы да гестапога чама белән билгеле. Тик аларның һәрберсен аерым-аерым карап чыгу бик күп вакытны алды. Ахыр килеп шундый бозык хәрефле рус машинкасы немец пропаганда министрлыгында табылгач, гестапочыларның күзләре атылып чыга язды. Башка китерергә мөмкин булмаган хәл: фашизмга каршы аяусыз көрәшкә чакырган совет листовкалары ата фашист Геббельсның борын төбендә басылган ләбаса!

Союзникларның авиациясе төннәрен Берлинны бик еш бомбага тота. Министрлыктагы барлык бүлмәләрдән сотрудниклар бомбоубежищега төшеп яшеренә, өстә фәкать дежурныйлар гына кала. Менә шул иркенлектән файдаланып, радиотапшырулар хезмәткәре — дежурный Әхмәт Симаев листовкалар баскан!

Әхмәтләрне кулга алырга биш гитлерчы килә. Алар барысы да гражданский киемдә була. Радиопропаганда бүлегендә эшләүчеләргә стена буена басарга боералар, үзләре бөтен бүлмәне, өстәлләрне, кә-

газьләрне карап, тикшереп чыгалар, сотрудникларның һәммәсен тентиләр, документларын җыялар, язулы кәгазьләрен аерым бер төргәккә төрәләр.

Әхмәтнең документларын алган гитлерчы, аның таныклыгын укыгач:

— О-о, Зимаев!— диде нидер белгән кебек. Аннары Әхмәтнең өстәлен янә бер тапкыр, бу юлы җентекләбрәк, карап чыкты, хәтта өстәл тартмаларының асты ике катлы түгелме дип тә тикшерде.

Әхмәт күзләре белән гитлерчының һәр хәрәкәтен күзәтеп торды. Өстәл эчендә андый-мондый нәрсә яшерелмәгәнгә, Әхмәт аннан курыкмады. Әмма гитлерчының тиз-тиз хәрәкәтләнүче озын, үлекнеке кебек ак бармакларына карап: «Тентергә өйрәнгән, ләгънәт!» дип уйлады. Ихтимал, ахыр килеп кулга аласыларын белгәнгәме, үзен шул сынауга алдан хәзерләгәнгәме, Әхмәт артык курыкмады, тик бик аз эшләп калуы өчен генә үкенде. Бу көнне ул соңрак көтә иде. Аннары Алишлар турында уйлап алды: аларның хәлләре ничек икән, аларга тимәсәләр ярар иде.

Радиода эшләүчеләрнең барысы да кулга алынганлыгын әйттеләр.

— Ә сезнең белән, Зимаев, тора торган бүлмәгезне карап чыгарга тиешбез,— диде башлык.

Әхмәт чак кына агарынды. Әллә тәҗрибәсезлек, әллә тәвәккәллек, әллә тагын бер нәрсә шунда — Әхмәтнең бүлмәсендә үзе җыйган әзер радиотапшыргыч тора иде. Ул хәтта еракка яшерелмәгән дә. Бу инде гестапо кулында зур дәлил булыр, алар аяк терәп аны гаепли алырлар, чөнки радиотапшыргычның нәрсәгә кирәк икәне бик яхшы билгеле. Шкаф артыннан радиотапшыргычны чыгарган гитлерчы явыз шатлык белән иреннәрен кәкрәйтте:

— Әһә, совет шпионы!

Әхмәт соң мәртәбә үзенең бәләкәй бүлмәсенә, кечкенә өстәленә, гестапочы кулындагы блокнотына карап алды. Анда Мусаның бер шигыренең русча тәрҗемәсе бар иде. Ярый әле, кем шигыре икәне күрсәтелмәгән. Ә Әхмәт үзе русча шигырьләр язгалый, татар шигырьләрен русчага тәрҗемә иткәли иде.

Әхмәт Симайга моңсулык хас булмаганга, ул тормышының гаять кыен минутларында да югалып калмый, аңарда балаларча тәвәккәллек, бераз гамьсезлек һәм ташып торган самимилек бар иде. Менә хәзер дә ул, инде һичкайчан бирегә әйләнеп кайтмаячагын белсә дә, бүлмәдән үз алдына көлемсери төшеп чыгып китте, хәтта гитлерчы, бармагын чигәсенә куеп, күзләре белән Симайга күрсәтеп, иңбашларын җыерды. Икенчесенең карашы кырыс, ул гүя: «Рус шпионы белән сак бул» дип кисәтә иде.

Әхмәтне Александрплацтагы Тегель төрмәсенә алып килделәр. Биредә гитлерчылар, нәкъ Варшава төрмәсендәге кебек, тоткыннарны физик яктан сындыруны күздә тоталар икән. Җәзаларның иң катыларын кулланалар.

Әхмәт үзе белән бергә кулга алынган кешеләрнең кайсы камераларда утыруларын белми иде. Алар яшерен оешма членнары түгел, әгәр дөресен генә сөйләсәләр, алар ягыннан әллә ни куркыныч юк шикелле. Хәер, гестапоның алымнарын белмәссең. Шәфи Алмас, билгеле, бигрәк тырышыр, аңа үзенең ачык авызлыгын яшерергә кирәк булыр, Әхмәткә «җылы» мөнәсәбәт күрсәтүен нинди булса мәкер белән эшләгәнлеген әйтер. Аңардан барысын көтәргә була. Әбикош та Әхмәтне мактамас. Сәрхуш аны турыдан-туры белми. Ваграк чукмарбашлары беләләрдер. Димәк, Сәрхуше дә белә. Алар инде тырышырлар, бергә унны өстәрләр. Әхмәт студиядә юк чакта Сәрхуш үзе дә кереп чыккан булган...

Әхмәтне бер кешелек камерага яптылар. Биш-алты адым алга-артка атларлык кына урын. Урын-җир ятагы белән стенага кайтарып

бикләнгән. Түшәм янындагы берданбер тәрәзәдән сыек кына яктылык сирпелә.

Әхмәт сызгырына башлады, башына бер-бер артлы күңелсез уйлар килеп китте. «Алар тәэсиренә хәзердән үк бирелергә ярамастыр. Күп яшәгән, күп күргән бабайлар әйткән ич — кеше тәмугка да күнегә дип. Без дә күнегербез әле.»

Әмма күнегүләре, ай-һай, читен булды. Йокларга ятар алдыннан өстәге бөтен киемнәрне салдырып алалар, күлмәк-ыштаннан гына каласың, кул-аякларга богау салына. Стенага кайтарып бикләнгән сәкене төшерәләр, юрган, матрац, мендәр урынына юка гына җәймә. Менә шул «җылы» урында син төн үткәрергә тиешсең. Тешең тешкә тими, дер-дер калтыранасың, тәнең күгәреп чыга, юеш салкын эченә үк үтә.

Берничә көн Әхмәтне беркая чакырмадылар, гүя шушы салкын таш ләхеттә мәңгегә оныттылар. Һава суларга ялгызын гына чыгардылар. «Абзаңа почет зур, Берлинның бөтен саф һавасын бер үземә сулата-лар, малай», дип үзалдына мыскыллы көлемсерәде ул.

Уйларын тәртипкә китерергә Әхмәтнең вакыты җитәрлек иде. Әхмәт үзе бик күп нәрсә белә, шуларның никадәре гестапога мәгълүм икән, нәрсәдән аеруча сакланырга, нәрсәне танырга, нәрсәдән кискен рәвештә баш тартырга? Радиотапшыргыч алар кулында, моңа алар аеруча ба-сым ясарлардыр. Барысын үз өстеңә алырга, беркемне бутамаска. Радиотапшыргычны нинди максат белән җыйдыгыз дип сорарлар, ничек җавап бирергә? Тагын нәрсә беләләр, нәрсә сорыйлар икән?

Муса Берлинда юк, ул Радомда. Әллә бу хәлләр легионда восста-ние булганнан соң башландымы? Эх, шулай булсачы!

Әхмәт Муса Җәлилнең Варшавадан Берлинга китерелүен белмәгән шикелле үк, Шабаев белән Булатовны кулга алган чакта басарга әзер-ләнгән листовкаларның матрицалары, кулдан язылган оригиналлары — барысы гестапо кулына эләгүен, бер үк вакытта Абдулла Алишның да төрмәгә утыртылуын белми, провалның зурлыгын күз алдына ачык ки-терми иде.

Коточкыч көннәр башланды. Сорау алулар җәзалаулар белән чи-ратлаша. Әхмәт еш кына аңын җуя, башына салкын су коеп һушына ки-терелгәч — тагын сорау алу, тагын җәзалау. Гестапоны Симай белән Муса Җәлилнең нинди тыгыз элемтәдә булуы кызыксындыра бугай. Һәр сорау алу шуннан башланды.

Бүген Әхмәтне тагын җир асты юлларыннан Принц-Альберехт-штрасседа махсус эшләнгән җәзалау урынына алып киттеләр. Биредә аны шул хәтле газаплыйлар иде, яңадан монда якынлашу белән ул я калтырарга, я акылын җуярга тиеш иде кебек, әмма Әхмәт, гүя язмышка карышкан сыман, тикшерүче алдына кабат килеп баса. Аның куллары богаулы, ә күзләргә богау салып булмый, алар гестапочыга шул хәтле тирән җирәнеч, шул хәтле көчле нәфрәт белән карыйлар, хәтта теге утырган урынында вакыт-вакыт кыбырҗып ала, һау-һаулап өрергә тотына:

— Я, бүген акыллырак сөйләмәссезме?

— Мин юләр сатмыйм.

— Радиобүлеккә Гумеров еш килеп йөрдеме? Сез аның белән нәр-сәләр турында сөйләшә идегез?

— Кабатлыйм: Гумеров минем яныма бер вакытта да килеп йөр-мәде, без аның белән һичкайчан сөйләшмәдек.

— Бүлектән тыш тамы?

— Бүлектән тыш та.

— Радиотапшыргычны Гумеров кушуы буенча җыйдыгызмы?

— Миңа беркем кушмады.

— Ә легион подразделениеләренә командировкага барганда Гумеров нинди заданиеләр бирә иде? Кемнәр белән очрашырга куша иде?

— Миңа «Татар комитеты»ндагы начальникларым гына задание бирә иде. Аларның боерыгын гына үтәдем.

— Нигә бу кадәр киреләнәсез? Гумеров сезнең янга килеп йөргән, заданиеләр биргән бит. Моны иптәшләрегез әйтте инде. Гумеров та раслады.

Әхмәт һаман да әле Мусаны Берлинда юк дип саный иде.

— Ялган! Күзгә-күз очраштырыгыз!

Гитлерчы уйланып торды, аннары көлемсерәде:

— Яхшы. — Ул звонок бирде. Богауланган шагыйрьне керттеләр. Әхмәт гаҗәпләнгән күзләрен аңардан алмады. Мусаның йөзе шешенгән, күгәргән, сул кулбашы салынып тора. Шунда Әхмәт барысын аңлады: провал!

— Бу кешене таныйсызмы? — диде тикшерүче, Әхмәт Симайга бармагы белән күрсәтеп. — Аның янына килеп йөрүләрегезне кабатлагыз!

— Кабатлар сүзем юк,— диде Муса, тылмачның тәрҗемәсен тыңлагач. — Мин аның турында сезгә беркайчан, бернәрсә сөйләмәдем, чөнки аны белмим, аның янына барып йөрмәдем.

— Танмагыз! — дип акырып куйды тикшерүче, сикереп аякка басты. — Барып йөргәнсез. Бүлектәге иптәшләрегез барысын да әйтте. Ә сез,— диде гитлерчы Әхмәткә карап,— элекке күрсәтмәләрегезне кабатлагыз, алдашмагыз: Гумеров сезнең янга күпме тапкыр килде? Нинди заданиеләр бирде? Радиотапшыргычны аның кушуы буенча җыйдыгызмы?

Әхмәт гитлерчыга туп-туры караган килеш:

— Мин кабатлыйм, — диде, — Гумеров минем янга бер тапкыр да килмәде, заданиеләр бирмәде. Радиотапшыргычны үзем җыйдым.

— Нәрсә! Танасыз... Ах, дуңгыз!

Тагын җәзалаулар дәвам итте. Ә берничә көннән соң Әхмәтне Абдулла Алиш белән дә күзгә-күз очраштырдылар, тагын шул ук сораулар инде икенче яктан китереп бирелде: Гумеров сезгә ничек җитәкчелек итә иде, үзе килеп йөри идеме, кешеләр ашамы? Листовкаларның оригиналларын каян ала идегез?

Алиш та, Симаев та Муса өстеннән бер сүз әйтмәде, тик аның зур шагыйрь булуына гына басым ясадылар. Совет әсирләренең, алдан сөйләшеп куйган төсле, бер үк җавап бирүләре гестапочыларның ачуын кабартты. Танарга мөмкин булмаган нәрсәләрне алар үз өсләренә алдылар, Мусаның монда бернинди катнашы юк диделәр. Алар һәрдаим Җәлилне акларга тырыша иде. Ахырда тикшерүче түзмәде, ачыктан-ачык әйтте:

— Сез Гумеровны гөнаһсыз шагыйрь итеп кенә күрсәтергә тырышсагыз да, без беләбез: ул — сезнең төп җитәкче. Без дөреслекне әйтергә барыбер мәҗбүр итәрбез.

Сораулар алып барганда еш кына авиабомба гөрселдәүләре ишетелә иде. Әмма Әхмәт: «Бу газапларны күргәнче, ичмасам, башыма бомба төшсә икән!» дип бер вакытта да уйламады. Ул газаплардан качып җир астына яшеренергә җыенмый иде. Көрәш әле бетмәгән, ул әле дәвам итә — үлемең белән дә дошманга өстенлек бирергә ярамый. Җәлилчеләр үзләре дә белә, аннары тикшерүче дә әйтте: бөек рейхка каршы эшләгән җинаятьләрегезнең уннан бере өчен генә дә сезгә үлем тиеш. Дошман белән соңгы сулышкача көрәшеп үлү — ул җиңелү яки эзсез бетү түгел әле. Көрәшчеләрнең кызыл каны тамган җирдә кызыл чәчәкләр үсә. Бу хакыйкать күптән әйтелгән.

Хәзер Әхмәт бик еш Эрнст Тельман турында уйлый иде. Кем белә, бәлки немец пролетариатының юлбашчысы, сыгылмас көрәшче Тельман да нәкъ менә шушы төрмәдә, шушы ук камераларда җәфа чиккәндер. Ул кичергән җәфалар җәлилчеләр кичергәннәргә караганда да дәһшәтлерәк булгандыр, әлбәттә. Менә кемнәрдән көрәштә үрнәк алырга кирәк!

Совет шагыйрьләреннән — зурысы, кечкенәсе — кайсы гына Тельман турында, аның батырлыгына, түземлелегенә сокланып, шигырь язмады икән? Әхмәт тә язды. Тик ул чакта үзенең дә бөек көрәшче яткан салкын камераларда бер утырасын гына уйламаган иде...

Бүген Әхмәттән аеруча җентекләп Рәхим Саттаров турында сорадылар. Ул Гумеровтан нинди задание алып китте, диделәр.

— Сез Рәхим Саттаров һәм Муса Җәлил-Гумеров белән Вустраудa ук очрашкансыз, җинаятьчел эш алып бару турында анда ук сүз куешкансыз... Менә бу большевистик листовканы сез шул максат белән язгансыз.— Тикшерүче Әхмәткә бозык хәрефле машинкада басылган листовканы күрсәтте.— Я, бу турыда нәрсә әйтә аласыз?

— Нәрсә әйтим. Листовканы мин бастым.

— Кем кушты?

— Үз йөрәгем.

Әхмәтне бүген дә аңын югалтканчы кыйнаганнан соң гына камера идәненә илтеп ташладылар. Шунда ул берничә көн аунады. Саташты, төшләр күрде. Имеш, ул Мәскәүдә, Кече татар тыкрыгындагы китапханәгә ашыга. Анда бүген әдәби түгәрәкнең утырышы, атаклы язучы Мәхмүт Галәүнең хикәяләрен укып тикшерәләр. Зур портфель күтәреп йөрүче бер чибәр егет кызып-кызып сөйли, хәзерге язучыларның бөтен бәлаләре шунда, алар бүгенге тормышны тирәнтен белми, ди. Менә язучы күкеле сәгать турында хикәя кыла. Нәрсә ул күкеле сәгать? Буржуаз тормыш калдыгы...

Муса Җәлил белән Әхмәт Фәйзи аска карап утыралар. Аннары Муса сөйли. Карт буын язучыларны тормышны белмәүдә гаепләү бик зур дорфалык, ди. Алар ул тормышның төбеннән күтәрелгән. Беләләр.

Ул да булмый, Муса инде клуб сәхнәсендә. Ул үзенең «Авыру комсомолец» поэмасын укый. Сәхнәдә шагыйрь түгел, Махно бандаларына каршы көрәшеп йөргән «ярты кәҗә тун» кигән авыру комсомолец үзе басып тора кебек. Әхмәт нигәдер аның кәҗә тунына кызыга. Ул тун бик җылыдыр кебек, аның белән салкын вагоннарда да тунмый торганнардыр. Әхмәтнең шундый тун киясе килә...

## 29

Шул ук төрмә, тик башка каты, башка почмагы. Әхмәт Симай белән бер үк вакытта җәзаланган, аннары һушсыз хәлендә камерага китереп ташланган Муса Җәлил салкын таш идәндә ауный. Шул хәлендә күпме яткандыр — билгесез. Аннары әкрен-әкрен зиһенен килде, ләкин торып утыра да, йөри дә алмады. Камера дөм караңгы иде. Бөтен тәне сызлый, тамагы кипкән. Мөгаен, ул шул коточкыч сызлаулардан аңына килгәндер. Беркадәр тынычланганчы байтак вакыт үтте. Инде кешечә уйлана башлады.

Алардан, Әхмәт Симай белән икесеннән, бер үк тикшерүче сорау ала иде. Ул еш кына юка ирен почмагын кыйшайтып хәйләкәр генә елмая, нәрсәдер белгән кеше кебек кылана, гүя телең ачылыр әле, сөйләрсең әле, большевистик горурлыгыңны чүплеккә ташла, монда Гитлер акылы хөкем йөртә, дия иде. Бусы да Мусаны таң калдырмады, күбрәк стандарт буенча эш итәләр, тоткыннарны түгел, үзләрен акыл ягыннан чагыштыргысыз өстен итеп саныйлар. Арнецлар, имеш. Ләкин

Мусаны тикшерүченең бер ягы гаҗәпләндерә иде: вакыт-вакыт ул татар кешесенең холкын бик тирән аңлагандай кылана һәм, әйтергә кирәк, моны ярыйсы оста эшли, сорауларны Мусаның иҗатын, уйларын яхшы белгән кешедәй тирәннән каерып бирә, еш кына Мусаның кызы, хатыны исемнәрен телгә ала, алар хәзер Казанда да, Мәскәүдә дә юк, салкын Себердә, ди. Язучыларыгыздан кемнәр калды? Бер Тукай. Чөнки ул күптән үлгән, югыйсә, аны әллә кайчан дарга күтәргән булырлар иде. Бабичны аттылар, Галимҗан Ибраһимовны, Кәрим Тинчуринны да...

Дөрес, бу исем-фамилияләрне ул көчле немец акценты белән әйтә, буташтыра, тагын нинди дер фамилияләр кычкыра, астыртын гына елмая, бер күзен кысып ала. Мусаны бер нәрсә гаҗәпләндерә: каян белә ул аларны? Көтелмәгән провокацияләргә бирелмәс өчен Муса үтә сак булды.

Бер көнне аны аерата каты газапладылар, аеруча төпченеп поляк партизаннары, әрмән легионерлары, немец коммунистлары турында сорадылар, аралашкан кешеләрнең исемнәрен әйтүне таләп иттеләр. Муса, һәр вакыттагыча, берни дә белмим, дип кабатлады. Аңа әллә нинди язулар күрсәттеләр. Муса, мин боларны беренче күрәм, диде. Баш тарткан саен аны катырак җәзаладылар, һуштан язгач, салкын су белән дә, әллә ниләр иснәтеп тә аңына китерделәр, тагын шул ук сорауларны яңабаштан бирделәр, юкка киреләнәсез, безгә барысы да билгеле бит, диделәр.

Бер чакны, аңына килеп күзен ачкач, Муса гестапочы белән янәшә немец офицеры киемендә Солтан Гарипне күрде. Күз аллары томанлы иде әле. Муса күзләрен йомды. Тагын ачкач, тагын Сәрхушне күрде. Юк, Муса саташмый иде. Солтан Гарип аның өстенә үк иелгән, нидер пышылдый. «Хаин, хаин!» дип уйлады Муса. Бу юлы ул һушыннан язмыйча бик озак түзде. Нәфрәт тә кешегә көч бирә икән!

Кинәт кайдандыр шундый үз, шундый кадерле «Сагыну» җыры яңгырый башлады. Көе дә, сүзләре дә, җырчының моңы да шундый якын, шундый газиз, Мусаның күзләреннән шундук яшь атылып чыкты. Коточкыч газаплаулар вакытында еламаган Муса хәзер елый башлады. Аннары күзләрен ачты. Ул берүзе идәндә ята. Башын күтәрергә хәле юк. Кайдандыр кара чаршау артыннан талгын гына җыр сибелә. Бу минутта Муса өчен барысы да — вәхшиләрчә газаплаулар да, тән сызлаулары да, котны ала торган җәзалау камерасы да, барысы беткән, бары тик сихри музыка һәм тылсымлы җыр гына калган иде.

Ул күзләрен йомды, ә кайнар яшьләре акты да акты.

— Бу бит сезнең җыр, — дигән тавыш ишетелде. — Нинди матур җыр!

Муса күзләрен ачты. Аның янында тикшерүче елмая иде.

— Шундый матур җыр, шундый матур тавышлы артистка хакына, ниһаять, нәни кызыгыз хакына яшәргә теләмисезме? Сездән бит күп нәрсә таләп ителми. Барысын ихлас күңелдән сөйләгез, исем-фамилияләрне атагыз. Шул гына. Миһербанлы герман суды сезне гафу итәр, гомерегезне саклап калыр...

Муса эндәшмәде. Җыр тагын башланды, аннары кинәт өзелде. Тикшерүче яңа янаулар белән үзенең сүзләрен кабатлады. Муса инде аны тыңламады. Ул бары тик аңсыз рәвештә генә берәр нәрсә ычкындырмагаем дип курыкты.

Аны тагын газаплый башладылар...

Яңадан берничек тә һушына китерә алмагач кына үз камерасына илтеп ташладылар. Күпме шулай аунагандыр — билгесез. Бер мәлне бик каты саташа башлады. Яңадан аны җәзалыйлар, имеш, тәнен әллә нинди чәнечкеле тимер чыбыклар белән өзгәлиләр, утта кыздырыл-

ган тимер таяк белән көйдерәләр, поляк партизаннары, әрмән легионерлары турында сорыйлар, «Сагыну» җыры ишетелә. Сәрхуш — Солтан Гарип килгән, имеш, кулында кәгазь:

— Бу сезнең язу ич! — дип үкерә. — Сез аларны немецларга каршы бергәләп хәрәкәт итәргә чакыргансыз!

Кинәт кап-караңгы булып китә, әйтерсең ут сүнә. Муса тына, салкын таш идәндә әллә ничә сәгать ята. Аннары тагын саташа: ул тагын җәзалау камерасында, имеш, тагын җыр. Кул бармакларын итек табаннары белән изгәлиләр...

Ниһаять, әрнүләр, сызлаулар күпмегәдер онытыла, ул төш күрә башлый. Имеш, Оренбург якларында гына була торганча даладан сәмум җиле исә башлаган: коры, кайнар — бугазны гына түгел, үпкәләрне көйдереп ала. Күз ачкысыз ком бураны. Муса йөзен кая яшерергә белми, кайнар ком бөртекләре битләрен инәдәй тишкәли. Ул ниндидер кара әйбер артына ышыклана. Бервакыт күзләрен ачып караса, бу әйбер түгел, дөя малае. Әлеге коточкыч эссе шул дөя малае тәненнән бөркелә, имеш.

— Кит әле, — дип, Муса куллары белән аны үзеннән этәргән була. Мескен хайван елышмый, шәмәхә күзе белән бик кызганыч итеп Мусага карый. Әллә елый инде, күзеннән мөлдерәмә яшь ага. — Нигә елыйсың, малайлар еламый ич.

Һай, нинди эссе! Дөя аңа тагын да ныграк сыена, Муса бәләкәй куллары белән дөяне тукмый, имеш.

— Чү, тиле песикәем, сугышма, мин сиңа дөя йонынннан менә нинди һәйбәт бияләй бәйләдем, — ди Мусаның әбкәсе Гыйльми әби һәм оныгына җылы бияләйләр суза.

— Кирәкми миңа бияләй, миңа эссе, әнә кар ява, кар! Миңа кар бирегез! — дип кычкырмакчы Муса кинәт.

Ком бураны инде басылган. Мусаның бөтен тәненә зәмһәрир суык үтә башлый, бармаклары туңа. Муса Гыйльми әби сузган җылы бияләйләрне эзли, таба алмый. Әбисен дәшә, ул да каядыр киткән инде.

Янына әнисе килгән, имеш, улының башыннан сыйпый. Муса, әнисенең кытыршы кулын тотып, мендәр итеп, яңагы астына куя. Һай, нинди йомшак, җылы ана кулы, каз мамыгы тутырылган мендәрмени!

Муса әнисен бик ярата иде, күңеленнән аңа һәр вакыт әллә нинди яхшылыклар эшлисе килеп йөрде. Шәфкатьле ана һибарына бик канәгать иде, үзенә артык бернәрсә таләп итмәде, булдыра алсаң, улым, сеңелләреңә бераз булыш, китап әйтә, кыз баланың бусагасы алтын булса да, хәер куеп кит, ди.

Газиз балалары өчен ана күпме газапланды, күпме төн йокыларын калдырды, бишекләрен тирбәтә-тирбәтә әлли-бәлләләрне күпме көйләде, күпме теләкләр теләде. Кабул булырмы соң алар, балалары бер заман барысын, рәхмәт әйтеп, үзләреннән аңа кайтарырлармы?

Муса гомерен бер әнисенә багышлый алмады, бар күңел җылысын яшь иленә бирде. Менә шунда инде улының кадерле әнисенә булган чиксез мәхәббәте дә чагылды.

Күптән билгеле бер хакыйкать бар: үз анасын яратмаган кеше башка аналарга изге эш эшли алмый. Ана һәм аналар һәр вакыт күзгә күренмәс җепләр белән бергә тоташкан булалар. Аларның берсенә яхшылык эшләсәң, икенчесе сөенә. Барысына да изге эш эшләү кулыннан килсә, син инде җирдә иң бәхетле кеше, сине инде беркайчан да, бер җирдә дә онытмыйлар...

Әнисе янына Мусаның сеңелләре — Зәйнәп белән Хәдичә йөгереп килгәннәр, икесе ике яктан әниләренең иңбашларына башларын салып абыйларына карыйлар, имеш, күзләрендә соклану һәм моң. Аннары барысы бергә Саелмыш болыннарына чыгып китәләр, имеш. Тирә-якларында чәчәк диңгезе. Алар иң матурларын җыялар, имеш.

— Боларын аеруча кадерләп саклагыз, мондый чәчәкләргә мин анда, еракта, Едлино урманнарында юлыккан идем, — ди Муса. Ул сеңелләренә соңгы күрәшкә ничек әзерләнүләрен сөйли, имеш.

Төш төш инде, күз ачып йомганчы кеше әллә кай араларга сикерә. Очсыз-кырыйсыз Оренбург далалары инде артта калган, Муса үзенең кадерле Әминәсе белән Мәскәү бакчаларында йөри, имеш. Алар юк кына сәбәпләрдән көлешәләр. Әминә тал чыбык кебек нечкә, зифа буйлы. Ул көлми дә кебек, елмая гына. Ул шундый инде, чәрелдәми, шатлыгы да, сөенүе дә эчтә. Менә алар кичке тымызык күлгәме, Мәскәү елгасынамы сүзсез генә карап торалар, тоник суда аларның пар күләгәсе тибрәнә. Башларын башка куйганнар, бер-берсенең йөрәк тибешләрен тоялар, имеш, су шуннан тибрәнә икән.

— Һай, бәгърем, кемнәр сине болай кыйнады? Йөзең күгәреп беткән ич. Бик авыртамы? — дип сорый, имеш, Әминә. Ул, имеш, төрмә камерасына килеп кергән, Муса ятагы янында утыра.

— Узар әле, син борчыла гына күрмә, җаным.

— Мин сине хәзер терелтәм, йом күзләреңне.

Муса күзләрен йома, Әминә аның уң яңагын чут итеп үбеп ала.

— Менә булды. Йөзең хәзер әүвәлгедән дә матуррак.

Алар тагын Мәскәү янындагы урманнарда, су буйларында йөриләр, электричкада баралар, имеш. Менә инде алар әллә Сокольники, әллә Измаил паркыннан култыклашып үтәләр, ул да булмый, Нескучный бакчага килеп чыгалар, Воробьево тавына менәләр. Таң сызыла, имеш. Бормаланып аккан Мәскәү елгасы күренә, акчарлак кебек ак җилкәнле көймә су өстеннән кыеклап йөзеп бара. Анда рәхәттер.

— Әминә, беләсеңме, кайдадыр шунда Герцен белән Огарев гомерләрен халык бәхете өчен көрәшкә багышларга ант иткәннәр. Мин шул турыда ялкынлы поэма язар идем. Син ничек уйлыйсың, язаргамы?

— Әлбәттә! — ди Әминә. Кинәт ул борчыла башлый. — Муса, Чулпаныбыз уянгандыр, әйдә тизрәк өйгә! — Алар үзләренең Столешников тыкрыгындагы бүлмәләре — «сыерчык оялары»на йөгерәләр, имеш.

... Муса инде театрда, бүген бәйрәм, бүген «Алтынчәч»нең премьерасы. Алкышлар давылы. Увертюра яңгырый. Әйе, музыка operаның җаны, аның сихри канатларында ук югары-югары күтәрелә, тыңлаучыларны үзенә ияртеп алып китә. Бу минутта бар җиһан юкка чыга, сәхнә генә кала. Муса Нәҗип Җиһановның талант көченә соклана. Ә тылсымлы музыка һаман яңгырый да яңгырый. Муса гаҗәеп бер бакчагамы, урмангамы атлый. Биредә дә музыка, тик хәзер бар табигать җырлый кебек. Илаһи музыка! Тагын алкышлар давылы. Кемгә болай кул чабалар? Җик Мәргән ролен башкарган Фәхри Насретдиновкамы, Алтынчәч — Галия Кайбицкаягамы, Тугызак ана ролендә уйнаган Мәрьям Рахманкуловагамы?! Аһ, нинди талантлы безнең җырчыларыбыз!

Музыка агыла, алкышлар ява, зал гөрли. «Авторларны, авторларны!» — дип кычкыралар. Нәҗип Җиһанов бер ялгызы сәхнәгә чыга. Халыкка баш ия, озын чәче каерылып төшә. Муса юк. Кайда ул?! Муса!!!

Тылсымлы музыка һаман яңгырый, аңа һичбер киртәләр юк, төрле телләрдә сөйләшүче бар халыклар да аңлый аны. Ул шулай бик-бик озак яңгырар, кешеләрне матурлыкка, гаделлеккә чакырыр...

Чү, тагын «Сагыну» көе ишетелә түгелме?!

## 30

Бу вакытта барлык җәлилчеләрне Варшава төрмәсеннән Берлинга күчереп бетергәннәр иде инде. Берлин казаматларында нинди генә ил, нинди генә халык вәкиле юк. Фашизм халыкларның кан дошманы — бу хакыйкать монда аеруча ачык күренә, бернинди махсус белешмә-

ләрнең хаҗәте юк, тәрҗемәче дә кирәкми, фашизмның шәрәлеге, явызлыгы сүзсез дә аңлашыла.

Берлин төрмәләре бик зур, коридорлары хәтсез күп, һава суларга тоткыннарны чиратлап кына чыгаралар. Шуңа күрә бер төрмәдә яткан тоткыннар айлар, хәтта еллар буе бер-берсе турында һичбер нәрсә белә алмыйлар. Кайчагында көтелмәгән очраклар да була. Нишлисең, монда да тормыш бит.

Чираттагы сорау алу вакытында Рушат Хисаметдиновны һуштан яздырганчы кыйнадылар, аннары, ярым үлек хәлендә, камерага китереп ташладылар. Кайчан аңга килгәндер — белми. Әллә күз кабаклары ачылмый, әллә һаман төн — берни күренми. Тамагы кипкән, теле шешкән. Бер йотым су, зинһар, бер йотым су бирегезче, дип күпме пышылдады ул, әмма су бирүче булмады, аның барлык ыңгырашулары җавапсыз калды — ул бер кешелек камерада ауный иде.

Күпмедер вакыттан соң — көннәр исәбе югалган инде — тикшерүче алдына яңадан килеп баскач, теге — симез йөзле, куш иякле, кыска муенлы, сул күзенә кара бәйләгән гестапочы мөмкин кадәр йомшак тавыш белән сөйли башлады. Ул, таш курчак кебек, башын уңга-сулга боргалаганга, бик сәер хәл килеп чыга иде: аңа бер ягыннан карасаң, бер кеше, икенче ягыннан карасаң, бөтенләй башка берәү сөйли төсле. Сүзләренең мәгънәсе дә үзгәрә кебек. Бер ягында зәһәрлек ташып торса, икенчесендә төчелек, астыртынлык ярылып ята.

— Кызганам мин сезне, егеткәем,— диде тикшерүче, Рушатның бугазына елан кебек шыпырт кына үрмәләп.— Сез укымышлы кеше, кулыгызда менә дигән һөнәрегез бар,— Хисаметдинов ветеринар врач иде,— нигә, нинди бөек идеаллар хакына шул кадәр газап алырга? Үҗәтләнергә? Киләчәк буыннар сезгә рәхмәт әйтер дип уйлыйсызмы? Юк, кешеләр тумыштан эгоист, алар үзләре турында гына кайгырта. Кирелегегезне ташласагыз — аны сезгә большевиклар таккан — сез дә шундый ук гади кеше. Бөеклек бер фюрерга гына бирелгән. Гади кеше булып сөйләшегез, юк белән башны катырмагыз. Безгә бит барысы билгеле, иптәшләрегез күптән инде гаепләрен таныды, аларны хәзер бимазалаучы юк. Бары тик ихлас күңелдән гаебегезне тануыгыз гына авыр язмышыгызны җиңеләйтә ала. Барысы да үз кулыгызда. Әлбәттә, тиешле җәзасын алырсыз — һәр җинаятьнең үз җәзасы була — ләкин гомерегезне саклап калырлар. Әгәр инде моннан соң да кирелегегезне дәвам иттерәсез икән, исән калырсыз дип, һич әйтә алмыйм.

Хисаметдинов моннан алдагы сораулар вакытындагы кебек бер үк сүзләрне кабатлады:

— Минем бер гаебем дә юк, булмаганны таный алмыйм.

«Хәзер тагы кыйный башлый» дип уйлады Рушат, инстинкт белән башын иңнәренә яшереп. Бу тикшерүченең гадәте — пистолет түтәсе белән башны төю. Тик бу юлы ул һәрвакыттагы гадәтен нигәдер үзгәртте, пистолетын чыгармады. Әллә уйга калган сыман, әллә явыз мыскыллау белән көлемсерәп әйтте:

— Ул чагында легионер Гайнан Кормаш турында сөйләгез. Нәрсәләр беләсез?

Хисаметдинов сак иде. Гитлерчыларга Гайнан Кормашның музыкаль взводта кече җитәкче булганы, аларның Рушат белән бер взводта эшләүләре билгеле. Шул билгеле нәрсәләр турында гына сөйләде Рушат, артык бер сүз ычкындырмаска тырышты.

Тикшерүче башын чайкап, йөзендә берьюлы ике төрле хис чагылдырып тыңлап утырды да, әллә көрсенеп, әллә мыскыллап әйтә куйды:

— Менә сез нинди беркатлы сабый: Кормашны бөтен көчегез белән аралаган буласыз, ул гадел, ул яхшы командир, фәлән-төгән дисез. Ә ул сезнең турыда бөтенләй башкача сөйләде. Менә укыгыз, укы,— дип, Хисаметдинов алдына язулы кәгазьләр салды.— Рәхим итеп, үз

күзегез белән укыгыз, сезнең гадел кешегез сезнең турыда нәрсәләр сөйли.

Кәгазьләргә карап алуга Хисаметдиновның тыны капты. Моңарчы Рушат баш тартып килгән нәрсәләрне Кормаш ачыктан-ачык таный иде. Хисаметдиновның бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте, йөзе үзгәрде. Ул тикшерүченең мәкерле алдавына каба язды. Ярый әле, вакытында аңына килеп өлгерде.

— Ышанмыйм, Кормаш болай сөйләмәс! — диде нык итеп. — Кәгазьгә теләсә ни язып була. Безне күзгә-күз очраштырыгыз.

— Сез шуны телисезме?

— Әлбәттә!

Хисаметдиновны алып киттеләр.

Камерада ул борчулы тирән уйларга чумды. Тагын һәм тагын тикшерүченең мәкерле сүзләре, Гайнанның күрсәтмәләре йөрәген көйдереп алды. Ышанмаска мөмкин, әмма чынын белә алмыйча газаплanulар, шиккә бирелүләр никадәр авыр. Бер шикләнгән кешенең башына ихтыярыннан тыш нинди генә уйлар килми, алар сине ничек кенә туракламый. Мөгаен, бу садист-тикшерүче Рушатны нинди утларга ташлаганны яхшы белгәндер, шуңа күрә ашыкмый. Рухи газаплanulар физик газапланууларга караганда мең мәртәбә авыррак икән. Менә нәрсә ул Берлин төрмәләрендәге «психологик эшкәртүләр»! Варшава төрмәсендәге «физик эшкәртүләр» беренче адымнар гына булган икән! Рухи әрнүләрнең кайчан бетәсен һич белмисең, үлереп кычкырасы, акылдан язып стенага үрмәлисе, йодрыкларыңны канга батырганчы камера стенасын дөбердәтәсе, мине тизрәк күзгә-күз очраштырыгыз! дип кычкырасы килә. Иң якын иптәшеңнең хыянәтен күтәрү — ай-һай, авыр. Рушат бит Гайнан Кормашны корыч кеше дип саный иде, ул берне сөйләп, икенчене — беренченең нәкъ киресен, бер вакытта да эшләмәс дип инана иде. Иптәшләренә хыянәт иткәч, кешедән нәрсә кала? Юк, бәлки ул һичкайчан чын кеше булмагандыр. Андый бәндәне кешегә санау нинди беркатлылык ул, гафу ителмәслек нинди түбән ваемсызлык. Рушат үзе шундый вак, талымсыз, сукыр кеше идеме соң әллә?

Иртә саен аны һава суларга чыгарсалар да, ул инде саф һаваның ләззәтен тоймый башлаган иде — гүя зәһәр агу йота. Менә шундый көннәрнең берендә, прогулка вакытында, аның артка куйган кулына кәгазь кисәге төрттеләр — кем икәнен Рушат күрми калды, артка борылып карый алмады. Әллә нәрсәләр уйлап, камерага кайтканчы түзде. Камерада ул учына йомарлаган кәгазьне укыды. Бу шигырь иде. Аны кем күчергәндер — билгесез, әмма шигырьнең Муса Җәлилнеке яки Гайнан Кормашныкы икәнен Хисаметдинов чамалады. Ул «Юату» дип атала иде.

Илгә кайткач, урының түрдә булыр,
Яшь балалар алыр уратып.
Кайгы сине хәзер кыерсытса,
Шатлык назлар, җиңү юатыр.
Син сөйләрсең җанлы әкият итеп
Безнең авыр яшерен көрәшне.
Бу әкияттә күпме ялкын барын
Зирәк яшьләр әллә күрмәсме?
Без әйтербез, безгә кирәк түгел
Мактау, бүләк, чәчәк бәйләме.
Иң зур бүләк безгә, барыбызга да —
Илнең уртак җиңү бәйрәме.

Килер ул көн, дускай, тик борчылма,
Бары өметең сүнә күрмәсен!

Рушат бу шигырьне бер дә, ике дә укыды. Ул ничектер үзеннән-үзе хәтердә кала иде. Укыган саен күңелгә көч бирә, рухны күтәрә, кара уйларыңны куа. Хәзер Рушат бу кадәр шикләнүләре, Гайнан турында

эллә нәрсәләр уйлап бетүләре өчен үзеннән-үзе ояла башлады. Әйе, шагыйрь дөрес әйткән: тик өметең сүнә күрмәсен!

Берничә көннән соң, һава суларга чыгарганда, Рушат коридорда Гайнан Кормашның үзе белән дә очрашты. Надзиратель артка кала төшкән иде, шуннан файдаланып, Гайнан:

— Рушат абый, сез мине саттыгызмыни? — дип сорады.

Хисаметдинов шаккатты.

— Кем әйтте?

— Тикшерүче.

— Шул ук сүзләрне ул миңа да әйтте. Хәтта сезнең күрсәтмәләрне үземә укырга бирде.

— Кабәхәтләр! — диде Гайнан чиксез нәфрәт белән. — Нинди генә мәкерле хәйләләр кулланмыйлар.

Шул чакта алар янына надзиратель йөгереп килеп җитте, җикеренә башлады, икесен ике якка этеп җибәрде. Ләкин откынннар инде җиңел сулап алды, ярым караңгы төрмә коридорына кояш нуры төшкәндәй булды, ул яктырып китте сыман.

Хәзер күзгә-күз очрашуга Рушат Хисаметдинов ярыйсы тыныч барды. Андый чакта дустыңның турылыклы булуына тагын бер тапкыр ышанудан да зуррак нәрсә юк. Әйдә, тагын кыйнасыннар, газапласыннар, син инде аннан курыкмыйсың, чөнки хәтәррәк газапны татып өлгергәнсең!

Сул күзенә кара бәйләгән тикшерүче бүлмәсенә ике сакчы куллары богауланган Гайнан Кормашны кертеп, үзләре чыгып киттеләр. Гайнан белән Рушат күзгә-күз карашып алдылар. Гайнанның бит алмалары, чигәләре күм-күк, авыз почмакларында кутырлар. Ябыккан, күзләре эчкә баткан, утыруы нечектер табигый түгел, кузгалмаска, селкенмәскә тырыша.

Коридорда, көтелмәгән очрашу вакытында, Хисаметдинов боларны күрмәгән иде, ахрысы, артык каты дулкынланган булгандыр.

— Бу кем, таныйсызмы? — дип сорады тикшерүче башын боргалап. Шунда ук ике яңагында ике төрле мыскыллау чагылды: берсендә куркыту, икенчесендә астыртын көлү.

— Бу кеше — Рушат Хисаметдинов. Без легионда аның белән бер взводта хезмәт иттек.

Шул ук сорауны тикшерүче Хисаметдиновка да бирде. Хисаметдинов шулай ук бу кешене таныганлыгын раслады.

— Хәзер Хисаметдиновның яшерен эшләре турындагы күрсәтмәләрегезне кабатлагыз. Кисәтәм, — тикшерүче Кормашка бармак янады, — бер күрсәткәнегездән баш тартасы булмагыз!

— Хисаметдиновның бернинди яшерен эшләре турында белмим, бу турыда мин сезгә бернинди күрсәтмә бирмәдем, — диде Гайнан нык итеп.

Тикшерүченең ике яңагы да кыйшайды, иреннәре тартылды, куш ияге югалды кебек. Ул үз-үзен тыя алмыйча кычкырып җибәрде:

— Ә болар кем күрсәтмәләре!?

— Белмим, минеке түгел!

— Легионда кем листовкалар таратып йөрде?

— Листовкаларны мин берүзем тараттым.

Тикшерүче пистолет түтәсе белән Гайнанның чигәсенә китереп сукты. Кан чәчрәде. Кан исе гитлерчыны шаштырды, ахрысы, ул Гайнанны җиргә егылгач та типкәләүдән туктамады.

Рушат Хисаметдинов әле белми иде: батыр Кормаш, бар гаепне үз өстенә алып, икенче иптәшен дә үлемнән аралый иде.

Хисаметдиновны алып киткәндә, Гайнан һаман идәндә ятып калды. Ни үкенеч, Рушат аңа борылып карый алмады.

Берлин өстеннән әле яңа гына яшенле яңгыр шаулап үткәнме, әллә чиләкләп яңгыр коярга җыенамы, — күктә кара-кучкыл болытлар актарыла. Кайдадыр болыт арасыннан кояш күренә, ахрысы, тәрәзә турысындагы калын болытның чит-читләре агара төшкән. Әмма бер минуттан барысы үзгәрә, яктылык каплана, камера эче караңгылана. Тәрәзә каршында чайкала төшеп басып торган Гайнан Кормашның йөзеннән күләгәләр шуып үтә. Аның имгәнгән кулы сызлый, йөзендә кан оешып каткан, башы чатный, ләкин бу минутта ул гүя аларны онытткан, зур күзләре, үз эшен ахыргача башкарып чыккан кешенеке кебек, тыныч, хәтта беркадәр ваемсыз карыйлар төсле, тик яшен яшьнәп киткәндә генә аларда чиксез кыюлык чагыла, әйтерсең хәзер таш стенаны вата башлар бу егет.

Төрмәләрдә Гайнан Кормашны башка иптәшләреннән күбрәк, катырак газапладылар. Аңардан бүтәннәр өстеннән сөйләүне теләделәр, бу — синең үз язмышыңны җиңеләйтер, диделәр. Гайнан беркемне бутамады, киресенчә, аларны араларга тырышты, ул, бернәрсә белмим, моны мин үзем генә эшләдем, диде. Кагыйдә буларак, күпме кыйнасалар да, ул барыбер шуны гына кабатлады. Әгәр монда булса, күрсә, Дим Алишев Кормашка нәрсә әйтер иде икән, тагын «уйнамый уйныйсың» дияр идеме? Аның биредә булмавы яхшы, бәлки исән калыр, илгә кайтып сөйләр...

Ил! Бу сүз кинәт искә төшкәндә дә Гайнанның күңелен әллә нишләтеп җибәрә иде. Тик ул аны зәгыйфьләндермәде, бар көченнән мәхрүм итеп егып салмады, ә актык көче белән көрәшкә ташлады. Гайнан белә иде, моннан аны исән килеш чыгармаслар, иптәшләренә аз гына булса да үпкәләмәде, тик ил өчен бик аз эшләп калуына әрнеде.

Ул һаман тәрәзәдән карый, болытлар актарыла да актарыла, аратирә яшен яшьни, күк күкри. Әй, дәһшәтлерәк күкрәсен иде!

Билгеле, бу яшьтә кешенең, нинди генә газаплар күрсә дә, үләсе килми. Кеше яшәр, эшләр, рәхәт күрер, хыялларына ирешер өчен туа. Гайнан бик аз яшәп, бик аз эшләп калды. Бала чактан ук ул шагыйрь булырга хыялланды, талант дигәне дә бар иде бугай, ләкин ул бер китап та чыгара алмый калды, тик берничә шигыре генә көндәлек матбугатта басылып чыкты. Дөрес, сугыштан соң, тормыш тәҗрибәсе туплагач, җиң сызганып язармын дигән иде, инде анысы да тормышка ашмас хыял гына булып калды.

Яшь чакта кешенең энергиясе ташып тора, нәрсәгә тотынса да, көче җитәр кебек. Гайнан, күңел биреп, үзешчән сәхнәләрдә уйный башлады. Уңыш та казанды шикелле, әмма бу бары тик яшьлектә үзенне эзләү, анда-монда ташлану гына иде. Бер килеп, әсирлектә бу һөнәре ярап куяр дип башына да китермәде, әлбәттә. Бигрәк тә ике генә сүздән торган тәнкыйть фикере әйткән «бөек тәнкыйтьче» Дим Алишевтан мактау ишетермен дип уйламаган иде. Билгеле, шаярып түгел, чынлап торып әйтсәләр дә, Гайнан «уйнамый уйный торган» артист булырга теләр иде, әмма бары тик тормыш спектаклендә генә шул талантын күпмедер күрсәтергә туры килде аңа.

Актарылган болытларга тагын бер тапкыр карап алгач, Гайнан, чайкала-чайкала, камера буйлап йөрергә тотынды. Ахыр килеп, ул үзенең язмышына рәнҗеми иде. Хикмәт ак сакаллы карт бабай булганчы яшәүдәмени, бар гомерне халыкка, илгә файдалы булып үткәрүдә бит. Гайнан куркак куян булып көн итмәде, һәрхәлдә, иптәшләре аның турында начар сүз әйтмәсләр шикелле. Иң кыен чакларда, булдыра алганча, аларның язмышын җиңеләйтергә тырышты, бар җаваплылыкны үз өстенә ала килде. Моның нәрсә белән очланасын ул бик яхшы белсә дә, бер генә тапкыр да намусына каршы бармады. Шуңа күрә үз вөж-

даны алдында газапланмады, монысын дөрес эшләмәгәнмен дип үкенмәде.

Кайчагында Гайнан күзләрен йома, үткәннәрен уйлап тын кала. Менә ул Бәрәңгедә студент, менә Актүбәдә мәктәп директоры. Әйләнә-тирәсендә балалар, күңелле шау-шу. Шул балалар алдында аның мәңге саф, батыр, намуслы булып каласы килә. «Менә безнең укытучыбыз кем булган!» дип балалар горурланып әйтсә, нинди бәхетле булыр иде ул!

## 32

Ниһаять, тикшерүләр, сорау алулар, газаплаулар тәмамланды. «Гаепләре» азрак булган яки расланмаган легионерларны, суд булганын көтеп тормыйча ук, төрлесен төрле концлагерьларга — Бухенвальдка, Дахауга һәм башка шуның ише яман ат алган җирләргә озата башладылар. Кайбер бик бәхетлеләре ирекә үк чыгарылды. Төп гаеплеләр — татарлардан унбер, немецлардан бер кеше Тегель төрмәсеннән Моабитка күчерелде. Биредә алар суд булганын көтәргә тиешләр иде. Тегельдән күчерелгәндә Абдулла Алиш ирекә ычкынган бер танышы аркылы Шәфи Алмаска кечкенә генә хат язып җибәрә алган. «Үзем өчен, дигән Алиш, һични сорамыйм. Муса турында кайгыртсагыз иде. Ул бит безнең татар халкына бик кирәкле кеше...»

Шәфи Алмас бу язуны укыгач сүгенгән генә.

Муса ак эмигрантларга баш иеп тә тормаган. Хәтта төрмәгә бернке тапкыр килеп киткән Илдархан Идрисигә дә мөрәҗәгать итмәгән. Илдархан төрмәгә барырга җыенуы турында энисе белән һичшиксез киңәшкәндер, бәлки бу тәкъдим энисеннән үк чыккандыр әле. Муса хәзергә хәтле Шәмсинур турында анык кына белми. Сорау алулар вакытында Муса аңардан шактый курыккан, аны, һич югында, шаһитлеккә чакырырлар дип көткән иде. Үткен акыллы, күзәтүчән Шәмсинур нәрсәдер сизгәндер — Әхмәт бу турыда сөйләгән иде бит — теләгәндә ул шактый зур зыян да китерә алыр иде. Әнә Солтан Гарип нинди эшәкелекләр эшләде. Мәхмүт Ямалетдинов та аннан калышмады. Ачык белмәгән ваграк «чукмарбашлары» күпме булгандыр тагын. Әшәкелек дигәндә сатлык җаннар тырыша инде. Ә Шәмсинур Идрисинең андый явызлыгы ачык сизелмәде. Әллә ул бик үткенме, әллә... Бу сорауны Муса үз-үзенә күп мәртәбәләр бирде, ләкин җавап кына таба алмады. Ахырда шундый карарга килде: әгәр Шәмсинур күңеле белән дә гитлерчылар яклы булса, аңа мөрәҗәгать итүе — түбәнлек, әгәр инде ул ару намуслы булса, Муса үзенең хаты белән аңа күләгә төшерергә теләми, чөнки аның хаты турында барыбер беләчәкләр.

Илдархан, ихтимал, берәр нәрсә китергән дә булгандыр, әмма төрмәчеләр Мусага андыйны ирештермәде. Ул, эшчеләр барагында торучы дусларына хат язып, җылырак кием, бераз икмәк сорады. Дуслары ярдәм кулы сузганнардыр булса кирәк — бер надзиратель, сер итеп, аңа шул турыда пышылдады — әмма бу юлы да төрмәчеләр Мусага берни бирмәде. Шулай да бер «миһербанлысы» табылган, ахрысы, ә бәлки төрмәдә эшләүче рус хатыннарыннан берсе яхшылык иткәндер, ни генә булмасын, кемдер аңа чиста ак күлмәк китереп бирә алган, чөнки үз күлмәге күптән инде ерткаланып, канга буялып беткән булуы билгеле.

Төрмәдә дә Муса үзенең җитәкче икәнен, ахыр чиккәчә иптәшләренә ярдәм итәргә тиешлеге турында онытмаган. Бер көнне һава суларга чыгарылганда ул Фәйзелхакны күреп ала. Иптәшләре аның бар «гаебен» үз өсләренә алганга, Фәйзелхакның котылу ихтималы туган. Муса Җәлил аңа шул турыда әйтеп, ирекә чыга калса, Франкфуртка барып, икенче вокзал янында сыра заводы бараклырыннан Шилов дигән кешене эзләп табарга куша, ул сиңа ярдәм итәр, ди.

Муса төн уртасында уянды. Камера дөм караңгы, һава тревогасы башлана, ахрысы — кайдадыр тоныкк кына гөрселдәүләр ишетелә. Вакыт-вакыт төрмә диварлары әкрен генә дерелдәп куя.

Йокы качты. Муса уйлана башлады. Хәзер беренче нәтиҗәне ясарга була инде. Нәрсәдән тотынырга — кимчелекләрдән, хаталарданмы? Юк, алар никадәр җитди, зур булмасын, төп эшне алар билгеләми. Туктаусыз һәм газаплы сорау алулар вакытында иптәшләре үзләрен нык тотты, бер-берсе өстенә кирәкмәгәнне сөйләмәде, киресенчә, кайберләренең гаепләрен үз өсләренә алып, аларның язмышларын җиңеләйтергә тырыштылар, алар һич тә үзара сүз куешмады. Һәрберсе үз вөҗданы кушканча эшләде.

Тикшерүчеләр Мусага һәм җәлилчеләргә утә мәкерле сораулар биреп килде, Рәхим Саттарның нинди задание белән качканлыгын белергә теләделәр. Рәхим гитлерчылар кулына эләккәч, аларга берни әйтмәгән булса кирәк, чөнки тикшерүчеләрнең аяк терәп сорарлык бернинди фактлары булмаган. Билгеле, аны бик нык газаплаганнардыр — моны Муса үз башыннан кичереп белә — әмма серне ачуга, иптәшләренә хыянәт итүгә караганда, Рәхим үлүне артыграк күргәндер, чөнки исән булса, аны Берлинга бик тиз китереп җиткерерләр иде.

Ян Габдуллинның[1] исемен исә тикшерүчеләр телгә дә алмады. Димәк, ул гестапо кулына гомумән эләкмәгән. Бәлки үз ягыбызга чыга алгандыр. Эх, шулай булсачы! Туган ил аларның әсирлектә язмышка буйсынып тик ятмауларын, дошманның үз өнендә аңа каршы батырларча көрәшүен белер иде.

Провал никадәр зур булмасын, ахыр килеп восстание барып чыкмаса да, айсберг, ягъни сугышчан «бишлекләрнең» барысы диярлек исәнимин калды, алар әле үзләрен бер күрсәтерләр. Гестапо аларга барып җитә алмады. Ул башлыкларны «сыпыру»белән канәгатьләнде булса кирәк. Яшерен оешманың немец патриотлары, поляк партизаннары һәм башка милли легионнар белән бәйләнеше барлыгын гестапо шулай ук анык белә алмады, дөресрәге, ниндидер татарларның шундый киң колач белән эшли алуларын башына анык китермәде. Татарлар үзләренең татарларын гына белә, ул кыргыйларга башкасы ят, дип хөкем йөрттеләр бугай. Шулай булса да, гитлерчылар Муса Җәлил белән аралашкан зәңгәр күзле бер немецны кулга алды. Ул җәлилчеләр кичергән барлык газапларны кичерде. Ихтимал, аңа ариец башы белән түбән раса кешеләренә «җинаятьчел мөнәсәбәт күрсәткәне өчен» катырак та эләккәндер, ә коммунист булганга аңардан аеруча үч алганнардыр. Аны һәр вакыт аерым — ялгыз камерада тоттылар, татарлар белән аралаштырмадылар. Тик Муса Җәлилдән генә берничә тапкыр аның турында сорау алдылар, күзгә-күз очраштырдылар. Муса мин бу кешене белмим дип кенә җавап бирде. Немец та шуны кабатлады. Ачуы кабарган тикшерүче аны барыбер гаепле дип тапты. «Кыргый татарларга да, сиңа да бер генә җәза — гильотина!» дип кычкырды.

«Әйе, — дип уйлады соңыннан Муса, — фашизм дөньядагы бар халыкларның, шуның белән бергә, немец халкының да кан дошманы. Фашизмны бер милләткә генә — герман халкына гына кайтарып калдыру дөрес түгел, фашизм социаль күренеш, аны империализм тудырган, ул аның уйнаштан туган баласы». Башта гитлерчыларны бөтен немец халкы белән бер итеп карый язуы белән Муса никадәр тирән ялгышкан булган. Ул Демблин лагерен, госпитальдә врач белән сөйләшүен хәтерләде. Рәхмәт, иптәшләр зур хакыйкатьне вакытында аңлаттылар

---

[1] Ян Габдуллин фронт сызыгын үтеп, 1943 елның 19 сентябрендә Прилуки шәһәре районында үз ягыбызга чыга. Партиянең Үзәк Комитеты исеменә Муса Җәлил житәкчелегендә әсирләр арасында яшерен оешма төзелүе, аның эшләгән эше турында докладной яза. Бу документ сакланган. Ян Габдуллин үзе 1944 елда фронтта батырларча һәлак була. Ул тумышы белән Башкортстан егете.

аңа. Аннары Муса үзе өчен сөенде. Ул шул хакыйкатьне аңларлык дәрәҗәдә югары торган...

Муса үлемнән курыкмады. Ул фронтта чакта ук бу турыда шулай катгый уйлаган иде, хәзер дә бу фикере үзгәрмәде. «Үлем турында башка берәр уй килеп төшә икән, болай фикер йөртәсең: «Үлемнән соң да яшәү бар бит әле. Бу поплар, муллалар вәгъдә иткән «теге дөнья» тормышы түгел, әлбәттә. «Теге дөньяның» юклыгын без беләбез. Ә менә үлгәннән соң халык күңелендә, халык аңында яши торган тормыш бар. Әгәр дә мин исән чакта нинди дә булса зур һәм мөһим, үлми торган эш эшләп калдыра алсам, моның белән мин икенче кабат яшәргә — үлемнән соң яшәргә хокук алам... Әгәр шуңа ирешә алам икән, ни дип үлемнән куркырга?»

Шул турыда уйланганда Мусаның күз алдына тагын Ясәви карт килде: мамык эшләпә кигән, шул ук кечкенә ак сакал, текә яр башында басып тора. Муса аның янына менә, ике куллап күрешә. Карт аның җилкәсеннән сыйпый.

— Рәхмәт, улым, халкыбызны хур итмәдең. Халык сине онытмас. Газиз иптәшләрең дә һәр вакыт аның күңелендә булыр.

Алар иртәнге кояш нурларында балкыган Иделгә карап торалар. Нинди киңлек, нинди хозур матурлык!

Озакламый аларга суд булыр, судтан соң, аның карарын раслаганчы, тагын күпмедер вакыт үтәр. Санаулы көннәр тиз үтә үтүен, ләкин кирәгенчә файдалана белсәң, шул көннәрдә дә берәр нәрсә эшләп булырдыр әле, дип уйлады Муса. Ул язарга тиеш —үзе өчен дә, иптәшләре өчен дә — чөнки аларның кайберләре язучылар, шагыйрьләр иде бит, кызганычка каршы, талантлары тамырда кипте. Соң булмас борын уртак уйларны кәгазьгә төшерергә кирәк, алар югалмасын, киләчәк буыннарга көрәш коралы булып калсын.

Яшәүнең үзе кебек үк кайнар бу теләкне ни дип әйтергә? Илһаммы? Башны палач балтасына тоткан хәлдә илаһи илһам киләме? Сугышка кадәр илһам турында фәлсәфә сатучы кайберәүләр язар өчен иң элек җан тынычлыгы, тирән рәхәтлек минутлары, ләззәтләнү кирәк, дип әйтәләр иде түгелме? Муса бит биредә боларны һичнничек белми, әмма язасы килә. Бу аның каләмгә тотынмыйча түзә алмый торган бердәнбер теләге. Ул элек тә күп язды, хәзер исә бөтенләй бүтәнчә җырларга ашкына.

Шулай да нәрсә соң ул тым-тылсымлы илһам? Бәлки Мусаны шагыйрьләргә хас булмаган беркатлылыкта гаепләрләр? Аңа калса, илһам яралгысы барыннан да элек эшлисе эшнең кирәклелеген тирәнтен аңлауда, шуны күңел белән тирәнтен тоюда бит. Югыйсә, теләсә нинди житди эш тә уен гына булып кала. Мусаның беренче иҗат җимешләре, дөресрәге, иҗат яралгылары солдаткалар соравы буенча аларның сугыштагы ирләренә язган сәлам-хатлар булды. Ул хатларның никадәр кирәк, никадәр мөһим икәнен бәләкәй Муса солдаткаларның чырайларына, күзләренә карап аңлый иде. Күрше-күлән солдаткалар бер вакытта да Мусадан илһамың бармы дип сорамады, бары тик берничә юл хат язып бирүен генә үтенде. Һәм Муса бар эшен ташлап хат язарга утырды, бар тырышлыгын шуңа бирде. Соңыннан, үзеннән чыгарып, хатларга җырлар да өстәде. Җыр белән күбрәк нәрсә әйтеп була шикелле, чөнки җырларны тыңлаганда кырыс солдаткаларның күзләренә дә ихтыярсыз яшь килә, кайберләре: «И, Муса балакаем! Чебешкәем!» дип кочып үбәләр дә иде.

Хәзер дә күңеле Мусага: «Яз!» дип эндәшә шикелле. Шагыйрь бу эчке чакыруны аермачык ишетә. Билгеле, хәзер аның тойгылары тирәнрәк, фикерләре житдирәк. Шунда ук аның башында аерым шигъ-

ри юллар, строфалар туа, кайчакта күптән уйланып та язылмый калган яки язылып бетмәгән шигырь фрагментлары исенә төшә. Элек аларның я дәвамнары, я азаклары бик үк ачык булмый иде. Хәзер исә шундый төгәл балкыйлар, кулына кәгазь белән карандаш эләксә, бернигә карамыйча, сулыш та алмыйча язар да язар иде. Аның күңелендә илгә, халкына булган чикләнмәгән саф мәхәббәте язгы елга кебек шаулый. Бу изге мәхәббәт дошманнарга булган көйдергеч нәфрәт белән бергә ургыла. Бу ике башлангыч — гүя аның илһамына төп этәргеч иде.

Иле, халкы турында уйлаганда, шуларның аерылгысыз бер кисәге булып, Мусаның күңелендә һәр вакыт сөекле Әминәсе, нарасый баласы Чулпан гәүдәләнде. Алардан башка аның өчен ил дә ил, халык та халык булмас иде шикелле. Әсирлектә иң хәтәр адымнарны атлар алдыннан ул һәрчак күңеленнән шушы күз нурлары белән кат-кат киңәште, алар гүя аңа һәрвакыт фатиха биреп килделәр. Муса бер нәрсәне бик яхшы аңлый иде: ул үзенең жаннан да артык сөеклеләренә, фронттан кайткан солдат шикелле генә, болай гына кайта алмый. Дошманны җиңеп кайткан сугышчыдан өстәмә рәвештә бер нәрсә соралмый, барсы аңлашыла. Ә әсирлектән кайткан кешедән: син дошман тылында җиңү өчен нәрсә эшләдең дип беренче чиратта сорарлар. Моңа туры, ачык җавап бирергә кирәк, сүз уйнатып кына котылып булмас, кызгандыргыч сүзләрнең дә бу очракта мәгънәсе юк, дошман илендә әсирләргә гөлбакча хәзерләп куелмаганны һәркем белә. Син коммунист идең, илне мактап, аның намына батырлык күрсәтергә ант итеп җырлар яздың, башкаларны шуңа өндәдең, ә үзең ни кылдың соң?

Иң газаплысы тагын шунда: ул инде иле, Әминәсе һәм Чулпаны белән күзгә-күз карап сөйләшә, эшләгән эшләрен аларга үзе күрсәтә алмас. Бик ихтимал, илдә аның турында дөрес хәбәрне дә бәлки тиз генә белмәсләр, ә кара күләгәле сүзләр күп йөрер... Ничек итеп аларга чын хакыйкатьне җиткерергә? Моның өчен бердәнбер юл — аның җырлары. Үзен фашистлар төрмәгә япты, бәлки башын да кисәрләр, ә җырларны төрмәгә ябарга да, башларын кисәргә дә мөмкин түгел һәм Мусаның күңелендә иң яхшы, иң саф шигырьләрнең берсе бөреләнә:

Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,
«Ул егылган арып»,— дисәләр,
Син ышанма, бәгърем!

Сиңа миннән хәбәр китерсәләр,
«Алмаштырган илен»,— дисәләр,
Син ышанма, бәгърем!

Илдән киттем ил һәм синең өчен
Автоматым асып аркама.
Илемне һәм сине алмаштыргач,
Җирдә миңа тагын ни кала?

Шигырьдә ул сөеклесе Әминә белән бер генә тапкыр сөйләшмәде. Йөрәгенең иң тирән җирләреннән аңа карата әйтелгән иң мөкатдәс сүзләр ургылып чыкты. Кайчак шул Әминә һәм кадерле кызы Чулпан турында уйлый-уйлый кыска, борчулы йокыга талды һәм татлы төш күрде.

Төштә миңа нәни кызым килде,
Чәчләремне сыйпап тарады...

Чыгып киттек шуннан без болынга,
Гизеп йөрдек чәчәк диңгезен.
Нинди татлы — яшәү, көчле — сөю!
Нинди якты, иркен — җир йөзе!

Уянгач та Муса бик озак нәни кызыннан аерылырга теләми. Күзләрен йомса, шунда ук күз алдына тагын Чулпаны йөгереп килә, аның

янында Эминәсе. Имеш, алар Мәскәүдә, Столешниковта, юк, алар инде Казанда, Казанка буенда. Суда ак үрдәкләр йөзә.

— Эти, эти, алар батмасмы? — дип сорый Чулпан.

— Юк, кызым, үрдәкләр суда батмый алар.

## 33

Ниһаять, яктыра. Надзирательләр камерага керәләр — тоткыннарның киемнәрен бирергә, ятакларын стенага кайтарып бикләп куярга.

Бу камерада алар өчәү. Бельгияле Андре Тиммермансны бирегә күптән түгел генә күчерделәр. Башта Муса аңардан бик сакланды, провокатор була күрмәгәе, дип курыкты. Андре шик уятырлык бер ни эшләмәде. Ул эчкерсез, самими, ачык чырайлы егет иде. Мусаның аңа булган карашы әкренләп үзгәрә барды, аннары хәтта дуслашып киттеләр. Муса үзенең иң яхшы шигырьләреннән берсен аңа багышлады. Гади шартларда якыннан танышу, дуслашу озаккарак сузыла, төрмәдә — икенче. Монда кешегә бәя биргәндә иң элек һәм барыннан элек аның фашистларга булган мөнәсәбәте искә алына. Бу аның үзенә күрә визит карточкасы. Андреның фашистларга каршы көрәшкән өчен төрмәгә утыртылуын белгәч, Муса инде аңардан сер саклап тормады.

Хәмер, шәраб безгә булмас инде,
Яшебезнең кайнар тамчысын
Бокалларга салып күтәрербез,
Шуның белән күңел ачылсын.
Шул яшь белән кырык өченче ел
Алып китсен йөрәк ярасын!
Каршы алыйк якты өмит белән,
Бәхет, шатлык белән яңасын!

...Бу яңа ел безгә татлы ирек
Һәм бәхетле яшәү китерсен.
Ул салдырсын кулдан богауларны
Һәм күзләрдән яшьне киптерсен.

...Шушы елда, дустым, житәкләшеп,
Кайтсак иде туган йортларга.
Балаларны, хатын, туганнарны
Данлы җиңү белән котларга.

Муса Андрега үзенең совет шагыйре икәнен, фашистларга каршы политик эш алып барганлыгын, хәзер суд көтүен, аны, иптәшләре белән бергә, үлем җәзасына хөкем итәчәкләрен сөйләде. Аңарда үлем алдыннан була торган берниндн курку, тетрәү күрмәде Андре. Бу кешенең рухи халәтенә аның исе китте. Совет кешеләренең «тимер ныклыгы» турында Андреның, әлбәттә, ишеткәне бар иде, әмма ул гаҗәеп кешеләрнең үзләрен моңарчы күрә алмады. Муса белән танышкач, аңа — бу кыска буйлы, саргая башлаган ябык йөзен сакал-мыек баскан кешегә бер могҗиза итеп карады: бу кадәр рухи ныклык каян килә аңа, диннәнме әллә?

Муса көлемсерәде.

— Юк, Андре, мин диннәргә дә, аллаларга да ышанмыйм.

Андре, чиксез гаҗәпләнеп:

— Кешегә рухи терәк, иман кирәк бит! — диде.

— Иманым бар минем, Андре. Мин коммунистик идеалларга ышанам.

Андреның гаҗәпләнүе тагын да артты.

— Мин моны... аңлап бетермим, Муса.

— Аңларсың әле. Тормыш аңлатыр, туган!

Андре татарлар турында бик томанлы белә иде. Алар кайдадыр Россия киңлекләрендә яшәүче нindидер кыргый халык, күзләре кысык. Ләкин Муса кысык күзле түгел, кыргый да димәссең аны, ул бик укымышлы, югары мәдәниятле. Әдәбият, сәнгать, шигърият турында тирән фикер йөртә, үз әдәбияты турында гына түгел, дөнья җәүһәрләре турында да белеп, эрудиция белән сөйли, үзе «Алтынчәч» либреттосын язган. Музыка турында да аның фикерләре гаҗәп тирән.

Көннәр әкрен генә үтә торды. Муса Андредан үзенең иң зур теләген яшермәде: аңа язар өчен кәгазь кирәк. Тоткынлыкта язган күп кенә шигырьләре бар, күңелдә яңалары ташып тора. Ул барысын яттан белә, үзе үлсә, шигырьләре дә үләчәк. Аларны саклыйсы, кәгазьгә төшерәсе, илгә кайтарасы иде. Элегрәк төрмә кухнясында бер татар эшләгән, ул, ак калпагы астына яшереп, аңа әйбер төрә торган сары кәгазь кисәкләре китерә торган булган, карандаш төпчеге биргән, хәзер ул күренми. Муса бик кыен хәлдә калган.

Бельгиялеләргә, илләренә хат язар өчен, төрмә лагеренда аз-маз кәгазь саталар иде. Андре шул кәгазьләрне берсүзсез Мусага бирде. Муса мең рәхмәтләр әйтеп алды. Аннары камерадагы өченче иптәшләре поляк Ян Коцура да — ул кухняда эшли иде — Мусага сары кәгазь кисәкләре китерә башлады. Муса шатланып туя алмады, дуслар барында югалмам әле, диде. Шул кәгазьләрдән кечкенә генә блокнот текте. Бу кадерле блокнотны ул шигырьләрен акка күчерер өчен генә тотты. Ә каралама өчен каян кәгазь алырга?

Тиммерманска укыр өчен «Фолькишер боебахтер» газетасы бирәләр иде. Укыганнан соң аны кире кайтарырга кирәк. Билгеле, бу фашистик газетада алар өчен укырлык, җанга азык бирерлек бер нәрсә дә юк. Ләкин, һәр начарның бер яхшы ягы була дигәндәй, бу газетаның да шунысы яхшы иде: аның кырыйлары шактый киң була. Муса аларны бик пөхтә итеп ертып ала, аннары шул тар тасмаларга үз караламаларын яза.

Һич көтелмәгән-уйланмаган яктан, Мусаның тагын бер «бәхет капусы» ачылды. Надзирательләрнең кайберләре армия хезмәтенә яраксыз картлар иде. Әгәр тоткыннар әчке тәртипне ачыктан-ачык бозмаса, башкасына алар әллә ни игътибар итми. Көннәрнең берендә бер колгасары Мусага хәтта әйтә куйды:

— Бүген төрмә начальникларының кәттәләре килә. Ихтимал, тентү үткәрерләр, — диде.

Бу кисәтү бик урынлы булды, Муса үзенең кадерле блокнотын ераграк яшереп өлгерде. Ә төнлә камерада чыннан да тентү булды, тоткыннарны стена буена бастырып, барлык матрацларын, мендәрләрен селкеделәр, ләкин бер нәрсә дә табылмады.

## 34

Иҗат сәгатьләре, яшьлек мәхәббәте кебек, иң татлы, иң ләззәтле сәгатьләр дип дөньяның бик күп мәшһүр шагыйрьләре язып калдырган. Аларга ничек ышанмыйсың, алар моны үзләре татыган бит. Бу минутта бар җиһан онытыла, бары тик йөрәктәге тылсымлы илһам белән алдындагы кәгазь генә кала. Шагыйрьгә бүтән бер нәрсә кирәкми, аның кулында сихри каләм!

Шагыйрь Муса Җәлил шулай онытыла ала идеме соң? Аягына ботинкасы өстеннән йон оек кигән, шуңа күрә адымнары бөтенләй ишетелми торган надзиратель, шыпырт кына килеп, ишектәге волчокны — «бүре күзе»н ачып, тоткыннар берәр ярамаган эш эшләмиләрме, дип каравы мөмкин бит, — аларның төрлесе бар, күпләре гестапога бик тырышып хезмәт итә. Сак булганың яхшы. Әгәр ул тоткын кулында тыелган эш күрсә — ә язу төрмәдә иң тыелган эшләрнең берсе — кулын-

дагы кадерле кәгазь кисәген тартып алып, үзенне карцерга ябуы бар. Болар барысы илаһи иҗат сәгатьләрен, әлбәттә, агулаган, шагыйрь җанының бер яртысы һәр вакыт сакта торырга мәҗбүр булган.

Иҗатның беренче чыганагы — шагыйрьнең үзе кичергән хис диләр. Төрмәдә Муса бик каты сызланган. Ләкин шушы өзлексез әрнү-сызланулар турында аның бер генә шигыре дә юк. Сораулар алганда гитлерчы палачлар итек табаннары белән изгәләгән, сугып имгәткән, сындырган кул бармаклары арасына карандаш төпчеге кысып тоту аңа әйтеп бетергесез бер газапка әйләнгән. Кайчагында аның гариплaveraged бармакларын көзән шул хәтле җыерган ки, ул аларны авызына кабып, берказ язылмасмы дип, тыны белән җылыткан. Шундый авыр сәгатьләрдә дә Муса үзенең мөшкел хәле турында камерадагы иптәшләренә зарланмаган, бигрәк тә җан сызлануларын шигырьгә күчермәгән. Ә менә шул ук төрмәдә шаян җырлар язган! Мең газаплар арасында, ишек төбендә шыр сөякчел үлем басып торганда, ул үзендә елмаерга көч тапкан. Бу нинди сер?! Гаҗәп бит!

Ник чакырдың су буена,
Үзең шунда килмәгәч?
Ник әйттердең «сөям» диеп,
Үзең «мин дә!» димәгәч?
Ник елмайдың каш сикертеп,
Яратмагач, йөрмәгәч?
Ник ашаттың тозлы балык,
Соңыннан су бирмәгәч?

Әйтерсең шагыйрь бу шаян да, моңсу да шигырен төрмә камерасында түгел, ә агым су буенда бер ялгызы җиңелчә моңланып йөргәндә язган. Моны шәрехләп, дөрес сыман тоелган әллә ничә төрле аңлатма табарга мөмкин, әмма чын дөресе булырмы икән? Мусаның гомумән шаян сүз ятраткаңы мәгълүм. Шул гынамы? Аһ, серле дә соң шагыйрь җаны!

Бу вакытта Муса үзенең тар, ярым караңгы камерасында бер уй, бер теләк белән яна: «Тик язасы килә, язасы!..» Ә аннары? Аннары теләсә нәрсә булсын, вәхши фашистлар котырынып үрле-кырлы сикерә икән, сикерсеннәр, Мусаның төшләренә кереп йөдәткән кара маймыллар кебек шашыналар икән, шашынсыннар. Ул, нәфрәтләнеп, ачуыннан буыла-буыла кычкырган:

Үтерегез, әйдә, үтерегез,
Котырыгыз аннан, биегез!
Тик шагыйрьгә кара китерегез,
Һәм кулына каләм бирегез!

Тагын мәңгелек сер! Үлем алдыннан шагыйрь үзенең газиз Ватандашларына нинди мөкатдәс сүз әйтергә тели? Ул зар-моңнарын теркәр өчен каләм, кара сорамый бит. Аның мәгърур җаны үлемнән дә тетрәми, үлсә, аягүрә үләсен дошманнарына күптән әйтеп куйган булган. Юк, аның әйтми кала алмый торган иң кадерле сүзе булган!

Күз алдына китерүе дә, ышануы да кыен, әмма Моабит төрмәсендә Муса гаҗәп күп яза. Ян Коцураны иртән торгач кухняга алып китәләр дә кичсез кайтармыйлар. Камерада алар Тиммерманс белән икәү генә кала. Сәгать сигездә ашарга китерәләр. Билгеле, аның туклыклыгы юк. Гомумән төрмәдә ачлык газабы даими бернәрсә. Мусаның әле Оренбургта, ачлык елларында, уенын-чынын бергә кушып: «Ач көе ачу да, илһам да күбрәк килә» дип әйткән бер каламбур кебегрәк сүзе булган икән. Нишлисең, биредә дә шуны кабатларга туры килә иде.

Унбиш минутлап һава сулаткач, төшкә кадәр тоткыннарны инде борчымыйлар. Муса язарга утыра, Андре, аңа комачауламас өчен, ишек төбендә арлы-бирле йөренеп, үзенең бетмәс уйларын уйлый. Кай-

чак Муса бер генә секундка Андрега карап ала, елмая, ә күз карашы шундый еракка төбәлгән, анда шундый рәхәт, шагыйрь ул дөньядан һич аерылырга теләми шикелле. Андре да елмая, ул шагыйрьне аңлый, шуңа күрә сүз катмый. Нигә сүз, эчкерсез елмаю аннан күбрәкне аңлата бит. Аннары тел мәсьәләсе. Андре русча белми, ул французча сөйләшә, ә французчаны Муса аңламый. Дөрес, ул төрмәдә французчаны өйрәнә башлады, ләкин бу арада ят телне күпме генә үзләштереп була. Ә немецчаны Тиммерманс ярым-йорты сукалый.

Кайчагында Муса үзенең язганнарын дусты Андрега укып күрсәтә. Телне аңламагач, ни әйтәсең, елмая гына Андре. Бер тапкыр ул, француз, немец сүзләрен бергә укмаштырып, мин монда дулкыннар тавышым ишетәм, кебегрәк бер нәрсә әйтте. Мусага бу охшады, ахрысы, ул дәртләнеп Идел турында сөйли башлады. Шәфи Алмаслар Иделе турында түгел, андый Идел дөньяда юк, ул чын Идел, үзе су кергән мәһабәт Идел, аның ирекле дулкыннары турында сөйләде. Күңеле күтәрелеп китте.

Камераның бер ягында Абдулла Алиш, икенче ягында Фоат Булатов утыра иде. Җан дуслары, шундый якын, ә сөйләшә алма шулар белән. Моннан да газаплырак күңел әрнүе булырмы икән? Алар белән туйганчы бер сөйләшсәң, җаның рәхәтләнеп китәр иде. Һәм Муса шунда ук хыяллана башлый.

— Абдул, Казанда, Матбугат йортында, нишлиләр икән хәзер? Фронтовиклардан хатлар киләме икән? Хәзер аларның кәефләре күтәренкедер, безнекеләр әнә ничек алга килә бит...— диде Муса Алишка, үзен аның янында утыргандай итеп сизеп. Ул да булмый, Муса инде балалык дусты Фоат Булатов белән сөйләшә башлый. Фоатның калку тере күзләре аның җанына карый сыман, ирен почмакларындагы чокырларны ап-ачык күрә шикелле: «Фоат, балыкка киттекме? Иртән кызыл канатлар иллә шәп чиертә диләр».

Муса тирә-ягына каранып ала, юешләнгән күзләрен сыпыра — һай, нарасый бала, аягүрә төш күрә ләбаса! Бер секунд үтүгә инде Казан да, Матбугат йорты да, Оренбург та юк. Кая китте ул хыялда гына күрергә калган газиз туган яклар!

Абдулла Алиш белән Фоат Булатов янында Андре Тиммермансның ватандашлары — бельгиялеләр утыра. Менә стенада тишек тишеп булса бер сөйләшерләр иде, ичмасам.

Муса белән Андре шул татлы хыяллар турында ымлап булса да кайта-кайта сөйләште. Әмма ничек итеп хыялны тормышка ашырырга? Мөмкинме бу, әллә аягүрә күргән төш кебек, күз ачуга юкка чыгамы?

Моабитта тоткыннарга кайчакта аз-маз эш бирәләр иде. Муса белән Андре үзләренә эш сорап карадылар. Төрмәдә эшсезлек — иң зур газапларның берсе. Әмма алар фашистларга эшләргә дип җан атып тормады. Алар болай уйлады: эш белән бергә нинди дә булса корал кисәге бирергә тиешләр. Чыннан да шулай булды. Алар ниндидер каплавычлар ясарга, ә өтерге белән шул каплавычларга тишекләр тишәргә тиеш икән. Каплавычлары ничек чыккандыр, анысы аларны борчымады, өтерге белән Булатовлар ягындагы стенаны тишә башладылар. Моның өчен параша артындагы урын сайланды, чөнки ул тышкы яктан күзгә күренми иде. Кирпеч балчыкларын, һава суларга чыккан чагында, сиздермичә генә җиргә сиптеләр.

Байтак көннәр үтте, ниһаять, ярты метр калынлыгындагы стена тишелеп бетте, Муса һәм Андре күңелләре булганчы дуслары белән сөйләшә башлады. Болар әйтеп бетергесез бәхетле минутлар иде. Нәрсә турында сөйләштеләр? Монысы инде таш стенага сеңеп калган сер, чөнки Муса сөйләгәнне Андре, Андре сөйләгәнне Муса аңламады. Их-

тимал, Муса белән Фоат туган якларын искә төшергәннәрдер, ихтимал, яшерен оешма эшләре, дуслары турында серләшкәннәрдер, ә бәлки алда торган суд турында сүз куешканнардыр...

Алишлар ягындагы стенаны да бораулый башлаганнар иде, ләкин монда аларның эшләре уңышлы бармады. Муса бөтен тырышлыгын кулланса да, таш стенаны тишә алмады. Бик әрнеде моңа ул. Ахырда барлык өзгәләнүләрен шигырьгә салды.

Кайгырма, дус, яшьли үләбез дип,
Без алмадык сатып гомерне.
Үзебезчә яшәп, үзебезчә
Без чиклибез аны түгелме?
Билгеләмә гомер озынлыгын
Еллар саны, картлык житүе.
Бәлки менә шушы үлем безгә
Мәңге үлмәс җиңү китерер?

. . . . . . . . . .

Чикләнсә дә гомер, яшьлек безнең
Эзсез сүнә, диеп уйлама!
Әйтсен яшьләр: менә шулай яшәп,
Шулай үлсәң иде дөньяда.

Бу шигырьне Абдулла Алиш укый алгандырмы, юкмы, өзеп әйтүе кыен, бәлки ничек тә булса кулына эләккәндер, ул аны күз яшьләре белән укыгандыр, ә бәлки ул бәхеткә ирешә дә алмагандыр. Күп нәрсәне анык белүе кыен хәзер. Көрәшчеләр гомере мәңгелек серләр мизгеленнән тора ич!

Көннәр һаман үтә торды, Мусаның бу блокноты да язылып тулды. Беренчесен тоткынлыкта танышкан һәм төрмәдән чыккан бер ватандашына биргән иде. Язмышын, билгеле, һич белми, төрмә ишеге төбендә үк тартып алдылармы икән, әллә илгә бер барып житәрме? Инде бусын кемгә ышанырга? Кем аны кадерләп әманәт итеп саклар?!

Муса күзләрен йомды. Тоткын иптәшләре никадәр генә турылыклы, батыр йөрәкле булмасын, алар бит илгә турыдан-туры кайтмый. Солдат юлы озын, хәтәр, утлар, сулар аша үтә, илләр гизә. Юлларында үзе шикелле дуслар күбрәк очраса, шигырьләрне саклашырга булышырлар, кирәксез бер нәрсә итеп утка ташламаслар. Чын дуслык канатларына чикләр юк, чын дуслар өчен телләр аермасы да киртә түгел, алар салкын кәгазьдән дә йөрәк җылысын тоялар, язганны укый алмасалар да, кешелек хисләрен аңлыйлар.

Шушы көннәрдә Мусаны төрмә начальнигына чакырып алдылар. Аннан ул күңелсезләнеп кайтты. Аңа карап алгач, Андреның да йөрәге өшеп китте.

— Ни булды, Муса?

— Ни булды дип, Андре... күңелле нәрсә түгел. Тиздән Дрезденга судка алып барачаклар,— диде Муса әкрен генә.

— Өметсезләнмә, Муса, бәлки...

— Юк, Андре, фашистларга мин һичкайчан ышанмадым, ышанмыйм. Әгәр намуслы кешеләр ул зобаниларга нинди булса өмет багласа, бу кешелек каршында, көрәшче вөҗданыбыз алдында җинаять булыр иде...

Тагын нәрсә әйтергә? Сүз бетте шикелле. Бер вакыт Андре күз читләре белән Мусага карап алды. Шагыйрьнең йөзе кайгылы, моңлы, күз карашы биеккә, төрмә тәрәзәсенә текәлгән. Аннан зәп-зәңгәр күк кисәге күренә, кайчакта ап-ак болытлар агылып үтә. Алар ирекле, алар мәңгелек хәрәкәттә.

Андреның гаҗәпләнүенә каршы, Муса еламады, нинди булса йомшаклык күрсәтмәде. Аның рухи бөеклегенә Андре кабат сокланмыйча булдыра алмады. Шундый батыр уллары миллионнар булган илне фашистлар җиңмәкче булганнар. Андре хәрби стратегик, политик булырга, эко-

номистлыкка дәгъва итми, әмма аңа да хәзер фашистларның көне бетеп баруы шикле тоелмый иде. Әлбәттә, яраланган ерткыч котырына. Фашистлар да шашыналар, ашыгалар, канлы эзләрен ераграк яшерергә тырышалар, шаһитларны, берсен дә калдырмый, юк итәләр. Ләкин тарихтан боларның барысын яшереп буламы? Тарих инде фашистларның үзләренә гадел хөкем хәзерли, ул хөкем үзгәрми торган булачак.

Тагын берничә көннән Мусаны төрмә начальнигына кабат чакырып алдылар, нинди дә кәгазьләргә кул куйдырдылар. Аннан кайткач, Муса Андре каршына килде, күзләренә карап, кадерле блокнотын аңа сузды:

— Татарлар мондый очракта әманәт диләр, Андре. Мин дә әйтәм: әманәт, Андре. Әманәткә хыянәт юк. Сакла син бу дәфтәрне! Әгәр исән калып, сугыштан соң иленә кайтсаң, Совет консуллыгына тапшырырсың.

Андре Мусаның бу сүзләрне бик тыныч әйтүенә шаккатты. Шундый батыр кешенең үтенечен үтәми кала идеме соң ул? Аңа ул белмәгән телдә язылган блокнот тапшыралар, ул аны укый алмый, анда нәрсә язылганын төшенми. Ул фәкать үз дәфтәрен аңа ышанган кешенең шагыйрь икәнлеген белә. Шундый кеше — бер камерада утырган иптәш — Андредан дәфтәрен саклауны үтенә икән, ул инде аның бу теләген үтәми кала алмый.

— Борчылма, Муса! — диде Андре.

Озак та үтмәде, төрмә сакчылары Мусаны алырга килделәр. Барлык әйберләрен җыярга кушылды. Нинди әйберләре бар иде соң аның?.. Муса белән Андре туганнарча кочаклашып үбеште.

Шул ук вакытта күрше камерада Абдулла Алиш та бельгияле дусты Майзонга үзенең якыннарына язган хатын бирде. Майзон бу бәләкәй хатка күзләрен ала алмыйча карап торды. Бу хатны ул шулай ук укый алмый, чөнки аңлашылмас телдә язылган, нәрсә турында икәнен анык белми, тик соңгы хат икәнен генә төшенә.

— Бу таш капчыктан исән-имин чыга калсаң, илемә җибәрерсең. Адресы күрсәтелгән,— диде Алиш һәм оялчан гына елмайды. Я алла, шундый тетрәткеч минутта да елмаялар бу татарлар! Нинди кешеләр соң алар?! Майзон бер генә тапкыр да аларның гыйбадәт кылганнарын, тезләнеп тәңрегә ялваруларын күрмәде. Ә үзләре нәрсәгәдер ышаналар, аллага ышанудан битәр ышаналар, аларның елмаюын акылдан язган бичара мескеннәрнең мәгънәсез, өметсез елмаюы дип әйтеп булмый!

Алишның Майзонга биреп калдырган хатында менә нәрсәләр язылган иде:

«Кадерле тормыш юлдашым, сөекле әнием, кадерле балаларым, туганнарым, дусларым! Сезгә бәлки соңгы кайнар сәламемне җибәрәм.

Мин, Алишев Абдулла Бариевич, язучы А. Алиш, 1001 укчы полкның кызылармиячесе, чолганышта булып, Брянск янында 12.X.41 ел әсир төштем. Төрле лагерьларда булганнан соң, ниһаять, Чехословакиягә эләктем, андагы заводта шлифовальщик булып эшләдем. 1942 елның ахырында Берлин янындагы лагерьда шагыйрьләр Муса Җәлилне, Р. Саттарны («Кызыл яшьләр» газетасыннан) очраттым. 1943 елның августында татар хәрби әсирләре — аларны легионерлар дип атыйлар иде — арасында листовкалар таратуда гаепләнеп, кулга алындым.

Минем белән бергә түбәндәге иптәшләр:

1. Муса Җәлил — шагыйрь. Казаннан.
2. Гариф Шабаев — финработник. Ташкенттан.
3. Сәйфелмөлеков — Үзбәкстан сәүдә наркомы урынбасары.
4. Фоат Булатов — инженер. Казаннан.
5. Әхмәт Симаев — журналист. Мәскәүдән һәм легионнан 20—25 кеше кулга алынды.

Без ярты ел Берлин төрмәсендә утырдык. Суд 7.2.44 Дрезденда булырга тиеш. Килдем, көрәштем һәм киттем. Язмышыбыз шундый, күрәсең. Без соңгы сулышыбызга чаклы туган халкыбызга турылыклы булып калабыз. Аһ, шул кадәр яшисе килә. Сез кадерлеләремне күрәсе, баштан кичкәннәрне сөйлисе килә. (Р. Саттар 43 елның июнендә качкан иде, аның язмышы билгесез.) Күп язылган һәм уйланган әйберләр үзебез белән китә. Барыгызны да үбәм. Бигрәк тә Алмазым белән Айвазымны. Аларга белем бирергә тырышыгыз. Хушыгыз.

Сезнең турылыклы улыгыз, хәләл җефетегез һәм дустыгыз А. Алиш. 22.I.1944».



## 35

Дрезден төрмәсенә китергәч, җәлилчеләрне тагын аерым-аерым камераларга яптылар. Дрезден казаматлары Берлинныкыннан һич аерылмый, камералары шундый ук тар, кысан, салкын, юеш. Тимер рәшәткәле тәрәзәсеннән бер нәрсә күренми, көндез болганчык яктылык төшә дә күктә актарылган болытлар шәйләнә, ә төннәрендә кайчак ерак-ерак йолдызлар җемелди. Нәрсә әйтмәкче була икән тоткын шагыйрьгә алар?

Күкне тутырган йолдызлар арасында Муса бигрәк тә Зөһрә йолдызны ярата иде. Аның шигырьләрендә ул еш очрый. Әле төрмәдә язган шигырендә дә, Зөһрә йолдызга карап, бер чибәр кызның матурлыгы турында:

> Ләйләсеме әллә бу Мәҗнүннең,
> Зөһрәсеме әллә Таһирның,

— дигән иде.

Төнлә, Колама таудан караганда,— һай, бу яшьлек, нигә ул чаклы хәтердә калган!— ай уртасындагы көянтәле Зөһрә чибәрне ап-ачык күрә торган иде ул. Монда, төрмә тәрәзәсеннән караганда, ай түрендәге Зөһрә бөтенләй күренми. Йөзен шәлъяулыгына яшергәнме, мәхбус шагыйрьгә карарга оялимы? Оялма, сеңелем, туры бак, иркәлә назлы карашың белән шагыйрьне! Бәлки бу безнең соңгы тапкыр күрешүебездер!

Мусаның мондагы төннәре аеруча әкрен, аеруча газаплы үтә иде. Кул-аякларында богау, ятагы каты, салкын, шуның өстенә ул бик каты ютәлли. Үпкә авыруының көчәюен белә, ләкин моның нинди борчу тудыруы мөмкин хәзер?

Ютәле басыла төшкәч, Муса яңадан үзенең бетмәс-төкәнмәс уйларына чума иде. Әйе, алар соңгы чиккә килеп җитте. Моңарчы алар һичкайчан тормышка ашмас хыяллар белән булса да өзгәләнгән җанны азмаз җылыта, боек күңелне беркадәр юата иде. Хөкем карарыннан соң— аның нинди буласы җәлилчеләрнең һәммәсенә билгеле иде — бу хыял да калмас. Тикшерү вакытында Мусаның иптәшләре үзләрен чын батырларча тотты. Фашистларның коточкыч җәзалары, мәкерле алдаулары, хәтта тормыш вәгъдә иткән булып пышылдаулары аларны сындыра алмады. Инде соңгы сынауны ничек каршы алырлар? Актык минутта явыз дошман алдында, каушап, калтырамаслармы? Алар бит барысы да яшьләр, тормышны яраталар, яшиселәре, сөясәләре, сөеләселәре килә, илдә аларның карт әти-әниләре, кайберләренең сөекле хатыннары, балалары, туганнары, сөйгән ярлары бар. Алар хакына... нишләргә? Яшәргәме, үләргәме?

Мондый чакларда Муса Абдулла Алиш турында күбрәк уйлана иде. Һәр язучы шәхес буларак бик кызыклы бит, үзенчәлекле. Балалар язучысы бигрәк тә. Аның җаны балаларныкы кебек саф, керсез, самими булганда гына ул үзенең геройларын аңлый ала торгандыр. Бала бит бервакытта да батырлык эшлим дип уйламый.

Мусаның күз алдына Алиш гел балалар белән уралган хәлдә килә иде. Балалар аны чын ихластан яраталар, әкият сөйләүче абый килгән!— дип бөтен мәктәпне яңгыраталар иде. Әкият сөйләүчеләр, гадәттә, ап-ак сакаллы карт бабайлар була. Ихтимал, кайчан да булса, Алишны да «Алиш бабай» яки «Абдулла бабай» дип йөртерләр, сабый балаларга бу һичнинди сүз белән сөйләп, аңлатып булмый торган зур шатлык китерер иде. Нинди кабәхәтлек, фашистлар балалар шатлыгының тамырына да балта чаба...

Күпмедер вакыт үтә, уйлар бер-берсен алмаштыра. Бу юлы инде Муса үзенең шигырьләренең язмышы өчен кайта-кайта борчыла. Барып житә алырлармы йөрәк парәләре туган илгә? Әллә беренче тәжрибәләре бер абыйның галош башлары эчендә югалган кебек мәңгегә югалырлармы? Муса бала чакта аларга бер кардәшләре килә, галошларының зурлыгыннан зарланып, башларына тыгар өчен кәгазь сорый. Шунда Мусаның әтисеме, әнисеме улының өстәлдәге кәгазьләрен алып бирә. Юк, алар югалмасыннар, җан дусты Мирзаһит кулына барып керсеннәр иде. Аннары алар өчен борчылмаска да булыр, алар югалмас, халыкка җитәр, халык аларга бердәнбер дөрес бәясен дә бирер.

— Син, Мирзаһит, миңа үпкәләмә инде. Һәр язучының үз эше муеныннан ашкан була, ә мин сиңа тагын да зуррак мәшәкать йөклим. Сиңа бит ул шигырьләр эзе буенча йөреп бик күп вакытыңны сарыф итәргә туры килер. Бәлки каһәрләнгән Алман җиренә дә килеп чыгарсың, черчет ханның мин аунаган төрмә камераларының ишеген ачып керерсең, озакламый сугыш бетәр бит, чикләр мәңге бикле тормас, төрмә ишекләре ачылыр... Мин инде ул чакта булмам, син камера стенасына колагыңны куй, бәлки минем соңгы сулышымны ишетерсең...

Муса үзенең дусты Мирзаһит белән күңеленнән шулай бик озак сөйләшеп ятты, аннары ничектер йоклап китте. Төшендә исә ул үзенең нурлы Казанда икәнен күрде.

— Әй, кара әле, Мирзаһит, Тукай дөрес әйткән бит, безнең Казаныбыз чыннан да нурлы икән. Чит-ят җирләрдә каңгырып йөргәннән соң моны мин аеруча ачык күрәм.

— Әйе, Муса, син күпне күрәсең шул, син биек күтәрелдең.

— Гасыр биеклегенә түгелме тагы?— дип көлемсери Муса.— Юк, Мирзаһит, мин Колама тау башында гына әле. Син, Мирзаһит, Колама тау турында ишеткәнең бармы? Ул безнең Мостафа авылы янында. Авыл халкы әйтә торган иде: Колама түбәсеннән алма тәгәрәтсәң, ул аска таба ун чакрым җир үтәр дип. Безнең Гыйльми әби ул Колама турында гаҗәп дастаннар сөйли торган иде. Ә аңа йөз яшәр Гөлбостан карчык хикәя кылган аны. Борын заманда Колама тауның түбәсе болытларга ук тигән булган, ди. Мин менә шул Колама тау түбәсендә торып җырлыйм:

Карлыгач булса идем,
Канат кагынса идем.
Җидегән йолдыз батканда,
Чулпан йолдыз калыкканда.
Туган илем, якты өем,
Очып сиңа кайтыр идем,
Сызылып таңнар атканда.

Менә шул чакны хыялдагы биеклеккә дә күтәрелер идем бәлки.

...Суд башланды.

Җәлилчеләр беренче тапкыр бер-берсен бергә җыелган килеш күрделәр. Муса гына барысын белә, ә башкалары һәммәсе белән таныш та

түгел. Әхәт Аднашев белән Сәлим Бохаровны алар монарчы күргәннәре дә юк иде. Кулларын кысасы иде ул батыр егетләрнең, бик-бик кадерле сүз әйтәсе иде аларга!

Җәлилчеләрдән беркадәр аерымрак утырган тагын бер тоткын бар иде. Бу кешене дә Муса Җәлил генә таный: ул — зәңгәр күзле немец унтер-офицеры, аларның аерылгысыз көрәштәше.

Җәлилчеләрнең барысыябыккан, суырылган, әмма әчкә баткан күзләрендә ут сүнмәгән, ышанычларын җуймаганнар. Никадәр ихтирам, никадәр үз күрү, никадәр ирләрчә кырыс дуслык иде аларның бер-берсенә төбәлгән күз карашларында. Котырынган шайтан туе алдыннан алар өчен бу саф һәм бөек бер минут иде.

Фашистлар кәпрәеп, тавышларына ясалма эрелек биреп сөйләргә тырышты, җәлилчеләрне вәхшиләр төркеме, совет шпионнары, бандитлар һәм тагын шундый коточкыч исемнәр белән атадылар.

Бу артык зур булмаган залда тарих каршында гүя ике дөнья каракаршы килеп баскан иде: караңгылык вәкилләре — фашистлар; яктылык, азатлык уллары — бер төркем совет патриотлары. Бу минутта фашистлар тантана итсә дә, чынлыкта алар чери башлаган мәетләр иде инде. Аларның киләчәге юк, алар кайчандыр булган да беткән динозаврлар кебек иләмсез иде. Әгәр чынлап карасаң, монда унбер совет патриотын һәм бер немец коммунистын хөкем итмиләр, ә тарих бөтен фашистик стройны хурлык баганасына кадаклый иде.

Җәлилчеләрнең барысына да гаепләү нәтиҗәсен әйттеләр: алар немец рейхына каршы җимерү эшләре алып баруда гаепләнә. «Идел-Урал» комитетында, лагерьларда антифашистик яшерен оешма төзегәннәр, большевистик листовкалар басып әсирләр арасында таратканнар. Бу листовкаларда алар легионерларны кулларындагы коралны герман рейхына каршы юнәлтергә чакырганнар. Коммунистик подполье белән элемтәгә керергә маташканнар. Легиондагы кораллы күтәрелеш — аларның җинаятьчел эшчәнлегенең бер нәтиҗәсе...

Җәлилчеләрне гаепләү өлешен тәмамлагач, прокурор зәңгәр күзле тоткынга борылды:

— Бу адәм,— диде ул чиксез ачу белән,— үзенең чын фамилиясен герман судыннан яшерде, коммунист булуын танымады. Ләкин шушы азиатлар белән җинаятьчел элемтәгә керүе — аның бар гөнаһын исбат итә, ул шушы азиатлар белән бергә үзенең гадел җәзасын алырга тиеш...

Прокурор җәлилчеләрнең барысына да үлем җәзасы таләп итте. Хөкем карарының нинди буласын судка кадәр үк белгәнгә, күрәсең, прокурорның тантана белән кычкырган сүзләрен алар ярыйсы тыныч каршы алды, күзләрендә тетрәү күренмәде. Муса иптәшләренә сокланып карады.

Судья җәлилчеләрнең һәрберсеннән: алар үзләрен гаепле итеп саныйлармы? дип аерым-аерым сорап чыкты. Тоткыннар, сүз куешкан кебек, барысы бер төсле җавап бирде: алар үзләрен гаепле санамый, алар бары тик Ватан алдындагы изге бурычларын гына үтәгәннәр. Ватан аларның тавышын ишетер әле! Алар моңа ышана!

Судьялар башкачарак җавап көткән иде бугай — хәзер бит гаепләнүчеләрнең һәр сүзе исәпкә алына, хөкем карарыннан соң инде үзгәреш булмаячак. Җәлилчеләрнең каушаусыз кыю җаваплары бер-бер артлы ишетелә баргач, судьяларның күзләре акайды. Бу залда мондый сүзләрне әйтергә бәлки һичкайчан, һичкемнең йөрәге җитмәгәндер әле. Алай гына да түгел, тоткыннар фашистларның яңагына чапелдәтер кебек. Судны тизрәк-тизрәк тәмамларга, югыйсә, белмәссең, бу большевикларның тагын әллә нинди мөгез чыгарулары мөмкин. Суд әһелләре, беренче тапкыр бугай, суд кагыйдәләренә тешләрен кысып түзде.

Әгәр гитлерчылар бу трагикомедияне уйнарга булганнар икән,— аларга бу татарларны судсыз-нисез юк итү күп тапкырлар җиңелрәк булыр иде,— димәк, рәсми суд ясауның нигезендә җитди политик сәбәпләр яткан. Ихтимал, шуның белән алар Гитлерның банкротлыкка чыккан милли политикасын акламакчы булганнардыр. Хәбәрчеләр ложасында төрек корреспондентлары юкка гына утырмагандыр инде. Прокурор да, судьялар да, нотыклары вакытында, әледән-әле аларга карап-карап алдылар — шаһитлыкка чакырдылар булса кирәк.

Актык сүзне тоткыннарның бөтенесе исеменнән Муса сөйләде. Иптәшләренең аңа мондый зур хөрмәт күрсәтүе, аңа актыккача ышанулары, аны үзләренең җитәкчеләре итеп тануларына өчен ул чиксез горурланды, күз карашы белән аларның барысына рәхмәт әйтте. Билгеле, бу кадәр зур ихтирамны ул бер үзенә генә кайтарып калдырмый, ул — коммунист, ул актык сүзендә дә үзенең коммунистик вазифасын үтәячәк. Һәм ул бөтен фашистик стройны гаепләүче булып урыныннан күтәрелде.

— Безне монда Германия каршында, немец халкы алдында зур җинаять эшләгән кешеләр итеп күрсәтергә маташтылар, безне, янәсе, бөтен немец халкы хөкем итә, диделәр. Юк, бу алай түгел! Без немец халкына тирән хөрмәт белән карыйбыз, аны азат килеш күрергә телибез. Ул кешелеккә Карл Маркс кебек даһиларны, Гейне, Гете, Бетховен кебек бөтен дөнья таныган сәнгать осталарын, Роза Люксембург, Карл Либкнехт, Эрнест Тельман кебек сыгылмас революцион көрәшчеләрне биргән халык. Моның өчен кешелек аңа мәңге рәхмәт әйтәчәк. Бу халык алдында без түгел, канлы нацистлар җинаять эшләде, алар аңа коточкыч кара тап төшерде. Гитлерчыларның җинаятен тарих каршында берни белән аклап, каплап булмас, ул дегеттән дә карарак...

Фашизмны җиңү эшенә без үз өлешебезне керттек, ләкин көрәшне артык дәвам иттерә алмаганга үкенәбез һәм әрнибез. Элек, безгә ниндидер ялган кәгазьләр күрсәтеп, безне куркыныч бандитлар дип атадылар. Хәзер инде, судья әфәнделәр, сезгә дә ачык булса кирәк, бу гаепләүләр барысы да сабын куыгы кебек шартлады. Тикшерүчеләр кулында безне гаепләрлек бернинди фактлар булмаган, шуңа күрә алар безгә стандарт гаеп тагарга маташты, имеш, без үз командованиебез белән элемтә тотканбыз. Шул нигездә безне шпионнар дип атамакчы булдылар. Бу баштан ахыргача ялган! Без беркем белән элемтә тотмадык. Бу безнең бик зур кимчелегебез иде. Моның өчен үкенәбез. Ләкин без, совет кешеләре, Ватаныбыз каршында үз бурычыбызны булдыра алган кадәр намус белән үтәргә тырыштык...

Муса Җәлилгә күп тапкырлар җикеренделәр, сүзен бүлдерделәр, фикерләрен әйтеп бетерергә комачауладылар. Судьяларның кара ачулары йөзләренә чыккан иде, тешләрен шыгырдаттылар, ә тоткыннар, киресенчә, горур карап, башларын югарырак күтәрде. Алар гүя моннан, әллә ничә мең чакрымнан, газиз ватаннарын күрәләр, бик аз эшләп калулары өчен аңардан гафу үтенәләр иде...

Актык сүзләрендә дә җәлилчеләр фашистлардан «гаепләрен» кичерүне үтенмәде, берсе дә күз яше белән аларга ялвармады. Фашизм бар халыкларның, шул исәптән ирек сөюче татар халкының да, иң явыз дошманы, аның белән бары тик корал телендә генә сөйләшергә мөмкин. Башка бер телне дә ул төшенмәячәк.

Дрезденда барган бу фаҗигале суд турында бернинди рәсми язма материаллар сакланмавы, шаһитлар калмавы бик кызганыч. Ихтимал, төрек матбугатында заманында шул суд турында бер-ике юллык хәбәр басылып чыкса чыккандыр. Әмма ул турыда бүгенгә хәтле ләм-мим ишетелгәне юк. Дөнья җәмәгатьчелеге хәбәрдар түгел.

Соң нишләргә? Иҗат фантазиясенә юл куяргамы? Юк. Бөек Ватан сугышының серләре һаман ачыла тора әле. Бәлки җәлилчеләр турында да вакыты белән берәр яңа сәхифә калкып куяр.

1944 елның 24 мартында Дрезден төрмәсенең таш стенасына җәлилчеләрнең берсе болай дип язып калдырган: «Монда Әхмәт Симаев утырды. Журналист, Мәскәүле. Без Россиядән унбер кеше идек, барыбызны да икенче германский имперский суд үлем җәзасына хөкем итте. Кем дә кем бу язуны табып укыса һәм исән килеш Ватанга кайтса, туганнарыбызга, якыннарыбызга шушы адрес белән хәбәр итүен сорыйбыз»...

Борынгылар әйтә торган булган: ташка басылган нәрсә югалмый. Әхмәт Симай шул юлларны таш стенага тырнаганда аларның кайчан булса туган илгә барып җитәселәрен уйладымы икән? Уйлагандыр, югыйсә, язмас иде. Фашистлар җәлилчеләр турындагы барлык документларны юк итсәләр дә, менә шушы бәләкәй язуны «күрмәгәннәр», ә ул хәзер, зур документка әверелеп, аларның җинаятьләрен бөтен кешелек алдында янә бер фаш итә.

## 36

Германия, Германия! Син татар шагыйренә, аның көрәштәш дусларына, үзеңнең барлык «мәшһүр» почмакларыңны — кешелек каршында кара дан алган атаклы төрмәләреңне, казематларыңны күрсәттең. Ерактан күрсәтеп кенә калмадың, эчләренә алып кердең, ялгыз камераларында айлар буе яткырдың, һәртөрле җәза алымнарыңны таныттың, җир асты юлларыңнан йөреттең, таш идәннәрендә аунаттың, салкыныңда туңдырдың. Алар Тегелеңдә, Моабитыңда булдылар, Шпандауга килеп җиттеләр, Плетцензеега да бер генә адым калды. Алар бөек Германиянең чын мәгънәдә мәшһүр якларын рәхәтләнеп карарлар иде, син аларга аны күрсәтмәдең, яшердең. Германия ул килмешәкләр күңелендә мәңгелек караңгылык, дәһшәт, коточкыч куркыныч дөньясы, җәһәннәм ишегалды булып калсын, дидең, ахрысы. Алар немец халкына — зур талантлы, хезмәтчел немец халкына ачу сакламады. Алар бары тик нацист палачларны гына күралмады, аларга каршы соңгы сулышларына кадәр курку белмичә көрәште... Моның өчен алар синең башкалаңда, яңа, азат Германиянең башкаласында мәрмәр һәйкәлгә лаеклы. Куярсыңмы син аларга кайчан да булса ул һәйкәлне? Фашизмга каршы күтәрелү белән алар Германиянең якты киләчәге өчен дә көрәштеләр бит. Бу һәйкәл киләчәк буыннарга Германиянең бөеклеге һәм түбәнлеге турында сөйләп торыр иде.

...Үлемгә хөкем ителгән тоткыннарны — немецларны һәм совет әсирләрен ябык грузовиктан Шпандау төрмәсе ишегалдында төшерделәр. Бу машинада Муса Җәлил белән Фоат Булатов та бар иде. Алар ерткыч кара кошка охшаган шомлы төрмә бинасына күзләрен йөртеп чыктылар. «Төшкә дә кергән нәрсә түгел»,— диләр мондый чакта татарлар.

Муса һаман кара костюмнан, ак күлмәктән. Фоатның өстендә легион формасы. Мусаның йөзе ябык, саргайган, Фоат артык бирешмәгән шикелле. Көн яктысында бу аеруча ачык күренеп тора.

Ә зәңгәр күктә болытлар һаман агыла да агыла. Ирекле шул алар, юлларын бернинди киртәләр бүлми. Бу юлы болытлар, узып барышлый, Мусага да сәлам җибәрделәр шикелле. Муса аларга күңеленнән рәхмәт әйтте, сокланам сезнең бәйсез ирекка! диде.

Шул гади күренеш озын, тар, ярым караңгы төрмә коридорлары буйлап атлаганда да шагыйрьнең күз алдында торды.

Бикле тимер ишекне ачтырып, тоткыннарны рәшәткә аркылы үткәрделәр дә каядыр өскә алып менделәр. Өченче катта бугай тагын озын, тар коридор. Монда бик күп ишекләр, ишек саен кызыл рамкага алынган язу — үлемгә хөкем ителгән кешеләрнең фамилияләре.

Ниһаять, шундый ишекләрнең берсен ачып, Муса Җәлил белән Фоат Булатовны керттеләр.

— Безнең беренче класс номер шушы була икән,— дип Фоат көлемсез генә шаяртып куйды. Муса бик җентекләп камера эчен карап чыкты, стеналардагы уелган урыннарны бармагы белән капшап-капшап алды,— юк, болар тишек түгел, болар болай гына.

Анда стенага беркетелгән ике тимер карават, каршы якта, шулай ук стенага беркетелгән өстәл, идәнгә беркетелгән ике урындык. Тәрәзәгә башны күтәреп кенә карарга мөмкин. Тәрәзә пыяласы да, стеналар да каралып беткән. Бик җентекләп баксаң гына стеналарда язулар тулы икәнен күрәсең. Муса шул язуларны укый башлады. Бу таш китапта бөтен бер тарих — фаҗигале язмышлар, туган илләре, сөеклеләренең исемнәре, соңгы сәлам, соңгы аһлар, соңгы күз яшьләре...

Менә шулай аларның Шпандаудагы тормышлары башланды. Монда алар ике айлап утырганнар булса кирәк, әмма 1944 елның 5 июнендә Мусалар камерасына италияле Рениеро Ланфрединины керткәндә алар инде беренче каттагы 53 нче камерада утыралар иде. Яңа килгән «кунак»ны алар тиешле хөрмәт күрсәтеп каршы алдылар. Шунда ук таныштылар. Рениеро шуны күрде: шагыйрь күрер күзгә ябык, әмма күңеле белән сәламәт, күзләре бик җанлы, акыллы. Маңгай чәче һәр вакыт күзләренә төшеп тора. Муса бер кулы белән чәчен әледән-әле артка сыпыра.

Яңа тоткынга Муса белән Фоат бик игътибарлы булды, аның шактый төшенке күңелен күтәреп, төрле мәзәк сүзләр әйттеләр, сүз җитмәгән урында елмайдылар. Алар төрмәләрдә мимика белән сөйләшергә шактый остарган инде. Нишлисең, еш кына син белмәгән телдә сөйләшүче кешеләр арасына туры киләсең, ә йөз хәрәкәтләрен исә бар миллләт кешеләре аңлый. Бәхеткә, Рениеро немецча сөйләшә икән, шуңа күрә Муса белән бик тиз уртак тел таптылар.

Беренче көн Рениеро өчен бик мәшәкатьле булды, аны әледән-әле каядыр чакырып тордылар, күрәсең, чакырган бер җирдә сөйләшү җиңел булмагандыр, ул һәр вакыт тәмам алҗып кайтты. Ниһаять, караңгы төште, Рениероны борчымый башладылар, ләкин аның йөзе һаман хәсрәтле иде, ул бик аз сөйләште, һаман үзенең ниндидер эчке уйлары белән мәшгуль булды. Мондый чакта кешенең рухи дөньясына саксыз бәреп керергә ярамаган кебек, аны шул шомлы уйлар эчендә үзен генә калдыру да килешми, чөнки кара уйлар җанны да каралта.

Элек бик вак-төяктән — кашык-котелоктан сүз башланды. Кичке аш вакыты якынлашкан иде, ә Рениероның кашыгы-табагы юк.

— Бездә солдат кеше котелогы белән кашыгы турында барыннан да элек кайгырта диләр,—диде Муса елмаеп.—Кашыксыз, котелоксыз солдат яши дә, сугыша да алмый... Сез башыгызны имәгез — табарбыз.

Чыннан да, Мусалар Рениерога кашык-табак табып бирделәр — алар мондагы тәртипләрне беләләр иде инде. Яңа дуска бәрәңгене дә күбрәк салдылар.

Төрмәдә тоткыннар башта бер-берсен азмы-күпме сынап карарга тырыша. Бу юлы ике яктан да якынлык тиз урнашты, чөнки язмышлар уртак иде. Муса Рениерога үлемгә хөкем ителүләрен сөйләде. Рениеро шаккатып тыңлады: Муса да, Фоат та үлемгә хөкем ителгәннәргә һич охшамыйлар, рухлары күтәренке, хәтта елмаялар!

Рениеро озак эндәшмәде, гүя нәрсәдер аның бугазын кыскан иде. Аннары сулышы бераз иркенәеп китте кебек, ул да ачы язмышын сөйләп бирде: 1943 елның җәендә Муссолини власть башыннан бәреп тө-

шерелгәч, Италия рәсми рәвештә Германиягә каршы сугыш игълан итә. Гитлерчылар итальян частьларын ашыгыч рәвештә коралсызландыра башлыйлар. Менә шул буталыш вакытында Ланфредини гестапо кулына эләгә. Аны каторга эшләренә җибәрәләр. Анда ул чехлар белән аралашып китә. Төп мәсьәләдә барысының да карашлары бер төсле була, алар фашистларны яратмыйлар. Җитмәсә, Ланфредини, гитлерчыларны ачыктан-ачык хурлап, бер дустына хат яза. Менә шул хат ничектер гестапо кулына барып эләгә. Ренмероны үлем җәзасына хөкем итәләр... Хәзер менә ул да, Мусалар кебек, шул карарның үтәлүен көтеп ята. Кайчан булыр бу хәл — бүгенме, иртәгәме — билгесез.

Ланфредини шактый диндар кеше булып чыкты. Мусалар аның рухи кичерешләреннән көлмәде, төрмәдә гыйбадәт сәгатьләре җиткәч, беркем аңа комачауламады. Ланфрединига калса, Муса белән Фоат та үзләренчә «гыйбадәт» кыла иде. Хәлбуки, алар үзләренчә җырлыйлар гына иде.

Төрмәдә мөселман мулласы булмаганга, алар янына беркем килеп йөрмәде. Башка үлемдарлар янына, шул исәптән Ланфредини янына да, төрмә пасторы Георгий Юрытко килеп йөри башлады. Ул киң күңелле кеше иде булса кирәк, Ланфрединига бүгенге үгет-нәсихәтләре беткәч тә китәргә ашыкмый, бик теләп Муса белән гәпләшеп утыра. Мусаның тыныч табигатьле, югары инсафлы булуы, укымышлылыгы, мәдәниятлелеге пасторда бу кешегә карата тирән хөрмәт уятты. Аннары Муса немец телендә ару гына сөйләшә. Юрытко аның соравы буенча аңа үз китапханәсеннән Гетеның немецча «Фауст» китабын, ә Ланфрединига итальян телендә Дантеның «Илаһи комедиясе»н китереп бирде.

Һәр көн саен кичке сәгать алтыда камерага надзирательләр килеп керә, барлык үлемдарларны чишенергә мәҗбүр итәләр, киемнәрен коридорга чыгарып куялар, һәр тоткынның кулларына богау кертәләр. Шул хәлендә алар йокларга ятарга тиеш. Ә иртә белән богауларны салдыралар, киемнәрен китереп бирәләр. Һәр яңа көн шулай башлана.

Иң авыр көннәр чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга һәм шимбә була торган иде. Бу — җәзалау көннәре. Иртәнге сәгать бишләрдә-алтыларда камерага кораллы солдатлар килеп керә, мескен тоткынга, фамилиясен әйтеп, «эшең бетте, генерал Фромм сине гафу итмәгән», дип белдерәләр. Шуннан камерада үзәк өзгеч елау, соңгы кабат саубуллашу башлана...

Мусалар җәзалау көннәре саен шундый дәһшәтне кətәләр иде. Бүген узды, ә иртәгә?

Гитлерга һөҗүм турында ишеткәч, тоткыннар бик куанган иде. Мусаның күңелендә дә өмет чаткысы кабынды, Фоат белән Ланфредини да сөенделәр, хәзер аларның язмышларында үзгәреш булыр төсле тоелды. Әмма бу өмет бик тиз сүнде. Һөҗүм уңышсызлыкка очраган.

Озакламыйча генерал Фроммны алмаштырдылар. Хәзер үлем карарларын иң явыз палачларның берсе — Гиммлер раслый башлады. Ул, уйлап та тормыйча, дистәләрчә кешеләрне көн саен соңгы юлга озатты.

Шундый көннәрнең берсендә Муса Җәлил пастор Юрытко аркылы иреккә соңгы хатын җибәрә алган. Анда түбәндәге юллар булган:

«Туганнар!

Без салкын, тар камерада үлем турындагы хөкемнең җиренә җиткерелүен көтеп ятабыз. Ләкин безгә үлем куркыныч түгел, чөнки фашистларның да кабере казылган, алар инде Советлар иленнән куып чыгарылганнар. Прибалтикага гына ябышып тора алмаслар. Без илебезне азат итү юлында һәлак булабыз, азат совет халкы җиңү бәйрәмендә безне дә искә алыр. Үтенечем шул: миңа чиста күлмәк кирәк, сез аны минем квартирадан табарсыз. Күңелем саф, намусым ару булгач, тәнемне дә чиста кием каплавын телим.

Аннан соң, кемгә булса да илгә исән-сау кайту бәхете килсә, Совет иленең азатлыгы өчен көрәштә һәлак булган татар улларыннан туган илгә, халкыбызга, семьяларыбызга сәлам тапшырсын һәм озын, тигез, шат гомер теләвебезне җиткерсен. Хушыгыз!»

Төннәрендә союзниклар авиациясе Берлинны бомбага тотуны һаман дәвам иттерә иде. Мондый чакларда гадәттә сакчылар подвалга төшеп яшеренә, ә тоткыннар исә, тәрәзәләргә менеп, янган Берлинны карап шатланган, күрше камерада утыручы иптәшләре белән сөйләшкән. Муса тәрәзә аша үзенең шигырьләрен иптәшләренә укыган, я әйтеп яздырган... Шундый шартларда тоткыннарның иң фаҗигале соңгы көннәре үткән.

Унбишенче августта Ланфрединины ни өчендер башка камерага күчерәләр. Ул Абдулла Алиш, Габдулла Баттал, Әхмәт Симаевлар белән бер камерада утыра башлый. Ул монда да татарларда күңел төшенкелеге күрми. Алар хәтта шаяралар, елмаялар. Ланфредини аларга исе китеп карый: нинди кешеләр соң болар!

Ниһаять, соңгы көн килеп җитте. Бу 1944 елның 25 августы иде. Күңеле сизенгәнгәме, шул көнгә каршы төндә Муса бик озак йоклый алмады, уйланды да уйланды. Аеруча бер ачыклык белән Демблинда врач белән сөйләшүе исенә төште. Муса аңа ачуланмады, үпкәләмәде.

— Без китәбез инде, туган. Бик аз эшләп калуыбыз өчен безгә рәнҗемәгез,— диде ул врачка күңеленнән.— Исәннәр безнең вакытсыз бүленгән эшне дәвам иттерер дип ышанабыз. Без гасыр биеклегенә менә алдыкмы? Белмим. Менә исәннәр, сугышны күрмәгән яшьләр, без эшләп киткән эшләргә гасыр биеклегеннән карасыннар иде. Ул чагында алар безнең эшнең зурлыгын, матурлыгын ачыграк күрерләр, ул Ватан сугышының гади бер эпизоды булмавын, зуррак нәрсә икәнен аңларлар. Безне онытмаслар, чөнки без киләчәк буынның бәхете өчен дә булдыра алганның барысын эшләдек.

Муса күңеленнән врач белән әле байтак сөйләште. Ул бары тик таң алдыннан гына йокыга китте.

— Мандолинамны, мандолинамны бирегез!— дип кычкырды ул. Кемнәрдер Демблинда калган мандолинасын кулына китереп тоттырды. Ул шунда ук чиертә һәм бик моңлы көйгә җырлый башлады:

И мөкаддәс моңлы сазым,
Уйнадың син ник бик аз,
Син сынасың, мин тынамын —
Аерылабыз, ахрысы...

Ул да булмады, инде башка көйгә, дәртлерәк, ышанычлырак тавыш белән сузып җибәрде:

Үлгәндә дә йөрәк туры калыр
Шигырьендәге изге антына.
Бар җырымны илгә багышладым,
Гомеремне дә бирәм халкыма.

Шул җыр дәвам иткәндә камера ишекләре ачылды. Муса белән Фоатны уятып коридорга чыгарга куштылар. Анда инде тугыз татар кычкырып сөйләшә, саубуллаша иде. Аннары коридорга тагын бер тоткынны чыгардылар. Бу зәңгәр күзле немец иде. Аның күзләре Муса Җәлил күзләре белән очрашты. Алар баш иеп исәнләштеләр. Ә тагын бер минуттан, башларын югары һәм горур тотып, соңгы юлга атладылар...

Мусалар юк инде... Ә җирдә тормыш дәвам итә, көн була да төн җитә, күктә болытлар агыла да агыла. Хәзер аларга бүтән шагыйрьләр карый. Аларда мәңгелек хәрәкәт белән мәңгелек сер бар. Дөньяның бик күп шагыйрьләре аларны үзләренчә ачарга тырышкан, әмма ачып бетерә алмаган. Муса да аларга, нәүмизләнеп, озак-озак карап торган. Нәрсәләр күргән, нәрсәләр ачкан ул аларда? Моны инде кешеләргә аның шигырьләре генә сөйләр. Тик алар әле юлда, ә юллары бик-бик озын, бәлки әле тагын төрмәләргә керерләр, концентрацион лагерьларда булырлар, француз партизаннары арасында азатлык өчен көрәшеп йөрерләр, ә сугыш беткәч, батыр солдатлар кебек, илләр һәм чикләр аша туган якка — Идел буйларына кайтырлар. Аларны анда сагынып көтәләр бит.

...Берлин өстеннән дәһшәтле болытлар ургылып-ургылып агыла. Кайчакта, кичке шәфәкъ вакытында, аларның чит-читләре кызылга манчыла. Бу куе кызыл болытларны татар карчыклары күрсә: «шәһитләр каны» диярләр иде. Актарылып аккан болытлар ташкыны немец карчыклары күңеленә дә шом сала. Алар да аналар, аларның да газиз уллары сугыштан кайтмаган. Каһәр генә төшсен бу сугышка дип пышылдыйлар алар. Кем башлады соң бу нәләтләнгән сугышны?! Я, раббем алла! Алар әле Гитлер, Гиммлер, Геринг һәм Геббельсның шомлы исемнәрен кычкырып каһәрләргә куркалар, яннарыннан үтеп киткән биек фуражкалы нацист офицерларына шикләнеп, түбәнчелек белән карыйлар. Ләкин тарих инде бу бәдбәхетләргә үзенең аяусыз хөкемен чыгарган: күп тә үтмәс, Берлин өстендә җиһанны сафландыргыч күк күкрәр. Ул көннәр, бернигә карамыйча, бернинди тоткарлыкларны белмичә, давыл аша чын тормышны даулап килә, үч ялкыны көчлерәк дөрли, гүя шагыйрь немец халкына чакыру авазы сала:

Арагызда кем бар Цеткин улы,
Тельман егетләре кайсыгыз?
Ишетегез бөек хаклык сүзен,
Төрмәләрне безнең ачыгыз!

Моабит дәфтәрләре илгә кайтып җиткәч, укучылар тагын бер нәрсәне ачык күрерләр: дөньяның барлык шагыйрьләрен җилкендергән күчмә ак болытлар образы Мусаның Моабит дәфтәрләренә тупланган шигырьләрендә, шулай да, күп түгел икән, ул күбрәк үзенә һәм халкына якын, аңлаешлы булган традицион шигъри образлар белән эш иткән, гүя тагын бер тапкыр үзенең җыр улы, халык улы булганлыгын әйтеп узган: чәчәкләрне, гөлләрне, сандугачны, ашъяулыкны, аклы күлмәкне, акбүз атны, сөю-мәхәббәт, дуслык, батырлык, аеруча ирек, азатлыкны җырлаган, карурманнарга, таң җилләренә мөрәҗәгать иткән. Ләкин Мусаның шигъри арсеналы шуның белән чикләнгән дип уйларга һич ярамый. Ул бер вакытта да бүгенге көн белән генә яшәмәгән, ул алга, киләчәккә омтылган, тик вакытның чиксез тар булуы, язарга зур мөмкинлеге, хәтта кәгазе дә булмаганга шигъри бизәкләрне артык мавыгып эзләмәгән, әйтәсе килгән уйларының үзләрен тизрәк язып калырга ашыккан. Бу аның бөек шагыйрьлеген һич тә киметми, киресенчә, шундый кыен шартларда шулай яза алуы белән ул шигъриятнең чиксез бөеклеген, киңлеген генә күрсәтә. Гүя үзеннән соң киләсе шагыйрьләргә: «сезнең алда якты юллар тора, иренмәгез, кыю иҗат итегез, яңа серләр ачарсыз» дип әйтә. Бу — шагыйрьнең яшь каләмдәш дусларына васыяте.

Караңгылыкка чумып барган Берлинның таш урамнарыннан юеш кара плащ кигән — һаман яңгыр ява иде — бер хәрби кеше бара. Йөзе чытык, күзләрендә тетрәү. Кинәт нәрсәдер лыпылдап алуга, хәрби, сискәнеп, тиз генә таш йорт стенасына сыена, аннары, курка-курка, башын күтәрә: нәкъ баш түбәсе өстендә свастикалы юеш әләм тибрәнеп тора, әйтерсең җан бирә, калтырана...

Хәрби, шомланып, төкерде дә кузгалып китте. Бер чат та үтмәгәндер, тагын туктады: аның каршында, урамның икенче ягында, биек таш койма белән уратып алынган Плетцензее төрмәсенең шомлы соры бинасы. Караңгыланып килгән кичтә ул кап-кара тау булып күренә. Чү, аның һәр вакыт бикле тимер капкаларын кемнәрдер каерып ачып куйган кебек. Аннан... башлары чабылган тоткыннар чыгып килә! Алар арасында Муса Җәлилнең базык гәүдәсен танып алуга әлеге бәндәнең котлары оча. «Башлары киселгән кешеләр ничек йөри?» дип пышылдый ул үз-үзенә.

Бу бәндә куллары терсәкләренә кадәр Мусаларның кайнар каннарына буялган Солтан Гарип иде. Ул тизрәк яшеренергә, караңгыга кереп китәргә тырышса да, яшен яшьнәгән саен, аның бөкрәйгән гәүдәсе һаман-һаман күренеп кала. Караңгы төшкән, яшен яшьнәп күк күкрәгән чакларда ул һәрвакыт, ләгънәтләнгән Иблис кебек, бүп-буш Берлин урамнарында каңгырып йөри, имеш. Илен һәм аның иң яхшы улларын явыз фашистларга саткан бу хаинга бер җирдә дә тынычлык юк икән!!!

## 38

Нинди генә авыр, газаплы чаклар булмасын, бер көн килеп алар үтәләр дә китәләр. Сугыш афәте мәңгегә килгән кебек тоелган иде, 1945 елның 9 мае туды — сугыш бетте, Гитлер Германиясе тар-мар ителде, коточкыч киеренкелектән соң дөнья халыклары беренче тапкыр җиңел сулап куйды, бинһая шатлыкларына түзә алмыйча, урамнарга, мәйданнарга йөгереп чыкты. Бигрәк тә Советлар Союзында тантана зур булды, хәрби киемдәге кешеләрне кочып үптеләр, һавага чөйделәр. Бу көн күрелмәгән бәйрәм, хәйран тамаша төсен алды. Монда яшекарты, ире-хатыны батыр иде, чөнки бу бөтен халык сугышы иде, бәйрәме дә бөтен халыкныкы.

Әмма шулай да тарих сәгате тукталуны белми. Шул хәтле зарыгып көтелгән Җиңү бәйрәме дә кичәге көн булып бара инде. Тик кешеләр күңелендә генә бөек җиңү хисе тиз сүрелми, ул гаҗәп күп төсмерләр ала бара, салават күпере төсле күп бизәкле булып балкый, тирәнәя, шатлыгы-сагышы бергә үрелә.

...Казанда, Матбугат йортында, бу көннәрдә гадәти булмаган җанлылык һәмишә дәвам итә иде әле. Язучылар союзы бүлмәләрендә, озын-озын коридорларда, кая карама анда хәрбиләр. Яшьләрен танырлык та түгел, үскәннәр, тазарганнар, чын ир булганнар, ә өлкәннәре, киресенчә, яшәргән кебек. Дөрес, сугыш салган тирән җыерчыклар, бераз соңга таба, күзгә аеруча бәрелә башлар, ә хәзер, гомуми шатлык эчендә, бөтенесе дә чәчәк аткан гөл кебек. Елмаялар, көләләр, кочаклашалар, аркаларыннан кагалар, бер-берсенә ерактан кул болгыйлар, Җиңү белән тәбрикләләр. Күкрәкләре тулы сугышчан орден, медальләр.

Мирзаһит, кайчакны озын коридорның бер читендә тукталып, бу олы тамашага тын гына карап тора. Бу минутта аның күңелендә нәрсәләр ташуын анык кына белүе кыен. Йөзе кырыс, күзләре кешегә ничектер сынап, тирәннән карый, ул кешенең кычкырып әйтелми торган эчке рухын белергә тели кебек. Тормыш сынаулары бу кешене, фронт-

та булмаса да, күп нәрсәгә өйрәткән. Ул һәр ялтыраган нәрсәнең эн-же түгеллеген яхшы белә. Билгеле, язучыларның күбесен исән-сау килеш кайтуын күрү аның өчен зур шатлык. Ул ерак юлдан әйләнеп кайтучыларга сөенеп карый, бүген алар герой. Ә үзе турында уйламый. Аннары парторг башына төшә торган мең төрле мәшәкатьне ул кемнәрдәндер рәхмәт ишетү өчен эшләмәде бит. Ул — коммунист, коллектив алдындагы изге бурычын үтәде.

Кайчагында Мирзаһитка шушы шау-шулы хәрбиләр төркеме арасында Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Фатих Кәрим, Гадел Кутуй, Нур Баян, Мөхәммәт Әблиев, Рахман Ильяс... күренеп киткәндәй була. Алар кайтмады, ә Мирзаһит аларның барысын диярлек шушы Матбугат йортыннан озатып калды, явыз дошманны тар-мар итүне, Җиңү алып кайтуны, үзләренең исән-имин булуларын теләде. Дуслары аның теләгенең беренче өлешен намус белән үтәде, фашист чирүен юк иттеләр, ләкин үзләренең барысына... кайту насыйп булмады. Сугышның корбансыз булмавын Мирзаһит бик яхшы белә, әлбәттә, әмма йөрәге туктаусыз әрни, якын дусларын инде һичкайчан күрмәвенә ышанасы килми, ул алар белән хәтта әле бер очрашыр да төсле. Тик моны кул кушырып көтеп тормаска, аларга ярдәмгә ашыгырга кирәк.

Мирзаһитның беренче адымнары аңа бернинди уңыш китермәде, ул чын эзләнү юлына аяк баса алмыйча аптырап бетте. Әсирлектә булган кешеләр — алар да кайта башлаган иде инде — Муса яки Алиш турында я бөтенләй ишетмәгәннәр, я сөйләүдән баш тарталар иде. Ә имеш-мимешләр дулкыны исә кабат көчәеп китте, алар ифрат дәрәҗәдә каршылыклы, буталчык булулары белән бергә, арада кеше ышанмастайлары да калкып чыга иде. Бер тапкыр Мирзаһитка сер итеп кенә әйттеләр, имеш, Муса исән, тик ул американлылар ягына чыккан, монда кайтырга теләми, анда, яңа сугыш чукмарлары белән бергә, безгә каршы эшли башлаган ди.

Мусаны яхшы белгән Мирзаһит мондый сафсаталарга асла ышанмады, ләкин мондый чакта синең ни уйлавың бер нәрсә әйтми бит әле, ә кулыңда үз фикерең расларлык бер документ та юк. Мирзаһит тагын бик борчыла, башында чал бөртекләр сугыш вакытындагыдан күбрәк күренә башлады. Бу хәл Мирзаһитка җиңел түгел иде. Бу мәшәкатьле эштән бөтенләй читләш, синә башка эш беткәнмени, дип «киңәш» бирүчеләр дә табылды. Мирзаһит аларны да тыңламады, ул яңа бер энергия белән хаклыкны эзләвен дәвам иттерде. Хаклык бер килеп өскә чыга диләр дә, әмма алай җиңел генә, тиз генә чыкмый икән шул...

Язучылар союзы эшләре буенча Мәскәүгә барган саен Мирзаһит Әминәләргә кереп хәл белеп чыга торган иде. Әминә кызы белән яңадан Столешниковта тора инде. Соңгы вакытларда аңа Муса турында бик авыр сүзләр ишеттергәләгәннәр. Әминәнең матур йөзенә тирән-тирән сызыклар яткан, җыйнак, нәфис, җиңел гәүдәсе авырайган, үзе олыгайган булып күренә. Сугыш вакытында, гомум кайгы-хәсрәт эчендә, мондый хәлләр күзгә артык ташланмаса да, хәзер, кешеләрнең баштагы шатлык кичергәндә, бу сукыр күзгә дә бәреп керә кебек. Элек дус яки таныш булган хатыннар хәзер, я күрмәмешкә салынып, читләтеп узып китәләр, я, ах-вах килеп, сораштырган булалар, ләкин чын ихластан сөйләшмәүләре әллә кайдан күренеп тора. Ихтыярсыздан күзгә яшь тыгыла, бик зур ихтыяр көче белән генә кайгының эчкә йотасың.

Бер килүендә Әминә Мирзаһитка Фадеевның хатын укытты. Анда Фадеев Муса турында бер хәбәр алынуын яза. Берлинны штурмлаган

чакта безнең сугышчылар бер төрмә ишегалдына барып керәләр. Бу вакытта инде тоткыннар да, сакчылар да булмый, төрмә ишегалдында бер өем кәгазьләр генә яна. Сугышчыларның берсе чит-читләре көеп беткән бер кәгазь алып укый. Язу русча. «Мин, политик эш өчен гаепләнеп, Моабит төрмәсенә ябылган әсир-шагыйрь Муса Җәлил, мине тиздән атып үтерерләрдер. Бу язу берәр рус кешесенә эләксә, Мәскәүдәге язучыларга — дусларыма миннән сәлам тапшырсын, семьяма хәбәр итсен». Шуннан соң Александр Фадеев, Гладков, Бахметьев, Корнейчук, Тычина һәм башкаларның исемнәре санап кителә...

Мирзаһит бу хатны бик каты дулкынланып укып чыкты, Әминәгә күтәрелеп карарга көче җитмәде, тик аның да күзләреннән кайнар яшь агуын сизде. Озак еллардан соң Мусадан бу беренче хәбәр иде. Хәзер Мирзаһит кай тирәдән эзләргә кирәклеген белә. Рәсми органнар өчен дә бу бик әһәмиятле кәгазь. Фадеев инде тиешле җиренә хәбәр иткәндер...

Мирзаһит Мәскәүдән Казанга кайтып төшкәндә аның йөзе таш сыман, иреннәре нык кысылган, өстендәге сары күн пальтосы кешенеке кебек күренә иде — бу арада ул тагы ябыга төшкән. Башкалар аның бу халәтенә бәлки игътибар итмәгәндер, Мирзаһит шундыйрак кеше, үзе турында күп сөйләми, ә Һаҗәр ирендәге бу үзгәрешне беренче караштан ук сизеп алды.

— Мирзаһит, әллә күңелсез хәбәр алып кайттың инде? — диде Һаҗәр, икәү генә калгач.

— Ничек әйтергә дә белмим, Һаҗәр, — диде Мирзаһит һәм Фадеевның Әминәгә язган хаты, Мусаның Берлин төрмәсе ишегалдында янып ята торган кәгазьләр өеме арасында табылган кечкенә запискасы турында сөйләде. — Муса юк инде, ахрысы... — Мирзаһитның башы иелде. Бер карасаң, сугыш бу өйне читләтеп үткән иде кебек, Мирзаһит үзе инвалид, балалар әле яшь иде. Хәлбуки, сугыш бу өйдән һич чыкмады, менә хәзер дә, тынычлык урнашкач та китми. Бик озак еллар китмәс әле, ахрысы.

1946 елның яз ахырларында Татарстан Язучылар союзына озын гына буйлы бер кеше килеп керде, өстендә язгы кара пальто, аягында күн итек. Йөзе шактый ябык, күпне күргән, ахрысы.

— Кем кирәк иде, абый? — дип йомшак кына сорады секретарь-машинистка Нәфисә. Үзе дә фронтовичка Нәфисә бу кешенең аяк атлауларыннан ук аның хәрби булуын аңлады.

— Председателегез.

— Кем дип әйтим? Нинди йомыш? — диде Нәфисә урыныннан торып.

— Үзем әйтермен, сеңелем.

Секретарь-машинистка председатель янына кереп чыкты һәм әлеге кешегә:

— Рәхим итегез, абый, — диде.

Ир кеше үзенең фамилиясен әйтеп тормастан, кесәсеннән алып, председатель өстәле өстенә кечкенә генә бер төргәк куйды:

— Бу—фашистлар тырнагында һәлак булган татар шагыйрьләренең шигырьләре. Алар төрмәләрдә, концлагерьларда булган, бик күп кешеләр кулыннан үткән. Мин, шагыйрьләрнең соңгы васыятен үтәп, аларны сезгә тапшырам. Хушыгыз.

Мирзаһит ул көнне райкомнан соң гына кайтты.

— Менә кемдер Муса белән Алишның шигырьләрен китереп калдырды, — диде аңа председатель. — Син җентекләп кара әле, нәрсәләр бар. Аннары машинкада бастырып ал. Соңыннан киңәшербез, — диде.

Мирзаһит, кулына изге бөти тоткан кебек, Мусаның беренче «Моа-

бит дәфтәре»н алды, күзләре томаланды, сулышы кысылды. Тоткынлыкта Мусаның үз кулы белән язылган дәфтәр! Төрмәдән чыккан, бик күп кулларда булган, илләр кичкән дәфтәр! Әле шигырьләрне укымас борын ук Мирзаһит кулында бәя биреп бетергесез асыл таш тотканлыгын сизде. Йөрәге урыныннан кубардай булып типте, куллары калтырый башлады.

Ул аяк өсте басып тора иде, аннары ничек утырганын да белмичә, укыды да укыды. Вак, тигез хәрефләр белән язылган шигырьләр, шигырьләр! Барысы гарәп хәрефләре белән. Никадәр шигърият, никадәр чын җәүһәрләр! Боларны үлемгә хөкем ителгән кеше язган димәссең. Бер генә шигырендә дә Мирзаһит күңел төшенкелеге, аһ-зар тапмады, киресенчә, тормыш чаткыланып нурлана, я дошманнарга көйдергеч нәфрәт ташый. Шик юк, бу шигырьләр сугыш чорындагы бөтен татар шигърияген яңа баскычка күтәрер. Бөтен союзга, юк, бөтен дөньяга яңгырар!

Ниһаять, актыккы бит. Муса үзенең васыятен яза:

«Татарча язу танучы һәм бу дәфтәрне укучы дуска. Моны татарның билгеле шагыйре Муса Җәлил язды. Аның тарихы болай... 1942 елны сугышка килде һәм... әсирлектә күп газаплар чигеп, кырык үлемнән калып, ахырында Берлинга китерелде. Берлинда, сәяси яшерен оешмага катнашуда, совет пропагандасы таратуда гаепләнеп, кулга алынды, төрмәгә ябылды. Бәлки аны үлем җәзасына хөкем итәрләр. Ул үләр. Ә аның әсирлектә һәм тоткынлыкта язган 115 шигыре бар. Ул шулар өчен кайгыра. Шуның өчен 115 нең 60ын гына булса да күчереп калырга тырышты. Әгәр бу китап кулыңа төшсә, шигырьләрне яхшылап, дикъкать белән акка күчер, сакла һәм сугыштан соң, Казанга хәбәр итеп, үлгән татар халык шагыйренең шигырьләре итеп дөньяга чыгар. Минем васыятем шул! Муса Җәлил! 1943, декабрь».

Ахырда Муса Җәлилнең көрәштәшләренең исемлеге бирелгән.

Гариф Шабаев — бухгалтер; Муса Җәлил — шагыйрь; Әхмәт Симаев — журналист; Габдулла Баттал — Казан; Курмашев (Гайнан); А. Алиш — язучы; Фоат Булатов — инженер; Сәйфелмөлеков; Хисаметдинов — ветеринар врач; Мичурин — юрист; Әмиров — җырчы; Шәрипов... Шуннан соң шагыйрь тагын бер фамилияне өстәп куйган: бу — хыянәтче дигән.

Мирзаһит бу исемлекне кат-кат укыды. Ул бары тик Алишны гына белә. Ул кайтмады. Габдулла Баттал — шагыйрь Салих Батталның туганы түгелме? дип уйлап алды аннары. Сугышка кадәр консультация бюросында эшләгәндә башлап язучы Гайнан Кормашның исеме күзгә чалынып киткән иде. Бу — улмы, түгелме? Мирзаһит артистлар дөньясына гомумән якын торса да, Әмиров дигән җырчыны ишеткәне юк иде. Шулай да шушы кешеләрнең бәлки берсе ничек тә исән калгандыр. Эзләнү өчен бу бит үзенә күрә бер ачкыч.

Мирзаһит утә бер кызыксыну белән икенче блокнотны кулына алды. Монда Муса Җәлил белән Алишның шигырьләре күчереп язылган. Кем күчергәндер — билгесез. Мусаның шигырьләре астына М. Җ. дип куелган, Алишның шигырьләре астында тулы имзасы бар. Ләкин күчерүче Алиш та булмаган. Мирзаһит Алишның кулын таный иде. Әмма Алишның шигырьләре дә бик характерлы, аларда да, Муса шигырьләрендәге кебек, Ватанчылык хисе ташып тора.

Ниһаять, Мирзаһит башын күтәрде. Союзда бер кеше калмаган, барысы кайтып киткән, ишекне бикләмәгәннәр.

Кем булды икән бу блокнотларны китереп биргән кеше? Ул бәлки нәрсәдер белә булса кирәк.

Мирзаһит иртәгә үк шул кешене эзләп табарга булды. Билгеле, моны әйтүе генә ансат. Исем-фамилиясе дә билгесез кешене Казан хәтле Казанда эзләп табып кара! Ярый ла, ул әле Казанныкы булса, ә башка

бер шәһәрнеке, я республиканыкы булып, узып барышлый гына тукталса?

Икенче көнне Мирзаһит дәфтәрләрне акка күчертә башлады. Мусаның язганнарын күчергәндә машинистка Нәфисәнең күзләрендә яшь кипмәде. Ул Мусаны бик яхшы белә, аның кешелеклелеген тирән хөрмәт итә иде. Күз алдында шагыйрьнең елмаюлы сурәте торды.

Мирзаһит та бик күңелсез иде. Дәфтәрләрне китереп биргән кеше хәбәрсез-эзсез юк булды.

## 39

Беренче Моабит дәфтәре утлар, сулар, илләр кичеп Казанга кайтып җиткәч, Мусаның холкын, энергиясен яхшы белгән Мирзаһит күңеленнән аның икенчесе турында уйлана башлады. Шигырьләре үзе белән бергә үлмәсен, югалмасын өчен Муса бөтен көчен куеп тырышачак, хәтта мөмкин булмастаен эшләр кебек. Шуның белән бергә Мирзаһит шигырьләрнең Туган илгә таба юлы гади булмаска тиешлеген дә күз алдына ачык китерде. Беренче дәфтәре ирекккә ничектер чыга алган икән, икенчесенең чыгуына бөтенләй өмет юк түгел.

Ул өлкә комитетына, Мәскәүгә Фадеев янына барды, армиядән кайтучылардан сораштырды, аз гына өмет очы күренгән җирләргә — ераклыгы, юл газабы белән санашмыйча командировкаларга чыгып китте. Күп вакытта аның юлы да уңмый, тонык хәбәрләр генә алып кайта, кешеләр ачылып сөйләшми, ишеткән идем, шундый хәбәрләрне әсирләр сөйләгән иде, үзен күрмәдем, шуңа күрә өздереп берни әйтә алмыйм, бәлки дөрестер, бәлки дөрес түгелдер, анда мәхшәр иде бит, кебегрәк иде аларның җаваплары. Әмма Мирзаһитның күңеле төшми иде. Бу хәбәрләрнең тамчысы да кыйммәт, мөгаен, шагыйрь турындагы мәгълүматларны шулай тамчылап җыярга туры килердер дә. Йөри торгач, бәлки Мусаның дәфтәрендә күрсәтелгән кешеләрнең берәрсенә яки аларны белгән кешеләргә юлыгып куяр. Ул кайда гына булса да бу исемнәрне телгә алмый калмады. Әмма шул ук вакытта Мирзаһит боларның гына аз булуын сизә иде. Әйе, монда киң җәмәгатьчелеккә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Тик моны ничек эшләргә? «Идел-Урал» легионнары, аларның язмышы турында һичбер анык мәгълүмат юк, ул турыда элекке әсирләр гомумән сөйләми. Мирзаһит һәр вакыт гүя ниндидер стенага килеп төртелә, аны ничек әйләнеп үтәргә кирәген белми иде. Йөрәге белән генә сизә, легион мәсьәләсен читләтеп үтәргә ярамый, ачкыч кайдадыр нәкъ менә шунда яшеренгән булырга тиеш.

Халык сугыштан соң тынычланып җитә алганы юк иде әле, хуҗалык эшләрендәге төрле җитешсезлекләр — сугышның рәхимсез нәтиҗәләре һаман теңкәгә тиеп тора, тормыш авырлыгы үзен бик нык сиздерә. Мондый чакта кешеләр үткәнгә борылып карарга бик ашкынып тормый, бүгенге көне турында күбрәк кайгырта. Бу, әлбәттә, аңлашыла, ләкин бит вакыт үтү белән кайнар эзләр суынačак, аннары аларны эзләп табу бермә-бер кыенрак булачак...

Мирзаһитның командировкалардагы һәм Казандагы көннәре менә шундый авыр уйлар кичереп үтә торды. Редакция эше, сугыш бетте дип, әллә ни җиңеләймәде. Дөрес, хәзер кулъязмалар күбәйде, әмма кәгазь кытлыгы һаман хәл ителмәгән, редакциянең материаль ягы шактый читен. Парторг эше исә муеннан ашкан.

Шулай да вакыт дигәнең тиз агыла! Сугыштан соң инде бер ел үтеп тә киткән. 1947 ел башланды. Ул ниләр алып килер? Мирзаһит яңа командировкаларның маршрутын билгеләде. Эштән бераз бушый төшсә, хәзер чыгып китәргә тора, бәләкәй чемоданы күптән әзер.

Шул арада Брюссельдәге Совет илчелегеннән Казанга бер пакет килеп төште. Анда Муса Җәлилнең икенче дәфтәре иде! Мирзаһит күңеле алданмаганлыгын уйлап, шул ук вакытта чиксез дулкынланып, дәфтәрне кулына алды. Таныш кульязма, тик бу юлы шигырьләр барысы да латин хәрефләре белән язылган. Беренче дәфтәр гарәп хәрефләре белән иде, монысы латинча. Ник? Бер-бер сәбәбе бармы? — дип уйлады Мирзаһит.— Илчелеккә кем тапшырган? Әһә, Муса белән бер камерада утырган бельгияле Андре Тиммерманс! Их, күрсәң иде аны, сорашсаң иде!

Бу уйлар Мирзаһитның башыннан яшен тизлеге белән үтеп китте. Ул шигырьләрне укый башлады. Беренче бит «Җырларым» шигыре белән ачыла:

Җырларым...
Сездә минем бөтен тойгыларым,
Сездә минем керсез яшьләрем.
Сез үлсәгез, мин дә онытылырмын,
Яшәсәгез, мин дә яшәрмен.

Мирзаһит бу шигырьне аерыла алмыйча, кат-кат укыды. Ул Мусаның үзен күргәндәй булды, колак төбендә бик таныш, бик якын тавыш яңгырады. Кинәт Мирзаһитның сулышы капты, ул бер кулы белән галстугын бушатты, күзләрен йомды. Күр, Ясәви карт килгән. Мирзаһитның аны һичкайчан күргәне юк, фронтка китеп барганда аның турында Муса үзе сөйләгән иде. Хәзер дә Ясәви карт Мирзаһит белән түгел, кырын борылып, Муса белән сөйләшә кебек:

— Озакладың син, улым! Мин сугыштан соң чакырырсың дигән идем. Ярый, үз кешеләр, үпкәләшмибез. Кайтуың яхшы булган. Халкыбыз үзенең җырчысын сагынып көтә иде бит...

Мирзаһит күзләрен ачты, аннары томаланган күзлеген салып, кульяулыгы белән пыялаларын сөртте. Шуннан тагы шигырьләрне укый башлады.

Менә ул «Дуска» дигән шигырьгә җитте. Җәяләр эчендә А. А. га дигән. Кем А. А.?

Мин тиремне саклап исән калсам,
Үлем миннән аша сикерсә,
Шул яшәүме булыр, «хаин» диеп
Ил битемә минем төкерсә?!

Юк, теләмим мин бу «исәнлекне»,
Пөрәк минем моңа үчекмәс.
Кешеме мин илем үги иткәч,
Җирдә миңа эчәр су беткәч?!

«Муса илен һич онытмаган, ул аны сатмаган, ул хыянәтче түгел!» дип уйлады Мирзаһит. Моңарчы юк-юк дигәндә дә колакка ишетелгәләп торган шул ят, әшәке, котсыз сүзләр хәзер бик вак, бик мәгънәсез булып тоелды. Болар кайчандыр Һаҗәр сөйләгән кара күзлекле, «Остабикә» исемле диңгез күсесе күтәреп сату итеп йөргән базарчы сүзләре генә!

Аннары тагын А. А. дигән хәрефләргә игътибар итте. Кем ул? Бу, һичшиксез, Мусаның көрәштәше булырга тиеш. Габдулла Алиш? Тукта, беренче дәфтәрдә ул ничек? Габдулламы, Абдулламы? Бу исем бездә төрлечә языла, төрлечә йөртелә. Муса ничек яза иде икән? Беренче дәфтәрдә ул А. Алиш дигән иде ич! Әйе, бу Алиш!

«Бүләгем» дигән шигырендә Муса тоткынлыктагы дусты Андре Тиммермансның исемен тагын бер тапкыр атый. Мирзаһитның фикере яшен тизлегендә эшли: серле йомгакның очына чыгар өчен Андре Тиммермансны эзләп табарга! Бу бәлки бездәге бары тик исем-фамилия се билгеле кешене эзләп табуга караганда күп тапкырлар җиңелрактыр. Мирзаһитның чит илләрдә булганы юк, белми. Рус язучыла-

рына мөрәҗәгать итәргә кирәк, алар чит илләрдә еш була, бәйләнешләре зур, каршы килмәсләрдер.

Шулай эзләнүләр бер түгәрәккә җыела башлады. Икенче дәфтәр килгәч, Мирзаһит үзенең йөрүләрен көчәйтте, Советлар Союзының байтак республикаларында, өлкәләрендә булды. Аңа башка әдәбиятчылар кушылды.

Ниһаять, Мәскәүдә «Литературная газета» Константин Симоновның кыска мәкаләсен, Мусаның берничә шигырен русчага тәрҗемә итеп бастырды. Аннары 1953 елның азагында, «Моабит дәфтәре» Татарстан китап нәшриятында аерым китап булып басылып чыкты. Бик тиз арада Мусаның батырлыгы героик легенда төсен алды. Матур әдәбият сөюче меңләгән укучылар массасы хәрәкәткә килде. «Ул Мусаны белә булыр» яки «ул әсирлектә Мусаны күргән» дигән хатлар Казанга ява башлады, яңа исемнәр, адреслар әйтелде. Нәтиҗәдә әсирлектә Мусаны яки Алишны күргән байтак кешеләр табылды, аларның истәлекләре язып алынды. Ләкин алар арасында, Муса бер шигырендә әйткәнчә, «безнең авыр яшерен көрәшне җанлы экият» итеп сөйләрлек кешеләр юк иде әле.

1956 елның 2 февралендә Муса Җәлилгә Советлар Союзы Герое дигән иң югары мактаулы исем бирелде, ә тагын бер елдан соң «Моабит дәфтәре» дип аталган шигырьләре Ленин премиясе белән бүләкләнде. Дөнья Муса Җәлилнең батырлыгына таң калды.

## 40

Мирзаһит, уң кулын башына куеп, уйланып утыра. Әле яңа гына ул вокзалдан кайтты. Казанга вакытлы гына килеп чыккан Әминәне Мәскәүгә озатты. Мирзаһит дулкынланган, бераз арыган иде. Соңгы елларда ул бик күп юл йөрде, Архангельскидан алып Әфган чикләренәчә үтте. Матбугатта, радиода бик күп чыгышлар ясады. Аның тавышы кайларда гына яңгырамады, гади җыелышларда да, партконференцияләрдә дә — һәр җирдә аңа бик теләп сүз бирделәр. Нәтиҗәдә Муса Җәлилнең байтак кына актив көрәштәшләрен эзләп тапты. Кайдадыр Үзбәкстанның Алмалык шәһәрендә — кечкенә генә яңа шәһәрдә — Гарәф Фәхретдинов дигән кешене очратты. Әсирлектә ул Дим Алишев фамилиясендә йөргән икән! Алар музыкаль капеллада Муса Җәлилнең «Шүрәле»сен хәзерләгән, ләкин сәхнәдә куярга насыйп булмаган. Илгә Гарәф Франция партизаннары сафында сугышып йөргәннән соң гына әйләнеп кайткан. Кайдадыр Франция җирендә «үлгәнгә» саналган Рушат Хисаметдинов Кыргызстанның ерак Ош шәһәреннән үзе хәбәр бирде. Үзбәкстанның Ач дала артында адашкан Карши шәһәрчегеннән Фәрит Солтанов хат язды. Ул да, фашист төрмәләреннән соң, шулай ук Франциядән әйләнеп кенә туган җирләренә кайта алган. Тик Мирзаһит аны Солтанов дип эзләде бит. Ә ул Солтанбеков булып чыкты. Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре»ндә Мичурин дип күрсәтелгән кешене Мирзаһит ике ел буенча Урта Азиядән алып төньяктагы Печора шәһәренә кадәр арада эзләде. Ә ул Мичурин түгел, Гали Корбанов икән, тик әсирлектә генә Мичурин булып саналган. Ә җырчы Шәриф Әмиров Калуга өлкәсенең бер районында табылды. Әмма аның да чын фамилиясе Әмиров түгел, Гарифҗанов икән. Зиннәт Хәсәновның Сарман районы Иске Кәшер авылыннан икәне беленде. Ләкин аның да чын фамилиясе Хәсәнов түгел, Хөснуллин булган.

Рус язучылары чит илләрдән Андре Тиммермансны, Рениеро Ланфрединины эзләп табып, сөйләшеп кайтты. Ниһаять немец язучылары җәлилчеләрнең кайда, кайчан җәзалап үтерелүе турындагы рәсми документларны эзләп табып Казанга җибәрделәр. Үтерелүе хак булса да,

зәңгәр күзле немецның гына документы табылмаган. Күрәсең, фашистлар аны тагын да ераграк яшергәннәр.

Җәзалап үтерелгән җәлилчеләрнең тулы исемлеге менә нинди: Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Гайнан Кормаш, Әхмәт Симай, Гариф Шабаев, Фоат Булатов, Зиннәт Хөснуллин (Хәсәнов), Габдулла Батталов, Фоат Сәйфелмөлеков, Әхәт Аднашев, Сәлим Бохаров.

Соңгы икесе безгә шул документлардан гына мәгълүм булды. Кемнәр булган ул гаярь егетләр? Кайда туып үскәннәр, кайдан армия сафларына киткәннәр, кайсы фронтларда сугышканнар, ничек әсир төшкәннәр, ниһаять, кайсы лагерьларда яшерен оешма эшенә катнашканнар? Монысын инде яңа тикшеренүләр ачыклар.

Мирзаһит бу вакыт эчендә шактый арыган, ябыккан, чәче тәмам агарган иде. Шуның өстенә шәхси тормышында зур югалту кичерде — сөекле тормыш иптәше Һаҗәр кинәт дөнья куйды. Әмма күңеле белән Мирзаһит һаман нык, эшләгән эшеннән канәгать иде. Ул дусты Муса Җәлилнең васыятен үтәде, аның көрәш һәм тормыш юлын ачыклап мәкаләләр, китаплар язды. Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре» бөтен дөньяга таралды, бик күп телләргә тәрҗемә ителде, бүтән әсәрләре дә тулы басмаларда чыкты.

Абдулла Алишның иҗаты да балаларга кайтты. Рәхим Саттар шигырьләре дә китап булып басылды. Алар турында бик күп мәкаләләр, истәлекләр язылды. Билгеле, эшлисе эшләр, ачыклыйсы нәрсәләр дә байтак әле. Алары эшләнә.

... Мирзаһит, Муса Җәлилнең яңа чыккан китапларын караштыра-караштыра, язу өстәле янында утыра, уйлана.

Халык тормышында күп гасырлар буе кат-кат кабатланган бер хакыйкать бар: мескеннәр арасыннан батырлар, акылга таманнар арасыннан бөек акыл ияләре чыкмый. Дөньяда һәр нәрсәгә үсәр өчен зәмин кирәк булган кебек, батырларга да, бөек шәхесләргә дә үссен, чәчәк атсын өчен уңдырышлы нык нигез мәҗбүри — буш җирдә берни үсми, дип уйлады Мирзаһит. Мусалар үзләренең табигый зәмин-нигезләре — халыктан аерылмаган, алар тирәсенә арысландай батыр егетләрне берәү дә махсус тупламаган, халык арасында ул сәламәт шытымнар җитәрлек күп булганга, кирәк чакта, алар дөньяны таң калдырырлык яшел үрентеләр биргән. Тик, хаталанып, көрәштәш иптәшләрен Мусадан, Мусаны көрәштәш дусларыннан аерып алып карарга ярамый. Алар аерылмас бер бөтенне тәшкил итә. Мусаның бөек шагыйрьлеге дә шул гранит нигезгә килеп тоташа...

Мирзаһитның уйлары тирәнәйгәннән-тирәнәя барды. Бер хатында Муса бик дөрес итеп әйтеп калдырган: хәзер аларның халык күңелендәге икенче — үлмәс тормышы башлана. Ул гасырлар буе дәвам итәр, заманнар барышында үзенең гаҗәеп балкышын бөтен матурлыгында ачар. Әгәр Мирзаһит шул юнәлештә яңа әсәрләр яза алса — Мусаның шигърияте океан бит — үзен бик бәхетле санар. Ул язып өлгерә алмаганны яшь галимнәр, яшь әдәбиятчылар, язучылар дәвам иттерер.

Мирзаһит, башын күтәреп, тәрәзәдән карый. Зөбәрҗәттәй зәп-зәңгәр күктә тау-тау ак болытлар агыла. Өстәлдәге кып-кызыл канәфер чәчәкләренең чалмалары да, кояш нурлары белән яктыртылып, шул болытларга таба борылган. Мирзаһит күзләгән сала да күчмә ак кәрваннарның мәңгелек хәрәкәтен күзәтә башлый. Агыла да болыт агыла. Агыла тормыш. Хәят дәвам итә. Аның юлы очсыз-кырыйсыз...[1]

1977

---

[1] Безнең әдәбиятта Муса Җәлил һәм җәлилчеләр турында бик күп мәкаләләр, тикшеренүләр, китаплар басылып чыкты. Бу әсәрне язганда Мусаның сугыш еллары биографиясенә кагылышлы фактик материалларны, әлбәттә, искә алдым һәм алардан файдаландым. Шуларның авторларына чын күңелемнән рәхмәт белдерәм.

Автор.

Ренат Харис

# БӘХЕТЛЕРӘК КЕМ БАР БЕЗДӘН?

## Һавадандыр

Йөрәк кыса кайчак,
Тын кысыла...
Һавадандыр, диләр, һавадандыр...

Һавадандыр —
Урасы ашлыкны черетә яңгыр.
Һавадандыр —
Һава Җирдәге бар нәрсәгә кагылып тора,
Ил-җирләрне минем белән тоташтыра —
Кипрны да, Кытайны да, Ливанны да,
Чилидагы канга баткан диварны да...
Танкларның Җирне бозып даңгырдавын...

Тын кысыла.
Йөрәк кыса.
Һавадандыр...

●

Никтер еллар хәзер ак кар кебек —
Салмак бөтерелә...
Бик тиз тына...
Биткә түгел,
Янган иреннәргә түгел,
Чәчкә куна.

Ява... эри... ява... эри... ява... эри...
Карлы башымны чөеп мин
Эзләр салып йөрим.

Эзне вакыт көри...
Көрәгәне эри,
Җиргә сеңә,

Ташкын булып кушыла елгаларга...
Зәңгәр болыт безнең эзләр,
Көмеш балык, кызыл алма,
Яшел кына...

Ак кар түгел,
Ап-ак килеш безнең башка
Тормыш яме куна.

## Кермим

— Тәрәз ачтым,
Кер, кар,
Сиңа әйтер сүзем бар.
— Әйтер сүзең җылыдыр,
Ул җанымны җылытыр,
Кеше түгел — эрермен...
Тәрәзәң яп,
Кермим.

— Ишек ачтым,
Кар, кер,
Сөйләшеп утырыйк бер.
— Я сөйләрсең моң-зар,
Кеше түгел бит мин, кар —
Давылга әйләнермен...
Ишегең яп,
Кермим.

## Ялкын юрау

Гөжли-гөжли учак яна —
Шәүләсе чаршауда уйный.
Солдаткалар җыелганнар,
Һәркайсы үз ирен уйлый.

Чатный-чатный учак яна —
Шәүләсе чаршауда уйный.
Учак янында малайлар
Һәркайсы әтисен уйлый.

Ак чаршауда сугыш бара.
Ялкын ялмый, төтен ургый.
Шәүләләрнең хәрәкәтен
Барысы үзенчә юрый...

Ак чаршауда манзаралар
Алмашына бөрөзлексез.
— Әнә минем әти атта —
Аһ, аның аты сөрлекте...

Барысы да борылып карый
Шул малайның анасына.
Аның куздай кызыл йөзе
Көлгә әйләнеп бара сыман.

— Ялгыш күргәнсеңдер, улым,
Сөрлеккәндер дошман аты...
Ялкын шәүләсе кызарткан
Яулыгының читен капты.

Дүрт ел ядрә ерып йөреп,
Аның ире исән кайтты...

## Төнге урман

Битемне нидер тырнады —
Ботак булдымы,
Поши мөгеземе?

Алда нидер ялтырады —
Черек эземе,
Бүре күземе?

Нидер аякка чорналды —
Агач тамырымы,
Еланмы?

Муеным нидән чыланды —
Чыкмы, тирме,
Әллә канмы?

Чабам... Чабам... Чабаммы? —
Табан җирне таймый...

Капчык урынына башыма
Кап-караңгы дөнья каплап,
Куркаклыгым өчен мине
Шаулый-шаулый
Урман кыйный...

●

— Быелгы елның
Үткән елдан
Аермасы нидән тора?

— Кеше күбрәк йортлар сала,
Кошлар азрак оя кора...

## Яшел клавишлар

Яфракларга
Шыбыр-шыбыр яңгыр ява.
Яшел клавишлар батып-чүгеп ала.

Яңгырый агач,
Чыңлый чәчәк,
Җырлый үлән...

Һәм күңелдә яңгыр эзе булып
Илаһи моң-тынлык кала.

•

Тәрәзә, парланып, дөньяны каплады,
Түзмәде, тулышты һәм елап җибәрде.
Бер тамчы яшь сызып төште яп-якты эз.
Шул тамчы яшь эзе аша
Ачыграк күрдем дөньяны...
Яратмыйм кешеләр елаганны,
Ә елаганнарын күрсәм,
Күз яшьләреннән
Күземне ала алмыйм.

## Бәхетлерәк кем бар бездән?

Карда йөрдек,
Балчык издек,
Чирәмгә басабыз тиздән —
Бәхетлерәк кем бар бездән?

Җиребезне исән килеш
Кояш тирәли тагын бер
Зырылдатып әйләндердек —
Бәхетлерәк кем бар бездән?!.

Тетрәде Җир, корылык узды.
Андыйларга гына түзгән.
Җиребезне исән килеш
Кояш тирәли тагын бер
Зырылдатып әйләндердек —
Бәхетлерәк кем бар бездән?!.

Кыш килде көз уртасына.
Кырны карга бутаса да,
Ач калмадык, амбар тулы —
Андыйларга гына түзгән.
Җиребезне исән килеш
Кояш тирәли тагын бер
Зырылдатып әйләндердек —
Бәхетлерәк кем бар бездән?!.

Көнне бизи хезмәт яме.
Төнне бизи үбешүләр.
Яшь хатыннар бәби таба,
Тапкан саен сөенә-сөенә...
Әхлагыбыз нык нигездә.
Шундый тормыш өметсезме?!.
(Андыйларга гына түзгән!)
Җиребезне исән килеш
Кояш тирәли тагын бер
Зырылдатып әйләндердек —
Бәхетлерәк кем бар бездән?!.

Дошманнар кимесәләр дә,
Гайбәтләре арта бара.
Колак тулды, йөрәк тулды
Илебез өстенә койган

Төрле телле шакшы сүздән.
Күңелебез һаман да саф,
Байрагыбыз һаман чиста!..
Гайбәтләргә генә түзгән.
Җиребезне исән килеш
Кояш тирәли тагын бер
Рәхәтләнеп әйләндердек —
Бәхетлерәк кем бар бездән?!.

Карлар кичтек,
Балчык издек,
Чирәмгә басабыз тиздән!

## Беребез тирәли беребез

Беребез тирәли беребез
Якыная алмыйча йөрибез...

Сорыйсың:
    — Ник алай, әйтеп бир.
Мин әйтәм:
    — Син — Кояш! Ә мин — Җир.
Әйтәсең:
    — Нәкъ шулай, нәкъ шулай —
    Син Җир шул, ә мин — Ай!
    Ярты Ай...

Беребез тирәли беребез
Якыная алмыйча йөрибез...

●

Малай әйтә:
— Беләсеңме,
Айны күктә кем кабыза?..
Белмисең шул —
Минем абый... Шырпы сызып....

Кызчык әйтә:
— Беләсеңме,
Айны күктә кем сүндерә?..
Белмисең шул —
Сүндерттерә күрше кызы...

# ФАТИХ ХӨСНИГӘ 70 ЯШЬ



«Мәтәскәнең фантазер малае...»

Кайчандыр Ибраһим ага Гази тарафыннан дусларча шаярып шулай дип аталган һәм шуннан соң дуслары, кордаш язучылары арасында якын итеп шулай атап йөртелгән дустыбызга, язучы Фатих Хөснигә 70 яшь тулды. Шулай итеп, ул хәзер фантазер малайдан хөрмәтле аксакалга әйләнде. Аерма тик шунда: ул хәзер Мәтәскә авылыныкы гына түгел, ә республиканыкы, әдәбиятныкы, халыкныкы.

Бөтен язылган әсәрләре, тормышы һәм, шәхес буларак, үзе көләч юмор белән сугарылган Фатих Хөсни, юбилей бәйрәменә килгән бу очракта да, аның гомер юлы белән кызыксынучыларның бәйләнчек сорауларыннан юмор бөркәнчеге астына качып котылып калмакчы булды. Мәсәлән: «Сезнең барлыгы ничә китабыгыз бар, Фатих абый?» — дигән сорауга ул гадәтенчә кеткелдәп көлә-көлә: «Белмим, мин китапны санар өчен түгел, укыр өчен язам», — дип кенә җавап бирде.

Шулай да әдәбият сөючеләр аның 1927 елдан бүгенге көнгә кадәр сүнмисүрелми дәвам итүче иҗат дәверендә (авторның түбәндә укучыларга тәкъдим ителгән яңа повесте шуның матур бер мисалы булса кирәк) утыздан артык китап язып, алар арасында ике роман, унике повесть, дүрт сәхнә әсәре һәм күпләп хикәяләр бар икәнен беләләр инде.

Хикәя дигәннән, Ф. Хөснинең бу жанрга карата аерым мөнәсәбәте бар. Әйдәгез, әдипнең үз сүзләренә колак салып карыйк әле: «... хикәя жанры миңа иң якыны. Хикәядә мин үземне кунакта дип түгел, «үз өемдә» итеп хис итәм», — ди ул әле узган ел гына Башкортстан китап нәшрияты бастырып чыгарган хикәяләр китабының сүз башында. Әйтергә кирәк, кызыксынучы укучы авторның бу сүзләре белән тулысынча килешә.

Ф. Хөсни үзенең гомер юлы белән кызыксынучылардан юмор белән генә котылырга уйласа да, кылны кырыкка ярып, кыл эчендә ниләр бар икәнен күрә белүче укучылар яраткан әдипләренең тәрҗемәи хәленнән байтак моментны да белеп алдылар. Мәсәлән, «Гыйльмениса һәм аның күршеләре» дигән повесте һәм хикәяләре өчен Ф. Хөснинең 1972 елда Г. Тукай исемендәге республика премиясе лауреаты булуы; татарча басылу белән берлектә язучы әсәрләренең күбесе Мәскәү нәшриятлары тарафыннан рус телендә чыгарылуы; шул җөмләдән, әлеге ике романы, өч повесте һәм бик күп хикәяләре рус, казакъ, үзбәк, башкорт, чуваш телләрендә басылуы; Ф. Хөснинең үзенең дә үзәк матбугатта әдәбиятның теге яки бу актуаль мәсьәләләре буенча еш кына чыгышлар ясап килүе; аның төрле елларда Татарстан Язучылар союзы идарәсе, «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы редколлегиясе, Тынычлыкны яклау буенча республика комитеты члены булып торуы; язучыларның Бөтенсоюз һәм РСФСР съездларында өлгергән

*мәсьәләләр буенча чыгышлар ясавы һәм тагын бик күп, бик күп җәмәгать эшләре башкаруы укучыга билгеле.*

*Әлбәттә, Ф. Хөснинең язучылык һәм җәмәгать эшләрен укучы белән бергә партиябез белән хөкүмәтебез дә күреп торды һәм аны Хезмәт Кызыл Байрагы һәм «Почет билгесе» орденнары, медальләр һәм Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләде.*

*Күрәсең, эшләгән эшләрне һич кенә дә юмор бөркәнчеге астына яшереп тотып булмый икән. Шуңа күрә без бүген хөрмәтле Фатих ага Хөснинең бай һәм кызыклы иҗади мирасын күреп торабыз, күп санлы әдәбият сөючеләр белән бергә әдипкә яңа иҗади уңышлар телибез, олы бәйрәменең мөбарәк булуына ышанабыз.*

## Фатих Хөсни

# КАРТАЯ БЕЛМӘС КАРТЛЫК

ПОВЕСТЬ

### I



Әлбәттә, картлык шатлык түгел. Шул ук вакытта картлык соңгы тукталыш та түгел. Соңгы тукталышның сине кайчан һәм кайда сагалап торганлыгын белмичә яки белмәмешкә салышып, дөньяда яши бирәсең. Алда әле иртәге көнең, аның иртәгесе бар, кем белгән, бәлки бик күп якты иртәләр бардыр... Кайдадыр сине көтелмәгән шатлыклар, күңелле очрашулар, көләч йөзләр, яшь вакытта югалткан гашыйкларың каршы алыр кебек. Өмет, ымсынулар, төсен җуймаган хыяллар, кайдадыр еракта-еракта, офык читендә әлегә сүнмәгән, ләкин үзең сизеп торасың: сүнә баручы ялгыз бер йолдызың — нәкъ менә синең үз йолдызың бар. Алып ташлагыз картлыктан шушы таяныч нокталарын, асты куышланган ком тавы кебек, ул дәррәү ишелеп төшәчәк.

Тагын шуны да онытмагыз, шәфәкъ шәфәкъка охшамаган кебек, бер картлык икенчесенә шулай ук охшамаган. Берәве бар — сызланып туктамый, зарланудан башы чыкмый, кешеләр белән дуслаша алмый, хәтта үз балаларын, балалары балаларының да кыланышларын өнәми, кычкырып көлүчеләр аның җенен кузгата. Икенче берәүләр бар — андыйлары сызланган әгъзаларын тыңламас өчен юри тормыш эченәрәк чумарга тырышалар, яңа тип анекдотлар уйлап чыгаралар, кешедән көлгән булып үзләреннән көләләр, некрологлардан бүтәнне укымыйлар, гомумән, бер нәрсә дә укымыйлар, кара көзгә хәтле шәһәр аръягында бакчаларында яшиләр, карчыклары алданрак дөнья куйган булса, бер мәлгә аларны юксынып йөриләр, ләкин бу юксынуны бер-

вакытта да трагедиягә әйләндермиләр, жае чыкса, тизрәк икенче карчыкка өйләнү ягын карыйлар...

Гомумән алганда, эч пошуны белмәс, картлык турында уйламас, ишекләрен үлем шакып торганны ишетмәс шат күңелле картлар болар. Бу повестьта мин, парадоксаль хәл: бәлки үзем беренче категория картлардан берсе булганлыктандыр, күбесенчә икенче тип картларны геройларым итеп алам, чөнки аларның әлегә геройлар булып соңгы мәртәбә бер ялтырап калырга хаклары бар.

... Узган ел көз, ноябрь урталарында, минем зур бер химзаводта инженер-механик булып эшләүче өлкән улым, үзе дә балалар атасы, әлбәттә, миннән аерым яшәүче Рафаил, бер дә тел яшермичә тора тартып әйтә куйды миңа:

— Картаеп барасың, үзеңнең туган авылыңны — Мәтәскәңне дә күрсәткәнең юк, отпускамның файдаланып бетмәгән ун көне бар, әллә бер-ике көнгә генә алып кайтасыңмы? Мәтәскә урманындагы куяннарны жәлләмәсәң... Бер-ике куяныгызны атып, соңыннан куян бәлеше белән сыйлармын үзеңне.

Аучы ул, буш вакытларында, шимбә-якшәмбеләрдә кырга-урманнарга китеп югала һәм, мактана бу дип уйламагыз, әлбәттә, буш кул белән кайтмый. Ә бу очракта мин малаем белән мактанырлык икенче бер фактны күргәндәй булдым: юк, әтисенең туган авылы, әтисенең туган жире аның өчен дә битараф бер географик төшенчә генә түгел булса кирәк.

Ник озакка сузып торырга! Мәтәскә качкан жирдә түгел, автовокзалда «атлар жигүле», Теләчегә хәтле билет аласы да, алган билетының бәясен дә чыгарып житкерми торып, Теләчедән жиде-сигез километр алда, урман уртасындагы кордонда төшәсе. Калган ягын тәпи-тәпи тыраклап.

Сәфәребез дөм буш булмады. Малай алтышар килолы ике куян атты — урманнан түгел, кырдан. Көзге ужым кыяклары чүпләнергә чыккан булганнар. «Өчесе чапты, аларына өлгереп булмады», дигән була үзе. Әйдә, анысы инде сунарчы мактанчыклыгы булсын, ди. Мин үзем Мәтәскәнең сигезьеллык мәктәбе укучылары һәм укытучылары белән очрашу үткәрдем. Аларда нинди тәэсир калгандыр, алар өчен жавап бирә алмыйм, үзем бик канәгать калдым — яңадан бала чагыма әйләнеп кайткан кебек хис иттем үземне.

Әмма сәфәребезнең иң кызыклы ягы бу түгел, сәфәребезнең иң кызыклы ягы шунда: безнең нигез күршебез, бергә уйнап, бергә кызлар сөеп үскән егет Хисами — хәзер инде ул да стажлы пенсионер — белән без бераз кардәш тә тиешле идек. Ләкин кайсы яктан? Ни дәрәжәдә? Анысын ачык кына белми идек. Бәлки ул кадәресе дә картая башлау галәмәтедер, бу очрашудан файдаланып, без әлеге мәсьәлә белән ныклабрак кызыксына башладык. Күршелеккә күрше, ул турыда сүз дә юк, ләкин, ниһаять, ачыкларга кирәк: кардәшлегебез ни дәрәжәдә? Кайсы яктан? Хисами үзенчә аңлата, мин үземчә. Малай, безнең янда юк мыегын сыпыргалап, «карт тиләләр, таптылар бәхәсләшер нәрсә!» дигәндәй, көлемсерәп утыра бирә. Хисаминың ерак авылдан килгән хатыны бу мәсьәләдә, әлбәттә, бер якка да катнашмый, ә табынга якын да килмичә, керә-чыга өй эшләре карап йөргән балаларына мин бары тик «кунак абый» гына — артык та түгел, ким дә түгел.

Шулай да бәхәсне куертмадык, Хисами әмәлен үзе уйлап тапты.

— Давай, без моны иртәгә Сәгытдин абыйдан барып сорыйк, ул безгә тәгаенен генә әйтеп бирер.

Кинәт аптырап калдым мин: тукта әле, тукта. Сәгытдин абзыйны беләм, Хисаминың әтисе Низаметдин абзыйның энесе, без малай чакта

ул Теләче базарыннан кош тоткандай кайта белүче, уен-көлкеле кеше, бик борынгы кеше ул, әле ул исән микәнни?

Минем аптырап калганны сизеп, Хисами шундук ачыклык кертергә ашыкты:

— Туксан алты белән бара, ләкин әлегә бик бирешкәне сизелми. Яшь хатынга өйләнде. Узганны биш бармагы кебек белә, хәзергене сорама.

— Ай-һай, яшәсә дә яшәр икән кеше!

Димәк, Мәтәскәгә ясаган бу визитыбызның мин күреп җиткермәгән өченче ягы да килеп чыкты — аяклы тарих белән очрашачакбыз. Әле моның тагы шул ягы да кызык: җитмеш бусагасына таба үрләсәк тә, без әле чагыштырмача яшьрәк, үзебез очына чыга алмаган мәсьәләнең очын табар өчен йөзгә җитеп килә торган карт каршына барачакбыз.

Сәгытдин абзыйларның кайчандыр тегермән очында торганлыкларын белә идем, Хисами, капкадан чыгуга, капма-каршы якка — зират очына таба алып китте.

— Кайберсен ул сиңа үзе аңлатып бирер... Туксан алтыга җиткән кешенең зиратка якынрак елышуы гаҗәпмени,— дип шаяртып алды ул. Бара-бара тәфсилләде: моннан берничә ел элек тегермән очында зур янгын чыгып, шул янгында Сәгытдин абзыйларның өйләре дә көлгә әйләнгән. Башка яшьрәк кешеләр үз урыннарында инде яңа өйләр җиткезеп кергәннәр, ул чагында ук туксанга җиткән, карчыгыннан да аерылып калган, бүтән бер кеме дә булмаган картка колхоз икенче очтагы иясез бер өйне сипләтеп-яңартып биргән. Бер килә башласа килә бит кешегә, чама белән шул елларны картыбыз үзенә иптәшкә алтмыштан ашкан бер карчык табып, өйләнеп тә куйган. Хәзер исә шул яңа ояда бер-ике торык каралты-кура да торгызып, каз-тавык, сарык асрап, кеше рәтеннән төтен чыгарып яшәп ятмакта, имеш. Теге «зиратка якынрак елышу» дигән сүзләр дә Хисаминың үз сүзләре түгел, кеше сүзен үзенеке итеп мактанасы килмәде иске күршемнең:

— Карт үзе шулай да, үләм дип исе дә китми, ичмасам, авылда аяклы тарих булып яши бирә,— дип өстәде соңыннан.

«Исе китсә-китмәсә дә», шулай да туксан алты яшь үзенекен иткән, без барып кергәндә яткан урыныннан калкыр-калыкмас түгәрәк ак сакаллы, кырган булганлыктан чәченең ни төсле икәнлеген аерып та булмаслык, җитмәсә, башына хәтфә кәләпүш чәпәгән, тирәнгә батып кергән нурсыз күзләре әйле-шәйлерәк күргәнлектән, без кергәнне барыннан да элек аяк тавышыннан гына чамалаган картыбыз, биргән сәламебезне алу өчен ничек кирәк алай селкенгәләп торып утырды:

— Бәрәкалла, кунаклар каршылыйсы көн дә бар икән, кара әле, сиңайтәм, тиз генә самавырыңны яңартып җибәрче,— дип, карчыгына команда бирергә дә өлгерде шул арада.

Без, әлбәттә, аларны андый мәшәкатьләр белән бимазаларга теләмәдек, монда күбрәк, агай-эне кеше буларак, дилбегәне Хисами кулга алды.

— Мин — ярый, үз кеше, чәйне сездә бер генә түгел, күп тапкырлар эчкән бар, мине танийсыңдыр,— дип тезеп китте ул, картның колагына таба авыша төшеп һәм нык кына кычкырып өстәде,— я әйтеп кара, менә бу минем белән килгән кешене кем дип танийсың?

Картыбыз, бар күк җегәрен җигеп, төбәлә төшебрәк бер мәл миңа карап торды да, мелт-мелт кыймылдап торган иреннәре арасыннан һич көтелмәгән сискәндергеч көчле тавыш белән:

— Бакчы... Пәтыйх түгелме соң?.. Пәтыйх үзе ич бу,— дип кычкырып җибәрде. Шундук, урыныннан шуыша төшеп, күрешергә дип ике кулын сузды. Без кул кысышып, озаклап күрештек, аның сөяк белән тиредән генә торган куллары өшеткеч дәрәҗәдә салкын иде. Карт,

беравык ни дип сүз башларга белмичә, юка, җансыз иреннәрен кыймылдаткалап торганнан соң, кинәт шундый шәп сүз тапканлыгына үзе дә куанган кебек, булдыра алганча кычкырып:

— Сөбаханә-алла, маша-алла, күз тимәсен, үсеп беткәнсең ич син, Пәтыйх җаным.

Әйтәсе дә юк, зур комплимент булды бу миңа, житмешкә житеп килә торган кешегә. Монда, әлбәттә, көләргә дә урын бар иде, ләкин шундый борынгы кешедән көләргә мөмкинме соң! Мин, үз чиратымда, Сәгытдин абзыйның шушы өлкән яшькә житкәнче исән-имин торуына, аның бер күрү белән мине танып алуына сокланып, нидер әйтмәкче булып тик авызымны гына ачып өлгердем, картым, ялганып-ялганмавы белән исәпләшеп тормастан, яңгын вакытында башыннан кичкән хәл-әхвәлләрне, ут эчендә калган әйберләрне алырга дип кергәндә үзенең бармакларын яндырганлыгын, тагы әллә ниткән, әллә ничаклы тамашалар булганлыгын үзенчә бик дәртләнеп, миңа бөтен тулылыгында житкезергә тырышып сөйләп китте. Мин аның бу очсыз-кырыйсыз сүзләрен жупләгән атлы күренергә тырышып:

— Шулай да, Сәгытдин абзый, шөкер итегез... шундый тамашалардан соң да...— дип сүзгә кысылмакчы булган идем дә, Хисами, картка сиздермичә генә, ым какты. Кайтышлый аңлатып бирде: кем генә, кайдан гына килгән кеше булмасын, картның бөтен сөйләгәне шул янгын, аның кешеләргә сөйләрдәй бүтән сүзе калмаган һәм ул моны житкезгәндә, әгәр бүлдерсәләр, балалар кебек үпкәли, башыннан ук бөркәнеп урынына ук йомарланып ята.

Ә мин — беркатлы — үземчә салпы ягына салам кыстырмакчы идем: янәсе, шөкер итегез, Сәгытдин абзый, шундый-шундый тамашалардан соң да шушы яшькә тикле исән-имин яшәгәнсез.

Бактың исә, аның үзенең дә тел төбе шуңа бара, ләкин ул, артыннан эткәнне көтмичә, үзенчә әкренләп барырга ярата икән. Әле ул гынамы? Шушы яшендә картыбыз Мәтәскә кешеләренә хас юмор хисен дә югалтмаган.

— Бармакларым инде үлделәр,— дип, үз җае белән янә ялгый ул,— чынаяк тәлинкәсен учым белән тотып эчәм, илла да, зиратка якынрак күчеп килсәм дә, ул якка бик ашыкмыйм әле.

Ул, сүзеннән туктап, иреннәрен тагы беравык «мелт-мелт» кыймылдатып торды, йөзенә, күзләренә елмаю сыман бер нур чыкты, юк, юк, сүзләре бетмәгән иде әле аның.

— Ашыкмавымның сәбәбе шунда: беренчелектән, дөньясы зрә рәхәткә китте, теге дөньядагы җәннәт бик кызыктырмый хәзер бәндәне. Икенчелектән килгәндә, көфер булса да әйтим: Газраилне адаштырдым бит мин тәки. Ул бичара мине теге очтан — тегермән очыннан эзли, ни генә әйтмә, гомер шул очта узган ич. Ә мин, аңарга сиздермичә генә, бу очка килеп кунакладым. Җәлләп тә куям кайчак Газраилне: эзли дә эзли, ә таба алмый. Юк Сәгытдин карт хәзер тегермән очында.

Бу картның сөйләгәнен, гәрчә әйләнә-тулгана һаман шул бер янгын тирәсендә буталса да, тыңлаудан ялыкмадым мин. Хисами кече якта карчыкның самавар кайнатып матавыклануын шәйләп алган, эшнең зурга китүеннән шикләнеп, кузгалырга булдык.

Чыгышлый, салкын өйалдында өрлектә дүрт сарык, сигез каз түшкәсе эленеп торганны күреп, мин Хисамига күз кыстым.

— Үзләренеке... үз хәзинәләре,— диде Хисами, минем күз кысуымны аңлатканны бик тиз төшенеп. Шундук аңлатып бирергә дә ашыкты:

— Абзыебыз йөзне тутырачак та тутырачак. Әнә ул симез түшкәләрне, өстәвенә яшь хатынны калдырып, «теге дөнья»га ашыгуның нинди хасияте бар?

Соңыннан бу повестьны язып бетерәрәк ишеттем: шулай да ахырчиктә бу мәшәкатьле дөньяны калдырырга туры килгән Сәгытдин абзыйга.

## II

Урамга чыккач исебезгә төште, без Хисами белән булган туганлыгыбызның ни дәрәҗәдә икәнлеген Сәгытдин абзыйдан төгәл генә ачыклауны сорарга, кыскасы, төп йомышыбызны йомышларга оныткамбыз лабаса! Яңадан керү, әлбәттә, уңайсыз иде. Әйдә, мона чаклы йөрелгән, шул сукмаклар моннан соң да ярар әле.

Тагын шушыңа игътибар иттем: яшьләр кайсы кайда эштә булсалар кирәк, урамда картлар һәм казлар гына очраштыргалап куя иде. Сәлам бирү, исәнләшү белән эшне бетереп, тизрәк узып китү ягын карыйбыз. Сөйләшә башласаң, озынга китә: син кем дә, мин шул. Картаймыйбызмы да, шайтан картайсын, яңадан көрәшкә керергә исәп бар әле быелгы мәйданда! Җор телле Мәтәскә кешеләренең сүзләре бетәсе түгел. Ә чынлап әйткәндә, берсен дә танымыйм үзләрен. Төсмерләүгә төсмерлим, ә кем дип атап эндәшергә дә белмим.

Шундый онытылган авылдашлардан берсе тиз генә узып китә торганнардан булмады. Кызык: Хисами да танымый, мин дә танымыйм үзен. Ә үзебез урам уртасында тукталып калганбыз. Бездән дүрт-биш яшькә өлкәнрәк, шулай да сөйләшергә яратучан ябышкак адәм булып чыкты үзе.

Аптырагач, сүз таба алмагач, әйттем:

— Мин сезне кайдадыр күргәнем бар. Ә кайда? Суегыз, әйтә алмыйм.

— Ипподромда түгелме?

— Юк, мин ипподромга йөрмим.

— Зрә йөрмисез. Ат яратмаган ирне мин иргә дә санамыйм.

Турыдан бәрә бу карт. Без Хисами белән, сиздермичә генә, карашып, елмаешып куйдык. Күрмәс дип уйлаган идек, күргән икән, тагы да ныграк бәйләнергә тотынды. Әллә башында ук бар инде, тәмам сагызга әйләнде.

— Ә стадионга йөрисезме?

— Булгалыйм.

— Булгалау гына җитми, бер матчны да калдырмый йөрергә кирәк. Мин үзем берсен дә калдырмыйм. Безнең «Рубин»ның эшләр ходка китте хәзер. Сентябров кына томалап яткан икән Казан футболчыларын.

— Сентябров дигәнегез кем?

— Ышандым, чын болельщик түгел икәнсез, шуны да белмәгәч соң!.. «Рубин»ның элекке тренеры.

Кызык бер караганда: Мәтәскә урамында басып торабыз, Казанның футболын тикшерәбез. Үзебез — өч карт.

— Сез Казаннан булсагыз кирәк?

— Тумышым шушы Мәтәскәнеке, ә торуым Казанда, утыз ел мехкомбинатта скорняк булып эшләдем, пенсиягә киткәч тә биш ел эшләдем, тире исенә борын іяләшкән, аерыласы килми. Хәзер патентованный пенсионер. Җәен балыкка йөрим, футбол матчына чабам. Шунсыз булмый: мин бармасам — безнекеләр оттыралар.

Һәм кинәт, истә-остә юкта, дуамал гына ярып салмасынмы:

— Кайтырга уйласагыз, без иртәгә — сәфәр. Минем малай машина белән.

Аның дуамаллыгы миңа да йокты, болай ансат алып кайтучы табылып торганда соң... Аз гына урынымнан да купмыш идем булса кирәк, тәкәллефсез генә сорадым:

— Нишләп йөреш иде соң болай ашыгыч?

Сүзгә беткән абзыебыз чак кына көлемсерәп тынып калды. Соңра, «Беткән баш — беткән, чының әйтүгә ни житкән!» дигәндәй, ярып салды:

— Уен корып йөрү, дөресен әйткәндә. Чардуган кайтардык. Мәтәскә зиратында бер дигән булачак. Тоташ чуеннан.

Уен кора торган сүз түгел бу — зират, чардуган. Аптырабрак булса да киравксез сүз ычкынды.

— Әллә өегездә берәр үлем-житем булдымы?

Абзый шаркылдап көлеп куйды:

— Чардуган корып, урын алып куюдан кемгә зыян: минамы, аллагамы? Безнең ишегалдында, күршебездә генә диярлек, бер урыс карты бар. Кучкач тә тач имәннән үзенә гроб ясап куйды, ә үзе имән кебек таза, яшь бирә.

— Үз кулы белән ясадымы? Үзе исән чакта ук? Шулай да әллә ничегрәк.

— Дөрес, минем дә күңел тартмый тартуын,— кинәт ул дәртләнеп, кабынып китте,— дөресен генә әйткәндә, Яңа бистә зиратының хужасы Фәрвәз корсакка ачу чыкканнан эшләдем. Үзебезнең якныкы, панимаеш, Шыңар авылыннан: соңгы вакытларга хәтле иске зираттан урын вәгъдә итеп йөрде, кайда икәнлеген дә күрсәтте, магарычы да эчелде. Хәзер килеп, «әнә теге очтан синң ход, Фәрхулла абзый, яңа капкадан каршы алырбыз» ди. Кулын әллә кая, урта Кабан ягына таба жәя. Беләм мин ул юлны, керәле дә чыгалы. Жәен аяк йөзеннән тузан, төтен, туфрак. Нишләп тузан-төтен арасыннан йөрергә тиеш, ди, мин соңгы юлымны. Үзем эшләгән мехкомбинат яныннан, иске капкадан, иске зиратка булса, әйтер сүзем юк. Ә миңа — яңа капкадан, имеш. Шул корсак Фәрвәзгә ачу итеп урынны Мәтәскә зиратыннан сайлап куярга булдым. Ата-бабаларыбыз янына. Малай минем шофер, самосвалда эшли. Вакыты гына житсен, алып кайтырлар шул самосвалга салып та, бушатырлар. Дөньяга яңа килүчеләргә әзер урын кала дигән сүз.

Без үлем һәм зират кебек нәрсәләр турында шулай жиңел, уенкөлке кыстырып сөйли торган бу абзыйга гажәпсенеп, авызына текәлеп торган арада абзый шундук тагы бүгенге көнгә күчәсе итте.

— Анда безнең Мәтәскәгә, Жаһилгә силсәвит башы булып Әхмәтшаныкылар Габдрахманының Хажие утыра икән. Кердем, күрдем — корсак дигәнең аныкы да шактый. Шулай да шүрләп тормадым, әйттем: «Анда синең зират коймаларың торык-торык авып ята, мине жирләгәнче нығытып, тоттырып куй. Югыйсә, син яшь кеше, белеп тә бетермисеңдер, «Чуар йөрәк Фәрхулла» диләр мине. Күмгәннең икенче көнендә үк качтым киттем булыр зиратыгыздан. Соңыннан жавапка тарттырып йөдәтеп бетерерләр үзеңне, мин әйтәм.

Фәрхулла картның «самосвал» дигән сүзе колакка керде керүен дә, әллә ни комфортлыгы булмас инде, Кордонга хәтле жәяү тыраклаганчы, алып кайтсалар, шөкер диген. Аннары, гомумән, ошады ул Фәрхулла карт миңа. Юлда сөйләшеп кайту үзе ни тора. Иртән жыенып барсак, «самосвал» урынына өр-яңа «Волга» ялтырап тормасынмы. Малайның — аучы кеше бит — эте дә бар иде, «Волга»ны күрүгә капкадан шундук кире борылды.

— Кая качасың, без машинада, барыбер куып житәрбез үзеңне,— дип кычкырды Фәрхулла карт. Алтышар килолы әлеге ике куянны, мылтык вә башка жиһазларын багажникка салдык, карт белән машина йөртүче малае алга, аучы Рафаил белән мин түргә кунакладык. Үзебез кырнына эт тә сыйды тагын. Мондый кадер-хөрмәт күргән хайванмы соң эт, әлек гажәпләнгәндәй як-якка башын боргалады, аннары юл буе тәрәзәдән яланны, юлда очраган ыругдашларын тамаша кылып кайтты.

— Тик шуны колагыңа киртлә, энем,— диде Фәрхулла карт, бу юлы малайга таба борылып,— куян бәлешенә этиең белән бергә мине дә чакырырсың. Безгә — карт кешеләргә — күп кирәкмени...

— Анысыннан эш терәлеп калмас,— дидем мин, малай өчен тизрәк җавап бирергә ашыгып.

— Авылга ашыгуымның сәбәбе бар,— диде бераздан картым уйчанланып,— килен белән уртак тел таба алмадык. Килә-килешкә өнәмәде, кирәген дә, кирәк түгелен дә күп сөйләшәсең, эткәй, ди.

Күреп торам ич мин арттан, малае, баранканы кысыбрак тоткан атлы булып, этисенең янтыгына җиңелчә генә төртеп куйды. Янәсе, кузгатма кузгатмастай сүзне. Дипломатия өлкәсендә эшләмәсәм дә, мин дә бит төшеп калганнардан түгел. Фәрхулла карт малае шоферга да, үземнең малай җаена да ятарга тырышыбрак, әйтә куйдым:

— Без картларның шул инде: билдә ыштан, телдә сүз тормый. Ихтимал, күбрәк тә сөйләшеп ташлыйбыздыр кайчак.

— Кайчак түгел, күп чак,— дип эләктереп алды карт, аның тизрәк акланасы килә иде булса кирәк,— бу чардуган кайтарып мәйханә килеп йөрүнең бер секреты да шул — киленне тынычландыру. Юкса, яхшы кешеләре көннән-көн күбәя барган бу якты дөньядан китәмме соң мин. Ике сугышта — гражданнар сугышында, Отечественныйда китмәгәнне.

Әле генә килененә кагылып сүз кузгатырга ниятләгән карт кинәт шуны якларга керешкәнен сизми дә калды:

— Килен дә шулай ди. Юкка йөрисең тилереп, утыртып кайткан чардуганың шул утырган җирендә күгәреп черер, ә син калырсың әле, эткәй, ди. Җибәрәсе килми.

— Димәк, малаеңа да, килененә дә тел тидерерлек түгел.

— Малай белән киленне бутама. Малай минем телсез. Аның авызыннан сүзне келәшчә белән тартып алырга кирәк, ә киленем үзем кебек шалаван. Калач ашамаса ашамас, аңа уен-көлке сүз бир. Әле бу сәфәргә китешли дә җәллатмәкче булып сүз кузгатып карадым: «Безнең ул Мәтәскә зираты салкынлыкка салкын булыр инде, баштарак уйлап җиткермәгәнмен», — янәсе.

«Яныңа тимер мич илтеп куярбыз, эткәй, ул яктан ике дә уйлама»,— ди. Әй, ул минем килен, көндез чыра яндырып эзләсәң дә тапмалы түгел андый кешене, валла! Көләргә кем өйрәтте диген мине? Килен өйрәтте. Юкса, мин, нәкъ шушы төнтек кебек — ул шофер улына ымлады, — телсез бер тумыран идем. Хәзер килен әйтсә берне, мин ун белән җавап кайтарам. Рәхәт безнең өйдә эшләр.

## III

Минем малай, гәрчә аучы-инженер сүзенә ышану икелерәк күренсә дә, әйткән сүзендә торды, безне куян бәлешенә чакырды. «Безне» дим, мине һәм машинасына утыртып алып кайткан авылдашыбыз Фәрхулла абзыйны. Хатыннарыбызны түгел. Ник дисәң, сәбәбе бар: юлда кайтканда ук мәгълүм булганча, беренчедән, Фәрхулла абзыйның карчыгы вафат икән. Минем хатын, ягъни минем малайның әнисе була икенче төрле әйтсәк, атып кына үтерелгән куяныгызның итен ашарга күңелем тартмый, бигрәк тә анда хатынсыз килгән олы яшьтәге кеше дә булгач дип, бармады. Шулай итеп, без, җитмеш өстендәге Фәрхулла абзый, җитмеш бусагасындагы мин фәкыйрегез, утыз алты яшьлек минем малай, «мальчишник» ясап, куян бәлеше тирәсендә утырабыз. Мин башта малайга без картлар белән күңелсез булыр, ник шунда берәр иптәшеңне чакырмадың, дигән идем,

игътибар да итмәде, әйдә, җыен Мәтәскә токымы — үзебез генә бер гөрләшеп утырыйк әле, белән бетерде.

Куян бәлешенең, әлбәттә, «алды» да бар иде, кыстатышып торыш булмады. Тик Фәрхулла карт кына, әдәп саклау йөзеннән, «мин картка ни... алла кабул итәр микән соң?» дигән булып бераз боргаланды да:

— Әй, алланың кабул иткәнен көтеп торсаң, — дип, мыек очын да чылатмыйча, рюмканы авызына чөйкәлтеп тә җибәрде.

Куян бәлеше дә бик тәмле булып пешкән иде, моның өчен киленгә бераз мактау яудырдык та и китте безнең эшләр ходка.

...Малайда куян бәлеше белән сыйлануның дәвамы рәвешендә, Фәрхулла абзый, җавап итеп, безне өенә чакырды. Малай яшь кеше, без картлар чабуына тагылып йөрүне урынлы тапмады. «Рәхмәт! Капремонт көннәре, бездә урак өсте», — дип котылып калды. Мин бардым. Фәрхулла абзый кайчандыр үзе белән меховойда эшләгән һәм гомумән керешкәләп-йөрешкәләп торучы танышы Фазыл атлы тагын бер тол картны чакырган икән, көттереп кенә ул да килде. Бусагадан атлау белән күзгә ташланганы һәм мине җәлеп иткәне шул булды: бу — мәһабәт олы гәүдәле, җете ак чәчен керпедәй бастырып кыркыткан ялан баш һәм, шул ак чәчен искә алмаганда, чыраенда, күзләрендә һичбер картлык галәмәте күренми торган тап-таза бер әзмәвер иде. Фәрхулла абзый, гәрчә матчларга йөрүе, спорт белән шөгыльләнүе белән бик мактанса да, яңа килеп кергән кунагы янында песием булып кына калды.

— Шушы салкын яңгырда әллә башыңа берни дә кимәдеңме, тиле? — дип каршы алды ул кунагын, тегенең биргән сәламен дә колакка элмичә.

— Бүтән кайгың булмаса, минем баш өчен көймә, — кунакның аптырап калганлыгы бер дә сизелми иде. — Беләсең ич минем үзем өчен чыгарган законны, беренче декабрьсез башка нипочем кигән юк.

Гәүдәсенә караганда аның тавышы алай көр яңгырамый, шул ук вакытта бик үк бетәшкән дә түгел, ахрысы, ул миңа ятсыныбрак карый иде булса кирәк.

— Минем авылдаш бу. Язучы кеше. Мин кырык биш ел, ул кырык ел шушы Казанда кайнап, авылга кайтып танышып килмәсәк, танышасыбыз юк икән, әкәмәт.

— Вана сакаллы сабый. Ник соң моны алданрак әтмәдең? — Кунакның тавышы бу юлы гөрләбрәк чыкты, ул хуҗага дәгъва белдерә иде. — Язучы белән очрашасы булгач, мин соң киенебрәк, кершән-иннек сөртебрәк киләсе булган. — Аннары ул миңа төрттеребрәк өстәп куйды: — Язучы халкы киенеп йөргәнне ярата, язган геройларын да кершән-иннеккә манып, балга, балавызга катырып чыгаралар берчәк.

Ләкин зур һәм каты кулы белән минем кулны кысуына караганда, аның язучы халкын кимсетергә җыенганлыгы сизелми иде. Алай да без бу беренче утырышуда ук әллә ни ачылып китә алмадык. Ашадык, эчтек, белгәнебезне селкеп салырга ашыкмыйча гына сөйләшкәләп утырдык. Монда безгә хуҗаның җор сүзгә юмартлыгы ярдәмгә килде. Үз өе, үз сые, янындагылар: берсе авылдашы, берсе озак еллар бергә эшләп, бергә ашап-эчеп йөргән эшнәсе, шушы форсаттан файдаланып, ул бөтен җорлыгын, үзенең Мәтәскә токымыннан иткәнлеген селкеп салырга булды. Ләкин кунагы Фазыл карт та, гәрчә бу беренче очрашуда шәрран-яра чишелеп китмәсә дә, төшеп калганнардан түгел икән, китешли әлеге көчле зур кулы белән ми-

нем кулымны кысканы хәлдә, хәтсез генә вакыт ычкындырмыйча, шул ук вакытта өй хуҗасына дусларча төрттеребрәк, киная белән әйтте:

— Фәрхулланың буасы җырылды бөген, кунак булсаң тыйнак бул, дигән атай-бабайлар сүзеннән чыгып, без инде аны бүлдермәдек.— Ул боларны миңа әйтә, ә үзе җилкәсе аша кордашы белән сөйләшә иде,— мәгәренки ул уйламасын: язучыга сүләрдәй хикмәтле хәлләр гел аның келәтендә генә өелеп ята дип. Башка келәтләрдә дә юк түгел тамашалар.

Һәм кинәт бөтен йөзе белән миңа борылып, чак кына якыная да төшеп, бер үк вакытны кулны янә катырак кысып әйтте:

— Киләсе атнада, якшәмбе көнне кич мин сезне үз гүрнәчәмдә каршы алырга тиешмен. Алдан ук әтеп куям: минем апартаментлар Фәрхушнеке кебек үк ялтырап тормас, мәгәренки язучыга сүләрлек хәл-әхвәлләр миндә дә табылыр.

Ул миңа адресын бирде һәм һич икеләнмичә килергә кирәклеген, үзенең, әлбәттә, көтәчәклеген тагын бер кат исемә төшерде.

Киттем. Сүз уңаеннан әйтеп узу: мин үзем, чакыручы була-нитә калса, һич кичекмичә тизрәк барып җитү ягын карыйм, үзем кунак чакырырга бик яратмасам да...

Бу хикәянең моннан соңгы дәвамы Фазыл абзыйларга ясалган шул визиттан соң, аның сөйләгәннәреннән чыгып, стилистик яктан, әлбәттә, бераз төзәткәләп, ничек тә киртәсенә кертергә тырышып язылган керпе чәчле Фазыл пенсионер хикәясе булыр. Ул Чистай ягы мишәре булып чыкты. Чакыруы ихлас булган икән, сөйләрдәй сүзләре бетәсе түгел, әле миңа сөйләгәннән соң да, шәт, калгандыр. Мин, ниһаять, шундый бер карашка килдем: җор теллелек, картлык белән исәпләшергә теләмәү бер безнең Мәтәскә авылында гына түгел, Чистай ягында да, бөтен авылларда, тормыш булган бөтен җирдә дә бар икән.

## IV

— Мине таяк хур итте. Әтмә дә, сүләмә дә, былай күк белән җир арасында пенсионер булып селкенеп йөри торган адәм түгел, Фазыл Гыйматдинович дип зурлап дәшәләр иде заманында,— дип башлап китте Фазыл агай. Аның тавышында бер үк вакытта чак кына мактану да, үз-үзеннән җиңелчә генә мыскыл да ишетелә иде шикелле.

— Ниндидер табышмак бар бу керештә, Фазыл агай,— дип куйдым мин аны бүлдереп. Агайны кыздырырга тырышудан түгел, үземнең кызыксынуымны баса алмыйча.

— Миннән үзеңә матриал кыдырырга киләсәң, янә дә шыны этим: «Фазыл агай» лап китапчалап сүләшмә, Фазлуш и Фәрхуш — синең авылдаш белән минем арада жеп — әнә шулай кыска җөри. Әлбиттә, сине мин эткән әлеге таяк мәсьәләсе кызыксындыра инде, ул чаклысын алдан ук күрәм.

— Бу дөньяда мине кызыксындырмаган нәстә юк, сезнең кебек гаярь картны хур итә алган таяк бигрәк тә.

Артык тәкәллефсез мине үз агымына куя алуы өчен карт үсенеп китте булса кирәк, хәйләкәр көлемсерәп бер мәл миңа карап торганнан соң, кызу-кызу сөйли башлады:

— Турыдан икән турыдан. Олы юлга чыгарга турыдан хут барында ничу читтән-чаттан урап кәмәштерергә. Мин генә ул, бер хут алгач, шул җайга җәяү тыракламыйча, сүземне бозып, паром белән Каманы аркылы чыгасы, үземнең Чистай якларына сугыласы иттем, янәмәсе, туган якларны күздән кичерәм и, әтергә кирәк, ураза

бозылды шының белән. Чү, кая мин икенче кабат сөрлектем әле, гәп башланды бит таяк турында. Шулай, брат, бар иде минем бер таяк, кәкре башлы, буынтыклы-буынтыклы, буынтыгы саен маржа башы сырлап куйганнар. Рижское взморьеда, санаторийда ял итеп ятканда Сигулда дигән җирдән тилереп апкайткан идем. Әлеге шул маржа башлары өчен апкайту — кесәдә акча котырып торганнан түгел. Әлбәттә, апкайттым да кара бүлмәгә тотып аттым. Беренчелектән, яшь чак булмаса да, карт чак та түгел, таяк таянып йөрү батмый. Икенчелектән, Сәлимә җингәнең исән чагы, маржа башы белән тулган таякны кулда күрсә, аның эчен мәче тырнавы бар, сүз булуы да мөмкин түгел, без аның белән ару яшәдек. Ә фасон өчен таякны кул очында уйнатып, эшләпәне кыңгыр салып, пинжакны юри бер як иңгә генә элеп, урам уртасыннан фасонный гына үтеп китәргә теләгән чаклар була иде — янәмәсе, күреп калыгыз меховой Фазлушны, курортка барганчы ничек ие дә, курорттан кайткач ничек! Валла, бирелмәдем шайтан коткысына, алмадым таякны кулга. Ничек кайтарып аттым кара бүлмәгә и шында калды бу ятып. Ә бит еллар уза, бармы синең түбә астында берәр шомың, әллә син гел шулай элеккечә шыр тилеме, аның белән исәпләшеп тормый, аның үз хуты, тәрәзәң каршыннан җыл арты җыл — выж да выж! Ул арада карыйсың күзгегә, бак, чәчкә чал төшкән, күз төбендә җыерчыклар. Иң хәтәре ул түгел, иң хәтәре бу: Сәлимә җингәң үлеп китте, бахыр. Түшәк хастасы булып озак та ятмады, шәм төсле эреде дә төште. Калдым чыжым баганасыдай ялгыз. Әтмәгән генә, аның шыл, месқенкәйнең, бөтенесе җөрәккә җыела килгән булган. Карты зрә гренадер, эше буенча грамыты арты грамыты ява, җыл саен булмаса да, җыл аралаш курортка җибәреп торалар. Дөрес, карты ничаклы гына гренадер булмасын, башны туры тота, уңга-сулга авышмый, нәмәхрәмгә күз салды җук. Но, бит илнең авызы иләк, томалап булмый, сүләгәне сүли бирә, курортта, имеш, теге дә бу, шәхши-вәхши. Колагына керми дисәң дә керә булгандыр Сәлимә җанашның. Әтмәгәч тә, может, әлеге теге буынтыгы саен маржа башы көлеп торган таяк та күзенә чалынгандыр мескенемнең. Кыскасы шул: калдырды да китте мине Сәлимәм. Тиле бәрән булып йөрдем берчәк. Малай бар барлыкка да, ул әлегәчәк үләнмәгән, бер казанда ике мужик кайныйбыз. Мәгәренки, эшкә зыян китермәдем, ничек булган — шулай чабам. Малай үләнде бер заман, үгә хатын-кыз кулы керде, оныка туды, тагы әзгә төштек дигәндә генә... Вана әкәмәт, пенсиягә вакыт җитмәсенме. Дөрес, пенсиягә вакыт җиткәнне иске төшереп, бөергә төртүче булмады, пенсиясен дә алам, эшлим дә. Коллективта караш үзгәрмәде, элек ничек Фазыл Гыйматдинович булган, соңыннан да шыл ук Фазыл Гыйматдинович... Биш ел эшлим, сигез ел эшлим, и пенсия дә килә бер үк кесәгә. Кура җиләге, бер сүз белән әткәндә, дөнья түгел. Мәгәренки, бер нәрсә кура җиләге түгел, вахыт-вахыт баш әләнгәләп куя башлады берчәк. Духторга күрендем, нсе дә китми, склероз галәмәте, абзыкаем, яшь барганныкы, ди. Анысы дөрес, баш әләнү өянәге элек-электән бар иде миндә, яшерен-батырын түгел. Сәлимәм-мәрхүмәкәемә үләнгәнче, узган эшкә салават, әтми булдыра алмыйм, матур кызлар күргән саен башым әләнеп китә торган иде. Может, шул өянәкнең янәдән кузгалуыдыр, мәтәм. Сәлимә-мескенкәемнән калгач, мәтәм. Син, агай-эне, көлсәң көләрсең, мәгәренки, фактны әтми булмый: матур кызлар хәзер дә юк түгел. Берчәк ишәеп тә киттеләр түгелме дим әле мин. Кыска итәклеләре, озын итәклеләре... Шомлык, бер уйлаганда.

И шылай бара эшләр. Уза ай, уза ел... Әллә алай ансат кына узмыймы? Төрлесе була торгандыр инде тере калган әдәм баласы белән, гаеп-кыек итең булмасын. Шыл төрлесеннән берсен сүләп узыйм

әле. Бер вакытны, кем, кара бүлмәдә нидер эзләнеп актарынганда, күземә әлеге теге, биш былтырның аргы ягындагы маржа башы белән тулган таяк чалынды. Күрүем булды, шайтан вәсвәсәсенә кабуым булды и аккурат шарт та бар котырып кузгалырга: Сәлимәнең нервысына тимәгәе дип шүрләп торган жук, сирәк-сирәк булса да башның әләнгәләп торган көне. Дөрес, склероз галәмәтедер, ди духтыр. Ә, может, башканыкыдыр. Бетәсеме бу фани дөньяда галәмәт. Кыскасы шыл: мин ул Сигулда таягын кара бүлмәдән чыгарырга булдым и бер фасон корырга: киярга өскә яңа кәчтүмне, тагарга сандыкта яткан ике медальне, алырга кул очына әлеге таякны и китте Фазыл Гыйматдинович урамның кыл уртасыннан. Яшь чагында алай килештермәгән, хәзер мазасы жук, килештерә. Бер карасаң, кеше күрер дип башка да китергән жук, ә күреп калучылар булган. Кем әтер директор хәтле директор күреп калыр дип. Күреп калган бит шомлык. И фабком Бохараевны чакырып әтмәсенме:

— Шундый-шундый эшләр, товарищ Бохараев, ник болай бик фасон йөри башлады әле безнең кадровый Фазыл Гыйматдинович? Беләсеңме син шуны?

Теге ык-мык:

— Белмим, Сергей Васильевич, хет ас, хет кис.

Фабком кешегә гел алай «белмим!»ләп тору да килешми, шул арада тәртәне борып та куя бу, кирәк бит нидер әтергә.

— Тол калган кешенекен кем белеп бетергән, может, берәрсенең күзенә чалынырга йөрүедер.

Шомлык төгел диган син вана, директорның үтә дә каш жыерган көне туры килгән, сүз әтергә дә бирмәгән фабком Бохарайга:

— Монда минем кыз күзләп, тол калган ирләргә хатын сайлап бирү урыны төгел, миннән план сорыйлар. Вообщем, чакырып сүләш Фазыл Гыйматдинович белән. Эштән китәргә нияте бар икән — каршы килмә. Торжественный озату оештырырбыз, ничек тә бер путевка табу ягын кара, озак еллар эшләгән кадровый рабочий, коллективка үпкә белән китмәсен.

Ул көнне төгел, икенче көнне фабком Бохарай мине кабинетына чакыртты. Башның күрәчәге булгандыр, ул көнне дә мин әлеге шыл Сигулда таягын тотып килгән идем, утка ягасы хәерсез таякны. И фабком Бохарай сүзне шуннан башлады да:

— Таякка калдымыни эшләр, Фазыл Гыйматдинович? — ди бу директордан отып алган корылык белән.

— Таяк дигәч тә... ул ни... фасон өчен иярә ул миңа.

Авыз ачарга да бирмәде бу, янә элеп алды:

— Беләбез, беләбез. Сез һәр вакыт шылай чын дөресен мыек астыннан йөртергә өйрәнгәнсез. Илла бу очракта без дә төшеп калганнардан түгел, олы кешене кирәгеннән артык сыгарга хакыбыз юк. Эшләмәдегез түгел, пенсия яшенә кергәчтен генә дә артыгы белән сигез ел. Кыскасы, Сергей Васильевич белән бу турыда сүз булды. Алдагы шимбәгә каршы чин чином: фабком исеменнән жыябыз коллективны, табарбыз кешеләрен, әйттерербез ару гына сүзләр, бүләге, айлык зарплаты өстәмә, санаторийга путевка и соңыннан торжественный ужин. Сергей Васильевич үзе дә сүз әйтергә булды. Юк-бар кешегә мондый озату әләкми, ә сездән, Фазыл Гыйматдинович, жәл түгел... озак еллар кымшанмыйча бер урында эшләдегез и начар да эшләмәдегез.

Мин тагы ык та мык, күреп торам, котыласылары килә миннән, валла шылай.

— Ул чаклы зурламасагыз да киткән булыр иде, — мәтәм. Кабынып сүләшмим, үз дәрәжәмне сакларга тырышам. Дәрәжә генәме, берчәк шаярган да булам:— түлке ни... таякка калган, шының өчен бу алла

бәндәсеннән тизрәк котылыйк, дип уйламагыз. Таяк ул болай гына, фасон өчен генә.

Бөеренә төртсәләр, Фазыл Гыйматдиновичта сдачасы әзер, хәзергә кадәр төшенә алмыйм, кайдан телгә килде диген мондый китапчалык, бер кызгач янә былай дип тә ялгап салдым:

— Бүләкләрегез кирәкми, путевкагыз да үзегездә калсын, җыелыш җыеп шау-шу кормагыз, аннан башка да шау-шу җитәрлек. Мәгәренки, Фазыл Гыйматдиныччыгызны хөрмәт күрсәтеп озатасыгыз килә икән, табып бирегез агаегызга рәтлерәк бер тол хатын. Меңләгән кеше арасында андый гына бер мәхлүк табылмый булмас. Юкса, турысын әтим, кырык ел эшләгән меховойдан яңгыз гына китү миңа бер дә аккурат түгел.

Шаркылдап көлде фабком Бохарай.

— Соңгысы булса да мунчаның әлегә пары чыгачакмыни? Их, мут та син, Фазыл Гыйматдинович, — дигән була.

Озын сүзнең кыскасы, озаттылар абзыкайны бөтенләйгә. Шау-шуы да булды, конвертка салып, айлык эш хакын да учыма китереп тоттырдылар, «Васильево» санаториена путевкасын да тапканнар, тик бер гозеремне генә үтәмәделәр, меңләгән мехчы хатын-кыз арасыннан бер хатын табып бирә алмадылар.

— Бу чаклысын инде, Фазыл Гыйматдинович, синең үз инициативаңа ышанып тапшырабыз, — дигән булды фабком Бохарай колагыма пышылдап.

Уен-муен бер якта торсын, җиңел булмады коллективтан аерылып китү. Айлар буе җаныма урын тапмыйча динкеп йөрдем. Сәлимәм-мәрхүмәкәемнең каберен зыярат кылырга барган саен, йомышым булса да, булмаса да, меховой территориясеннән бер урап чыгам. Теге маржа белән тулган таякны үземнән калдырмыйм. Бәйрәм ашы — кара каршы, меховой эшчесе буларак, ул минем башыма җиттеме? Җитте. Инде чыдап торсын, үземә иптәш итеп җүри сүрим мин ул таякны. И үземә иптәшлеккә бирәр озын чәчле каракаш тапканчы сүрәячәкмен! Каракаш дигәнем кызык сүз әтергә яратканнан гына, мәгәренки, арка җылытып ятарлык бирәр тере җан иясе очрап куйса, каршылыгым ич тә җук, валла, дөресе шылай.

## V

— Вана шылай итеп, путевка тоттырып, озату кичәләре оештырып, ул озату кичәсендә сару кайнаткыч куштанлыклар әтеп, алтмыш сигез белән бара торган азыкайдан шома гына котылдылар. Рәхмәт инде шау-шуына да. Пенсия яшендә кырын какмыйча җиде-сигез ел эшләгәнләренә дә. Әле китешли дә әтә калдылар:

— Син ни, Фазыл Гыйматдинович, безне ташлама, кергәли йөр. Хәер, кайгырма, синең сөялле кулың кирәк була-нитә калса, адресыңны беләбез, без сине машина җибәреп момент алдырырбыз. Яшьләрдән тәҗрибәңне, шәт, җәлләмәссең.

Илла да хәйләкәр соң безнең фабком Бохарай да. Сизә, каһәр, азыкайга кырык ел эшләгән меховоеннан китү уен түгеллеген. Җумалый, салам кыстыра. Әллә мине белми дип белә, синең үрәткәнеңне көтеп, тешсез авызыңа карап тордылар, ди, хәзерге яшьләр. Техникум, урта мәктәп бетереп килгән, турысынга китсә, анадан туганда ук җиде класс бетереп туган яшьләр. Сүли юк-барны, значится, карт кадр боегып китмәсен.

Китте, ди, боегып. Миңа, һичнигә исем китмичә кәкре башлы таякны селкеп, көннең теләсә кай чагында урамнан бер әләнеп үтү үзе ни тора! Таякка таянып түгел, таякны кул очында селкеп. Икесе ике нәрсә былар. Таянып булса — тиздән тәртәләреңне сузасы, көне кефирга кал-

ган бәлҗерәгән карт дигән сүз. Таякны кул очында селкеп, метр җитмеш сантиметрлы гәүдәңне шәм шикелле үрә катырып, подъежик кырдырган башыңны кояш күзендә кыздырып, кызу кабар дип тамчы да өрекмичә пенсиядә йөрү үзенә башка каленкор, узган-барганнар зурлап исәнләшеп китә, телләре белән әтмәсәләр дә күзләре белән әтәләр: «Вана бит, бу да пенсионер, ә түш — патша самаварыдай».

Аннан кире бу якны да аңлый Фазыл Гыйматдинович: яшьләргә, яңа үсеп чыккан кадрларга да урын кирәк. Алар иңнәренә төшкән җалларын туздырып гел шылай буй селкеп йөрсеннәрмени. Әле дә, аллага шөкер, күбәеп баралар андый озын чәчләр. Эшләсеннәр, бил бөксеннәр берчәк. Эшләп ашагач тәмле ул әбәт. Кыскасы, үземә-үзем биргән акыл шыл: исең дә китмәсен, картлач, һәр муенның үз камыты, һәр җегетнең үз вахыты була. Җитәрлек биедең үз вахытында, инде әнә яшьләр биесен.

Алай да кайчак аптырабрак калган минутны сизә, шындый бер очлы күзле килен бар минем. Килен белән ара шәп безнең, сезнең авылның Фәрхуш кебек этле-мәчеле төгел, момент эш таба. Оныканы тагып бакчага чыгарып җибәрә. Оныка белән безнең дуслык әтеп тә, сүләп тә бетермәле төгел, детсадка үзем бирдермәдем. Миңа бер иптәш ул, мәтәм, карчык та җук, хет малайны миннән җәлләмәгез. Әй, туган, үзем теләп алган ул ташбаш белән күргәннәр минем! Барып җитәрбез, сүләрмен әле, тыңлар чамаң булса әгәренки...

Әле бит минем алда барасы җирләр бар, ул да булса «Васильево» санаториясе. Әллә син буш килгән путевканы яндырды дип уйлыйсыңмы? Яндырыр Фазлуш азыкаең.

Срогыннан бер көн алда, бер көн соңга калып төгел, киенеп-ясанып, сакал-мыекны кырдырып, ни булса — шыл, башка төшкәнне күрермен дип, чәчне чем-карага буятып, кем китте аккурат «Васильево»га? Факт кемлеге, тырыш хезмәте өчен алган путевкасын куен кесәсенә салып, заслуженный пенсионер Фазлуш Гыйматдинович китте санаториягә. Анда да килен — шаяртып инде анысы — факт, кабыргага төрттерми калмады:

— Бик яшәреп барасың, әткәй, берәрсен ияртеп кайтмасаң ярый.

Хәер, мин дә җавапсыз уздырмадым, җавапсыз калу дигән сүз — киленне иңбашына менгезү дигән сүз.

— Алып кайтсам, берне генә төгел, ике як култыкка икене кыстырып кайтачакмын, килен. Берсе идән юарга, икенчесе Марсикны карарга, дим. «Марсик» — әлеге шыл минем дүрт яшьлек оныка, инәсезҗепсез минем итәккә тагылып җөрүче шабашник.

Гөнаһысын үз өстемә алам, гөнаһы миндә болай да мең потка тула-дыр инде, күңелгә хуш килердәйрәк берәр карчык-корчык булмасмы дип караштыргалый җөрдем курортта, малай. Тәҗрибәле яшьрәк кешеләр әттеләр, танышу срокларын ук бүлеп куйганнар, әкәмәт. Килгәч тә биш көн караштыргалап җөрергә, унбиш көн култыклап, калган дүрт көне суынырга, менә сиңа төп-төгәл егерме дүрт көн — точно-точ путевка срогың. Чая хәзерге яшьләр, денсезләр. Үзләре килгәч биш көнне дә көтмиләр, икенче көнне үк, икенче көнне булмаса, аның икенчесендә култыклап алган булалар. Авыз — авызда, чүкер дә чүкер. Обедка соңга калуларын да белмиләр кайчакта. Әлбиттә, минем дә күз бар, караштыргалап җөрим, юк кына бит сүз катырдай адәме. Карты — зрә дә карт, ул таралган арба белән ни кылмак, кайдан уртак тел тапмак кирәк. Ә яшьрәкләре миңа карамый. Югыйсә, таякны да калдырып киттем үдә, чәч тә буятылган, яланбаш җөрүдән, кояш сугудан да курыкмыйм, ә җук кына бит.

Күземә чалынганы бар, яздылар берчәк гәҗиттә. Гәҗиткә дә, журналга да яздылар. «Бездә аталар һәм балалар проблемасы җук» дип. Бармактан суырып язганнар, менә нәрсә дим мин ул гәҗит язучы-

ларга. Булмас, менә үзләре картаеп карасыннар әле. Столовойда, дүрт кешелек өстәлнең дүрт ягында утырабыз дүртәү. Икесе кырык тирәсендә, ат төгел, тешләрен карап булмый, чамалап әтүем. Берсе бөтенләй яшь, үләнмәгән карт егет. Ике-өч көн үттеме икән, таптылар, әй. Таптылар үзләренә. Ә минем турыда кайгырткан адәм жук.

Обедка жыелгач, ашны син килеп утыруга дәррәү генә китереп бирмиләр ич, көтәргә кирәк берчәк. Әнә шындый авыз буш калган минутларны туры китереп, уйнаган-шаярган атлы булып башладым сүзне.

— Сез, егетләр, туры әткәнгә ачуыгыз килмәсен, үзегезгә дигәндә, мәтәм, таптыгыз. Шушы обед, ужин вакытларында очратмасаң, очратып та булмый сезне, гел солнечный ваннада, тиле кеше әтмешли. Ә менә өлкән азыкаегыз турында кайгыртучанлык күрсәтү жук. Югыйсә, минем дә кул-аякка тышау салынмаган. Карчыгым вафат, үземнең әлегә теш коелмаган, күреп торасыз, тешкә йомшаграк берәр «ризык» заты күренсә, мин брамат та баш тартмас идем.

Көләләр тиләләр. Тычканга үлем — мәчегә көлке. Аннары, күреп торам, ачыктан-ачык юатырга тырышып, тотыналар алланы кузгатып ант итәргә:

— Бар иде берәү, зрә дә майлы чүлмәк иде, нишләтәсең, срогы чыккан, кичә китеп барды.

— Срогы чыкканны мин үзем дә табам, сез миңа ни... тач срогында, тач согында булганны табыгыз, чучка малайлары.

— Булыр, Фазыл абзый. Өметсез шайтан, диләр. Чак кына сабыр,— ди икенчесе.

Какой чорт «чак кына сабыр», кайчан көн артыннан көн үтеп тора. Ул арада минем баштагы «керпе»нең буятканы өскә үсеп, астан ак чәч ыржаеп чыга башлады. Жук инде жук, балалар белми аталар сабагын. Ничу «проблемалап» вакланып торырга.

Аннары нәрсә булды соң әле ул курорт дигәнендә? Минем бүлмәдәшем, Мамадыш районыннан килгән колхозчы рус — Николай Федорович, киң сакаллы, таза гәүдәле, зур борынлы булса да йоклаганда борыны белән сулыш ала алмый, авызын ачып, тамак белән сулыш алучы һәм шунлыктан бик яман гырлаучы иптәш булып чыкты. Шул минус жагын искә алмаганда, бөтен жактан плюс куярлык бүлмәдәш: анекдот сүләргә оста, домино сугарга дигәндә мачтырның да мачтыры, шашка тактасы алдында да аптырап калмый. Корпус күләмендә уздырылган ярышларда ике мәртәбә чемпион калды, шуннан үзегез уйлап чыгарыгыз инде адәм баласында нинди баш икәнлеген. Сакал тагып жәрү өчен генә тагылган баш төгел, кыскасы. Ике ара торыш болайрак: көндез дус, төнлә дошман. Шылай булмыйча соң, йоклап кара аның разный фасон гырлавына. Уятам: «Әләнеп ятып кара әле, Николай Федорович, бик каты гырлыйсың»,— дим. Каршы бер сүз әтмәс, әләнеп ятыр. Уза микән биш минут, тагы гырлый башлый, бусы элеккесеннән дә яманрак.

Кәмит килеп чыкты моның азагы. Дәвалый торган врачыма чираттагы бер күренүемдә сорый ул миннән:

— Ничек соң, Фазыл Гыйматдинович, эшләр кай якка таба бара? — ди.

— Эшләр бер якка таба да бармый, гел бер урында... алтмыш сигез яшьлек пенсионерның соң эшләр кай якка барсын... Әнә яшьләрнеке ул, әтсәң дә ярый.

Врачым үзе дә шутник кеше иде, минем башка да килмәгән мәгънә казып чыгарды бу әлеге сүздән.

— Большой мут сез, Фазыл Гыйматдинович,— ди авыз чите белән генә көлеп,— врач белән шылай шаярып сөйләшергә ярыймы соң, житмәсә ханым кеше белән.

Соңыннан гына аңышып алдым: алайрак килеп чыккан икән шыл, шәригатькә сыймый торганрак. Хатамны соңыннан булса да бераз төзәтергә тырышып, иплерәк күренү өчен башны калкыта төшеп, ярып сал моңа дуамал гына:

— Бармый диуем «бер җирем дә авыртмый» дип әтергә келәгәнлектән. Белмим, ник җибәргәннәрдер мине монда, берәр аяклы хастаны җибәрәсе урында.

— Баш нишли? Әйләнә дигән идегез ич бер көнге карауда. Биргән даруларны кулланасызмы?

— Баш инде ул гел шыл бер баш, дару эчмәгәндә ничек булган, дару эчкәч тә шыл үз урынында. — Тукталасы иде кана шында, нәгъләт төшкән тел бит миндә, урыннан бер кымшанса туктый белми, тагы кирәкмәс сүз ычкындырганмын, — башны алыштырып булмас инде аны, духтыр, элек-электән шындый өянәге бар: әләнгәли матур кызлар күргәндә.

Җә, тагы бер авыз җырып көлдек, ди. Моның белән генә котылып буламы соң беркетелгән врачыңнан. Ачуланды бу миңа. Кыскасы, нәрсәдәндер зарланмыйча котылып калу мөмкин түгел иде. Шында шыл, эшләр болай текәгә киткәч, мин дә, әлбиттә, әтмичә булдыра алмадым:

— Йокы начар минем, духтор, йокыга китә алмыйча интегәм. Берәр сәгать йокладыммы, тагы уянам... тагы интегергә тотынам. Әлеге шыл вакытында туктый белмәү галәмәте. ... Җитмәсә, бүлмәдәш кешем гырлый торган адәм булып чыкты.

Мин — сер тотмас үрдәк — күрәсең, беркетелгән врачымны үз җаема салып өлгергәнмен.

— Йокысызлык — анысы шәп түгел, — ди врач. И шундук минем җайга ятарга тырышыпмы, теленә шулай туры килепме, өсти бу. — Ә сезнең бүлмәдәшегездән калышып торырга ни хакыгыз бар? Туктагыз әле, мин сезгә шундый бер дару язып бирим.Сестрага күрсәтерсез, таблеткаларны ул бирер. Шуны һәр кичне бер таблетка исәбеннән йокыга ятар алдыннан унбиш-егерме минут алдан эчеп җибәрерсез. Как же так, кешедән калышып торырга...

Сүләнүендә үк бер төлкелек бар иде аның, духторны әтәм, биргән икән даруның да тычкан сыртлысын. Ятабыз. Николай Федорович яткач бераз килде-китте сүз сүләшеп ятарга ярата, анекдотлар, колхозында булган төрле кызыклы хәлләр... Нәрсәдән башлаганын беләм, нәрсә белән бетергәнен белмим, йоклап киткән булам, бахыр.

Иртәгесен күзне ачып җибәрәм и күзне ачып җибәрүгә күршем минем өскә жалоба белән ташлана:

— Әй, голубчик, ишәсең дә йокыны. Бүлмәбез белән космоска күтәрелеп китәбез дип торам.

— Әллә гырладыммы?

— Гырлау дип кенә әтү аз моны. Просто, караватың ничек чыдаганга аптырам яттым.Ну и ну! Озаграк тыңлап ятсам, ихтимал, бу тамашаның очына чыккан да булыр идем, үзең беләсең, ул яктан минем дә эшләр шул чама: синнән бик артка калмаска тырышып, үзем дә гырлап киткәнмен.

Ләкин безнең дуэт белән парлашып гырлау озакка сузылмады. Стеналар юка бит хәзерге үләрдә. Уң як күршеләр дә, сул яктагылар да, өстән дә, астагы каттагылар да бер-бер артлы главврачка жалоба белән чапканнар. Шындый-шындый тамаша, иптәш главврач, без монда хәлал акчабызны түләп төннең төн буена үгез суйгандагы үкерүне тыңлап ятарга килмәдек. Просто невозможно! Аңардан да яманрагы булмаса әгәр.

Ниһаять, Николай Федорович белән безне икебезне ике очтагы аерым бүлмәләргә салдылар. Бик күңелсез булды аерылышкач. Тәмам дуслашып, парлашып җиткәндә генә, панимаешь!

Төнлә борын белән бүрәнә тарттыручылар дигән данны тагып йөрү әллә мач килде дип уйлыйсызмы? Мач килмәгән кайда! Путевканың срогы чыкканчы ук кайтып китәргә җыенган чакларым булды, ашау-эчү ягына килгәндә, үдә дә аллага шөкер хәзер. Тотып торганы шыл булды — килен мыскыл итәр дип шүрләдем. Әтер, этмәсә күңеленнән уйлар: «Әткәй бик мутланып, чәчләрен буятып киткән ие, берәрсе белән берәр тамаша чыгарып, срогыннан элек куып җибәргәннәрдер», — дип уйлавы бар. Ә ул яктан минем артъяк аяз. Нәрсәдән икәнен дә белмим, шулай да соңгы вакытларда юк-бар васвасәгә бирелеп китүчән адәмгә әләндем. Мөгаен, эшсезлектәндер. Ай, эш җаный. Андый чүп-чар белән баш ватарга вакыт бирми ул сиңа.

Менә син, агай-эне, писатель бугай. Фәрхуш кордаш таныштырганнан әтәм бу сүзне, үземнең бер китабыңны да укыган җук, ул яктан душам күзгедәй чиста. Чынкый да писатель икәнсең, кыстырып җибәр бер почмак табып, эштән дә шәп лечение җук дөньяда, диген. Ышанмаган кешене тот та минем җанга җибәр, адресны беләсең, җибәр. Мин ул адәм актыгына ышандыра торган итеп сүләп бирермен, валла вана шылай.

Ул «Васильево»ларыннан кайткач берчәк ярыйсы җөрдем, баш та әләнмәде, йокы да үз урынына утырды. Безнең өй болын чаклы, ике катлы өйнең аскы катын шөйлә үзебез билэп торабыз, бер үземә бер бүлмә. Сәлимә каракашым исән чакта икебезгә иде, аны җирләгәч, бер үземә бер бүлмә калды, җанын ничек тели, шылай йокла. Илла мәгәр, кешеләр генә белми, буш калмады мәрхүмәкәйнең урыны. Аның китүе булды, бүлмәгә күзгә күренми, кешегә әтеп булмый торган әчпошу урнашты. Була шындый вахытлар, әчпошудан хет урамга чыгып разбой сал. Карчыкны сагынудан дисәң, чәч агарткан ир кешегә, элекке рабочий класс вәкиленә әллә ничегрәк, килешми кебек, ә душа тырнала, панимаеш. Үзең уйлап бак, иртә оныканы, Марс ташбашны садка илтәм — мин «Васильево»да чакта аны садка урнаштырып өлгергәннәр. Бәласеннән баш-аяк, тынгы җук иде аны садка илтмәсәң, ул миңа сагыз, мин аңарга сагыз. Садка илтеп кайткач бер ялгызым табын корып озаклап чәй әчәм, чәй индийский, арттан куып торучы җук, эшкә ашыгасы тәгел, эч тә эч эчең сыйдырганчы. Бусы булды, аптыраганнан әтү, шылай да рәхәт озаклап чәй эчеп утыру. Шыннан кухняга керсәм, киленнең кичтән ашаган савыт-сабалары юылмаган. Җылытам су, сызганам җиңне, савыт-сабаны ялтыратып юып куям — бу булды янә бер файдалы эш. Шыннан нәрсә кала? Шыннан Лядской садка чыгып һава иснәп утыру кала. Врачлар болай әтәләр, «Васильево» врачлары да колакка тукып җибәрделәр: «Күбрәк һавада бул, баш әләнүең дә бетәр, йокың да рәтләнер, бөтенесе склероз галәмәте», — диделәр. Үзеңне үзең юатыйм дисәң, бакчага чыгып утыру да файдалы эш, рас врачлар да шулай әткәч.

Ә боргаламыйча әткәндә, болар бөтенесе чепуха! Ниндидер кызыклырак берәр шөгыль табасы иде. Чынлап торып җылаҗаң, сукыр күздән яшь чыга, ди торган иде минем атай карт. Ә мин җылап тормадым, элекке рабочий класска җылап тору килешмәс тә иде, җыламыйча гына таптым. Кайсы чатта нинди афиша бар, күз сала җөрим. Билетына акча түли торганнарына алай исем китми, «Керү буш», «Керү ирекле — рәхим итегез!» дигәннәрен берсен дә калдырмыйм. Ул лекция, малай, ул лекция. Атеистик темага, халыкара темага, сәламәтлекне саклау темасына, пожардан саклау темасына. Ул да төгел, күргәзмә судлар, аерылышулар, ир белән хатынның квартир бүлешә алмаудан чыккан талашлары... Шындыйларны йортлар идарәсендә, гыйбрәт йөзеннән, ачык судта тикшерүләр — берсен дә калдырмыйм. Ул сорау бирергә остарып

киттем, урыннан реплика ташларга... Ә үзем сизәм: күңелне тырный торган мәче һаман басылмый, вакланганнан-ваклана баруым күз алдында. Шылай буш лекция эзләп җөри торган кеше идеме соң Фазыл Гыйматдинович кабәм? Җитмәсә тагы киленнең шелтәсенә дә тап була башладым. Кайчак шылай кызыклырак бер лекциядә утырып, пацанны садтан алып кайтырга кирәклекне дә онытам, имеш.

Бер шылай, гаеп-кыек итеш булмасын, сез писательләр җыелышында утырып төнлә генә кайтып кердем. Малайны садтан алып кайтканнар, ул йоклаган ук иде инде. Шылай да килен күзләрен шарландырып бер карады. Алай гына калса бер хәер иде, төрттереп болай дип тә куйды:

— Әткәй бик сонга калып җөри башлады, берәр яшь әнкәйияртеп кайтмаса ярый бер дә бер көнне.

Төрттерә бирсен, аннан куркып торган җук, үз үем, үз ишегем, үзем ачам, үзем ябам. Илла мач чыкты да соң ул кичем. Писательләрнең «Әдәби җомга» дигәннәренә электә дә баргалаганым бар иде, домпичәтнең бишенче катында, Тукай клубында. Кайчак җырлар була, кайчак шаирләр күләп-күләп шиер укыйлар, бөтенесе буш, бөтенесе кызык.

... Кеше дигәнең бәлане кайчагында үз аягы белән йөреп тә таба икән. Әлеге шыл язучылар тирәсендә бутала, аларның шиер укуларын, аларның яңа язылган китапны кызып-кызып тикшерүләрен тыңлап йөри башлагач, картаймыш көнемдә әллә үземә дә берәр китап язып багаргамы, дигән «тегендирәк» уй башка килде. Профсоюз билетым бар — пенсионер булгач анысы өчен членлык взносы түләү дә шарт түгел икән, бер көн барган идем фабком Бохарайга, Гыйматдинычка авыр иштетелер дип тормады, күземә терәп этте: «Китергән-китергән, бусын алып калам, Фазыл Гыйматдинович, икенче тапкыр маршрут билән килеп җөрмә, синнән — заслуженный пенсионердан взнос алу ич тә соралмый», — диде. Дөресен этим, әллә ничек булып китте, кешене бөтенләй исәптән үк төшереп калдыру була төгелме соң бу? Фабком Бохарай ни этмәс, мин барыбер түләп киләм әле. Димәк ки, профсоюз билетын кесәдә йөртергә тулысынча хакым бар. Аннан кире, әллә кайчаннан кесәдә аунап йөри торган «Алласызлар...» ягъни теге атеистлар җәмгыяте, билетым да бар. Дөрес, картая-картая башка берчәк шик тә килә, әллә бусын бөтенләй ертып атып, Насыйри урамындагы мәчеткә йөри башларгамы, дим үземә-үзем. Белмәссең, «теге дөньяга» баргач, якаңнан борып алсалар? Йә, житте, бусы тишек авыздан чыккан үлчәүсез сүз и шылай булып калсын да. Ә менә шыл ике билет янына өстәп язучылар союзы билеты да тыксаң, ә? Кайчаннан бирле бара-кайта җөрим шул домпичәтләренә, «җомга»ларын да калдырмыйм. Китап тикшергәндә сораулар да биргәләп куям, гел сурьюзныйга кабул итәләр. Соңыннан ныклабрак уйлап болай дип тә катгыйлап куям: не стоит язучылар союзына тыкшынырга. Китап язам дип көчәнгәндә башыңны бер вату килеп чыкса, язган китабыңны тикшергәндә башыңны икенче, өченче кабат чәлпәрәмә ясарлар. Йөрдем, күрдем: уйнап сүләшмиләр алар китап тикшергәндә.

Ә тулаем җыеп эткәндә, соңгы вакытта баш тагын да ныграк әләнә башлады. Язучылар тирәсендә кысылып йөргәннеке — анысы факт. Килен дә ирештергәли: «Үзеңә аерым бүлмәң бар, тапмадың син дә, эткәй, үзеңә пар килердәй берәр карчык! Гомер буена синең ыштаныңны юармынмыни мин?» — ди. Сизеп торам, котыртып этә, ә минем тиле-тилемсә башны бутарга шул да җитә. Гренадердай гәүдән, керпе энәседәй басып торган чәчең белән йөр садтан оныкаңны ташып. Чыгарсын иде кана ходай киленнең котыртып эткән сүзен чынкый итеп.

И шуның янына плюс: йокының җуне китте. И киттем врачка. «Шылай-шылай, мәтәм, йокының җүне чуалды, баш әләнә, авызның тәме

жук. Чак кына ычкындырмадым: «Килен дә котырта» дип. Сыкты-бөкте, яткызды-торгызды, күкрәккә түк-түк, аркага түк-түк, кыскасы, врачка тамчы да үпкәм жук, фасонын житкереп карады. Үзегез чамалыйсыздыр, әлбиттә, таблеткалар, порошоклар язды и утыз укол... Иода уколы, баштан склерозны юдыртмакчы бу.

Әтсәм этим: ярады бу укол дигәне. Кадатырга барганда, ичмасам, кеше күрәсең. Керешли — кетеп утырганда, чыгышлый — ял итеп уколны сеңдергәндә, бер көнне берсе, икенче көнне икенчесе белән очрашасың. Ә миңа шул гына кирәк тә, көннең-көн буе япгыз үдә селкенеп тел тутыккан, аны ходка жибәрәсем кели. Мәгәренки, бер жүне күнелгә ошамады: арадан берсе белән әледән-әле очрашып, аның кылын тартып, үз күнелендә жыелганны түгеп, инде тәмам парин белән парин булып життек дигәндә генә тегене терелткәннәр дә куйганнар. «Бүген минем соңгы укол, иртәдән тагын йөз процентлы кеше абзан», ди. И танышлык шуның белән вәссәләм. Иртәгесен процедурный ишеге төбендә мин бар, ул жук.

Мәгәренки, утыз укол утыз көн дигән сүз бит ул. Изге урын буш тормый ди бит урыс, берсе килми башласа, аның урынына икенчесе калкып чыга. Кыскасы, көн туып тора, яна белеш-таныш табыла тора. Арада минем күп лыгырдаганны өнәпме, әллә өнәмичәме, мине кәмит хәленә калдырырга мәтәшүчеләр дә булды. Ә жук, шалиш, заманасында мин үзем кәмит базарында базарный хакы түләп, басып торган кеше, андыйларның үзләрен кәмиткә калдырып, авызларын томаладым.

Шындый тарихларның берсен, кызыгын тапсаң, сиңа да сүләргә була.

Утырабыз шылай бер мәлне процедурный алдында. Теге кадатып чыккан, мин кадатырга керәсе. Утыргычлар йомшак, ашыгасы жир жук, сүләш тә сүләш. Минем шыл инде, эч пошканнан зарлану, яңгызлык, теге дә бу, тормыш иптәше кирәк иде, син әзләгәндә генә чыгамы соң. Аннан соң годтан чыккан карчыкларга пенсия биреп тә аздырып бетерәбез түгелме и так далее. Әлбиттә, шаярткан атлы булып сүләнәм. Тынлый бу законный гына, сүләгәнне бүлдерми, күрәм, культурный кеше. Минем бетергәнне көтте бу, торып китәргә ашыкмады, күрәм: түрә кеше бу, «кайда болай йөрдең?» дип сорау алучы кеше булмаслыгына ышанган. И шылай ашыкмыйча гына мине иләргә исәбе.

— Күрер күзгә мин сезгә ул яшьне бирмәс идем, дөрес, чәчегез агара төшкән, но бит бар бериш кешеләр, илле яшендә чәчтән бөтенләй мәхрүм кала. Нә агы, нә күге. Ә сезнең агарган булса да подъежик кыркылган, Жигули урманы кебек... Инбашларыгыз да, мускулларыгыз да. Конечно, эч пошарлык урын бар сезгә...

Күрәм, минем жайга сукаламакчы бу, мәгәренки сизәм: тел төбендә бер хәйлә утыра моның. Эндәшмим, көтәм. Хәер, озак көттермәде бу, этәсен шындук этеп салды.

— Миндә бер эш бар сезгә, агаем. Эч пошуны момент басачакбыз.

— Тыңлап күрик: тыңламыйча мин бер сүз әтергә дә күнекмәгән.

— Шоферым кәкәй булып чыкты минем,— ди бу шундук эш кешесенә әверелеп.— Салмыш баштан машинага утырган, сулагайга эшләмәкче булган, и тотып правосын алдырмасынмы! В общем целом әйткәндә, шофердан колак кактым. Сүз-сүз булып кына калмасын, давай, кер миңа шоферлыкка. Син сөйләшергә яратасың, ачык күнелле кеше мин дә яратам, сүләштекме шылай?

Күрәм: тамак төбендәге хәйләсе башын суза, чыкма кели моның, мине ирештермәкче. Мәгәренки, ирештерү ягына килгәндә, мин дә төшеп калганнардан түгел, школасын үткән шәкерт. Серне бирде жук, мыек белән киңәш иткән кеше сыман, берчәк эндәшми генә утырам и ялт күтәрелеп карыйм тегенә.

— Тәкъдим бу, мин каршы түгел! — кистереп әтәм, өзеп әтәм, штобы тел төбендәге хәйләсен ахырына тиклем чыгарсын, ярым-йортыны

яратмыйм мин,— наш брат вполне согласен с таким деловым предложением,— дим юри русчалатып. Күргәч-күргәч күрсен, без дә валет белән каплап була торган король түгел.

— Шыннан-шыннан? — ди бу, әллә кызыксынып, әллә һаман мине мәтәштерергә тырышып.

— Шыннан аргысы шыл, агай-эне — мәтәм, кистереп, өздереп. Андый чакта тимерне кызуында сугарга кирәк, партнерыңа уңга-сулга каранырга бирмә,— минем ике шартым бар, әгәр шыңа риза булсагыз...— Юри өзеп калдырам әтәсе сүземне, җансын тегенең эче кызыксынудан. Фазлуш Гыйматдинович кем белән ничек сүләшергә икәнен чамалый ул. Җамалый күршесе.

— Шыннан? Шыннан? Әтеп сүләш шартларыңны? — Кызганнан-кыза бара тегенең ташы. Әллә чынлап, әллә һаман ирештерергә маташудан? Артык авыз чайкап торуны кирәк тапмадым, күзенә төрәп әттем дә салдым сүземне:

— Беренче шарт шул: учреждениең кассасы исәбеннәнме, үз кесәңнәнме, иң элек водительләр курсында укытып, шоферлык правосы бирдерәсең.

Ул тагы «Шыннан? Шыннан?» дип ярсытмакчы иде, мин моңарга артык ярсытырга ирек куймадым.

— Икенче шартым шул: миннән аз дигәндә илле яшемне алып ташлап, яңадан егерме сигез яшьлек әтәчкә әләндерәсең. Шылай булганда мин риза сиңа шофер булып керергә.

Артык «шыннанлап» торырга урын калмады, берьюлы ике як калак сөягенә әләнеп төште түрә абыең.

Янә икенчесенең авызын болай томаладым — әлеге шул процедурный алдында утырганда. Төрле адәм бар бит бу дөньяда. Шыл исәптән үзенең искелегендә бөтенләй катып калган адәмнәр дә бар. Бу миңа гәп ачкан адәмне әтмим, ул үзе өчен дипломат түгел, аны дипломат иткәннәр кияве белән кызы. Юк, кызы да түгел, кияве. Әйтмешенчә, карт кеше дә түгел икән кияве, алайга китсә, менә безнең эше каткан сүәкләрне берәү дә кияү итәргә ясканып тормый. Җае чыкса бик утырасы иде кана түрдә кияү булып. Тукта, мин тишек борын тагы үз хәсрәтемә күчтем, хәсрәт пока теге кияүнеке бит. Шул — иске тормыш калдыгы — өч яшьлек пацанын садка йөртми, ди. Ник? Садка йөртсә, янәмәсе, теле бозыла. Ни урысча, ни татарча, янәмәсе. Вона сиңа, бабакай, яңа хәсрәт. Мин эшсез тора алмыйм, миңа син әпәй ашатма, бертуктаусыз кыймылдап торырлык эш бир, штобы Яңа бистә яклары искә төшмәсен, дип әтәчләнә генә башлаган идем, колагы торды куйды бабаңның.

— Эш бар сиңа, валла әгәр, — ди бәбәген туп-туры миңа төрәп. Беләм сүзнең җүнлегә бармаганлыгын и бармаслыгын да. Шылай да сүләштерергә моны исәп.

— Нинди эш? Шылай да әтеп күрегез, җанга ятешле булса... белмәссең, — мәтәм.

— Эш тә түгел, уен гына бер караганда,— ди бу, мине ничек тә үз ягына аударасы келәп, — үзләре көндез эштә чагында әнә шул малай белән чуаласың. Сорый торганнары шул: малайны син ана телендә сүләшергә үрәтәсең. Кияү кешенең категорический әйткәне: штобы аның баласы саф үз телебездә генә сүләшеп үссен.

Көлсәң көл, җыласаң җыла. Бу минем белән сүләш алып баручы адәмгә кияү тиешле кеше булгач, шәт, яшь кешедер инде ул. Янә шул теге адәмне әтәм, кияү кешене, яшь кешене. Башы-аягы белән ычкынган адәмдер ул, янәмәсе, теле бозыла дип баланы садка йөртмә. Мәгәренки, мине дә бүрек белән генә атып екмалы түгел, Чистай мишәре, бәк тә чыңкыйлап уйланган булам: янәмәсе, ничек котылырга ул шыр тиле кияүнең шыр тиле бабасыннан.

— Мин каршы төгел пацанны саф татар теленә үрәтергә, — дим, өздереп, кырт кистереп әтәм. И, тегеңә тын алырга да җай бирмичә, өстим, — только, мәтәм, минем бер шартым бар.

— Нинди шарт ул, әйтеп сөйләшикче, — ди оныкасы өчен зрә дә көйгән бабасы. Шыннан мин тегеңә, шалт Мөхәммәтҗан, үз шартымны:

— Шартым шул: әт киявеңә: иң әүвәл ул минем үземне, Әбугалисина тау тишегенә качып дөнья гыйлеменә үрәнгән кебек, тау тишегенә ябып саф татар телендә сүләргә үрәтсен, аннан кире мин аның пацанын үрәтермен. Күрәсең ич минем хәзерге телне, керделе дә чыктылы. Нилектән бу? Шыннан бу: мине бит тау тишегенә ябып саф татар телендә үрәтүче булмаган.

Бабаң ык та мык, мин эткәнгә дә җавабы җук, кияве белән кызының пацаны да жалко. Мин, дуамал мишәр, бабанның болай да изрәп тәшәргә торган башына тагын бер тибеп куй шул чәк:

— Янә дә шыны да өстәп әт киявеңә: без беребез дә пыяла колба эчендә яшәмибез, шышы Казанда, шышы дөньяда — урысы, татары, чувашы, мукшысы бергә буталып яшибез и шылай булгач, ничу бер үзләре өчен генә пыяла колба эзләп мәтәштерергә. Тузга язмаганны.

Әтүен эттем бабасына да, ә үземнең күнелдә кара мәче тырнаша: ә кем белә, бәлкем бабасының көюе дә урынлыдыр: тел бит синеке дә минеке генә төгел, тел бит безнең атай-бабайларныкы, бабайларның бабайларыныкы. Шылай булгач, аны мусор ящигы урынына чүпләү егет кеше эшеме? Төгел. Мин мишәр чүпләгән дә догорла. Кайсыбер йокысыз үткәргән төннәрдә шындый дурак уй килә башка. Картаюга таба барабыз, мәгәренки, көннәрдән бер көнне кәкрәеп, җир астына илтеп тыксалар и, разный анда мулла-мунтагайның эткәне дөрескә чыгып, каршына әлеге теге... атлары ничек әле, авызларын корт чаккырысы? Мөнкир вә Нәнкир килеп, сорау ала башласалар, әкәмәт, кайсы телдә җавап бирмәк кирәк? Буталган баш.

Әй, куйсана, Фазлуш Гыйматдинович, җук белән баш катыруларны. Син, лучше, шыны әт: файдасы тидеме әлеге утыз уколның? А как же? Күренеп торган беренче файдасы: мин уколга йөргәндә килен Марсикны садтан үзе ташып тәмам шашкан. Малай, түгәрәк баш, үзе кәтүк кенә булса да тәмам татып өлгергән икән Фазлуш бабакаеның тәмен: «Бабай килсен, бабай килмәсә, катьмим», — дип киреләнә, имеш. Мин бит аны төрле чүп-чар сүзләр сүләп көлдерә-көлдерә апкайтам.

Икенчеләтә файдасы шул: әлеге утыз көн эчендә күпме кеше белән танышып сүләштем: акыллысы белән дә, үзем кеше кырыкка бер тулмаганнары белән дә. Бай дөнья! Арыгы, симезе, акыллысы-тилесе — бөтенесе бергә буталган.

Шыл файдалы якларын искә алудан булгандыр инде, соңгы кабат врачка күренгәндә, үзем дә абайлап өлгермәстән:

— Тагын утызны яза алмыйсызмы, духтор? — дип әтеп ташлаганмын.

Көлде генә духтор.

— Берьюлы эчеңне тишмәсме соң? Уколның бит аның, күпкә китсә, эчке яктан тишеп чыга торган алама гадәте бар. Сез инде, кем, Фазыл Гыйматдинович, күбрәк җәяү йөрү, яшелчә, фрукты ашау ягын карагыз.

Колак салдым киңәшенә, врач кеше белмичә әтмәс. «Дөрес әтә бу, мәтәм. Җәяү йөрү дигәне бигрәк тә. Анысына акча чыкмый, аяк-кул исән чакта анысын булдырырбыз».

## VII

Уколны тагын утызны бирмәделәр. Килен эштә, малай эштә, мин тагы үдә бер янгыз. Дөрес, эшләсәң үдә дә эш юк төгел, килен юмый калдырган кашык-аякны юам, идән себерәм, фанталдан су апкайтам и

бүтән шындый чүп-чар эш. Ә бит гренадердай гәүдәң белән гел шындый чүп-чар артыннан вакыт уздыру — даром шар тәгәрәтү. Кырындым-ясандым бер көнне, түшкә орден-медальләрне тактым, таякны да бик тотасы... аны ярамый бу көнне, ярамагач, ярамый. Ничек дисәң, ният меховой ягына барып чыгарга и эчтәгесен түкми-чәчми сүләп бирергә. Тапсыннар нинди дә булса бер эш. Әтергә: «Эшсез булмый яшәп, егетләр. Акчасын бирмәссез, пенсиям баштан ашкан, мәгәренки, нинди дә булса бер эш бирегез. Хет охранником, хет кочегаром шында?.. Эш кенә булсын!» Иң элек фабком Бохарайга сугылдым. Зурлап каршы алды, утыртты өстәле каршына, һәр чәктәге кебек, тотынды җон унаена сыпырырга: «О, Фазыл Гыйматдинович, бөтенләй үзгәргәнсез. Яшәреп киткәнсезме дип әтим, кыскасы, пенсия әпәе килешкән сезгә». Сыпыруын сыпырды бу, өстәвенә чәй дә китертте, мәгәренки эш ягына килгәндә, «карарбыз, сүләшербез. Сезне бит, данлыклы скорнякны, охранник итеп утыртып булмый, җае чыгу белән мин үзем кеше җибәреп хәбәр иттерермен. Аннары бит, Фазыл Гыйматдинович, үзең беләсең, хәзер бөтен җирдә яшь кадрлар», белән бетерде. Белә, бик белә Фазыл Гыйматдинович, эшлим дисә картларына да эш табыла. Мәтәштермә, фабком Бохарай. Аның шул сүзләреннән җенләнеп, директорга ук сугылмакчы идем дә, ишеге төбенә барып җиткәч, тукталдым. Фабком Бохарайныкы да дөрес бер яктан, яшьләрне кысрыкларга җөргән төслерәк килеп чыга. Аннары тагын фабком Бохарай өстеннән жалу белән чапкан кебек. Ә мин, бөтен Яңа бистәсе алдында ант итә алам, үз гомеремдә кем өстеннән дә жалу белән чапкан адәм түгел — хет макта, хет мактама ул ягымны. Шылай итеп шыл, «карарбыз»ны кесәгә салып, кайтып киттем үгә.

Бәхет бар икән, уйламаган җирдән көтмәгән шөгыль килеп чыкты, әле нинди генә! Яшь кадрны үзем хәзерлим хәзер, гәзитчә иттереп әтә калсак. Мәсьәлә шунда: оныканың детсадында кайсыдыр бер пацанның эче китә башлаган, дизентирий значит, и шыннан яп капканы бөтенесенә. Ике атнага диме шында, кәтү чыкмый, имеш, хәзер, авылча әтсәк. Кая барасың, Марсик башы-аягы белән янә минем карамакта, түкмәчәчмә, урамга чабып, машина астында калмасын.

Яшь кадр икән — яшь кадр. Башыңа төшкән бәла икән — башыңа төшкән бәла. Теләсәң ничек сал кателогыңа. И тотындым мин бу «яшь кадрны» әзерләргә. Иданне дә бергәләп себерәбез, кашык-аякны да бергәләп юабыз — мин тәлинкәләрне, ул кашыкларны. Тәлинкәләрне аңа ышанырга ярамый, төшереп ватуы бар. Ә минем квалификация бар тәлинкә юу ягыннан. Шының өстенә, тавык чүпләп бетмәслек әлеге шыл чүп эшләр өстенә, үзем уйлап таптым сурьюзный бер эш: малайны татарча сүләргә үрәтәм. «Бу нәрсә? Кашык!» «Ә менә бусы нәрсә? Себерке!» И шылай алга таба. Җитмәсә тагы үзем дә бик үк буш түгел икәнмен. Малай чакта, авыл мәптегендә укыган чакта ятлаган бер шиер истә калган:

> Безнең Гали бигрәк тату кәҗә белән,
> Менә кәҗә карап тора тәрәзәдән.

Дөресен әтим: малайга кәҗәсе дә, кәҗәнең рәхмәт әтеп сакал селкүе дә, Гали атлы пацаны да бик ошады. Мин көйлим бер яктан, оныка көйли икенче яктан. Яшь хәтер, әкәмәт тиз сеңдереп алды. Әле алай гынамы? Ике-өч көн үтте микән, әтисе белән әнисе алдында экзамен тота бу:

> ...Безнең Али бигрә̄к тату кәзә белән...

И шыл кәзәдән актыкка точкасына хәтле. Тегеләргә дә ошады малайның бу кәзәсе. Шылай да килен киленлеген итте, каһәр, остармыйча кала алмады.

— Бу малай белән кәҗә Марска бер иптәш булган, анысы бик ярый. Әйдә, белсен татарчасын да, — ди юри мине очындырырга тырышып,— ләкин, эткәй, Марсны гел кәҗә саклатып үдә генә мүкләндермә, бакчага да алып баргала. Һава кирәк бит аңа нык булып үссенгә дисәк.

Белмимме соң һава кирәклеген, бабасының да эчен тишми һава. Икенче көнне без оныка белән, әлбиттә, Али белән кәҗәне дә ияртеп, Эрмитаж бакчасына киттек. И бер тамаша булып чыкты бу Эрмитаж бакчасына йөрү. Рәхмәт киленгә киңәше өчен. Эрмитаж бакчасы безнең Профессорский переулоктан кул сузымы гына җирдә. Ә әтмәгәнмен икән, әлеге шыл башның чуалган чагы. Ә әтмичә ярамый моны, белеп торыгыз: абзагыз Профессорский переулокта тора! Бу сиңа бер кило бәрәнге түгел. Ары сад, бире сад, әлеге азон дигәннәре авызыңнан, борыныңнан гына түгел, прәме үкчәңнән керә. Шылай итеп шыл, пацанны Эрмитажга ташый башладым, раз килен әткәч.

Эрмитажга йөрүдән килеп чыккан тамашаның тычкан сыртлысы шында: монда мин үзем кебек тол калып каңгырып яшәүче бер түтәкәй белән таныштым. Али белән кәҗә и оныка бер якта торсыннар, шул турыдан җәелеп бер сүлим әле.

... Оныка көрәге, чиләге белән комда уйный. Шында ук башка балачагалар да ыгы-зыгы килә. Ә мин түшне үрә катырып яшел эскәмиядә утырам. Күпме-азмы утырганмын, анысын белгән җук, шында шыл уң якка күз төште. «Уң якка» дип басым ясый әтәм, ходай кушып, ахыры да уң булып бетсенгә җурыйм бу тамашаны. Миңа яхшылык теләсәгез, сез дә шылай дип дога кылыгыз. Әйе, күзем төште уң якка. Ә анда, баксана, нишләп мин моңа хәтле шәйләмәгәнмендер, ярыйсы гына бер түтәкәй утыра. Ул да шылай, минем кебек, оныкасы белән килгән булса кирәк. Янында термус белән су, янәсе, оныкасы эчсенгә и яхшы ук ялтыравыклы сумкасы. Сумкасына да күз төшә, бигрәк тә күз үзенә төшә, бәдбәхет түгел диген син Фазыл Гыйматдиновичны. Ярыйсы гына тутырган тавык бу күрер күзгә. Әлбиттә, көчеп утырам мин бу түтәкәй янынарак. Сүз башлыйм мин аның белән — анлык кына вагым бар. Мәгәренки, дуамал мөгезеннән алырга ашыкмыйм, җай белән кирәк. Ул арада минем оныканың тубын икенче бер пацан шул якка таба тәгәрәтеп җибәрмәсенме. Якынрак елышу өчен аяк астыннан килеп чыккан бер сәбәпме бу? Сәбәп бу. Киттем туп артыннан. Элек пацаннарны әрләгән булам: «Алай бер-берегезнең уенчыкларын атышмагыз, ару гына уйнагыз, тату уйнауга, тату яшәүгә ни житкән? И шыл унайдан «хап!» алга-артка карамыйча. Туп-туры түтәкәйнең нурлы чыраена карап:

— Дөрес әтәм бугай, бәлкем сез дә уртаклашырсыз минем бу гәпне?

Тегенең ни дип җавап бирүен көтеп тә торды җук, утырдым ук мин ул утырган эскәмиягә. Андый чакта җебеп калырга ярамый, әттеңме бер сүз, биш сүзең тамак төбендә запас торсын.

— Минем оныка, әнә ул минем Марсик атлы бәләкәй земснаряд, иптәш малайларына каршы тору дигән нәрсәне ич кенә дә белмәс. Минемчә, сезнең малай да драчун булмаса кирәк, үзегезгә карап хөкем йөрткәндә.

Тора торгач бер амин төслерәк килеп чыкты бугай, шылай икәнлеген үзем дә сиздем, мәгәр инде соң, әтеләсе сүз әтелгән иде. Түтәкәй бераз читкәрәк күчеп утырды, аны-моны дәшмәде, күзләрен шарландырып миңа бер карап куйды. Шылай да ямьсез итеп карады дип әтмәс идем мин.

— Гүлечка! Кызым. Рәтлерәк уйна, күзенә ком кертә күрмә,— ул комда уйнаган кызчыгы янына барып, аның өстен каккалады, уенчыкларын җыештыргалап бирде. Ә бит аның ул кызы болай да бик рәтле уйный иде. Юк, бу аның кызына әтүе түгел, бу аның миңа әтүе булды. Беренчелектән, болай дип әйтүе: «Юк, минеке малай түгел, минеке—кыз, шуны белеп тор» дип әтүе. Икенчелектән, янә шыны әтүе: «Син, абзы-

каем, дамалар белән сүләшәсең кели икән, алай дуамал башлама сүзеңне. Теге ни... тамак кыргалап, «ханым-солтаным!» ише китап сүзләре кыстыргалап, кыскасы, культурный итеп башла, шыннан мин уйлап карармын», — дигән сүзе. Мин аның шылай әтергә теләгәнлеген момент абайлап алдым. Әлбиттә, ул хаклы. Күчеп утыра бирсен, мин күчеп утырмыйча да сүләшә беләм. Ә тулаем алганда, бу ханым-солтаным, әлбиттә, культурный итеп сүләшерлек: җәелгән арыш камыры төгел, бите-күзе үз урынында, әтергә кирәк, мазасын китәреп прическа ук ясатып җибәргән. Беренче бәһа шыл минем тарафтан: ярыйсы бу апакайгынам. Сүләшеп утырырга можно моның белән. Тик менә мәсьәлә шышында: тагы ничек сүз башларга?

Яшь чактан ук җыела килгән тәҗрибәм бар, шыл әтә: боргалама, җебеп торма, кыз-хатын күп боргалаганны өнәми ул, ди. Аллага тапшырдым, сүләшәм мин бу тутырган тавык белән и ныклап торып сүләшәм. И тәвәккәлләә, Фазыл Гыйматдинович.

— Ерак торасызмы, әллә минем кебек шышы тирәдә генәме?

— Шышы тирәдә генә торсак, әллә ни... кунак булып керәм, дип әтергәме исәбегез? — ди бу. Әллә чынкыйдан, әллә юри мин карт тилене үчекләп шылай әтүе.

Кыскасы, куркаклар базарыннан төгел булса кирәк бу апакай да. Ул күчеп утырган икән — нигә, әтик, миңа да берчәк кенә аңа табарак шуышып утырмаска! Шуыштым и шыл бер ходтан авыз эчемнән нәрсәдер әвәләдем — хәзер, хет суй, искә төшерә алмыйм. Нәрсәдер чыкты бугай, чәй турыннанмы, кунакка йөрешү турыннанмы, кем хәтерләп бетергән андый чакта телдән ычкынган сүзләрне. Ә менә ул әткәннәрне аермачык хәтерлим.

— Хәер, кунак-кунак уйнашуларның кызыгы бетте хәзер. Миңа килсәң дә шыл плитәдә кайнаган чәй, сиңа барсаң да шыл плитә чәе. Борынгы заманнардагы кебек самавар җырлатып чәй эчеп утырулар бетте.

Тукта әле, тукта! Җае чыгып тора ич бу сүләшнең, нигә монда авыз эчендә бутка пешереп утырырга. И кис тә сал мин шыл берочтан:

— Безнең үзебездә, мәсәләнгә китсәк, самавар җырлатып утырырга да мөмкинчелек бар. Ак самавар кухняның түр башында, кунак кыз кебек, бөркәнчеген ябынып утыра. Тик сүләшкән кеше генә юк үзе белән. Килен иртүк эшкә чаба, аның өчен чәй әллә бар, әллә җук. Малайга чәең шулай ук нипочем.

— Самавары аның кемдә дә бар, агаем, — ди түтәкәем, сүзне ялгап, — тик менә хәзерге яңа йортларда самавар төтенен җибәрердәй юллыгын калдырырга гына оныталар. Теләсәң-теләмәсәң дә, самавар мескенкәйгә почмакта посып утырырга гына калды...

Узганны сагыну да, шаулап утырган самавардан чәй эчәсе килү дә, без фәкыйрьне дөм кире какмау да ишеттем мин бу сүзләрдә — инде бу мачлыкны да ычкындырсаң!

— Ә бездә, безнең үзебездә, мәсәләнгә китсәк, самавар куяр урын әлегә бар.

— Урыны булса, күмере юктыр, сез дә бит икенче дөньяда яшәмисездер, — белмим, әллә мине мыскыл итеп, әллә минем хәлемә керәсе келәп әтте бу сүзләрне. Юк, көлеп тә, хәлгә кереп тә әтүе төгел, күңелендә җыелган моңны түгүе булган икән, өстәде бу аннары килеп, — хәер, эш күмергә генә терәлеп калса, анысын аның рәтләргә дә булыр иде.

Тукта әле, тукта! Тагы чәк кенә җылышып утырыйм, сүләшү чыгарга тора бит безнең арада.

Зрә дә дуамал уйлый күрмәгез, әлбиттә, без шыннан ук безгә самавар куеп чәй эчәргә китмәдек. Бөтен эшнең үз чираты бар. Бу, беренче чиратта, әүвәлән килеп, аның Гүләсе белән минем Марсикны таныш-

тырдык. Гүлә дигәне — Гүзәл булып чыкты моның. Марсик белән шындук уртак тел табып, бергә уйный да башладылар. Тел дигәне шыл, хәзерге заман теле инде: яртысы урысча, яртысы татарча. Була бирсен, тик сугышмасыннар, җылашмасыннар гына.

Ә без ханым-солтаным белән сүләшә калдык, кара-каршы утырып чәй эчүгә тиклемгә барып җиткәнче ачыклыйсы нәстәләрне ачыкларга кирәкме? Бик кирәк, сүләмә дә ул турыда. И ачыкладык: ул тол икән — мин тол. Ул пенсия ала икән, без фәкыйрегез стажлы пенсионер. Ала торган пенсияләребезнең күпмешәр булуына хәтле ачыкладык: аныкы 75 сум икән, мин алам 90 сум. Икесен бергә китереп кушканда, йөз дә алтмыш биш сум була дигән сүз бит бу. Зрә дә күңелле булып китте минем өченгә. Әй, кушасы иде шул ике пенсияне бергә дә, саласы иде минем кесәгә.

## VIII

Бер көн уза шылай, бер атна уза шылай, пенсияләрне бергә кушу турында сүз кузгатырга тел бармый, малай. Нилектән дигәндә, яше олы күренсә дә, кыяфәтне шәп тота, тезгенне бирми. Шулай да сизенеп торам: без-керпе чәчтән алай ансат кына олагасы да киләми булса кирәк. Көн дә күлмәк алыштырып, төрледән-төрлесен киеп килә, прическасы да теге фасон да бу фасон, әтмәле төгел, эченә ут үрли бара булса кирәк бу толбикәнең. Хәзергә пожар ук дип әтергә ашыкмыйк. Мин дә, хәтәр, яшәреп үк киттем, килен белән малай эштә, бәбәген тәрәп нишләгәненне астыртын күзәтеп торучы оста килен җук, иренеп торулар бетте, көн дә Марсикны Эрмитажга алып чыгу алдыннан янакта, сакал урынында «безопаска» уйнатам. Келәсәм, анысы электробритвам да бар, «Харьков», мәгәренки, «Харьков» булса да безнең Казанны чиста урмый, урыны-урыны белән аударып кына уза. Ә мина булса булсын, күзгедәй ялтырап калсын, меховойда ударник булып үткән гомерем шикелле.

Ну, әлегә меховойда үткән гомергә кагылган җук, балалар турында бара сүз. Аларның кайда, кем булып эшләүләре, күпме зарплата алулары турында, янә дә килеп, ул үз оныкасын мактый, мин үз оныкамны. Без шылай кирәге-кирәкмәсе турында тирәли әләнеп йөргәндә, безнең оныкалар — минем Марсик белән түтәкәемнең Гүлечкасы берберсенә чистый да сырышып киттеләр бит, малай. Минем малай белән киленнең эшләгәннәре түбән төгел, аныкының да әлләни югары төгел, прическаның да пенсиясе шул бер чама, минеке дә чамадан ашмаган, кыскасы, беребезнең дә борын чөярлек урыны җук. Ник соң әле болай тел яшерәбез, ник беренче мәлдәге кебек бер-беребезгә елышыбрак утырмаска! Шыларны уйлыйм да, малай, янә дә килеп үземнең ир кеше икәнлегемне уйлыйм да — тәвәккәл-хода, картлар әтмешли — батырлык минем тарафтан булырга тиешле, дигән карарга киләм и әт тә сал бер көнне янымда утырган прическа тутакайга.

— Карагыз әле, йөрәк маем, торуын да моннан шактый ерак торасыз, Җдановта дидегез шикелле, автомобильгә утыртып китереп куючы, түрдән-түргә алып китүче малаегыз да җук, минекеләр дә җәяүләп чабучылар, синекеләр дә җәяүләп чабучылар, канса-канис сорау туа миндә: нишләп әле сез безнең Эрмитажга җәтли башладыгыз? Җитмәсә, көн дә яңа күлмәк киеп?

Текә чыкты сорау, кайдан мондый думаллык телгә килгәндер? Шындук күңелемнән үземә-үзем сорау куйдым и, яшерен-батырын төгел, шөрли калдым. Аңласа ярый әлеге сорауның астында нинди кызыл төлке яшеренеп ятканны, то есть, дөрес аңласа ярый дигән сүзем.

И, йөрәк майларым, адәм булсын да, дөрес аңламасын, имеш! Шундый гренадер ир, керпе чәч янында утырып торганда. Яңгыш булса, ха-

тын-кыз кавеме без Чистай мишәрен гафу итсен, барысында да печән кибәне хәтле хәйлә утыра бит хатын-кыз братның. Ничек сыйганлыгын, кайда утырганлыгын белмим ул «кибәннең», мәгәренки, белгәнем шыл: утыра. И дуамал гына чыгарып әләндереп салырга ашыкмас та ул аны. Минеке дә (янә гафу! Минем янымда утыручы купшы хатын, Гүләнең дәү әнисе турында бара сүз) сораудан әллә ни өреккәнлеген сиздермәде, шул ук вакытта тотып алган мәәнәсен зрә тиз селкеп салырга да ашыкмады.

— Безнең якын-тирәдә мондый зур, мондый күләгәле бакча юк шул, — диде өзеп, тегеләй-болай уйларга ич тә урын калдырмыйча. Кыскасы, барып чыкмады атака, алтмыш сигезгә җиткән башың белән соң, сүз арасына «кызыл төлке»ләр кыстырып азаплангач. Мин шундук коелып төштем, авыз ачып икенче сүз әтмәскә, азгын телемә ход бирмәскә булдым. Түбән карап кына утырам, эчемнән уйлыйм: «Ара өзелде бу тутакай белән!»

Өзелмәгән икән, сүзне ничек яңартырга дип эченнән усаллык уйлап утырган икән алла бәндәсе. Бераз шым утырганнан соң, берчәк күтәрелеп карап, берчәк елмаеп та төгелме әле, өзелгән сүзне үзе үк ялгап җибәрде бу:

— Ждановтан арлык килә-китә йөрүемнең тагын бер сәбәбе бар: Профессорский переулокта нинди әдәмнәр тора икәнлекне беләсем килә. Утыз ел Казанда яшәп, шәһәребездә шундый матур исемле урам, йә булмаса тыкрык барлыгын ишеткәнем дә юк иде.

— Ишетмәгән булсаң, айса, менә ишет: бар шундый урам, — дидем мин, бу юлы инде баягы «ычкынып китүемне» ничек тә булса төзәтергә тырышып, үтә дә сурьюз кешегә әләнеп. Ә апакай гел үзенчә бора, хәтта берчәк кенә миңа таба шуышыбрак та утырды төгелме әле.

— Җыен зур кешеләр яшиләрдер инде анда, профессорлар тыкрыгында?

— Кечкенә кешеләр төгел, — дип өздем бу юлы да. Ә аның, минем янда утыручы апакай гынамны әтәм, сүзне өзәсе килми иде булса кирәк, авызын җырып миннән көләргә үк уйлады:

— Шуларның, шул зур кешеләрнең берсе, кайчандыр, мине гөжләп кайнап торган самавардан чәй эчерергә вәгъдә дә биргән иде. Күрәсең, күңеленең нечкәргән чагында теленнән янгыш ычкынгандыр.

Көлә бит бу миннән, әбәзәтелне көлә. Ә минем адәт начар: үземнән көлгәнне ич яратмыйм. Шундук сикереп торып, ул җырык авызның нәкъ каршысына килеп бастым.

— Гафу итегез, ханым-солтаным,— дидем бу юлы да кырт кына өзеп. Белмим, кайдан телемә килгәндер шындый культурный сүзләр, — шындый чакта кешенең исемен оныта торган алама адәтем бар. Кызганычка каршы.

Бак, янә дә китап сүзләре килеп чыкты, имештер, «кызганычка каршы». Гомердә былай кәнфитләнеп сүләнә белә торган адәм төгел Фазлуш Гыйматдинович. Күрәсең, Профессорский переулокта торганлыкны акларга тырышып шашыну булгандыр инде.

— Бик иске исем минем иҗем, әти белән әни шылай куштырганнар, ә минем каршы торырлык көч булмаган.

— Шылай да әтеп сүләшкән ару, мин конкрет булганны яратам.

— Әйтергә калгач, әйтәм: Шәмсеҗамал минем тулы исемем, ә мин Җамал дип кыскартып әйткәнне яратам.

— Шулай да без бу хәзергесе минутта тулы атыгыз белән атап сүләшик әле, Шәмсеҗамал кодача.

— «Кодача» да булдыкмыни инде? — шаркылдап көлде прическа. Мин бу көлүне тагы үземнең адреска дип кабул иттем и дуамал тилереп җенем кузгалды.

— Әле генә бер әткән идем, тагы әтәм: мин конкрет булганны яратам. Баянак та читләтеп-читләтеп кенә минем бакчага таш аттыгыз: кайчандыр мин гөжләп кайнап торган самавардан чәй эчәргә вәгъдә иткәнмен дә, янәмәсе, имеш, сүземне онытканмын. Кузгалдык шушы минутта, и киттек шушы минутта. Минем үгә моннан өч кенә атлыйсы. Самавар вакытлыча бөркәнчеген салып торыр, күмер подвалда гына. Кайтабыз да жырлатып жибәрәбез самаварны.

— Аннары икәүдән-икәү кара-каршы утырып чәй эчәбезме?

— Ник икәү, Гүлә белән Марсикны ник счет төймәсеннән төшерәсең?

Сүз әтергә бирмим Җамал күгәрченгә. Үзем дә күгәрченгә әләндем, каршында гөлдер дә гөлдер. И, коры «гөлдерәү» белән генә алдырырсың пенсия ашап үрәнгән хәзерге тол хатыннарны. Алып кайтырсың, пычагым, чәй белән генә кызыктырып. Ни кыстадым нәгъләтне, кайтмады.

Беләм инде мин хатын-кыз братны, эчләрендә мең төрле эт эчәгесе уралып ята аларның. Мин икенче кабат чәй турысыннан сүз катмагач, көтеп-көтеп эченә кату чыккан булса кирәк тутакайның, бер дә бер көнне шул сүзне янә дә китереп чыгармасынмы. Әлеге шул эт эчәгесе галәмәте: көн дә термус белән чәйме, газированный сумы алып килә торган бу ханым-солтаным, баксана, бер көнне термусын онытып килгән, имеш. Ә көн галәмәт эссе, кояш баш түбәсенә бездәй кадалып тора. Шундук, конкретның да конкреты: Гүләсе су сорап җылап килә моның. Үзенең дә тамак чатнагандыр, билгеле. Ә мин тик утырам бер читтә. Әле Африка, әле космос, әле үз күршебездәге бер кешенең инженер малаен Кубага командировкага җибәрүләре турында сүләнәм. Сүзләремнең очы-очка ялганмый, бу фактны үзем дә сизәм, мәгәренки, андамыни эш. Әһәмият шунда: башны зрә югары тота торган бу укымышлы тутакайны, шушы уттай эссе көннән файдаланып, сусавыннан тәмам көйдерергә исәп. Аннары ул мина кереп чәй эчү турында ихтыярсыз сүз кузгатачак. Тактик ход шушы. И тәки шулай булып чыкты да.

— Гаеп-кыек итүче булмасмы соң? — дип башлады бу интеллигентный гына итеп,— әгәр, сүздән әйтик, сезгә кереп, тегe бөркәнчек бөркәнеп утырган самавартызны куеп җибәрсәк, ә? Күмер бар, төтенең җибәрер урын бар дисез ич.

Шым бул! Тактик ход барып чыкты бу килештән. Кердек. Айлар буена кузгалмыйча эче пошып утырган самаварны кузгаттык, подвалдан күмер менде. Дүрт-биш минут үттеме икән, самавар җырлый бер якта, уенчыклары белән балалар мактанышалар икенче якта, Җамал тутакай белән Фазыл Гыйматдинович гөрли өченче якта.

— Яратам шушындый тыныч почмакта тавыш-тынсыз гына яшәүне. Баш очыннан трамвай зырылдап узмый, күршеңдә исереп кайткан ирнең дөнья хәкарәте сүзләр әйтеп, хатыны белән талашканы ишетелми, газетын кичә чыкканны бүген китереп бирәләр...

Чү, газиткә кагылма, күз өстендәге кашым, безнең почтальонша Пелагеяга сүз әттерде юк, иртәнге чәйгә авыз тигәнче гәзитне китереп тоттыра: «Тукта әле, Фазлуш Гыйматдинович, чәйгә аннан соң да өлгерерсең, иң элек менә политика, дөнья хәлләре белән таныш!» — янәмәсе.

Шулай да кунагым, самавар гөжләп кайнаган җайга, безнең урамны, безнең үне, безнең, фанер такта белән бүлгәләнеп, этем дә сизмәслек итеп обойланган бүлмәләрне болай мактап торганда минем дә телгә бер сүз килеп тора торуын. Эч пошуларың момент басылыр иде, мач китереп әтә белсәң. Мәгәренки, ул чаклы ук чишелеп китәргә ашыкмыйм. Алай бик ошатса, үзе әтер бер дә бер көнне. Чәйгә сусагач, Гүләсен җитәкләп йөгереп керде ич.

Озаклап чәй эчтек, сүләнмәгән сүз калмады, гөжләп кайнап утырган

самавардан эчкән чәй бөтенләй икенче шыл, каршында шындый интеллигентный дама да сайрап торгач, тьфү, тьфү...

«И так далее!» дияр иде дә бетерер иде урыс булса. Ә минем алай кыска тотасым килми, шылай килде-китте булса да сүләнеп утыру рәхәт миңа.

...Ә җәй кызу килде ул елны, әлеге ханым-солтаным да термусын часты оныткалап килергә үрәнә башлады. Мин Чистай мишәрен ал, гомер иткән Сәлимә-мәрхүмәкәемә «син!», «сиңайтәм!», «анасы!» дип эндәшүдән башканы белмәгәнне, бу прическалы интеллигентный толбикә алдында гел юхаланырга үрәндем: «ханым-солтаным» кебек китап сүзләре белән генә сиптерәм.

Безнең болай көндез-көндез кереп, самавар җырлатып утырулар, может, алга таба дәвам иткән булыр иде, кем белсен, бәлки тора-бара теге тамак төбен кычыттырып йөргән сүз дә әтелер иде... бөтенесен Марсик каһәр, әлеге шул сер тотмас үрдәк, кылкылдап харап итте.

— Әй-лә, эчәсем килми... тәмле түгел син куйган чәй, — ди бу бер кичне әнисенә. Эшеннән болай да кәефе кырылыбрак кайткан әнисенең момент колагы торды бу сүзгә.

— Сөйләнден чүп сүзне... Кем куйган чәй тәмле була соң, әниең куйган чәй тәмле булмагач?

Беләме соң малай, тишек авыз. Безнең җәйнең-җәй буена диярлек, бигрәк тә эссе көннәрдә, бигрәк тә «ханым-солтаным» термусын онытып килгән көннәрдә, көндезен безгә кереп, самавар җырлатып чәй эчеп утыруларыбызны, («ул апаның Гүлә атлы кызы» булганлыгын) Гүләнең дә бездә чәй эчкәнлеген — барысын, барысын да берьюлы түгеп ташламасынмы! И точка шуның белән безнең рәхәтлекләргә. Ансат эттем, итәрсең точка минем киленише чая киленнәр белән. Чистый да чынкыйга алган Марсик лыкылдаган сүзләрне, ягъни безнең көндез-көндез кара-каршы утырып чәй эчкәләп җөрүләрне. Әтә бер көнне, эштән кәефләнебрәк кайткан ире алдында күзен дә йоммыйча әтә:

— Кәефең шәп чагында сорап калыйм: ничек карыйсың әгәр эткәйне өйләндерсәк? — ди. Чистый чынкыйлап әтә.

Усман, бусы инде минем утыз бишкә җиткән үз гренадерым, кәефләнеп кайткан булса да, юк сүзне алай тиз чынкыйга алмый, үземә охшаган ул ягы.

— Кайдан башыңа килде әле мондый гениальный идея? — дип сорый киленнән. Үзе шундук миңа мыскыллы бер карап ала, — белмим тагы... Әти үзе ничек карый торгандыр бу тәкъдимгә.

Килен чая, теле-телгә йокмый, җәен көндез-көндез бергәләп чәй эчкәләп йөргән «ханым-солтаным»ны искә төшерде, минем бер үземә бер бүлмә биләп торганлыкны телгә алды, кайнатасының керләрен юу да ансат булмагандыр, ахры, читләтеп-читләтеп кенә булса да ул мәсьәләгә дә кагыла узды. Кыскасы, киленнең үз тактикасы: мин картның мәшәкатьләрен үз җилкәсеннән икенче бер җилкәгә ыргытасы кели.

— Белмим тагы... Әти үзе ничек карый торгандыр бу эшкә, — диде Усман тагы бер кабатлап. Бу юлы инде уйлана төшебрәк әтте.

Уеннан уймак чыктымы, тиктормас картлач! Хәер, онытмагыз, Фазлуш Гыйматдинович та карт чыпчык, сүзгә кесәгә кереп тормый. Берьюлы точка куйдым соңгарак калып күтәрелгән бу киңәшкә.

— Җә, булды, атай картыгызны үләндердегез, ди... Нишләрмен икән соң мин үләнеп? Алтмыш сигезгә җиткән карт әтәч.

## IX

Үдә япа-ялгыз калам кай чакларда, ә менә гәүдәм үгә сыймагандай. Тыгыз, эч поша, берчәк оят та кебек. Бөтен планнарны җимерде ич әнә теге карсак малай, Марсикны әтәм. Үзе бер карыш, теле биш карыш.

Теге прическа-яланбаш белән көндез-көндез кара-каршы утырып чәй эчүләр бетте, аның Гүләсе дә, безнең Марсик кебек, озын телле булып чыккан, үдәгеләренә тишкән. Бер караганда, нәрсәсе бар инде көн кызуында күләгәдә кара-каршы утырып чәй эчүнең... Бакчы, яшең берчәк кояш батышына таба киткәч, нәрсәседер бар икән шул, без наданнар белмибез генә икән!

Янә килеп, тагы шул наданлык галәмәте, теге көнне киленгә әткән сүздән чыгып әтәм әле бусысын. Янәсе, имеш: «Иә, үләндердегез, ди... нишләрмен соң мин үләнгәч?» Шушы да булдымы сүз, киленгә әтердәй сүз! Килен бит ул, ничек кенә ука-чук булмасын, чит йортта туып үскән чит кеше баласы, ә син шуның алдында үз булдыксызлыгыңа пичәт басып утыр.

Уф алла, җаным түшәк күрми, ятып йокы керми, өрә белмәгән көчек үгә кунак чакыра, ди торган ие минем анай, мәрхүмәкәй. Юкса бит, чатылдатып әтеп бирәсе сүз чыккач: «Үләндерегез әле башта, аннан күз күрер»,— дип. Кыскасы, ничек акланасы килен алдында?

Бер юл бар: шундук читек-кәвеш аласы да, Насыйри урамындагы мәчеткә чаба башлыйсы и момент мәчет картына әләнде дә куйды Фазлуш Гыйматдиновичыгыз. Иртәчәк мәчет, кич мәчет. Теләсә ничек ташыгыз садтан күпне белә торган Марсигыгызны. И шундук шик юылып төшә: булмый былай и ярамый былай. Гомер буена как первый класс рабочий булып эшлә дә, аннан килеп старший сержант булып Гитлерга каршы, Родинаны саклап йөр дә, соңыннан килеп, диннән чи надан килеш мәчеткә чаба башла. Тавыклар көләр, кешеләрне әткән дә җук.

Бак, икенче бер җулы табылырга тора, очко бирәм бу килештән килен-җырык авызга. Шыл көннәрдә газиттә бәләкәй генә бер хәбәр укыдым. Башына:

**Җәяүләп 3000 километр**

дип, шар-шар хәрефләр белән язылган да киткән тезеп, киткән тезеп: янәмәсе, Луис-Мишель дигән бер француз, кәсебе белән гәзит-хат ташучы, күрәсең, әлеге кәсебеннән тәмам гарык булгачтыр, бер дурак эш уйлап тапкан. Мадагаскар дигән утрауның төньяк яры буйлап җәяүләп үтәргә. Өч мең километрлык араны. Нибарысы ике айда, әтергә генә ансат. Ике айда өч мең километр. Көнгә ничә километр чыга әле ул? Укыган чакта ук арифметикадан әллә ни рәтем җук иде, хәзер алтмыш сигез яшемдә ике җирдә икең — дүрттән узмый. Хәер, укуымның аты корысын, өч класс та бер коридор, дип җибәрә торган иде безнең меховойда бер тел бистәсе.

Иң актыктан нилектән мондый сәфәргә чыгуын аңлатып бирә. Уйлап баксаң, бер дә дурак эш түгел, имеш. Янәмәсе, кешенең озак вакытлар рәттән нинди физик хәрәкәткә сәләтле икәнлеген, простой телгә күчереп әтсәк, авызыннан җаны чыкмыйча күпме җәяүләп траклый алуын күрсәтеп бирә. Бериш, мич башыннан төшмичә, килене-малае белән таләшып ятучы җанлы өрәкләргә сабак. Акыл бу, бер яктан караганда. Икенче яктан баксаң, бәлки, минем сыңар, эче дә пошкандыр. Тик ятып. Ә йөргәндә эч пошырга вакыт юк, ил-җир күрә. Шыңа өстәп, миңа киңәш биргән кебек, врачлар да җәяү йөрергә киңәш биргән булсалар... ә?

Мин, әлбиттә, Луис-Мишель түгел, нибары Фазлуш Гыйматдинович кына! Мәгәренки, минем дә аякларым бар. Аяклар янына таякны да өстә. Дөрес, ул Мишель-мактанчык яшен күрсәтмәгән, бәлкем аңарга нибарысы 50 яшь кенәдер, ә миңа — әтергә ансат — тиздән 68. Алайга китсә, мин, Мишель кебек, журналистларга интервью дә биреп тормам. Тордым булыр бер көнне таң тишегеннән, чыктым киттем булыр. Үдәгеләргә дә калдырсам тик язу гына калдырырмын. Янәсе, имеш: «Атай картыгызны юксынмагыз и ду кубып эзли дә чыкмагыз, ул җәяүләп Татарстан чикләреннән бер әләнеп кайтырга сәфәр чыгып китте. Кеше

әнә анда өч мең километрлы Мадагаскарны да әләнә, Татарстан Мадагаскар төгел, үз җирем, шәт, югалмам».

Менә бит ул ничек шәп килеп чыга, мондый шәп итеп китапка да язылмагандыр, валла. Тавышсыз-тынсыз гына тәвәккәлли азыегыз, мәгәренки, үз исәбе үзендә. Төгәл шуны белеп кайтырга: Җир шарын түгәрәк диләр, Татарстан түгәрәк микән? Аннан кире, келиләр икән, язып чыгара бирсеннәр газитләрендә. Минем төп максат: теге көнне авыздан яңгыш ычкынган сүзнең дөрес төгеллеген киленгә чекерәйтеп әтеп бирү — юк, аптырый торганнардан төгел синең кайнатаң. И шул уңайдан теге прическалы тол тутакайны да берчәк аптыратып калдыру. Бик иңбашларын сикерткәләп сүләшмәсен әле Фазыл Гыйматдинович белән. Ул прическа булса, Фазыл Гыйматдинович җәяүләп тәгәрәргә оста акробат.

Сәфәремне башлыйм. Идел-Кама буйлап. Беренче көнне, әтик, Лаешка хәтле кусам, аннан Балык бистәсенә, аннан Кама яры буйлап... Тукта, чү? Чистай турына килеп җиттем төгелме? Ничек инде үзеңнең туган ягыңны урап узмак кирәк? «Җәяүләп»кә чик куелды, Кама хәтле Каманы җәяүләп жырып үтеп булмас, ә үтәргә кирәк. Яхшымы-яманмы, туган нигезгә сәләм бирмичә, монау озын юлга олагу ярамас. Беләм, Карамалыда «ах» итеп торучы әллә ни кардәш-ыру, туган-тумача жуктыр инде, озакка батмам. Пенсиям кесәмдә, алдагы айларныкын — кайдан туры килә шуннан — телеграмма җибәреп соратып алырмын дип сүләштем. Торсам, берме, икеме көн торырмын, шыннан ук Шерәмәт, Түбән Кама якларына элдертергә исәп. Шерәмәт тирәсендәге Иөзәйле авылында минем фронтовик дус бар, юл уңаеннан аның да хәлен белеп чыгарга булыр. Бергә гитлерчыларны дөмбәсләдек, бергәләп госпитальдә аунадык улсы белән. Хәзер ничектер, сугышта буй бирмәде, борчак сибәргә дә ярата иде, сүли башладымы, авру-сырхауларыңны бер якка куеп тор. Карта алып кайттым, өйдә кеше юк чакны чамалап картаны өстәлгә җәеп салдым, маршрутны билгеләдем, кыскасы, ориентирлар кул астында.

Әкренләп җыенам. Аны-моны сизгән кеше әлегә жук. Шулай да килен, очлы күз, бер көнне бик ачу китергеч сорау биреп куйды. Сугыш медальләрен и сугыштан соң бирелгән орден-медальләрне ялтыратып, разный анда нашивкаларны костюм түшенә тагып утырганда, шул тиктормас тел шөпшә тешләгәндәй кадый узмасынмы:

— Эткәйне әйтәм, бик шомарына-ялтырана башлады соңгы вакытта, әллә инде, безне ташлап, теге чәй ярата торган Гөлбикә түтәкәй янына китәргә җыена, белмәссең хәзерге пенсионер картларныкын.

— Гөлбикә түгел, Җамал. Шәмсеҗамал искечә әтсәк, Җамал ханым була яңачасы, — дип, юри бәгърենә кадалырдай итеп кычкырдым и аннары былай дип тә өстәдем, — китсәм, Җамалыңнан да, барыгыздан да качып китәм, кайнатайны гел чагып яшәүче киленнән күлмәк-ыштан юдырып яту җитте.

Шушы булды бөтен дипломатия, беләм, малайга ул моны, әлбиттә, ике капчык итеп, түтырып, түкми-чәчми җиткерәчәк. Уйлыйм, артык хәсрәт чигүче булмас, киткән — китеп яхшы иткән булыр. Белмим, Марсик ташбаш кына юксынса инде, сер килешә иде безнең ул оланшак белән.

Күп уйлап тормаган шикелле, күп әйбер дә алмадым. Кулга зур портфель, бөтен мөлкәт шунда. Бер пар чиста күлмәк-ыштан, сабын, сөлге и, кирәк булса-булмаса, бер блокнот белән бер авторучка. Теге Мадагаскар җәяүлесе аны да алмагандыр әле, җәяүлегә янчык та авыр диләр иң. Мәгәренки, минем аңардан өстенлегем шында: миннән интервью сорап йөдәтүче булмады, аягым ат, кулым камчы, шоп-шома чыктым да киттем. Аякка помошник таяк та бар иң әле, анысын әтергә онытканмын.

Шылай да... Шылай да, энекәш, юк икән безнең заманда, булмый икән алай мөгез чыгарып. Барып чыкмады жәяүләп Татарстанны әләнү дигән планым. Барып та чыгар иде, юлында гел сулы елгалар очрап тора, кая карама — анда машина, кая гына барып чыкма — душасын урталай жарып бирергә әзер торучы яхшы кешеләр. Әтергә кирәк, просто аңламыйлар синең нинди план белән йөргәнлегеңне...

Ансат булды дип мактанырга келәмим, нәрсә булды — улсы булды, факт шул: дүрт көн үтеп бишенчесендә азагыз Қаманың сулъяк ярында, үзенең Чистаенда басып торамы? Тора.

Туп-туры райкомга ук киттем. Шында шыл өметләнәм, мәтәм, күргән-белгән иске белешләр очрап куяр бәлки. Хәер, андыйлар очрамады, булмаганны булды дип әтер хәлем жук. Бөтенесе яшьләр, чырайлары ачык, галстуктан, интеллигентный халык кругом. Каршыларындагы йомшак креслодан урын күрсәтәләр, авызыннан ни чыкканны көтеп торалар. Хәер, мин озак көттермим, эш кешеләре, юк-бар белән урындагы кешеләрнең вакытын алдым жук. Мәгәренки, жәлт кенә күңелдәген селкеп салдым да төгел. «Пенсионер кеше, — мәтәм, — вакытны кая куярга белгән жук. Чыктым әле менә, картлар ничек әтәләр, дөнья күрергә. Үзебезнең Карамалыда булырга кирәк, бәлкем берәр чыбык очы кардәш-ыру исән калгандыр. Аннан кире, күрше-тирә районда бергә Гитлерга каршы сугышкан таныш фронтовиклар бар, аларның да хәлен белергә исәп...»

— О, бик яхшы, бик хуп, Фазыл агай, — диләр болар сүзне бүлдереп. Райком кешеләре, эш кешеләре, минемише жукны бушка бушатырга чыккан кеше белән озак сүләшеп утыра алмыйлар, знамо шулай. Шуннан мине машинада илтеп куймакчылар болар. Жук, чыдамлыгым житмәде, райком дип тә тормадым, ниятләп чыккан планымны сүләп бирмичә булдыра алмадым.

Ишетергә дә келәми секретарь:

— Жукны сүләмәгез, Фазыл Гыйматдинович, — ди бу (шул арада кайдандыр минем атай картның исемен дә белеп алган, вона тамаша!). — Сугыш ветераны, хезмәт ветераны, житмәсә, безнең якташ... сугышның беткәненә, Гитлерның муенын сындырганга 30 ел тулган елны шундый ветеранны жәяү йөртергә ярыймы соң. Сез безне алай дорфалар рәтеннән санамагыз.

Кыскасы, портфельдә ята тор, жәяү жөрү маршруты. Таякны да кайдадыр онытып калдырганмын, мине «Волга» машинасында зырылдатып Карамалыга илтеп куймасыннармы!

Кая ул! Мин киткән чактагы Карамалы жук, кругом яңа үләр, калай түбә дә шифер түбә. Кибет тә клуб, урамнарында мотоцикл да велосипед.

Колхоз правлениесендә утырабыз, председатель дигәннәре яшь кенә адәм, минем Усман сыңары, мыексыз ир, мәгәренки, иплә сүләшә.

— Күптән кайткан жук, — мәтәм, гаепне тизрәк үз өстемә алырга келәп, — дөнья мәшәкатьләре, туган-тумача да калмагач... берәр жары баш төртер урын табылыр микән?

— Иң әлек сиңа менә мин туган-тумача, — дип үзде дә куйды бу яшь-жилкенчәк председатель. Әтергә кирәк, райкомдагыларга караганда да зәһәр сүләшә, — гомер эчендә бер туган авылына кайтып... ветеран войны, ветеран труда, понимаешь. Башлап миндә икеме-өчме көн кунак буласың. Шул арада Карамалының үз ветераннары ярдәме белән әкренләп сезнең ботак-чатакларны, кардәш-ыруларны да табарбыз.

И китте, әкәмәт, китте башланып. Бригадаларга да алып жөриләр, сыер, сарык жәйләүләренә дә барып чыгабыз, урманга да, болынга да... Тагы шунысы кызык, яшьләрнең берсен дә танымыйм, ә алар бөтенесе мине таный: «Фазыл азый да Фазыл азый!» Кыскасы, туган-тумача, чыбык очы жуктыр дип кайтсам, бөтен авыл туган-тумача булып чык-

ты. Ул кунакка җөрү, бөтенесе сәбәбен табып тора тагы. Берсе тәкә суйган, икенчесе мунча яккан, өченчесенең кибеттән алып кайтканы бар, хатыны бер ялгызына гына рөхсәт итми, имеш, аңа иптәш кирәк и так далее... и так далее.

Мәгәренки, бер күрәсе килгән кешем бар, әлегә аны очрата алганым юк. Бәдәр атлы иде бугай, исеме дә хәтердә чут-чут кенә эләгеп калган. Мәптектә бергә укыган идек, көтү кайткач кичләрен ындырда сыер саклый идек, матур иде, зәңгәр күлмәкле иде, күзләре дә күлмәге төсле зәңгәр иде, рәхәт була торган иде миңа аның белән бергә туры килсәм. Былай сайрамас идем, яраткан булганмындыр шыл.

## X

Элекке ындыр урынында ферма каралтылары, элек без сыер саклаган чирәмлекләрдә мин берсен дә танымый торган яшьләр үтеп-сүтеп йөриләр. Элеккедән сакланып калганы — күк тә җир генә булса кирәк. Валла, менә шылай. Былай кыздым ук булмас та иде, эндәшми-тынмый гына җөри торгач, Бәдәрне мин шылай да күрдем, олыдан кубып ант итүгә вона шул сәбәп. Бәдәр Түбән очта, кияве бөер чиреннән үлеп яшьләй тол калган кызы белән генә тора икән, мин барып кергәндә үдә ялгыз үзе генә иде. Әлбиттә, башта ул мине, мин аны танымадым. Бак, шул теге чактагы Бәдәрме соң бу? Кайда аның мине саташтырган зәңгәр күзләре? Кайда ул чәчрәп торган тере кызый? Бер карыйм, кешесе җук, үдә күлмәк кенә селкенгәләп җөри.

— Ни дип әтим? Бәдәр, синме соң бу? — дип сорадым аптырагач «күлмәк»тән.

— Күрше авылныкымы? Раюннан килгән берәр урындагы кешеме син? — дип, минем үземә сорау бирә, «күлмәк».

Күлмәк дигәнем шул Бәдәр булып чыкты, бөтенләй чүккән, саны гүпчи дә юк кебек, күзләре чепи, мин карыйм аңа, ул карый үнең почмагына. Тамаша, үзгәрсә дә үзгәрер икән бәндә?

Кергәнсең икән, җәлт кенә чыгып китеп булмый, сүләшергә кирәк берчәк.

— Мин ни... Фазлуш булам, ындырда бергә сыер саклый торган идек ич. Танымыйсыңмыни?

— Кызым үдә җук шул. Ул белә инде безнең андый вак-төяк алыш-бирешләрне.

Ахрысы, колак ягы да чамалырак калган моның, якынрак киләм, кычкырыбрак әтәм:

— Төбәбрәк кара әле, Бәдәр. Шушы авылныкы ич мин. Гыймади малае Фазлуш булам. «Ат күзе, Фазлуш үзе» дип мыскыл итә идең малай чакта.

— Ат белән килдем дисеңме? Әле атлар да калган, айса, сезнең якларда. Кругом машина ич хәзер.

— Ә мин сине күрүгә таныдым. Син бер дә үзгәрмәгәнсең, нәкъ элекке Бәдәр, — юри тегенең күз бәбәгенә төбәп ялганлыйм, юри үчектерәм. Үземә дә әллә ничек бер яктан. Илле-алтмыш ел күрми тор да, дуамал акыра башла кешегә. Әле кемгә диген. Малай чакта күз төшеп йөргән кешегә. Аннарысы тагы мыскыл иткән төслерәк, кыскасы, әллә ничегрәк килеп чыга. Ә фактически алып әткәндә, кичен кызы колхоз эшеннән кайтканчы пычагым да сүләшеп булмады. Мин әтәм берне, ул сукалый бөтенләй икенче җарытын. Мин сорыйм чөшле, ул китереп тоттыра сырлы бәләк. Үзе шулай да ата-анасыннан, нәсел-ыруыннан килгән кунакчыллыгын онытмаган, момент самавар куеп җибәрде, табын әзерләде, атлан май чыгарды, ак күмәч турап куйды. Чәй янында, кинәт зиһене ачылып киттеме дип әтим, ахрысы таныды бу мине.

— И, кара әле... Гыймай азый малае ич син. Фазлуш ич син. И, кара гынам әле... ничек картайгансың.

— Шылай, Бәдәр, кешедән калышкан җук, үсәбез. Хет тануың өчен рәхмәт.

Танып алганнан соң сөйләшү тагын да хәрткә әләнде. Бәдәр үзенен картаюыннан, күзләренен чепилегеннән оялыпмы, яны беләнрәк борылып утырды, яулыгын күзенәрәк төшереп бәләде, күксел тамырлардан гына торып, корышып калган кулларын ничек тә җиң эченәрәк яшерергә, күрсәтмәскәрәк кели бу. Үзе шылай да, яшермим, миңа чәйне ничек тә күбрәк эчерергә, сыен мактабрак ашатырга тырыша иде.

Алай да сөйләшү керделе-чыктылырак барды. Бер ачылып, аруланып киткән кебек тә була. Бигрәк тә фронтта үлеп калган ире Әсгать турында сөйләгәндә шөйлә дә терелеп, тернәкләнеп китә. Аның Әсгате тегеләй булган да, аның Әсгате былай булган. Аның Әсгате чәк кенә авызы белән кош тотмаган... Яратышып гомер кичергәннәр булса кирәк, әттә генәсе икән, гүпчи дә терелде бу. Икенче сәбәбе янә дә шыл: Әсгате турында сөйләгәндә мин аны сораулар биреп бүлдермәдем. Әйдә, мәтәм, ачсын бер душасын. Синең ни эшең бар аларның ничек торуларында. Әсгатьне чәк кенә чамалыйм, без җегет булып йөргәндә ул әле: «Миңа кайчан җитәр икән шылай җегет булыр чаклар?» — дип күзләрен тозландырып, безнең арттан гармун сыздырганны тыңлап җери торган пацан малай иде. Бәдәргә караганда, әлбиттә, яшь иде, Бәдәрнең аның турында сөйләгәндә җыр җырлаган кебек тернәкләнеп китүе дә, мөгаен, шуннандыр. Аннарысы килеп, зрә былай бетерешүенең, күзсез һәм колаксыз калуының бер сәбәбе дә может шылдыр; шындый яшь, таза и гайрәтле ирең фронтта үлеп калсын да...

Ә Әсгатеннән соң булган сөйләшү — тагы шул чөшле сораганга сырлы бәләк тоттыру булып чыкты.

— Хәзер ничек соң, Бәдәр, кызың белән икәү генә яшисез инде, алайса? Кызың гел эштәдер инде. Янгыз башың шөйлә уйланып мазалана торгансыңдыр. Сабыррак булырга тырышып кара, — мин әтәм боларын. Авылдашны, яшь чак әшнәсен үземчә тегеләй... җуатырга тырышып әтәм. Вәгазь укыйм, кайдан килгән указлы мулла.

Ә Бәдәр эндәшми-тынмый утыра да утыра. Аннан кире, миңа дип ясаган чәен йөзен күрсәтмәскә тырышыбрак миңа таба суза да, ни калага, ни салага дигәндәй, бөтенләй көтмәгәнне ермачлый башлый:

— Чишмә тавы ишелде бит безнең, Фазыл. Узган ел шылай өч көн, өч төн рәттән коеп яңгыр яуды. Су буендагы мунчалар акты, терлекләр кая керер урын тапмадылар... Хәзер эчәр суны колонкадан гына алабыз.

— Әтәм, кызларның, ак алъяпкычлар ябып, тезелешеп-тезелешеп чишмәдән су китергәннәре күренми. Вона аккошлар тезелешеп очкан кебек су ташыйлар иде ич әлгәредә.

— Алкышлар анысы хәзер дә гел булып тора, — дип әлеп алды бу. Ахрысы, минем узгандагылар белән исереп очырган «аккошларым» аңа алкышлар булып барып җитте булса кирәк,— әле ай-ай ярым элек кенә Казаннан килгәннәр ие өчәү, берсе шуның шул хәтле әйбәт җырлады... Клуб түбәсен күтәрердәй итеп кул чаптылар. Мин чукракны әт, мин булып мин, Әсгатемне искә төшереп, әстәгъфирулла, янгыш әтсәм, бер почмакта лышык-лышык җылап утырдым.

— Хәзер инде тамак тук, мать җакасына. Эчең пошса, җырла да җырла.

«Мать җакасына»ны зрә ычкындырганмын, колак ягы тегеләйрәккә калган Бәдәр моны үзенчәрәк ишеткән, яисәмәсе, мин аның самавары җырлап утырмаганга бик риза түгел.

— Туздышул бу самаварыбыз, утлыгына су тибә... Яңасын куясым

калган икән аны. Әсгатем төсе итеп шул... гел шушы иске самавар колагына ябышам.

Әтәсе дә юк, тапты чәй хуры, җилтерәтеп самаварын яңартырга кузгалды. Без шылай ишектән керәсенә тәрәзәдән кереп, ә фактически алып әткәндә, бер-беребезне ич аңламыйча күпме тәкелдәгән булыр идек, бер заман колхоз эшеннән моның кызы кайтып керде. Вона, ичмасам, бусы булды тамаша, шундук эш көйләнеп китте. Мин сүз әтәм анасына, кычкырып әтәм, югыйсә. Мин әткәнне ишетми Бәдәр. Кызы мин кычкырып әткәнне тегенең авыз төбенә барып пышылдап кына әтә, анык ын ишетә. Әлбиттә, берьюлы селкеп салды юк, сукырмы ул, чукракмы, хәйләпоты белән хатын-кызда. Кызына сүзне минем белән бергәләп ындырда сыер саклаудан башламады, мин тилене яшь чак истәлекләрен эзләп йөрүче гидай бәндә итеп тә атамады, янәсе, имеш, мин аның Әсгатенең ахири бер дусты, актык сыныкларыбызны бергә бүлеп кабучы чын товарищы итеп таныштырды. Без никрут булып җырлап урам әләнгәндә, аның Әсгатенең гармун тавышына уштан язып, арттан няреп җөрүче ачык авыз булганлыгын алда бер әткән идем инде, монда аны кабатлау кирәкмәс, товарищ булган икән товарищ, былай берчәк шәбрәк тә, кызы фронтовик әтисенең элекке әшнәсе алдында дәррәү ачылып-юмартланып китте. Баздан йомарламы белән тагы май чыкты, чоланнан кәрәзле бал керде, шул арада самавар да янәдән гөжләп килеп утырды.

— Безнең ни... хатын-кызның сые чәй дә, әлеге шыл хәзинәдә бары инде... — дип батыраебрак сүләнә башлады Бәдәр үзе дә, — ир-ат булса ни... кибетенә дә барып кайтыр ие коры тотып кына...

«Кибет» дигәннең астында нинди маза ятканлыкны беләм, хатынкызны расходландырырга келәмәдем, мәгәренки, аналы-кызлы икесе дә шылай ачылып торгач, үземне тотып кала алмадым, дуамал гына кирәкмәс бер сорау биреп ташладым:

— Без яшь чакта, әле исемдә... — дип башладым, түбән генә карап. — Күзләрең зәңгәр иде синең Бәдәр, малай...

Сораунын яртысын әтеп житкермичә, тотып калдым. Әтә калсаң, алла сакласын: «... хәзер нишләп чепигә әләнде?» дип бәйләнү кебек картина килеп чыгачак.

Кызы, аны-моны нечкәртеп тормастан, минем дуамал сорауны, әле ярый, шул әйтелеп бетмәгән килеш, гадәттәгечә пышылдап кына әнисенә «тәрҗемәләп» бирде. Шундук җавап кайтарырга ашыкмады Бәдәр, кузгалып, кече якта бер мәл торып керде, аның чепи күзләре тагын да кызара төшкән иде әләнеп кергәндә. Ул тагын да яны беләнрәк, йөзен ничек тә миннән яшерергә тырышыбрак утырды.

— Булгандыр инде яшь чагында, — диде ул аннан арысы, сузып кына,— нишләмәк кирәк, дөньясы шылай гел җанны үртәп торгач. Ирем Әсгатьнең фронттан үлгән хәбәрен алгач, яшем белән җудырып бетердем мин күземнең зәңгәрлеген.

Баксана! Кем әтте моны шылай шигырь китапларында язылa торганча килештереп? Хәллә Бәдәре әтте, мин малай чакта ындырда бергә сыер саклап үскән кыз әтте. Күрәсең, багырына үткән ачысы, тагын шыл әлеге сугышны әтәм.

Беравык ни дә булса сүләшми утырдык. Ни сүләмәк кирәк. Шындый өзелеп китәр чакта. Әле ярый, нужа күргән без картлардан гына тормый дөнья, бала-чага, яшүсмер чыр-чуы бар. Безнең оеган тынлыкны ватып-җимереп, дәррәү шында пыр тузышып яшь буын чабып килеп керде. Чекерәешкән ике пацан. Өйдә ят бер бабай утырганны күреп, момент шым калдылар, берсе әбисе Бәдәргә, икенчесе аның кызына сырышты, әллә аларның култык асларына кереп, мин факырдан үзләренчә качкан булулары инде. Олыларының ым кагуы буенча, мин момент

белеп алдым: Бәдәр кызының малайлары, шау-гөр акаешып, садтан шулай кайтышлары икән.

Хәер, калдырырсың хәзерге сад балаларын тавышсыз-нисез, үземнен Марсик ташбаштан беләм.

Берсе, кечерәге, култык астыннан җәлт чыкты, җәлт минем алга сикереп менде. Сүзе дә, соравы да шундый җәлт чыкты.

— Бабай! Син сугышта булдыңмы? Безнең Әсгать бабайны күрдеңме?

Бусына җавап биреп өлгергәнче, икенчесе атылып килде. Анысының авызыннан сүзнең тагын да чырлырагы чыкты:

— Әтмә, әтмә... Әллә белмимме, син бит үзең безнең Әсгать бабай. Сине фашист үтерә алмаган, менә кайткансың. Әби безне алдаган. Безнең үз бабаебыз. Кайткан! Кайткан!

Эшнең хәтәрләнә баруы күз алдында, мин, малайлардан бигрәк, олыларының үзләрен юатып, тизрәк сыпырту ягын карадым. Теге ике малай, минем китәргә җыенуны күреп, үрсәләнеп җылашырга тотынмасыннармы:

— Бабай, китмә! Бабай, кал бездә безнең бабай булып!

И так далее. Шулай итеп шыл, чистый әкәмәт чыга язды. Җәяүләп Татарстанны әләнергә дип чыккан карт, беренче авылда ук яшь кияү итеп, сәфәреңне бүлдерүләре бар. Үзара гына эткәндә, башка мондыйрак шайтан вәсвәсе дә килмәде түгел: калырга да булыр ие берчәк. Бабай икән бабай, бигрәк тә шундый тере пацаннар чат ябышып торганда. Мәгәренки, күңел бик коткылы: өнәп үк житкерми, үдә үз пацаным— Марсик бар. Икенче яклатып эткәндә, теге Казанда калган прическалы тутакай да истән чыгып бетми. Дөрес, аның белән арада вәгъдә-фәлән булмады, мәгәренки, җәйге челләдә озаклап-озаклап чәй эчүләр булды. Янә килеп, шуны да онытып бетерергә ярамый: пенсиясе зур.

## XI

— Житте, Гыйматдинович, унбиш көн кунак булдың, әллүр изге сәфәреңә!

Кеше ишетмәгәндә генә үземә-үзем шулай әтәм. Исәп — иртәләрнең берендә торырга да әзне суытырга, белми дә калсын Карамалы. Командировка-мазар түгел, «килдем-киттем»не сельсоветтан билгеләтеп, пичәт суктырасы җук. Килдең — капка ачык, киттең — капка ачык.

Ансат кына ычкынасы, акылы алтын Гыймай малае Фазлуш мөсафирның. Бер җулы ике чөй кагып куйдылар табанга.

— Шулай да шулай, күрсәткән сый-хөрмәтегез өчен рәхмәт, иртәгә таңнан мин җук Карамалыгызда, алда тора озын сәфәр, вакытында итә белергә кирәк әпәр.

. Шулай дип телемә салынмакчы идем колхоз председателе алдында, авызны ачтым гына тик, җабарга ирек тә бирмәде бу.

— Тора тор, әллә нидә бер кайтып... үзенең туган-үскән авылына, тәк сказать, — ди бу, минем сүзне чыңкый да бүлдереп, — тор тагы өч көн, дүрт көн дип әтмим, өч көн. Бөтен авылны җыеп, демонстрация корырбыз дип тә әтмим, эш вакыты, ул чәк кыландыра алмабыз, но правление «Волга»сы баскыч төбендә көтеп тора булыр. Әллә сине, сугыш ветеранын, хезмәт ветеранын, әллә нидә бер күренеп, җәяү җибәрерләр дип уйлыйсыңмы?

Хәтәр китереп куйды бит бу мәсьәләне, белмәгәч белми әдәм баласы, хет и булсын колхоз председателе. Минем план бит машинада кататься итү түгел, җәяүләп республиканы әләнү. Кай җирем ким минем, әтик, Мадагаскарны җәяү әләнеп чыккан француз Луис-Мишельдән. Председательнең үз сүзе, минем үз сүзем: машинага утырды җук, минем, мәтәм, үз принцибым. Чәк кенә теләдән ычкынмады, янәмәсе, минем шын-

дый-шындый научный максат. Исләре китә хәзерге яшьләрнең син җил капчыгының максатына. Шындук авызны томалады.

— Житмешкә җитеп килүче картны таяк таяндырып, кырлар-басулар буйлата җәяү җөртергә әллә син Николай заманасы дип белдеңме? Хурлыгы кем өстенә? Хурлыгы колхоз өстенә. Җәяү киту турында авыз да ачасы төгел.

Каршы килеп кара шыннан соң, чынкые да шыл: колхоз өстенә хурлыгы төшүе бар. Үзеңнең дә башыңнан сыйпамаслар, колхоз күрсәткән хөрмәтне кабул итмәгән өченгә. Калырсың берчәк француз Мишелең белән дуракка. Чараң җук, председатель сүзенә күнәргә туры килде, Утырырга туры килер, ахры, шул «Волга»ларына.

Бер уйлаганда, җае да җук төгел моның. Алда барып төртеләсе авылым моннан егерме биш километр ераклыкта. Күрше районда. Анда минем фронтовик дус Харисов Якуп бар. Сүз дә җук, җәяү барып егылганчы, «Волга»да шуып барып төшү — авторитет. Бер үзем өчен генә дә төгел, шул ук Харисов Якуп өчен дә. Кем кунагы ничек килеп төшкән? Харисов Якуп кунагы шылай килеп төшкән «Волга»да, панимаеш.

Бәхәс бетте, «Волга»да икән, «Волга»да. Ләкин дә «тагы өч көн» дигәннәренә категорически каршы. Былай да ике атна кунак булдым, тәшәккердән гаҗизмен. Малай чакта безне укыткан Шиһап хәлфә шылай әтә торган иде. Пичәт басылган, протокол шыл булсын: иртәгә, кешекара аягы кузгалганчы, гостиница төбенә килеп туктасын «Волга»лары. И никаких гвуздев, урыс әйтмешли.

Бу чаклысында колхоз председателе белән килешкән дә идек, мәгәренки, «ике чөй» дигәнемнең тагы берсе калды бит әле.

Башта корган планымның сүтелүеннән бераз кәефем кырылып, ә чынлыкта, кеше-кара ишетеп тормасын, «Волга» белән озаттыруларына эчемнән генә куанып, гостиницага кайтып, титан кипятогыннан гына булса да чәй изрәтеп, бүрек белән сүләшә-сүләшә инде бер чәйләп алырга ясканып торганда, ишек тә кагып тормыйча, мәгәренки, бүреген култык астына кыстырып, бер иптәш килеп керде. «Иптәш» дигәнем мин карт җулаучы белән чагыштырганда энекәш, ә болай кырыклар тирәсе булыр, әгәр артыграк та булмаса. Бүреген култык астына кыстырып керүеннән үк күңелем сискәнгән иде, дөрес сизенгән икән, гозер белән килгән бу. Гозере нәстә диген? Аз да төгел, күп тә төгел, тагы ике көнгә үзләрендә кунак булырга чакыра килгән. Батыррак сүләшү өчен булса кирәк, килешли сала килгән, күзләре ут яна моның. Мине олылап дәрәҗә саклавы ишектән кереп сәлам биргәнчегә генә җитте. Шыннан китте бу, китте бу, миңа авыз ачарга да бирми, гел ул сүли, гел аныкы дөрескә чыгарга тиеш.

— Бер дә дөрес төгел бу эшең, кардәш-ыру булган кешегә бер дә килешә торган эш төгел, туганый,— сибепме сибә миңа үзенең указын,— гомер эчендә бер авылга кайтып, әнекәй генәм, шушы комырыкта җомарланып ятасың. Әни күземне ачырмый, «апкил булгач, апкил туганыеңны», ди. Моңа чаклы үзем үдә булмадым, Чистайда ит сатып җөрдем. Аңарчы бер кыҗыраган идем апкилергә, вакыты мач килмәде, безнең монда, үзең беләсең: колхоз эшләре, кәнишне үз эшләрең дә бар. Инде дә килеп, әни карчык күземне ачырмый. «Нинди эше бу Фазылның, ата-бабадан кардәш-ыру була торып, безнең бусаганы атламыйча китәргә йөри икән»,— ди.

Бүреген култык астына кыстырып керүдән бер шикләнсәм, ике сүзнең берендә «Туганый»дип кыстыруыннан колагым икенче торды, «Туганый» дигәне «Туган абый» дигән сүзе икән моның. Мин карт тиле тамчы да белмим, кай яктан туган абыйсы буламдыр аның. Әлбиттә, бәхәскә кереп, каршы төшеп карадым, «Туганый»га каршы төгел, Туганый икән — Туганый, чорт с ним, тик иртәгә кузгалам дип торганда, тагы ике көн тоткарланасым килми иде.

— Минем инде сүләшенгән, колхоз председателе үзе этте... Иртәгә миңа машина бирәчәкләр, — дип карадым, җиңәремә ышанып җитмичәрәк. Аннан кире, кирәк бит телгә әләнергә, — мин янә шыны да төшенеп җитмим: кайсы яктан кардәш-ыру икәнбез без? Хет шыны әтеп сүләшегез: исемегез кем була соң сезнең?

Һәр кызмача кеше бәйләнчек була, гозер белән килгән адәмем минуты-секунды белән җәелгән кочакка әверелде и мине кочып алып, битемне-яңагымны ялый ук башлады:

— Мин синнән моны көтмәгән идем, Туганый. Бу сүзеңне әни карчыкка кайтып әтсәмме? Илла туганлыкны онытса да онытыр икән адәм баласы.

Анын бу үпкәле сүзләре дә, әлбиттә, куырган иде, ә ул җитмәде дип уйлады булса кирәк, кинәт мине кочагыннан ычкындырды, тузгып ишеккә ыргылды.

— Бәлкем, ни... дукәминт кирәктер сиңа. Дукәминтсез ни... атасының кем булуына да ышанмый хәзерге кеше. Алайса, мин ни... Күз ачканчы дукәминт китереп җиткезәм...

Үттеме икән ун-унбиш минут, ашъяулыкка төреп бөтен Корьән күтәреп килгән бу. Аптырарлык бер карасаң, ә аптырарга ирек бирмәде, чыгарды төргән җиреннән, китереп терәде Корьәнне минем күкрәккә.

— Минем гарәп ягына грамотым сай, Туганый. Яңалиф, аннары менә бу керәшен хәрефе белән баш каткан. Укып бак үзең, әни карчыкның әтүе дөрес, минем кочаклап килүем дөрес. Менә бу арткы битендә безнең кайдан чыкканлык чочма-точ язылган булыр.

Корьәннең арткы «буш бите» минем бәбәк төбендә, карамыйча никак. Ә анда табагач кебек эләктергеч-тарткыч гарәп хәрефләре белән язылган «дукәминт» дигәне нәкъ үзе. Миңа яшь чакта гарәп берчәк эләккән, ул хәтле томана төгелмен. Укыйм:

«...Бу кем язылады акка кара белән бер мең сәкез йөз алтмыш алтынчы җылда, җылкы җылында, тамгалап әйткәндә. Ягъни кем, атадан балага, баладан анын баласына калсын өченгә:

Безнең ыругның башы башланадыр Иманша хәзраттән, хода урынын җәннәттә кылсын. Иманшаның ике угълы булып, ике тармак шуннан сузылып китәдер. Бер угълы Бәхтияр намында улып, Бәхтиярнең угълы Хөрмәтулла, Хөрмәтулланың угълы Әгъләмша, Әгъләмшаның угълы Зәкария, улсынын угълы Корбанай, ягъни без фәкыйрегез. Бездән тумышы, ягъни безнең асаба газизебез Солтанайдыр, ягъни җәмгысе җиде буын, җәмгысенең дә урыннары оҗмахта булсын.

Иманша хәзрәтнең икенче угълы Гыйлемдар үз нәүбәтендә шулай ук орлыклы вә янә ыругысына тугырылыклы калып, байтак кына ир угъланнар калдырмыштыр. Хәтергә ышанып кына ул газиз угъланнарның әммәсенең дә исем-шәрифләрен атап тормастан, соңгысы, ягъни үз заманында гомер кичермәктә улмыш Гыймадетдинны гына атап үтмешем.

Язылды бер мең сәкез йөз алтмыш алтынчы сәнәдә, сәфәр аенда, җылкы җылында. Бездән соң бу дарелфәнагә киләчәк угълан вә кыз-хатын таифәләре моны белеп торсыннар, бу юлларны язып, нәсел-ыругыбызны тамгалап калдырганыбыз өчен безне һәр даим хәер-догаларыннан ташламасыннар өченгә».

— Йә, моннан соң да карышып торырсынмы, Туганый? — дип, тагын да чиләнебрәк ябышты кызмача баш. Мин Корьәнне тоткан килеш зрә дә кинәт торыксыз калдым. Катып калырсың, брамат, бердән, «Туганый»-ныкы да дөрескә килеп чыга, дөнья эше белән булашып, туганлык җепләрен чистый да онытып бетергәнбез. Икенчеләйгә китсәң, җитәкчелек

белән сөйләшенгән. Иртәгә иртәнчәккә минем баскыч төбенә «Волга» китереп куячаклар. Ничек дип әтергә, теге әкият итеп сөйләнә торган коданыкыча килеп чыга. Булган, ди, бит килсә китә белмәс бер кода. Кунакка килгән жиреннән ич кенә дә китәсе килми ди моның. Көн саен майлы коймак та, кайнар мунча белән узындырып торгач, ничек китәсе килсен, знамо китәсе килмәс. Ә китәргә кирәк. Кунак — ике генә көн кунак, артыкка китсә аннарысы муйнак. Шуннан шул бу кода үз дугасын үзе яшереп куйган ди кичке караңгылыкта. Иртәгесен, әй, эзләгән була ди дугасын, әй, эзләгән була ди. Янәмәсе, бик китәсе иде кана да, дуга юк бит вона.

Мин дә шул әлеге кода хәлендә. Болай «дукәминтләп» чакыргач, Туганыйларга да барасы килә.

— Анысы, туганлык дөрес тә булсын, бармыйча ару да түгел андый кардәш-ыру кешегә,— мәтәм.— И бер үк вакытта майланмаган көпчәк кебек шыгырдыйм да, — руководство белән сөйләшенгән бит, кадалып киткересе.

— Ул чаклысы хәл итеп булмый торган мәсьәлә түгел, — ди илче булып килгән кызмабаш, — моннан кайтышлый ук Хәллә абыйга үзем сугылам и шушы бөтен Корьәнне күтәреп, ант итеп сорыйм, «Волга»ны тагы өч көннән китертәбез. И баста шуның белән.

Китә башлагач, ишекне ачып чыгып киткәч, тагы борылып керде бу. Авызы жырылган.

— Белмәсәң бел, Туганый,— дип башлады бу керүендә,— Корьәнне бүтән чакта кулга да тоттырмый әни карчык, таһарәтсез кулың белән кагыласы булма, дип кенә тора. Инде килеп, шул таһарәтсез кулга шындый газиз әрбисен тоттырып жибәргән икән, монда, Туганай жаным, шәләй-вәләйгә урын жук. И Хәллә абзый алдында да шулай куячакмын мәсьәләне. Кыскасы, куй бу кайнар-кайнамас чәеңне, аягыңны киенә тор, Хәллә абзыйдан чыгышлый мин тагы кереп, култыклап үзем апкитәм, валлаһи-газыйм, син безнең үнең кайда икәнен дә белми торгансыңдыр әле. Үзең бул шындый дукәминтләр белән беркетелгән агайне.

«Туганый»ның китүе булды, янә бер чакрылмаган кунакның бусагага кереп басуы булды. Бусы колхоз «Волга»сының шоферы икән, ошаган ягы шыл: сылап-сыйпап тормыйча әтте сүзен:

— Менә нәрсә, кем, исемегезне белмим, эш болай тора: Хәлил азый, безнең прсидәтел улсы, Сезгә иртәгә «Волга» вәгъдә иткән икән дә шыны ачыклыйм дип килдем, көтмәгез иртәгә «Волга»ны. Прсидәтел белми машинаның көен, ә мин беләм, потомошты мин шофер. «Волга»бызның эше кәкәй, рессорлары какшаган, өч көнсез дә аякка басачак түгел.

Кәефем килде бу жегетнең ачыклыгына, сүзне өзеп тә әтә белүенә.

— Аяклымыни сезнең ул машинагыз? — дип берчәк ирештермәкче дә булган идем, кайда ул, жегетем шындук ишекне жәлт бәреп чыгып кыяклады. Менә, ичмасам, заманча чыкты бусы.

Ничек кенә булмасын, тагы өч көнгә калырга туры килде. Һәм калуым ярады да. Карт хәтер, истән үк чыгарган булганмын, узып бара торган айның пенсиясен шышы авыл адресы белән жибәрергә дип үземнең Казандагы райсобесыма телеграм жибәргән идем, икенче көнне пенсия дә килеп төште. Монда кунактан-кунакка жөреп, өйдән апчыккан да кесәне тишә башлаган иде, расход чыкмый, кая куясың. Ул гына житмәсә, мә бишне, пенсия акчасы да килеп өстәлде. Прәме, бәлә башка. Акча житмәсә дә бәлә булгалый иде, акча күп булса да бәлә икән, малай. Шылай да кесәне жиңеләйтердәй бер чарасын таптым. Төшеп калганнардан төгел, гәзитен укып, радиосын тыңлап барабыз. Кайбер нәчәльниклар бит әнә куяр урын табалар, кунак чакыралар, үзләре кунакка чабалар.

Ә Гыйматдиничның кай җире ким — сугыш ветераны, хезмәт ветераны. Унбиш көн буена авылда кунак булып җөрдем, ашамаган ризык, эчмәгән «теге»се калмады. Нишләп әле мина шуларның әҗәтен кайтарып, бөтен агайнене җыеп, бер «ответный визит» ясамаска? Уйлавым шында — карарым шында. Иртәгә китәсе дигән көнне кичтән гостиница ашханәсендә шәп кенә табын әзерләтеп, бөтен агайнене и, ташка үлчим, авызы кибеп җөри торган бөтен Карамалы кешеләрен җыеп сыйладым, газит теле белән дипломантларча әйткәндә, тантаналы ужин бирдем.

И мактадылар, и мактадылар үземне. Сыйларга гына кирәк икән, малай, сыйласаң, күгәрчен сөтенә генә коендырмыйлар икән.

## XII

— Сәфәремнең барышында дип әтимме, үзем дә йөреп-күреп торган көн, ике акыл керде картайган башка. Беренчесе шыл: авылның авызы икмәккә-майга туйган, йорт-җир, каралты-кура яңарган, мәгәренки бер яклары белән каладан калышалар: олы йомышка йөри торган җирләре бик салкын. Алган сабагымның икенчесе шыл: җәяү җөрүгә караганда «лефковой» машинада җөрү куда шәп икән. Француз Мишель дигәне, аяклары бик атлыгып торса, Мадагаскарын җәяү әләнә бирсен, ә мине менә егерме биш-утыз километрдагы, әтергә кирәк, күрше раюнга колхоз председателенең үз «Волга»сында, бер сәгать тә узмагандыр, китереп җиткезделәр.

Шылай да әлеге теге сүзен турыдан сиптерә белүче шофер, мин аның сукин-сынлыгын шыл бер күрүдә үк чамалап калган идем, көчеклеген янә дә күрсәтте. Күрше раюнга керүебез булды, шып туктатты машинасын:

— Дальше күршеләр эше, кирәк төшенә илтеп куярлар. Мин председательгә дә шылай әттем, раюн границасыннан чыгарам да бушатам кунагыңны, дидем. Җитмәсә, машина да чыгымлап тора, әле егерме биш километр кайтасы да бар.

Юкны сүли көчек, машинасы да көендә, председателгә дә алай әтмәгән, мәгәренки, кыр уртасында ул көчек белән сатулашып тору кемгә кирәк. Бигрәк тә шыл сүзенә хәтерем калды: «бушатам», имеш. Тирес бушатамыни!

Икенче яктан, рәхмәт үзенә: җәяү йөрергә дип чыкканлыгымны янә исемә төшерде: Йөзәйле авылына хәтле җәяү тыракладым.

Йөзәйле авылы — бу шыл минем фронтовик дус Харисов Якуп яши торган авыл инде. Йөзәйле, имеш. Саный китсәң, утыз-кырык өе бар микән? Анда тыкрык, монда тыкрык, әллә, ачуым килмәгәе, тыкрык дигәне бардыр бер кырык. Фронтовик дусның өенә, шабаш, тиз килеп җиттем. Соңыннан төшенеп алдым: тыкрыкларның болай күплеге тикмәдән түгел икән: колхозның төп участогы — правлениесе, парткомы, культура йорты дигәннәре и бер уңайдан шында культура дигәне үзе дә икенче авылда, әтергә була, үзе бер калага әверелеп бара торган зур авылда, имеш. Үзеннән-үзе борынгылар сүзе чынлыкка чыга: көнбагыш кая карый? Көнбагыш кояшка карый. Кешеләр дә культура ягына чабалар. Иң әүвәл мине шаккатырганы шыл булды: минем фронтовик дус Харисов Якуп, тегендә чакта минем отделениенең иң әтчәйни солдаты, панимаеш, культура ягына китәргә ник ашыкмаган, шышында, иске Йөзәйледән кырык өй, кырык тыкрык торып калган карга оясыннан ник күчмәгән? Дуамал башка китереп бәрә торган бер тукмак булып чыкты бу. Әлбиттә, мин бусагадан атлау белән проблеманы селкеп салырга ашыкмадым. Башта кочаклашу да үбешү, мәгәренки, шуны әтергә кирәк: үбәр җире гупчи дә беткән моның. Битне, янакны сакал баскан. Бусы булды

ФАТИХ ХӨСНИ ◆ КАРТАЯ БЕЛМӘС КАРТЛЫК ◆

проблема номер два. Әкренләп-әкренләп, икеме-өчме көн катыклы аш ашагач, мачлап кына чишендерә башладым мин бу иске тормыш калдыгы мужикны. Сезнең кызыксынуыгыз бар: янәмәсе, ник катыклы аш? Ник шундук егып бер сарыгын суймый? Ник дәррәү генә кибет якларыннан урап кайтмый? Между прочим: абзарында биш баш сарыгы, бер танасы, бер сыеры бар. Эчәргә, сарык итенә темтенеп әтүем түгел, мәгәренки, башын эшләтергә тиеш: кайлардан-кайлардан эзләп, фронтовик иптәше, алай гына да төгел, командиры килеп чыккан.

Әкренләп-әкренләп таптым мин моның нечкә кылларын. Башы эшләми төгел, мәгәренки үзенчә эшли икән моның башы. Эш менә нәрсәдә, имеш.

Авылның Түбән очында, ярга сыенып утырган тәбәшәк кенә бер кәҗә абзарында, ызба димәсән, хозяйкасының хәтере калыр, ызба диярге минем тел бармый, әйе, шында шыл чибәр генә бер тол тутакай тора, аты коргыры, Майтап атлы тутакай. Бала-чагасы булмаганмы, әллә булып та кайсын кая очырып бетергәнме, кыскасы, яши, имеш, ялгыз бер Майтап. Сүләшәм-сүләшәм, йомгакның очына чыга барам: шыл Майтап атлы чырлы толга минем фронтовик дусның күзе төшеп тора, имеш. Анысы ни... гаеп-кыек эш төгел, ата-баба җоласы, бер тол икенче толга тартыла. Мәгәренки, болар арасындагы тартылуның әдәм башына сыймаслык икенче ягы бар: шул яр читендәге Майтап тол, әле Якупның түшәгенә аягын да сузмас борын, бичара әдәм баласын үзенең җәтмәсенә эләктереп өлгергән, имеш. Җәтмә дим, кая ул җәтмә генә, полный тырнагы астына.

— Кияүгә чыгам мин сиңа, Якуп, син тол, мин тол, ике толга бер мәҗлес, бер амин,— дип әтеп әтәдер, ди,— түлке минем яктан ике шарт бар: биш баш сарыгыңны, бер танаңны, бер сыерыңны минем кулга исәнсау тапшырасың. Икенчеләтә килеп шартым шул: үзәк усадьба дигән булып Кушимән авылы ягына акаймыйсың. Минем ата-бабалар яшәгән Йөзөйледән китәсем килми, менә шул.

— Аяклы мал колы булгач нишләтәсең аны, вәсвәсәне, — дип тилмергәндәй, сузып куйды мескен Якуп, сүзен очлап. Бу ситуацияне ишетеп, мин шындук үземә мондый бурыч куйдым. «Юк сүз синең җәяүләп республиканы әләнәм дигән сүзең, сиңа җәяүләп җөрергә барыбер ирек бирмәячәкләр. Бүгенгесе көндә синең кәнкрит задачың: фронтовик дустыңны әлеге теге «вәсвәсә» тырнагыннан коткарырга булышу. Торырсыңмы бер ай, торырсыңмы бер җыл, әлбиттә. Йөз үдән утыз-кырык үгә калган бу котсыз авылда озак тору ансат булмас, мәсьәлә анда төгел, Фазлуш, мәсьәлә шында: «син теге «аяклы мал»га хирес хатынны ничек тә борып, аны фронтовик дусың Харисов Якуп янына авыштырырга и икесен тиң культура юлына бастырып, колхозның төп мөлкәте и идарәсе тупланган үзәк усадьбасына күчерергә тиешсең».

Әлбиттә, мондый зур эшне гел катыклы ашта гына башкарырга мөмкин булмаячак. Шуны күздә тотып, Якуп алдына кәнкрит мондый бурычны да китереп куйдым:

— Бүген үк бер сарыгыңны егып суясың, ә мин шыл арада кибет ягыннан урап кайтам, кичкә ике фронтовик сүләшеп утырабыз и шында мин сиңа үземнең планнарымны ачып салырмын. Ә син мине беләсең, белергә тиеш, Гитлерга каршы бергә сугыштык, ә синең ул «аяклы малга хирес» нәмәстән, шәт, Гитлер әтле үк усал төгелдер. Бергәләп тотынсак, без аны җиңәбез дә җиңәбез.

Харисов мондый кырыс куелыштан, әлбиттә, бераз миңрәп калды, ык-мык килергә уйлады булса кирәк, мәгәренки, фронттагы отделкомы старший сержант Фазыл Гыйматдиновичның характерын онытмаган икән, шындук пычак кайрарга утырды, янәмәсе, сарыкны үтмәс пычак белән суеп булмый.

Мин үзем кибет ягыннан бер әләнеп кайтырга булдым. Китешли хуҗага командирларча өзеп ике акыл бирдем — тормыш практикасыннан чыккан акыл икесе дә.

— Беренчелектән, — мәтәм, — мондый сакал баскан кеше белән мине компаниянә керер дип уйлама, башлап керешкән эшең шыл булсын: кырын ялап алган күк итеп. Бу синга теге вәсвәсә чутыннан беренче чиратта кирәге. Икенчелектән, — мәтәм, — бусын эткәндә ни тырышсам да көлмичә булдыра алмадым, — икенчелектән, үзең чамаларга тиешсең, бөтенләй үк минрәүләнеп бетмәгән булсаң. Катыклы ашта торып кына яшь хатынга ярап буламы соң, тиле. Сарыгыны үзем өчен суйдыра дип уйлама, гарык иттән. Үзебезнең Карамалыда да өй борынча сыйда йөрттеләр. Суйдырсам, синең үзең өчен. Ит ашамыйча ошарсың, бар, яшь хатынга.

Сарык ите алдыннан, фронтта булып узган хәлләрне, андагы дус-ишләрне — Әндриен, Мусабайны, Габадрилидзены и так далее искә төшерә-төшерә, кибеттән кайткан белән мыекларны чылаткалап кәефләнеп алгач, шуның өстенә өресе өскә бәреп чыккан ит шулпасын и, әтеп торган булам, итнең майлы-майлы калҗаларын да берсе артыннан икенчесен шудыра торгач, егетем бөтенләй шәбәеп китте.

— Дөресен эткәндә, товарищ сержант, мин монда хәзер Якуп түгел, Капутка әләндем. Әллә син Майтапны зрә сайратып йөртә дип беләсеңме? Мал җанлылыгы бар, минем сыер, тана, янә дә килеп биш баш сарык аның күзен яндыра — бусы бер статья. Икенче ягы да бар статьяның, икенче ягы шыл: бер дә кеше арасына кермим, собраниеләренә җөрмим, абзар кошы булып калдым. Хатын үлгәннән бирле шылай. Капут есть Капут.

— Җә булды, хатын үлүне статья дип тә санадык, ди. Хет әтергә мөмкин, сугыштан соң хатыннарның базары чабата базарына әләнде, берсе китте теге дөньяга, бишесе калды бу дөньяда. — Ә эчемне үземнең тычкан кимерә, — шапырынасың, Фазлуш, үзеңнең тапканың бармы? Кайчан Сәлимәң үлгәнгә? Берсе дә юлда аунап ятмый, — этәм. Ә тегенә турыдан-туры таранга барам — минем отделениенең менә дигән сугышчысы, тора торып нишләп әле син монда, үз илеңдә «Капут»ка әләндең? Бусы гүпчи дә башка сыймый.

— Ә анысына үзем гаепле, — ди сакаллы солдатым мөгрәп кенә, — сугышны бетереп кайткач, гел мактанып, ике сүзнең берендә «Гитлер капут!», «Нимес капут!», «Нужа капут!» дип кычкырып йөри булганмын, очкалак кеше ич мин, тегендә генә билгә буган каеш тотып торды.

— Хәтереңә авыр алма, Якуп малай, «кеше арасына кермим, собраниеләренә җөрмим, абзар кошына әләндем» дип, үзең үк этеп торасың. Кара инде бу сакал-мыегыңны, бөтен битеңне, авызыңны баскан ич. Әле ярый, калҗаларны шылай да үз урынына озата беләсең.

Таран арты таран тегенә. Кәеф күтәренке. Чукынсын, республиканы җәяү әләнү дигәнем барып чыкмаса чыкмас, мәгәренки, бу фронтовик дусны, бу «Капут»ны чистый акылына утыртмыйча моннан китте жук.

— Әйдә, ярый. Капут икәнсең Капут. Кырынмаган икәнсең — кырынмаган. Киттек Майтабың янына. Суд карарын шында ишетербез, — дип команда бирәм моңа.

— Пәкесе үтми ич аның, бик кырынасы да.

— Әле сүләшеп торган була. Командирның приказын нишлиләр?

— Үтиләр! — ди бу, җанлана төшеп.

Кыскасы шыл, мыек чылатудан, сарык итеннән соң беренче эшебез: ике этәч киттек без яр буе Майтап үенә. Исәп кыска: иң элек Майтап белән араларын ныгытырга, ике арага күпер салырга!

Урамда октябрь кичә, җил, салкын яңгыр сибәләп тора. Ә мин, башта бер эттем дә бугай инде, декабрьсыз башка киде жук. Ә хәзергесе

минутта бигрәк тә. Керпе чәчне үрә бастырып куйсам, хатын-кыз халкын сразы шом ала. Уйнап йөрмибез бит, ходай бирмеш кыяфәтенне күрсәтә белергә дә кирәк.

Барып кердек Майтапның үенә. Исәнме-саумы? Тегеме-бумы? Бер бездән генә калмаган, фасонына китермичә булмый. Мәгәренки, артык ваклану җук. Барып утырдым бер читкә дә, авыз тик тормасынга теш казый башладым. Тегеләр пышылдашалар икенче як читтә. Пышылдашалар, мин теш казыйм, мәгәренки, бер үк вакытта сүзләренә колак та салам.

— Бу ниткән әкәмәт кеше апкилдең син, Якуп? Шушы суыкта башына да кимәгән. Суык тияр дип курыкмый микәнни?

— Ул суыкка тимәсә, суык аңа тими. Минем фронтовик дус, командирым икенче төрле әткәндә.

— Хәлеңне белергә дип килгәнмени? Әллә үтеп кенә барышымы?

— Бөтенесе бергә, — и тавышын күтәребрәк, янәмәсе, мин дә ишетсенгә, — Татвоенкомат командировать иткән. Ягъни синең беләм минем араны юлга салырга. Син ни... саграк сүләш аның алдында. Юк-бар кәҗәләнүләреңне куеп тор.

«Капут» «Капут» та, сүләшә белә чукынмыш. Кара, кай яктан килеп сукалый. Ә мин, янәмәсе, ни дә ишетмим, минем үз эшем бар: теш казыйм.

Сүләштеләр-сүләштеләр дә болар, бер заман Майтабы монын юри минем якка борыла төшебрәк, күрәсең, юри мин ишетсенгә сузыбрак әтеп куймасынмы сүзне:

— Бик сыйлагансың, ахры, Якуп, кунагыңны. Бер генә дә теш казудан бушамый.

Инде дә ишетмәмешкә салышып калып булмый, сәгате сукты, әтергә кирәк сүзне и ишеттерә торган итеп әтергә кирәк.

— А как же сыйламаска фронтовик дусны. Җитмәсә, кеше командировка белән җөри. — Нәрсә булса шул, башта да бар чак, дәррәү өнен алырга булдым мин «аяклы мал ятратучы» бу шома Майтапның, — ике мужикка ни читенлеге бар, ектык та суйдык Якупның бер сарыгын. Командирыннан жәлмени.

Якуп та сүзгә кушыласы итте:

— Ул арада командиры җәлт кенә кибет ягыннан урап кайтты. Утырдык-утырдык та узганнарны искә төшереп, менәтерәк синең хәлне дә белергә булдык.

Өне алынмады Майтап толның, мәгәренки, Якуп ягына күзенең агы белән, бик тә ачуланып бер карап куйды и төртмәле итеп сорады:

— Алайса сарыкларың дүрт кенә баш калды, Капут?

Якубым ык-мык, тамагына имән чикләвеге тыгылган үрдәк күк — җәл дә мескен, юашлыгы белән ачуны да китерә. Дәрәҗә бар — командиры, командировка белән йөрүче — бу хәтлесенә хәтта үзем дә ышана башладым хәзер. Тотындым берьюлы кисеп ташларга:

— Кайдан чыккан сүз булды ул «Капут»? Сугыштан җиңеп кайткан кешегә, панимаеш. Минем әтчәйни солдатым рядовой Якуп Харисовка шындый кушамат? — И өзәргә икән өзәргә, белеп торсын уйнап җөрмәгәнне. — Әле үне, каралты-кураны колхозның төп участогына күчергән вакытта сарыкларның тагын берсе ычкынмагае. Өмәгә килүчеләрне, булышучыларны сыйларга кирәк ич. Әле сарык белән генә калсак!

Бу юлы икесе дә бер-берсенә караштылар, икесе дә аптыраганнар иде. Шылай өзеп сүләшми булмый бу мокытлар белән. Белеп торсыннар, азбар кошы булып, замана әткәнгә каршы килергә ярамый. Күчәргә икән — значится күчәргә. Үләнергә икән — значится үләнергә.

## XIII

Иртәгесен үк, икенче эшем итеп, әлеге төп участок дигәннәренә киттем. Ерак түгел, нибары дүрт-биш километрдыр. Алай булса әле. Сызгыра-сызгыра, җырлый-җырлый бардым — җәяү. Хет үтер, җәяү җөргәндә үтер, үлеп яратам җәяү җөрүне. Элек күзгә күренгәнне әтәм. Ике катлы таш мәптек, җанында бер катлы, мәгәренки янга җәелгәне, агач мәптек, җанында интернаты — күрше авыллардан килгән бала-чагага куна-төнә җату өченгә. Почта бүлеге, ике ишекле таш магазин, дворец культура, урам саен фонтал, кнопкасын басасың, суы ыргылып тора. Без яшь чактагы кебек тезелеп-тезелеп чишмәгә суга барулар беткән. Бу чаклысы, иске тормыш калдыгы дип әтсәгез әтерсез, миңа зык та ошамады. Авыл — чишмәдән су ташучы яшь кызлары белән матур ул. Җә, бер якка куй бусын, иске тормыш калдыгы ни әтмәс. Сельсовет, колхоз правлениесе, кунак йорты — бөтенесе балтадан-пычкыдан гына төшкән. Тирә-җүндә разный анда мастерскойлар, терлек каралтылары — гел бер таш кала. Бер кешегә бер сәләм бирмичә, бер кешедән бер сәләм алмыйча, керпе чәчемне үрә бастырып карап җөрдем дә, барып кердем правление дигән җирләренә. Кабинет та кабинет, кабинет саен телефон, кабинет саен өчме-дүртме кеше. Язалар, телефоннан сүләшәләр, счет төймәсе тарталар, гәзит укыйлар — әтеп-сүләп бетермәле түгел. Мин берсендә бер тукталып, вакланып тормадым, туп-туры председательнең үз кабинетына үттем. Башны салып торасы җук. Башта булмагач честь биреп торасы да түгел, туп-туры үгезне мөгезеннән алдым. «Үгезне» дигәнем үземне дигән сүзем.

— Шындый-шындый җирдән, шындый-шындый командировка, Якуп Харисов дигән колхозчыгызның элекке командиры, кәнкрит задачам: аның тормышын ипкә салу, аны үләндерү и так далее. Сезгә, сезгә дигәнем колхоз правлениесенә, претензиям: ник сез аны шушы таш кала-баш калагызга күчермисез? Анда, тыкрык та чат белән тулган иске авылда тотасыз?

Боларның нә әтәсен алдан ук белеп сүләшәм.

— Үзе гаепле, «без аңа, как элекке фронтовик, өч көндә бар мөлкәтеңне күчереп, үеңне алты почмаклы итеп салып бирәбез, бөтенесе колхоз чутыннан, — дип карадык, тешләк бит, сез дә, күрәсең, җитәрлек тәрбия бирә алмагансыз, сугыш та акылга үрәтмәгән. «Зыйрат, ата-ана нигезе, күпме яшисе калгандыр» — әткән сүзе вана шул булды.

— Карышмыйм, сезгә әткәне шылдыр, мәгәренки сезгә ул бөтенесен әтеп бетермәгән, йөрәк майларым. Аны җибәрмичә бәйләп торган «аркан казыгы»н мин белеп алдым и мин ул «казык»ны суырып чыгармыйча моннан китмәячәкмен. Моны фронтовик алдында фронтовикның биргән сүзе дип карагыз, анты дип үк әтсәк, зурга китү булыр.

Кыскасы, правление кешеләре белән кәнкрит сүләшеп, кәнкрит эшкә керешергә булдык. Әттем, материалыгыз, транспортыгыз әзер булсын, урынны авылның уртасыннан бирегез, ул уртада торырлык әдәм. Минем кул астында сугышты, начар сугышмады, калган ягын, как элекке командиры, мин үзем җайлармын, дидем. Честное пенсионерское, шулай әттем.

Китешли, әлеге тегe ике ишекле таш магазиннарына кереп, электробритва ала киттем. Тыкрык белән чаттан гына торса да, электрсыз калдырмаганнар авылны, әтәм, минем «Капут» дус тырмашып яткан авылны. Кайттым да кулына тоттырдым электробритваны.

— Элекке командирыңнан сиңа бүләк бу и шылай дип кабул ит, — әтәм и шундук приказ тәртибендә өстим, — хәзер үк, шышы минутта ук яңакларыңны бу сары сакалдан әрче, калганнарын азак сүләшербез.

Тимерне кызуында сугарга яратам, фронтта күнегелгән адәт и шында ук бу сакалбайга ләм-мим әтмичә киттем. Кая? Тегe ярга ябышып

каткан үгә, моның Майтабына. Аптырамакчы, иде теге, аптырап торырга сәбәп бирмәдем, кабыргасы белән куйдым сүзне:

— Уйладыгызмы? Нинди дә булса карашка килдегезме? — мәтәм.

Теге ык-мык, башына яшен китереп орган кебек үрәләй катты. Шыл миңрәгән арада мин автомат урынына яңадан «очередь» бирә башладым:

— Мин анда правлениегез белән сүләшеп кайттым. Авылның кыл уртасыннан урын бирергә булдылар. Материалы, осталары, транспорты колхоздан. Өч көннән эшкә керешергә булдык. Өмәчеләр, эшчеләр өчен Якупның тагын бер сарыгын суябыз. Шылай сүләшенгән. Тегесе бетүгә таба бара, ике мужик, көн-төн бүре урынына ит ашауга ничек төтмәк кирәк. Якупны хәзер танымассың, чырай бөтенләй үзгәрде, сүзе бөердән чыга, кырынды, чистарынды, чистый Суворовский кавалер, панимаеш. Сезгә, сеңелкәш, уйларга өч көн вакыт. Якупка кияүгә чыгып, аның белән алты почмаклы яңа үгә, кала дип үк этмәсәк тә, бер ише кечерәк каланны орып бирә торган шындый культура үзәгенә китәргә риза булмасаң, үзеңә үпкәлә. Миндә икенче бер решение дә өлгереп килә: Казанда минем ун ел ирсез каңгырап яшн торган балдыз бар. Ир чырае күрсәтсәң, җир читенә китәргә әзер. Якупка шул балдызны китерәм дә утыртам.

Бу ходны шында гына уйлап чыгардым, сабын күбеге бер эткәндә. Ә теге «культура үзәге», «каңгырап тора», «сүзе бөердән чыга», «сеңелкәш» кебек культурный сүзләр, этер идем, шылай ук ярап куйдылар. Кыскасы, берчәк йомшарттым бит Майтап тәтәнне. Мәгәренки, шылай да ык-мыктан узып ни дә булса этмәде. Әтерме соң дәррәү кубып, хатын-кыз бит ул кырык катлы, әгәр кырык биш үк булмаса.

Китешли, ишек токкасына ябышкач, яңадан борылып, янә бер өзеп этәсе иттем:

— Уйлар өчен өч көн срок бик җиткән, фронтта кала алу өчен дә андый озын срок бирмиләр. Үз башыгыз пешереп бетермәсә, булышу өчен иртәгә мин Якупның үзен җибәрермен.

И вәссәләм шының белән. Ышанычым нык: апагызны яртылаш бөктем. Чистыйга бөгеп салу анысы инде Якуп эше. Чынкыйлап та «Капут»ка эләнмәгән булса, әлбиттә.

Кайтып керсәм, Якубымны танымыйм. Бит-яңак ялтыраган, өстенә яңа кәчтүмен киеп алган, үзеннән одеколон исе аңкый, кыскасы, тач кияү җегете. Минем Майтап тәтәкәй алдында борчак сибүләр яртылаш барып чыккан дигән сүз. Инде мин тегендә булган сүзләрне дә тезеп салгач, Майтапның өнсез-телсез калганлыгын да өстәгәч, бөтенләй яшәреп, алсуланып китте булачак кияү җегетем. Шылай да эчен тырнаган бер соравы бар икән:

— Тагы бер сарыкны суярга туры килер, дигәч тә бер сүз дә этмәдеме? Только ни... Боргаламыйча, как фронтовик фронтовику сүлә сүзеңне.

— Боргалаудан миңа нинди чут? Миңа тизрәк синең тормышыңны җайга салу кирәк. Командирдан ни сорала? Оныткан булсаң, исеңә төшерим: командирдан беренче чутта үз кул астындагы рядовойлары турында кайгырту, аларның эшен җайга салу сорала.

Якубымның башы түшәмдә. Шылай булмыйча соң, эше күләнергә тора бит бахырның.

— Бүген, айса, бәйрәм итәбез бер. Казан тутырып ит салам.

Теле ачылды, сүләшә башлады бу. Хет сүзләрен тот та «Чаян»га бастырып чыгар.

— Иттә икән хикмәт, малай. Төннәрен торып утырам Майтап җаныйны искә төшереп, — дигән була җырык авыз. Кәчтүмен салу да җук, чолан белән ү арасында чабулап җөри. Янәтерәк командир сүзе кирәк булды бу котырганга.

— Акылыңдамы, әллә шаштыңмы син? — Әтәм моңа, — иртәгә Майтабың янына киеп барасы кәчтүмең ич. Казан, аш-су тирәсендә киеп җөрсәң нишли ул? Май чәчри. Корым тиюе бар. Салып ат элек кәчтүмеңне.

Әле ничек кенә салды, таслап төреп куйды, өстенә җәймә каплады — янәмәсе, тузан кунмасынга. И тотынды чабарга. Ул кичне янә утырдык. Мәгәренки бушка түгел, моның иртәгә булачак визиты өчен план корып утырдык. Кәефләнеп алгач моның авызыннан Майтап төшми. Шүрли дә үзе:

— Ничек сүз башларга булыр икән? Мин бит кыз-хатын белән сөйләшүнең рәтен үк онытып бетергәнмен. Ун ел хатынсыз торып соң...

— Нинди рәт кирәк аңа. Җебеп кенә торма, вана шыл. Башла уннан, күч әкренләп сулга.

Кешегә акыл сатудан да ансат эш жук. Ә соң үзем, Җамал-прическа белән, Гүләнең дәү әнисен әтәм. Җәйнең-җәй буе чәй эчеп йөреп ни кыйраттым.

Иртәгесен, әлбиттә, таң тишегеннән түгел, кичкырын, бу Якуп-жиңги сыерын саугач, җиренә җиткереп әзерләп, одеколонын-ниен сиптереп, кирәкле инструктажны ясап, озаттым моны и күз дә йоммыйча әләнеп кайтканын көтә башладым. Уен-муен түгел, батмаса гына ярый.

Көтәм-көтәм япа-ялгызым, башка шыр тиле уйлар килә: «Әллә сразы батты ук инде бичара әдәм баласы?»

Сәгать уникенчеләр булгандыр, кайтты бу. Хәвефсез-хәтәрсез генә. Хәтта, мин әтер идем, авыз ук җырылган моның.

— Имансыз гына икәнсең, иптәш сержант, — ди бу, солдатча точно булырга тырышып. Мәгәренки, авызны җыя гына алмый бит, — нинди генә догалар укып өшкердең син ул кире беткәнне. Майлаган кебек булган. Шундук самаварын куеп җибәрде, суелган сарык турында ник ләм-мим сүз кузгатсын. Минемчә балдызың белән котын алгансың син аның. Чынлап та, бармыни соң синең шындый балдызың?

— Җә бөтенләй ычкына башлагансың, җә берәр шикле эшең бар, шылай шыр тиле булырга ярыймы ир кешегә. Нинди балдыз, ди ул. Андый балдыз булса, үземнән артмас иде, ничә җәй, ничә кыш хатынсыз аптырап җөрү. Иргә чыгасы килгән тол хатынны шылай да куркытмагач, тиле. Юк белән башымны әләндермә, рапорт бирүче дневальный кебек ярып сал: эш пешәр төслеме?

— Самавар кайнаганчы кирегә сукалады, чәй эчкәндә дә шылай сукалап маташты, илла күрәм, ир диген кеше белән кара-каршы утырып чәй эчү ошый моңа. Бигрәк тә синең балдыз дигәнең өнен алган бичараның, кайта-кайта гел шул турыда сорашты.

— Рапорт булмады бу, су изеп май чыгарырга маташу булды, — дип шып туктаттым котырмышны, артык тыела алмыйча, — син миңа шыны әт: разведка нәтиҗә бирдеме? Үзәк поселокка күчәргә, сиңа кияүгә чыгарга ризамы? Тагын бер сарыкны суябыз дигәнгә ничегрәк карый?

— Бөтенесе без корган план буенча, Фазыл Гыйматдинович. Күчәргә дә, ЗАГС кәгазенә кул куярга да риза. Гупчи дә әләндереп куйгансың ич Майтапны.

— Әләндерүен анысын син әләндерерсең, — дим теге җырык авыз җаена ята төшеп, — шылаӣ да ачык әтеп сүләш: берәр ничек мачы булдымы соң? Вәгъдәләшү бүләге рәвешендә. Чиккән кулъяулык дип юкны сузып тормыйк, заманасы ул түгел хәзер, но берәр төрле кети-мети? Ич югы, битеннән бер пәп итеп алдыңмы?

— Җәсәнә, командир, син тагы бигрәк, — ди бу, кызлар кебек кызарып, — күрсәтер Майтап кети-метине. Ул якка җен кебек кире беткән нәрсә бит ул.

Аллалары үзләре белән — вакыты җиткәч җеннәре качар. Мөгәренки, Якупка нярең яңа урынга — культура учагына күчәргә риза булуы — беренче план хәзергә шыл.

Тыкрыклардан гына торып калган бу котсыз авылдан туйган идем. Колхоз сүзендә торды: бирде машиналарын, бирде осталарын, нинди-дер зур төзелештән артып калган агачлары бар икән, аларны атты, купты бер заман пәри туе: монда шатыр-шотыр каералар, сүтәләр, тегендә — культура учагында шак та шок кагалар, яңа дворец җиткезәләр. Үз чиратымда мин дә кыска тоттым сүзне:

— Минем командировка рядоваем Харисовның тормышын рәтләгәнчегә хәтле генә. Давай пәри туен яңа ү туена и, шында беррәттән, Майтап белән Якуп туена да әләндерәбез,— мәтәм.

Шыннан шыл, кушылдылар, башлары җиденче кат күктә. Бик шәпләп туй иттеләр. Шындый-шындый бер хәл була-нитә калса, дип ике якның да җыя килгән капиталлары булган икән, селкеп салдылар янчыкларын. И майлаган кебек торып киттеләр.

И әтергә кирәк, минем уйлап чыгарылган командировканың срогы да шында тулды. Кешегә чыккан кояшка гомер буе кызынып ятып булмас, үз кояшымны эзләп табарга кирәк. Рядовоем Якуп Харисовның тормышын ипләдем, хәзергә шыннан бик тә канәгать. Шыл яктагы бер атсыз-котсыз разъездга чыгартып куйдырдым да, шыннан поездга утырып чап үз Казаныма. Әтәм үз-үземә: «Минем кояш анда үзе мине көтә булыр».

## XIV

Көткән пычагым! Алтмышка җиткән башы белән чәченә прическалар ясатып, көн саен бер күлмәк алмаштырып, сүләшкәндә әллә ничек иңбашларын сикерткәләп сүләшүеннән анау җәй көне үк шикләнгән идем. Җәй буе самавар яндырып эчергән чәйләрем әрәм китте, тапкан үзенең сыңарын, кияүгә чыккан. Колакка кереп калган адресын искә төшереп, Жданов урамына — үзләренә үк бардым, беләсез, һәр чактагы кебек башны югары тотып. Әлеге кияүгә чыгу хәбәрен ишетүгә баш шундук сыгылып төште, юл буе сүгенеп кайттым. Әтәм, синең үзендә гаеп, Фазыл Гыйматдинович, имештер, җәяүләп Татарстанны әләнеп кайтмакчы. Гел шул прическалы тутакай тирәсендә генә әләнәсе иде, Ай Җир тирәли әләнгән кебек.

Бер уйласаң, чүп тә түгел. Башны бик югары, җиде кат күктә тота иде. Аннары, точны гына әткәндә, бик алай дан нәмәстәкәй дә түгел иде. Борыны янында гына күлмәк сәдәбе хәтле миңе бар иде, капкара миң. «Менә бу минем яшь кәләш була инде!» дип кешегә, дусишләргә күрсәткәндә, бигайбә, иң элек күзгә шул кара миңе бәреләчәк. Дөрес, сүзгә-өнгә осталыгы бар иде, хет алды, хет арты, ул тиклесен әтми булмый. Пенсиясе дә ярыйсы иде. Мәгәренки очкан бит, очкан артыннан очарга канат җук.

Аның каравы, бер юаныч калды күңелдә, яңа алып кигән тун шикелле гел җылытып тора. Ничәмә-ничә ел бергә азап чигеп, Гитлер бандасын бергә тукмап җөргән фронтовик дусымның тормышын рәтләдем. Әледән-әле хат язып тора, канәгать Майтабыннан. Алты почмаклы яңа үеннән, и әтергә кирәк, культура учагыннан да эрегән азыкаең, әтерсең яңа гына мунча чабынып чыккан.

Язган бер хатында: «Бөтенесе синең аркада булды, иптәш сержант, Майтап җаныкаем җәйгән җылы-йомшак урынга ·барып ауган саен син бәгырь искә төшәсең, син ачтың миңа бу күк капусын». И так далее и шылай тезә дә тезә.

Ә бер хатында хәтергә яхшы ук кереп калырдай бер нөктәсе бар иде. Анысын, лекторлар кебек, күзлек киеп, хатының кәгазенә карый-

карый, сүзгә-сүз укып бирәм, штобы «борчак сибә бу, гомергә сибеп бетермәгәнне» дип уйларга урын калмасын.

Язып килә-килә дә бу, аннары менә былай дип тезеп китә: «Ул Майтапны әйтерең бармы, сержант җаным, бу яңа җирдә алыштырып куйган кебек булды. Кич саен мине клубка сүри — спектакль, концерт карарга.

Аннары тагы әкәмәт ягы бар, аяклы мал өчен гел җан атып торган шыл коткы хатын, җен алыштырдымы үзен, бер көнне үзе китереп әтә: «Суй тагы бер сарыкны, Якуп. Үзем өчен дип әтмим, миңа ит булса ни дә, булмаса ни, ә синә ит ашамыйча гупчи дә ярамый. Ир кеше итсез ни... канатсыз кош», — дип куйды мәсьәләне. «Тагын берсен суйсак, икәү генә кала бит сарыгыбыз, Майтап. Уйлыйсыңмы шыны?» — дим. Җавапка аптырап тормады, җавабы кесәсендә генә икән: «Калса тагы. Язга бәрәнләп җибәрерләр, тагы дүртәү булыр», — ди.

Гел клубка йөреп, лекциясен-мазарын тыңлап, күзе ачылып китүеме бу, әллә озак тол торган кыз-хатынның бер мәл шылай котырып алу чире кузгаламы икән? Син олы кеше, командир кеше, тере нимесне «тел» итеп апкайткан чакларың булды, яшь чагында мәктәбен дә күргәнсең, мәңге онытасым юк, миңа карата күп яхшылыклар эшләдең, инде тагы бер яхшылыгыңны җәлләмә. Әтеп яз миңа дөп-дөресен генә: дөрес эздәме минем Майтабым, әллә ни... этергә дә уңайсыз уңайсызлыкка — берәр чир зәхмәте кузгалдымы, әдәм көлкесе?»

Мин, әлбиттә, алай кырлап-сырлап тормадым, хәер, кырлап-сырлап торырлык сәбәп тә күрмим. «Дөрес эздә, Якуп, Майтабың, яшь кәләшне ни... әллә азбар кошы булып сайрап кына тотармын дисеңме? Халык ни ди андый чакта? Халык менә болай ди андый чакта: «Хатын алмак — нә кирәк? Көн дә батман ит кирәк», ди. Ә синең, иптәш Харисов, гап-гади бер рядовой башың белән атай-бабайлар сүзеннән чыгарга какой-такой хакың бар?»

*

* *

Юктан гына танышып киткән Фазыл абзыйның миңа сөйләгәннәрен, дөресен әйтә калсак, миңа сөйләгән атлы булып, үз сүзеннән-хикәяләреннән үзе үк тәм табып, ләззәтләнеп сөйләп утырганын, мөмкин чаклы түкмәскә-чәчмәскә тырышып, булдыра алганымча, аның үзенчәрәк чыгарырга азапланып, сезгә сөйләп бирдем, укучыларым! Ләкин үзем сизеп торам: Фазыл абзыйча ук чыгарып булмады. Аннары шунысын да сизеп торам: тик үзләрен генә яратучы кайбер тәнкыйтьчеләрнең бу «куян шулпасының шулпасын» ошатмаулары да ихтимал — хәер, анысы алар эше. Ләкин бит дөнья киң, анда, чырай сытып яшәүчеләргә караганда, елмаеп яшәүче көләч кешеләр, шул җөмләдән карт көләчләр дә, чагыштырмаслык күбрәк. Мин бу әсәрне, барыннан да бигрәк, әнә шулар өчен яздым.

*1977. Казан.*

## Салих Баттал

### «Татарлар елмаеп үлделәр...»

Исән калырбыз дип өмет итеп
үз-үзеңне алдау нәрсәгә!
...Җәлилчеләр менә көрештеләр
душ алдында соңгы мәртәбә...

Яшәделәр бер җан, бер тән булып,
көрәштеләр янып бер утта.
Үлгәндә дә алар бер-береннән
калса калыр ярты минутка.

...Көрештеләр. Дуслык, кешелекнең
бөек дәрәҗәле бер чагы.
Бу мәңгелек кысыш — Курмаш кулы,
Алиш ирене, Булат кочагы...

Көрәштәшләр күңел төшермиләр,
бернәрсәгә юньләп ис китми.
«Үлем җиле исә күңел гөленә,
яфрагын да ләкин селкетми.

Үтерегез, әйдә, үтерегез,
котырыгыз, аннан, биегез,
тик шагыйрьгә кара китерегез,
һәм кулына каләм бирегез!» [1]

Кайда инде хәзер каләм, кара?!.
Язылыр урынын соңгы җыр тапмый.
Соңгы җырын Муса шырпы белән
сабын өсләренә тырнаклый.

Башкалар да үз сабынын суза —
җитте «автограф» алыр чак.
«Без үлмибез, мәңге яшибез, диләр,
Муса шигыре белән юынсак».

Култык һәм кул таякларын бергә
штативы итеп фотоның,
ботинкасын аппараты итеп
маташуын күргәч Батталның,

[1] М. Җәлил шигыреннән.

— Рәсемгә төшәбез! — дип, бер төркем
Муса тирәсенә елышты...

Бу көйдергеч шаярудан сакчы
куркып — карамаска тырышты.
Тик кояштан кем күз йомып котыла?!.
Күрде... Башкалар да күрделәр.
Мәңге яңгырар бу өч сүзлек җөмлә:
— Татарлар елмаеп үлделәр!..

## Ике юлчы

Ике юлчы сәфәр чыккан.
Атлыйлар алар сак-сак,
һәр адымга план корып.
Ун адым гүя — максат.

Исерекләр дә түгел бит,
юл да такыр лабаса,
нигә сират күпереннән
үткәндәй алар баса?

«Егылма... Тор!.. Шулай бас!» — дип
олысы кечесенә
әйтә. Гәрчә егылырга
чират җиткән үзенә.

һәм үзенең максатына
сөйрәлеп җитте чак-чак:
ишек төбендә эскәмия,
шуңар утыру — максат.

Сәфәр түгел, эстафета.
Бу — яшәү алымнары:
яшенең — беренчеләре,
картының — актыклары.

Ә үзләре гади генә
йөреп кайттык дип саный —
туксан яшьлек бабасы һәм
тугыз айлык бер сабый.

## Әнгам Атнабаев

*Талантлы башкорт әдибе — шагыйрь һәм драматург Әнгам Атнабаев исеме Татарстан укучыларына да яхшы таныш. Аның пьесалары буенча куелган спектакльләр республикабыз сәхнәләрендә уйналды, шигырьләре әледән-әле газета-журналларда күренә килә.*

*Февраль аенда Ә. Атнабаевка 50 яшь тулды. Әдипне олы бәйрәме белән кайнар котлап, укучыларыбыз игътибарына аның яңа шигырьләрен тәкъдим итәбез.*

### Сау булыгыз!

Язын килгән кошлар көзен китә,
Кояшлар да чыга баерга...
Кешеләрне язмыш очраштыра,
Язмышларны юллар аера.

Канатларны җилләр каергандай,
Юллар алып китә еракка;
Кемне илтеп ташлый теге ярга,
Кемне илтеп бәрә бу якка —
Юллар алып китә еракка.

Бер-беребезне күреп туялмадык,
Сөйләшәсе сүзләр күп калды;
Сезнең белән күзне-күзгә терәп,
Аттырасы иде күп таңны!

Кайгыларны шатлыкларга салып,
Күтәрәсе иде бер тустак!
Җырласак та, хәтта еласак та,
Гафу итәр иде бит дуслар.

Вакыт — мәңгелек тә, гомер — кыска,
Китәрләргә сукты сәгатьләр.
Кунак булып килә белгән кебек,
Китә белү дигән гадәт бар.

Сез каласыз, дуслар, без китәбез,
Атларыбыз инде җигелгән...
Сагынуыбыз сезгә килеп торсын
Иртән искән йомшак җил белән.

Таулар белән таулар очрашалмый,
Кеше белән кеше очраша...
Бер-беребезне күреп очрашмасак,
Очрашырбыз әле җыр аша...
Очрашырбыз әле җыр аша!

# Машиналар

*Шаяру катыш*

Җәй туктамый, кыш туктамый машиналар,
Көн йокламый, төн йокламый машиналар!
Җир өстеннән, су өстеннән, су астыннан,
Һавалардан ашыгалар машиналар.

Заманында тизлек һәм көч бирәмлеге
Булган атлар хәзер бездән көнләшәләр:
Утарларның киртәсеннән башын сузып,
Моңсу гына кешнәп безгә эндәшәләр.

Туктамыйбыз, тыңламыйбыз, ашыгабыз:
Тизлек кирәк, тизлек кирәк кешеләргә!
Мөмкин булса машинада керер идек
Читән аша керә торган күршегә дә.

Акыллы да, акылсыз да машиналар,
Сәбәпчеләр яманга да, яхшыга да...
Тора-бара, бара-тора үзебез дә
Әйләнмәсәк ярар иде машинага.

●

Көтмәгәндә килде яңгыр,
Давыллап, шаулап койды,
Болытларны бертуктаусыз
Яшен камчылап торды.

Аһ, күкләрнең күкрәүләре
Тетрәтте йөрәкләрне.
Тыныч кына гамьсез яшәү
Пәрдәсен ертып бәрде.

Урамнарга алып чыкты,
Елатты, шатландырды,
Яшен кебек уйнап торган
Толпарга атландырды.

Алып менде болытлардан
Күкләрнең зәңгәренә...
Һәм яндырды утларының
Тәмугтан зәһәрендә...

Көтмәгәндә китте яңгыр,
Ул башка җирдә коя...
Офык читендә яшенли,
Еракта күкрәп куя.

...Син дә шулай үтеп киттең,
Керәсең төшкә сирәк...
Ерактагы күкрәү сыман
Сулкылдап куя йөрәк.

●

«Бер алманы бишкә бүләек,
Беребез өчен беребез үләек...»
Дип җырлаган безнең бабайлар,
Дип җырлаган безнең атайлар...
Бер алманы бишкә бүлгәннәр,
Берсе өчен берсе үлгәннәр.

Җыр сыналган төрле заманда:
Яхшы заманда да, яманда...
Ил өстенә кытлык килгәндә,
Ил таянган шушы ирләргә:
Бер телемне бишкә бүлгәннәр.
Берсе өчен берсе үлгәннәр.

Җыр сыналган төрле заманда:
Ут-давыллы, яулы яланда...
Ил өстенә дошман килгәндә,
Ил таянган шушы ирләргә:
Бер үлемне бишкә бүлгәннәр,
Берсе өчен берсе үлгәннәр.

Җыр сынала әле һаман да,
Мәшәкатьле әле замана...
Ил өстенә кайгы килгәндә,
Ил таяна шушы ирләргә...
Бер кайгыны бишкә бүләләр,
Утка-суга бергә керәләр.

Тормыш дигән бөек яланда
Җыр яңгырый әле һаман да —
Үткән буыннарның авазы,
Ата-бабаларның наказы:
«Бер алманы бишкә бүлегез,
Берегез өчен берегез үлегез!»

●

Сагынганда
      аккан суга кара,
Сулар булып шаулап мин агам,
Ярларына дулкын кага, димә,
Йөрәгеңә килеп мин кагам.

Сагынганда
      болытларга кара,
Кара болыт булып мин агам,
Шыбыр-шыбыр яңгыр ява, димә,
Күз яшьләрең булып мин тамам.

Сагынганда
      яуган карга кара,
Ак бураннар булып мин явам,
Ак бураннар адаштыра, димә,
Сине адаштырган мин һаман.

Надежда Крупская

# ВЛАДИМИР ИЛЬИЧНЫҢ СЕҢЕЛЕСЕ

Мария Ильиничнаның бөтен тормышы Ильич тормышы һәм эшчәнлеге белән аерылгысыз бәйләнгән. Ул Сембер (хәзерге Ульяновск) шәһәрендә туып үсә. Әтиләре мәгариф фронтында армый-талмый хезмәт иткән кеше була. Югары культуралы бу гаилә үз заманының алдынгы интеллигенциясе мәнфәгатьләре белән кызыксынып яши. Ир һәм кыз туганнар үзара бик тату булалар. Ильич яшь чагыннан ук кечкенәләргә — сеңелесе Мария Ильинична һәм энесе Дмитрий Ильичка карата аеруча җылы мөгамәләдә була һәм алар каршында гаять зур авторитет белән файдалана. Абыйсы Александрның (1887 елның 8 маенда) җәзалап үтерелүе уңае белән әнисе, апалары һәм Ильичның кайгы кичерүе тугыз яшьлек Мария күңелендә тирән эз калдыра. Россиядә әле эшчеләр хәрәкәте күтәрелә башлаган гына вакытта бөтен иҗтимагый укладны тамырыннан үзгәртеп кору юлларын эзләгән абыйсының һәлакәте турында хәбәр алынгач, Ильич әйткән сүзләрне ул гомерлеккә хәтеренә сеңдерә. Александр Ильич чикләнмәгән золым һәм изелүгә каршы ялгыз көрәшчеләр юлын сайлаган булса, Ильич: «Без башка юл белән барырбыз», — ди, һәм Мария Ильинична шушы башка юл, Ленин юлы белән барды.

1895 елда, Мария Ильиничнага 17 яшь чакта, Петербургта Ильичны кулга алалар. Әнисе һәм апасы белән Мария Питерга килә, абыйсы белән күрешүләргә йөри, киң колач белән эшчеләр хәрәкәте җәелеп килүен күреп-белеп тора. Апасы Аннадан, Ильичтан яшерен эш алып бару серләренә өйрәнә. 1899 елда Мәскәүдә Мария Ильинична кулга алына һәм Нижнийга сөрелә. Мәскәүгә кайткач, Мария Ильинична эшкә тагын да ныклабрак керешә. 1901 елның мартында, апасының ире Марк Тимофеевич Елизаров белән берлектә, партиянең Мәскәү оешмасы эше буенча баштa төрмәгә утыртыла, аннары Самарага сөрелә.

Ул чакта чит илдә Ильич көче белән гомум рус социал-демократик «Искра» газетасын чыгару оештырыла. «Чаткыдан ялкын кабынyр» — «Искра»ның лозунгысы шундый. Бу ялкын революцион янгын булып дөрли башлый. Чөнки Россиядә эшчеләрнең бәйләнешлә-

рен ныгыту, оештыру буенча армый-талмый эш алып баручы куәтле оешма бар иде. Массалар арасында пропаганда һәм агитация эше җәелдерелә барды.

Оялчанлыгы һәм шул ук вакытта гадәттән тыш инанганлыгы, үз сүзендә нык торучанлыгы өчен без Мария Ильиничнаны яратып «аю баласы» дип йөртә идек. Барыбыз да аның кайгыртучанлыгын тоеп яшәдек. «Аю баласы»н яратмаска мөмкин түгел иде.

Самарада Мария Ильинична Кржижановский, Ленгник, Красиков кебек «Искра» агентлары белән берлектә партиянең II съездын әзерләшә. 1903 елда II съездда большевиклар ягына баса. Эш колач җәя бара. 1905 ел якынлашкан чак иде бу. 1904 елның гыйнварында Киевтә Мария Ильинична, апасы Анна Ильинична, энесе Дмитрий Ильич һәм аның хатыны Зинаида Павловна Кржижановская, Р. Образцова һәм башкалар белән берлектә, кулга алына. Июнь аенда төрмәдән чыгарылгач, бик сизгер күзәтү астында яшәү сәбәпле, эшләргә мөмкинлек булмый, һәм ул 1904 елның ахырында Женевага Владимир Ильич янына күченә. Шунда абыйсы җитәкчелегендә революцион эшкә чума. 1905 елда Питерга кайтып, эшчеләр арасында эшкә кушыла. 1907 елда, реакция кысрыклый башлагач, Мария Ильинична Ильич җитәкчелегендә Маркснын «Кугельманга хатлар»ын һәм «Зоргега хатлар»ын тәрҗемә итәргә утыра.

1908—1909 елларда Женевада һәм Парижда яши, Сорбоннада укый (француз телен ул яхшы белә торган була).

Мария Ильинична Ильичның отзовистларга һәм партиянең башка төрле дошманнарына каршы көрәшендә булыша. 1910 елда Мария Ильинична Саратовка килеп урнаша һәм, 1911 елда кулга алынып, өч елга Вологда губернасына җибәрелә. Анда тимер юлчылар арасында эшли, большевиклар партиясен ныгытуда булыша.

Мария Ильинична һәрчак Ильич турында кайгыртучанлык күрсәтеп яшәде: аның кием-салымы, туклануы турында кайгыртты, аны көнкүреш ваклыклары борчуыннан сакларга тырышты.

1917 елның мартыннан 1929 елның язына кадәр Мария Ильинична «Правда» газетасының секретаре, аннары редколлегия члены булып эшләде. Массалар белән эшли белүе, халык фикеренә ленинча колак салу гадәте аны эшче-хәбәрчеләр хәрәкәтен актив оештыручы итеп күтәрде.

Мария Ильиничнаны күпләр белә, ул үзе дә бик күп кешеләрне: эшчеләрне, хәбәрчеләрне белә, хәтерли иде.

Ильичның тормышына һөҗүм итү вакыйгасын, аның авырып ятуын һәм үлемен Мария авыр кичерде. Ильичны ул бик ярата иде һәм абыйсы да аны шулай ук яратты.

1933 елның 8 мартында ул Ленин ордены белән бүләкләнде. Партиянең XIV съездында ул ЦКК члены булып сайланды, аннары аның Президиумына кертелде, партия юлын бозуларга каршы көрәш алып барды. Партиянең XVII съездыннан башлап ул — совет контроле комиссиясендә, бераздан шул комиссиянең жалобалар бюросы мөдире. Бу эштә ул аеруча ачылып китте, һәртөрле ялгышуларны, бозуларны төзәтү өчен, совет эшен яхшырту өчен күп тырышлык куйды. Бу эшен ул үзе дә яратып, рухланып башкарды. Үзенең көчен ул кызганмый иде, иртәдән төнге сәгать дүртләргә кадәр ялсыз, тәнәфессез эшләде. Авыру килеш тә район, Мәскәү шәһәр һәм өлкә конференцияләре эшендә актив катнашты. Конференциядән кайтып ул үзен начар хис итә башлады, урынга ятарга мәҗбүр булды һәм шул ятуыннан күтәрелә алмады.

13 июнь, 1937 ел.

## Елена Стасова

# УЛЬЯНОВЛАР ГАИЛӘСЕ ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ

*Шул исемдәге истәлектән өзек*

Мария Ильинична — Ульяновлар гаиләсендә төпчек кыз. Гимназиядә укыган елларында ул еш авырый торган була — шунлыктан Владимир Ильич үзенең хатларында аңа сәламәтлеген сакларга, эш белән азрак шөгыльләнергә, укуы гел яхшы билгеләренә генә бармаганда артык борчылмаска киңәш итә.

Абыйсының кайгыртучанлыгына Мария Ильинична: «Эшләргә икән, бары тик җиренә җиткереп эшләргә», дип җавап бирә. Шушы сүзләре аның гомере буена девизы булып әверелә.

Мария Ильинична Владимир Ильичны фидакарьлек белән ярата иде һәм «Правда» газетасы эшче-хәбәрчеләренең берсенә хатында: «Ул минем һәрчак сөекле абыем булды» дип язды. Яшьлек елларыннан ук ул абыйсының дусты һәм турылыклы көрәштәше булып китә. 1895 елда, Владимир Ильичны төрмәдән азат итү мәшәкатьләре белән йөрер өчен, алар әнисе белән Петербургка киләләр. Шул чакта Мария Ильинична Надежда Константиновна Крупская белән таныша, һәм алар гомерлеккә дуслашалар.

Мария Ильинична Мәскәүдә хатын-кызлар өчен югары курсларда укый, ләкин, канәгать булмыйча, аны ташлап чыга. 1898 елда Бельгиягә—Брюссельгә китә, анда җитди рәвештә француз телен өйрәнергә керешә. Әмма бер елдан соң аңа укуын өзәргә туры килә, чөнки Мәскәүгә кайтуына ул кулга алына һәм Нижний Новгородка сөрелә. Бу — беренче сөрген, ләкин соңгысы булмый...

Мария Ильинична француз телен өйрәнү өчен һәр мөмкинлекне файдалана һәм соңрак укуын Парижда тәмамлап, француз телен укытырга хокук ала. Ул немец һәм инглиз телләрен дә яхшы белә һәм сөргендә тәрҗемәләр белән шөгыльләнә.

Мария Ильинична Владимир Ильич белән өзлексез элемтәдә яши. Төрмә һәм сөргеннәрдә Ильичны китаплар белән тәэмин итә, кызыксындырган мәсьәләләр буенча яңа хәбәрләрне җиткереп тора, чит илләрдә чыккан политик һәм экономик әдәбият турында мәгълүматлар өзерли.

Мария Ильинична хатын-кызлар хәрәкәтендә зур эш алып бара. Хатын-кызлар һәм балалар язмышына кагылышлы һәр нәрсәне күңеленә якын ала. Бервакыт алар Надежда Константиновна Крупская белән Пермьдә балалар йортында булалар. «Ничек инде ул шундый балаларны яратмаска мөмкин! Алар бит безнең балалар. Бары тик мәхәббәт белән генә алардан чын совет гражданнары тәрбияләргә мөмкин», — ди Мария Ильинична.

Ул үзе дә шундый тәрбияче иде. Аның олы күңеле «Правда» газетасында, совет контролендә эшләгәндә аеруча зур тирәнлек белән ачылды...

Үткәннәргә күңелем белән кайтып, Ульяновлар гаиләсенең гүзәл хатын-кызлары белән очрашуларымны хәтерләп, көндәлек алып бармаганыма үкенәм, шунлыктан бик күп очрашуларымны тулысынча күз алдына китереп бастыра алмыйм. Әмма шунысын әйтәм: ул очрашулар күңелемдә олы миһербанлылык хисе, акыл сизгерлеге һәм хатын-кыз иркәләве җылысы булып калдылар.

**Вячеслав Карпинский**

# КАҺАРМАНЛЫК

Мария Ильинична Ульянова данлыклы большевиклар гвардиясеннән профессиональ революционер иде. Кырык елдан артык ул Коммунистлар партиясе эшенә фидакарьлек белән хезмәт итте. Кайда гына эшләсә дә, ул аңа бетмәс-төкәнмәс энергиясен салып, янып, бирелеп эшләде.

1917 елның язынннан алып 1929 елга кадәр («Правда» газетасында эшләгән чорында) Мария Ильиничнаның оештыручы һәм публицист таланты ачылды. Минем уйлавымча, «Правда»га, моңарчы кешелек дөньясы белмәгән-күрмәгән яңа хәрәкәтне — эшче-крестьян хәбәрчеләре хәрәкәтен үстерүгә багышланган еллары — гүзәл большевик Мария Ильинична Ульянованың каһарманнарча хезмәт иткән еллары.

Чынлыкта ул бөтен редакциянең эшчәнлеген җитәкли иде. Аның эш көне иртәнге сәгать тугызда башланып, еш кына төн уртасына кадәр сузыла иде.

Кичләрен редакциягә алдынгы эшчеләр җыела. Эштән бераз ял итеп алгач, алар үзләренең яраткан газеталарына ашыгалар. Чөнки биредә үзләре өчен мөһим булган эшләр хакында редакторлар белән кара-каршы утырып әңгәмә корырга мөмкин булуын беләләр.

Алар редакциягә үзләре язган хатларны, мәкаләләрне алып киләләр, бергәләшеп шуларны тикшерәләр. Яхшы дип табылганнары «Правда»да басыла.

Мария Ильиничнаны алар хөрмәт итәләр, яраталар. «Правда»ның унбиш еллыгын бәйрәм иткәндә барлык хезмәткәрләр аның хезмәтләрен икърар итәргә, газетаның бөтен агымдагы эшен җитәкләүче турында — редакциянең секретаре Мария Ильинична турында барлык коммунистларга, совет яшьләренә, бар халыкка сөйләп бирергә теләк белдерделәр.

Аның хөрмәтенә нинди дә булса кичә яки тантаналы җыелыш оештыру хакында уйларга да ярамый иде. «Правда» газетасы эшендә үзенең шәхси өлешен зурларга маташуларны ул тимердәй ныклык белән кире кагып килде.

Һәм бер төркем иптәшләр «Мария Ильинична» дигән тыйнак кына исемле мәкалә яздылар. Редакция секретарена күрсәтелмичә генә, ул «Правда» газетасында 1927 елның 6 маенда басылып та чыкты. Мәкаләгә газетаның кырык ике журналисты, шул исәптән әлеге юлларның авторы да, кул куйган иде. Анда шулай дип тә язылган иде: «Һәр механизмны хәрәкәткә китерүче пружина була. «Правда»ның газет көне әйләнешен ун ел дәвамында хәрәкәттә тоткан ялыкмас, һәрчак нык тартылган, киеренке, корыч пружинасы Мария Ильинична булып килде һәм әле бик озак булачак. Без, «Правда» хезмәткәрләре, үзебезнең тормышыбызны, көндәлек эшебезне аңардан башка күз алдына китерә алмыйбыз, бүгенгесе көннәрдә «Правда»ның бөтенсоюз күләмендәге юбилеен аның белән бергә бәйрәм итүебез белән без бәхетле».

# ҖИҢҮЧЕЛӘР МӘРХӘМӘТЕ

*Хәрби комендант язмалары*

Кырык беренче елның июлендә фронтка чыгып киткәндә, мин, аяусыз сугышның кырыс таләпләренә буйсынып, ватарга һәм җимерергә генә түгел, хәрабәгә әверелгән авыл һәм шәһәрләрне яңадан үземә үк төзешергә дә туры килер дип уема китермәгән идем. Алай гына да түгел, бу эшне безгә Германиянең нәкъ үзендә башкару бурычы йөкләнде. Ләкин аңа кадәр әле сугышның чиксез авыр сынаулары аша үтәргә, чигенүләр газабын татырга, вакытлыча оккупантлар кул астында калган җирләрне азат итеп, фашизмның үз өненә барып җитәргә кирәк иде.

2 нче Белоруссия фронты гаскәрләре составында Везенберг шәһәренә мин 1945 елның маенда килеп кердем. Аның кешесез калган җимерек урамнары буйлап атлаганда, өстемнән хәрби киемне әле тиз генә салырга туры килмәячәген бик яхшы аңласам да, бу шәһәрнең коменданты булырмын дигән уй башыма да килмәгән иде.

Җиденче майда фронт хәрби комендатуралары белән җитәкчелек итүче бүлек начальнигы полковник Гончарукның көтмәгәндә чакыруы мине каушатып җибәрде.

— Сезгә Везенберг шәһәренә, аның якын-тирәсендәге авыллар һәм поселокларга хезмәт күрсәтү өчен хәрби комендатура оештыру бурычы тапшырыла, — диде полковник. Аннары кыска гына итеп өстәп куйды: — Комендант итеп сезне билгелим.

— Нинди күрсәтмәләрегез булыр?

— Бернинди дә... Син совет офицеры, — диде полковник кинәт «син»гә күчеп. — Йөрәгең һәм намусың ничек кушса, шуңа таянып хәрәкәт ит, капитан. Ләкин бернәрсәне — монда, немец җирендә, син үзеңнең Коммунистлар партиясе һәм Совет дәүләте вәкиле икәнлегеңне онытма.

Минем өчен яңа һәм тынгысыз хезмәт әнә шулай башланды. Ул көннәрдә шәһәрдә әйтерсең лә тормыш бөтенләй тынган иде. Нацистлар пропагандасы тарафыннан соң чиккәчә куркытылган барлык кешеләр диярлек, йортларын ташлап, якын-тирәдәге урманнарга һәм авылларга качканнар. Шунда ук исәнәеп йөрүче кораллы гитлерчылар әледән-әле Совет Армиясе солдатларына һәм офицерларына һөҗүм итәләр. Бу хәл исә хәрби комендатура хезмәткәрләренә өстәмә бер куркыныч тудыра иде. Шәһәр хуҗалыгы тулысынча чыгырыннан чыккан, күперләр һәм юллар җимерелгән.

Везенбергка концлагерьлардан азат ителгән хәрби әсирләр һәм тоткыннар килеп тулды. Аларны урнаштырырга, авыруларны һәм яралыларны дәваларга, азык-төлек мәсьәләсен кичекмәстән хәл итәргә кирәк иде. Комендатураның фашистлар белән көрәштә чыныккан тәҗрибәле кешеләренә таянып, без әнә шул бурычларны тормышка ашыра башладык. Миров шәһәрендә Везенберг хәрби комендатурасының филиалын ачтык, килүчеләрне исәпкә алу пункты оештырдык. Соңга таба репатриантлар лагере төзелде. Аның начальнигы итеп Чабаксар шәһәрендә туган полковник Николаев билгеләнде. Беренче көннәрдә Везенберг һәм Миров шәһәрләре урамнарында Европаның дистәдән артык ил кешеләре — фашизм тоткыннары әлгән милли флаглар җилфердәвен күрергә мөмкин иде. Совет солдатларына һәм офицерларына үзләренең әчкерсез рәхмәтләрен белдерү өчен комендатурага төркем-төркем булып кешеләр килә башлады. Аларны азат итү хөрмәтенә шәһәр мәйданында һәм комендатура бинасы каршында митинглар уздырылды. Ул митингларда фашистлар тырнагы астында газап чиккән элекке хәрби әсирләр чыгыш ясадылар. Алар бер-берләрен кочаклыйлар, үзләрен коткаручыларны үбәләр, шатлыктан елыйлар иде.

Соңгы атыш тавышлары тынды.

Рейхстаг өстендә җиңү байрагы җилфердәде. Немец халкы тарихында өр-яңа сәхифә ачылды.

Немец коммунистлары көндәлек тормыштагы теләсә нинди эшне башкарырга алындылар. Алар җирле халык белән бергә урамнарны хәрабәләрдән чистарттылар, шәһәрдә һәм районда нормаль тәртип урнаштырырга булыштылар, социал-демократларның, демократик караштагы кешеләрнең адресларын табып, аларның күбесе белән бәйләнешкә керделәр, әңгәмәләр уздырдылар, бергәләп хәрәкәт итү юлларын эзләделәр. Мондый кешеләрнең алгы сафында Германия коммунистлар партиясе члennары атлады. Алар арасында 1922 елда алган партия билетларына Эрнест Тельман үзе кул куйган Эрнест Петерес, Ганс Цандер, Альфред Иогансон, Рихард Роде һәм башкалар бар иде. Аларның һәркайсы Везенберг һәм Миров шәһәрләрендә эшне җайга салу өчен зур көч куйдылар. Ләкин «беренче сәгатьтән башлап активистлар» дип аталган иптәшләр күпме генә тырышлык һәм түземлелек күрсәтмәсеннәр, совет кешеләренең ярдәменнән башка алар көтелгән уңышка ирешә алмаган булырлар иде. Җиңелгән илгә дөнья тарихында беренче тапкыр бөтенләй башка характердагы җиңүчеләр — эшче-крестьяннар дәүләте солдатлары килде. Алар пролетар интернационализм рухында, гуманизм рухында тәрбияләнгән кешеләр иде. Һәм җиңелүчеләрнең күз алдында алар үзләре хәтта уйларына да китерә алмастай нәрсәләр эшләнде. Ә бит бездә — җиңүчеләр илендә азык-төлеккә әле карточка системасы иде, көнбатыш чикләре бездән алып Иделгә кадәр булган территориядә күпме авыллар һәм шәһәрләр җимерелгән, таланган иде! Ә менә шул илнең җиңүчеләре, кичергән газаплар һәм искиткеч зур югалтулар өчен үч аласы урынга, немец халкына ипи һәм консервлар өләшәләр, тормыш тизрәк үз эзенә төшсен өчен кулларыннан килгәннең бөтенесен эшлиләр. Совет Армиясе солдатларының тыныч халыкка тимәүләрен күреп, немецлар башта безнең комендатураларга кыяр-кыймас кына, аннан көннән-көн кыюрак мөрәҗәгать итә торган булдылар. Бик күпләр совет солдатларының алар җиренә үч алучылар булып түгел, азат итүчеләр булып килгәнлекләрен акрынлап төшенә башлаганнар иде инде. Боларның барысы да яңа Германия өчен көрәштә немец коммунистларының эшен шактый җиңеләйтте. Әмма «яңа Германия» дигән төшенчә нәрсәдән гыйбарәт иде соң? Бу сорауга Германия коммунистлар партиясе үзенең 1945 елның 11 июнь өндәмәсендә җавап

бирде. Тарих тәҗрибәсе күрсәткәнчә, диелгән иде ул өндәмәдә, бары тик эшчеләр сыйныфының крестьяннар, интеллигенция, урта катлауларның демократик даирәләре һәм башка барлык демократик көчләр белән тыгыз элемтә урнаштыруы гына, илдә империализм һәм милитаризм нигезләрен юк итәргә, тынычлык сөюче демократик Германия дәүләтен төзергә мөмкинлек бирәчәк.

Сугыш учагына әверелгән бу илдә тормышны яңабаштан үзгәртеп корырга алыну, ничә еллар буена нацистлар пропагандасы гипнозы тәэсирендә яшәгән кешеләр белән аңлашу өчен ул чакта нинди көчле оптимизмга ия булырга, киләчәккә һәм халыкка никадәр ышаныч багларга кирәк иде! Сугыш беткәннән соң беренче көннәрдә кемгә таянырга? Намуслы, аек фикерле немецларның күбесе гестапо зинданнарында һәм концентрацион лагерьларда җәзалап үтерелгән. Гитлер властька килгәнче Германия коммунистлар партиясендә член булып торган өч йөз мең кешенең яртысыннан күбрәге юк ителгән.

Әйе, яңа тормыш төзи башлау юлында немец коммунистларын зур авырлыклар көтә иде. Везенберг һәм Миров шәһәрләрендә яшәүче халыкның тормыш-көнкүрешен көйләп җибәрү безгә дә җиңел булмады. Комендатура хезмәткәрләренә, ял һәм йокыларын онытып, зур көч түгеп эшләргә туры килде. Әйтеп үткәнемчә, ул вакытта әле шәһәр тирәләрендәге урманнарда яшеренеп калган гитлерчыларның безгә каршы кораллы һөҗүмнәр оештыру куркынычы да бетмәгән иде.

1945 елның 8 маенда, мәсәлән, авиация хезмәте батальоны Везенберг — Миров юлында фашистлар засадасына эләгә. Ике арада көчле атышлар башлана. Совет солдатлары һәм офицерлары үз-үзләрен аямыйча сугышалар. Әмма аларның кайберләре, җиңү көнен күрә алмыйча, күзләрен мәңгелеккә йомалар. Мондый хәлләр ул көннәрдә әледән-әле кабатланып торды, фашистлар армиясе капитуляция ясаганнан соң да сугыш дәвам иткән очраклар булды.

Везенберг шәһәрендә яши башлауның икенче көне иде. Комендатурага бер немец килеп керде. Аны лейтенант Прокопенко кабул итте. Немец аның өстәленә ике пистолет чыгарып куйды.

— Каян алдыгыз боларны? — дип сорый лейтенант. — Үзегезнекеләрме?

— Юк, үземнекеләр түгел, — ди әлеге кеше, — мин Везенберг шәһәренең элекке бургомистрын һәм фашистлар партиясе җитәкчесен кулга алып, ябып куйдым. Аларны сезгә тере килеш тапшырам, әйдәгез, барып алыгыз үзләрен.

Җиңел генә кулга төшкән бу зур «трофейларны» тизрәк барып алырга кирәк иде. Мин, тагын бер солдат, тәрҗемәче кыз һәм әлеге кеше үзе машинага төялдек тә юлга чыктык. Бераз баргач, тәрҗемәче кызга карыйм, аның йөзе ап-ак булган: «Бер генә минутка туктагыз әле», — дип пышылдый ул миңа.

Машина туктый, төшәбез. «Мин аны кайдадыр күргән кебек булам, сез аңа ышанмагыз, безне ул берәр тозакка алып бармагае», — ди кыз... Безгә «трофейлар» вәгъдә иткән бу кешене тентеп карыйбыз. Аның кесәсеннән корылган «вальтер» пистолеты чыга. Шуннан без комендатурага әйләнеп кайттык, сораша башладык, җирле немец коммунистларын чакырдык. Бу кеше үзен Эрих Зельс дип атады. Тикшерүләр менә нәрсәне ачыклады: Эрих гестапо ялчысы булып чыкты. Берлинга һөҗүм башлангач, ул, махсус задание алып, Везенберг урманына килгән, анда урман каравылчысы йортына урнашып алган. Безнең гаскәрләр Везенбергка керәсе көнне Эрих шәһәрнең электр станциясен шартлаткан. Элек ул Америкада яшәгән булган. «Форд» автомашиналары алып, аларны Германиягә

китереп сату белән шөгыльләнгән. Сугыш башлангач, Германиягә кайткан. Эрихның күп эшәкелекләр эшләгән һәм киләчәктә дә эшләргә ниятләгән явыз фашист икәнлеге беленде. Ул безнең комендатура кешеләрен алдап алып китеп юк итәргә план корган булган. Тәрҗемәче кызның сизгерлеге аркасында без исән калдык һәм зур җинаятьче фаш ителде.

Халыкны азык-төлек белән тәэмин итү җиңел эш түгел иде. Беренче көннәрдә комендатура хезмәткәрләренә качып киткән алпавытларның элекке имениеләрендә ярдәмче хуҗалыклар оештырырга туры килде. Моның өчен без эшкә концлагерьлардан азат ителгән кешеләрне файдаландык. Бу ярдәмче хуҗалыклар шәһәр кешеләрен ит, май, сөт, яшелчә һәм башка продуктлар белән тәэмин иттеләр.

Везенбергка якында гына урнашкан Равенсбрюкта гитлерчылар тарафыннан хатын-кызлар концентрацион лагерьлары төзелгән булган. Аларда егермедән артык илдән куып китерелгән тоткыннар газап чиккән. Ул тоткыннарның 92 меңе үзләренең азат ителү көннәрен көтеп ала алмыйча дөнья куйган. Фашистлар тоткынлыгыннан коткарылганнарга безнең комендатура хезмәткәрләре кичекмәстән медицина ярдәме күрсәтүне, ашату һәм уңайлырак йортларга урнаштыруны оештырдылар. Сәламәтләнгәч, аларны туган илләренә озаттык. Киткәндә Советлар Союзы һәм Европа илләре гражданнары үзләрен үлемнән коткарып калулары өчен совет сугышчыларына чиксез зур рәхмәт сүзләре әйтеп саубуллаштылар.

— Озак елларга сузылган газаплардан соң 1945 елда безгә яңадан ирек һәм тормыш китергән сәгатьләрне кайнар рәхмәт хисләре белән искә алабыз, — диде Эрнест Тельманның тормыш иптәше — үзе дә Равенсбрюк концлагеренда утырган Роза Тельман, фашизм тоткыннарына багышланган милли һәйкәлләрне ачканда. — Җиңелмәс Совет Армиясе сугышчылары безне каршылаган һәм кочып алган, «Тельман, Тельман» дигән сүзләр белән яшь солдат мине тәбрикләгән минутлар минем һәм минем дусларым өчен мәңге онытылмас минутлар булды. Совет солдатының сүзләре Германиянең үткәнен һәм киләчәген гәүдәләндергән барлык немецларга юнәлдерелгән иде. Без барыбыз да гитлерчыларга каршы көрәшкән халыклар, безнең рәхмәтебез фашизмны җиңүгә өлеш керткән барлык милләт илләренә һәм хатын-кызларына барып ирешсен!

Гестапочылар кылган ерткычлыклар турында концлагерьлардан азат ителгән тоткыннар, немец коммунистлары һәм безнең комендатура хезмәткәрләре күп санлы кешеләр катнашкан җыелышларда сөйләделәр. Хәрби әсирләргә ярдәм күрсәткән һәм үзләренең җинаятьчел әмерләрен үтәүдән баш тарткан өчен фашистлар утыз меңнән артык немецны атканнар. Равенсбрюк концлагеренда немец хатын-кызлары да булган. Советлар Союзының һәм Европа илләренең басып алынган районнарында гитлерчылар эшләгән ерткычлыкларны үз күзләре белән күргән шаһитлар сөйләгәндә залда утыручылар нәфрәтләнәләр һәм елыйлар иде.

Совет кешеләре немецлар алдында үзләрен яманатлы итмәсеннәр өчен комендатура хезмәткәрләре үзебезнекеләрнең һәр адымын күзәтеп торды. Немецлар совет солдатына көннән-көн зуррак ышаныч һәм ихтирам белән карый башладылар. Немец һәм совет халыклары арасында дуслык ныгыганнан-ныгый барды. Халыкны тәрбияләү эшенә немец коммунистлары актив кушылдылар. Германиянең көнчыгыш өлешендә үзәк дәүләт органнары әле төзелмәгән ул көннәрдә безгә бик күп төрле кыенлыкларны җиңәргә туры килде. Ул чакта Германиядәге җирле үзидарәләр безнең хәрби комендатура җитәкчелеге һәм контрольлегендә эшләделәр. 1945 елның июнь башында Везенберг, Миров шәһәрләрендә һәм якындагы торак пунктларда

шәһәр һәм авыл бургомистрлары билгеләнде. Везенберг шәһәре һәм районы бургомистры итеп билгеләү өчен 1922 елдан Германия коммунистлар партиясе члены Эрнест Петерес кандидатурасы, аның урынбасары итеп коммунист Альфред Иогансон, пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире итеп коммунист Рихард Роде, полицейский идарәсе начальнигы итеп билгеләү өчен Германия коммунистлар партиясе члены Ганс Цандер иң кулай кандидатуралар иде. Шәһәрдә һәм районда җитәкче постларга күп кенә антифашист коммунистлар һәм демократик карашлы кешеләр куелды. Алар үзләренә йөкләнгән бурычларны намус белән башкардылар.

... Везенберг, Миров, Найштрлиц шәһәрләре Берлиннан төньяккөнбатышта 80—100 километр ераклыкта урнашканнар. Илнең уртача климатлы бу районнарында авыл хуҗалыгы алга киткән. Табигый шартлар әйбәт: шәһәр тирәләре нарат урманнарына һәм күлләргә бай. Ул җирләр борын-борыннан немец князьләренең, графларының, Берлин аксөякләренең ял итү, күңел ачу урыны булып саналган. Әлеге районнар хәзерге көндә дә үзләренең әһәмиятләрен югалтмаганнар. ГДРда яшәүче дусларыбыз анда һәр ел саен ун меңнәрчә хезмәт ияләренең ял итәргә килүләре турында язалар. Везенберг, Миров шәһәрләре тирәләрендәге күп санлы торак пунктлар ни өчендер Вустов, Штразин, Конов, Белов, Кляйн Квасов, Узерин, Миров, Рыхлинг һәм башка шундый рус фамилияләренә охшашлы исемнәр белән аталалар. Күп еллардан бирле шунда гомер кичергән кешеләрнең раславынча, ул җирләрдә кайчандыр славяннар яшәгән һәм әлеге исемнәр шул вакыттан калган. Миров шәһәреннән ерак та түгел үзенең күп санлы лабораторияләре белән Рыхлинг институты урнашкан булган. Гитлер армиясенең барлык төр коралларына шунда сынау уздырганнар. Сугыш вакытында тимер-бетоннан күп санлы күзәтү манаралары төзелгән. Сынаулар уздырыла торган полигон меңнәрчә гектар мәйдандагы чәчүлек җирләрне билигән. Бу полигонга якын авылларда яшәүчеләр башка урынга күчерелгәннәр. Алардан калган каралты-куралар бомба һәм снарядлар сынау вакытында җимерелгән. Сугыштан соң да әле анда ярылмыйча калган бомба һәм снарядлар аунап ята иде. Барлык хәрби корылмалар безнең тарафтан юк ителде. Бушап калган җирләр крестьяннарга бүлеп бирелде.

Немец активистлары катнашында урып-җыю эшләре башкарылды, ашлык, яшелчә һәм бәрәңге әзерләнде. Озак та үтмәде, завод-фабрикалар эшли башлады, күперләр, юллар ремонтланды, мәктәпләр, больницалар, кинотеатрлар, клублар ачылды. Боларның барысы да, әлбәттә, җиңел генә эшләнмәде, безгә һәм немец коммунистларына карата төрле провокацияләр булып торды. Бигрәк тә иптәш Иогансонга үч алу белән янадылар, аның исеменә имзасыз хатлар яуды, аны руслар ялчысы дип атадылар. Ләкин шуңа да карамастан, немец коммунистлары куркып калмадылар, эшләрен тагын да тырышыбрак дәвам иттерделәр. Яңа уку елы якынлашкач, без аеруча кыенлык алдында калдык. Балаларны укыта башларга кирәк, ә дәреслекләр юк, элекке укытучыларның яртысыннан күбесе — фашистлар партиясендә член булып торган кешеләр. Безнең алга яңа укытучылар әзерләү, Геббельс пропагандасыннан арындырылган дәреслекләр булдыру бурычы килеп басты. Бу катлаулы эшне башкару хәрби комендантның политик эшләр буенча урынбасары капитан Довги Андрей Родионович өстенә төште. Аңа уку-укыту эшләрен оештыру гына түгел, культура-агарту чараларын тормышка ашыру бурычы да йөкләтелгән иде. Бу мәсьәләләрне хәл итү буенча Германиядәге Совет хәрби администрациясеннән тиешле күрсәтмәләр алынды. Кино, театр һәм башка культура-агарту учреждениеләре аның җитәкчеле-

ге һәм контрольлеге астында эшли иде. Ул иң авыр бурычларны тәгәл һәм җиренә җиткереп үтәп килде.

Шверин шәһәрендә 1945 елның август аенда булып үткән киңәшмәдә урып-җыю эшләрен төгәлләү, ашлык тапшыру, көзге чәчү сроклары, халыкка икмәк һәм азык-төлек бирү нормалары, совет хәрби комендатураларының экономик, хуҗалык һәм культура эшчәнлегендәге бурычлары билгеләнде. Комендатура хезмәткәрләре Довги, Добраквашин, Беляев, Васильев, Серебряков, Фокин, Булатов, Зәйнуллин, Хәйруллин һәм башка офицерларның исемнәрен мин зур рәхмәт хисе һәм тирән ихтирам белән искә алам. Германия Демократик Республикасы халкына тыныч тормыш шартлары тудыру буенча алар кулларыннан килгәннең бөтенесен эшләделәр.

Везенберг һәм Миров шәһәрләренең коменданты булып эшләү минем өчен зур тормыш мәктәбе булды. Совет Армиясе офицеры һәм коммунист буларак, бу постта мин безнең совет гуманизмы идеяләрен үткәрүче икәнлегемне бик яхшы аңлый идем, җирле халыкка мин Совет дәүләтенең Германиягә карата нинди политика үткәргәнлеген җайлап кына төшендерергә тырыштым. Дөресен әйтим, гади немецларның психологиясе кайвакыт мине гаҗәпкә калдыра иде. Хәтеремдә, шулай бервакыт миңа өлкән яшьтәге ике кеше: «Безнең шәһәрнең коменданты итеп руслар ничек сезне, татар милләтеннән булган кешене билгеләргә уйладылар?» дигән сорау белән мөрәҗәгать иттеләр. Безнең илдә, Советлар Армиясендә теге яки бу җаваплы эшкә билгеләгәндә кешенең нинди милләттән булуы хәлиткеч роль уйнамавы аларның башына да сыймый иде. Әйе, фашистлар пропагандасы бер расаның икенчесеннән өстен булуы, Советлар Союзы халыклары арасындагы милли дошманлык турында немецларга аз тукымаган шул!

Көннәрнең берендә комендатурага үзләренә җир алган крестьяннар килеп керде. «Менә безгә бүлеп бирелгән җирләрнең элекке хуҗасы язган хат, — диделәр алар, кулларына тоткан кәгазьне миңа сузып. — Ул бездән үч алу белән яный, озакламый кире әйләнеп кайтачакбыз, ул вакытта бездән бернинди шәфкать көтмәгез, дип куркыта. Без инде хәзер нишләргә тиеш булабыз?»

Комендатурада аларга: «Тыныч булыгыз, яңа Германиянең чын хуҗалары хәзер сез үзегез», — дип аңлаттылар.

1946 елның ахырында Везенберг хәрби комендатурасы Найштрлиц шәһәре хәрби комендатурасы белән берләште. Мине Найштрлиц өязе комендатурасының авыл хуҗалыгы бүлеге начальнигы итеп билгеләделәр. Шуңа бәйле рәвештә миңа йөзләрчә авылларда булырга, урып-җыю, ашлык әзерләү эшләре, терлекчелекне үстерү мәсьәләләре белән шөгыльләнергә туры килде. Бүлеккә йөкләтелгән бурычларны үтәүдә миңа ярдәмчеләрем: лейтенант Лебедев һәм лейтенант Русляков зур булышлык күрсәттеләр. Алар гитлерчыларга каршы авыр сугышларда берничәшәр тапкыр катнашкан куркусыз офицерлар иде. Белгечлекләре буенча беренчесе агроном, икенчесе зоотехник буларак, бу иптәшләр үз эшләрен намус белән башкардылар. Найштрлиц өязенең хәрби коменданты, минем турыдан-туры начальнигым, хәзерге көндә Киев шәһәрендә яшәүче запастагы подполковник Виталий Герасимович Роленконы мин бүген дә җылы хисләр белән искә алам. Ул белемле һәм зур культуралы менә дигән кеше иде. Оста оештыручы сәләтенә ия булганы өчен аны комендатура хезмәткәрләре генә түгел, өязнең барлык намуслы кешеләре яраттылар һәм ихтирам иттеләр. Германия социалистик эшче-крестьяннар дәүләтен аякка бастыру өчен ул бик күп эшләде. ГДР эшчеләр сыйныфының

тыныч тормышын төзү эшенә керткән хезмәтләрен искә алып, Найштрлиц хезмәт ияләре аны үз шәһәрләренең почетлы гражданины итеп сайладылар. Найштрлиц шәһәренә кунакка барган чакларында аны хәзер дә үз туганнарыдай якын күреп кабул итәләр.

Үзебезгә тапшырылган мактаулы миссияне үтәгәннән соң, мин туган илгә кайтырга җыена башладым. Мине озатырга немец коммунистлары Эрнест Петерес, Альфред Иогансон, Ганс Цандер, Рихард Роде һәм башкалар килгән иде. Безнең комендатура хезмәткәрләренә рәхмәт белдергәннән соң алар совет кешеләренә социализм төзү эшендә яңадан-яңа уңышларга ирешүләрен теләделәр. Үз нәүбәтебездә немец дусларыбызга без дә иң матур теләкләребезне белдереп саубуллаштык.

1967 елның октябрь ахырларында мине партиянең Татарстан өлкә комитетына чакырдылар һәм Германия Демократик Республикасыннан килгән бер хат бирделәр. КПСС өлкә комитеты секретаре исеменә адресланган ул хатта мондый сүзләр язылган иде: «Хөрмәтле иптәш секретарь! Бөек Октябрь социалистик революциясенең илле еллыгы уңае белән без 1945 елдан соң яңа тормыш төзүдә немец халкына булышкан совет сугышчыларын кунакка чакырмакчы идек. Совет һәм немец халыклары вәкилләре белән мондый очрашулар безгә дәүләтләребез һәм партияләребез арасындагы туганнарча дуслыкны киләчәктә тагын да ныгыту өчен кирәк. Без Сезгә зур үтенеч белән мөрәҗәгать итәбез. Хәзерге көндә Казанда яшәүче Мөхәммәт Латыйп улы Галиев Везенберг шәһәренең беренче совет хәрби комендантына булып хезмәт иткән. 1967 елның 9 ноябреннан без аны бер атнага Германия Бердәм Социалистик партиясенең Найштрлиц район комитеты кунагы итеп чакырабыз».

Моңа кадәр дә инде мин немец дуслардан ГДРга кунакка чакырып язган хатлар алган идем.

1967 елның 5 ноябрендә Берлинга килеп төштем. Аның урамнары буйлап узганда Германия Бердәм Социалистик партиясе Үзәк Комитеты урнашкан яңа биналарны, халык укытучылары йортын, «Москва» кунак йортын зур дулкынлану белән карадым. ГДР башкаласы танымаслык булып үзгәргән иде. Немец дуслар мине шәһәр һәм атаклы Берлин зоопаркы белән таныштырдылар. Безгә дус илнең башкаласы миндә онытылмаслык матур тәэсир калдырды.

Найштрлиц шәһәренә килгәч, мин Бөек Октябрь революциясенең 50 еллыгына багышлап Германия Бердәм Социалистик партиясе шәһәр комитеты үткәргән тантаналы утырышта катнаштым. Партиянең шәһәр комитеты секретаре докладыннан соң СССР-Германия дуслыгы җәмгыяте делегациясе җитәкчесе профессор Румянцев чыгыш ясады. Председательлек итүче аннары миңа сүз бирде. Трибунага менеп, залдагыларны котлап бетерүемә, минем яныма ике кеше — Германия Бердәм Социалистик партиясе ветераннары Эрнест Петерес һәм Рихард Роде иптәшләр күтәрелде. Мине алар трибунада ук кочып алдылар, бу минутта һәркайсыбызның күзеннән яшь бәреп чыкты. Әйе, егерме ел вакыт узгач, без кабат очраштык. Алда инде әйтеп үткәнемчә, мин Везенбергта комендант булып хезмәт иткәндә Эрнест Петерес шәһәр бургомистры, Рихард Роде партия шәһәр комитетының агитация һәм пропаганда бүлеге мөдире итеп билгеләнгән иде. Тантаналы утырыш уздырылган көнне үк, немец дусларыбыз белән бергәләшеп, Везенберг шәһәренә юл тоттык. Анда Октябрьның 50 еллыгы хөрмәтенә хезмәт ияләренең пар-

тия, профсоюз, яшьләр оешмалары вәкилләре катнашында тантаналы җыелышы үткәрелде. Мин дә котлау сүзе әйттем.

Яшьләр һәм партия ветераннары белән очрашулар унөч көн буена дәвам итте. Найштрлицта 7 ноябрьда шәһәр хезмәт ияләренең совет кунаклары белән берлектә уздырылган зур митингысы аеруча дулкынландыргыч һәм истәлекле булды. Бу митингта Германия Бердәм Социалистик партиясенең округ комитеты секретаре иптәш Герхард Цетлер ялкынлы речь белән чыкты. Соңыннан без Найштрлиц шәһәрен фашистлардан азат иткәндә һәлак булган совет сугышчылары һәйкәленә чәчәк бәйләмнәре куйдык, шәһәр җитәкчеләре белән бергә Везенберг урта мәктәбендә булдык, укучылар, фанер-мебель, балык комбинатлары эшчеләре, авыл хуҗалыгы кооперативы членнары белән очраштык. Штразина, Конове авылларында, Миров, Феюстенберг шәһәрләрендә дә безне көтеп алынган кунак итеп каршыладылар.

Германия-Совет дуслыгы җәмгыятенең Найштрлиц бүлеге председателе иптәш Гарольд Минов белән бергә элеккеге Равенсбрюк хатын-кызлар концлагеренда безгә кабат булырга туры килде. Хәзерге көндә анда милли музей оештырылган, егерме илдән җыелган экспонатлар куелган, тоткыннар җәзалап үтерелгән җиргә чәчәкләр кую өчен махсус урын ясалган. Аның Советлар Союзы өчен билгеләнгән өлешенә без дә чәчәк бәйләмнәре куйдык. Элеккеге дуслар белән кабат очрашу, яңа дуслар белән танышу миндә матур хатирә калдырды.

1970 елда, җавап визиты белән, Казанда Германия-Совет дуслыгы җәмгыятенең Найштрлиц бүлеге председателе иптәш Гарольд Минов булып китте. Үз иленә кайткач, Германия Бердәм Социалистик партиясенең Нойбранденбург округ оешмасы органы «Франс Эрде» газетасында ул «Казаннан сәлам» исемле мәкаләсен бастырып чыгарды.

... Ике арадагы дуслык элемтәләре елдан-ел ныгый. Немец дуслардан мин ай саен дистәләрчә хат алам. Миңа Германия Бердәм Социалистик партиясенең Везенберг шәһәр комитеты секретаре Хайне Брун, Найштрлиц шәһәр комитеты секретаре Карл Мюллер, Нойбранденбург шәһәрендәге округ спорт мәктәбе директоры Гарольд Минов, 1922 елдан бирле Германия Бердәм Социалистик партиясе члены Ганс Цандер һәм Анна Петерес, Маргарита Иогансон һәм башка иптәшләр яза. Үзләренең хатларында алар немец халкына һәрьяклап ярдәм итүләре өчен совет кешеләренә тирән рәхмәтләрен белдерәләр, илебездә коммунистик җәмгыять төзү эшендә яңадан-яңа уңышлар телиләр.

МӨХӘММӘТ ГАЛИЕВ,
элекке хәрби комендант, хәзер Везенберг шәһәренең почетлы гражданины.

# ХУРЛЫК ТАМГАСЫ

Сугыштан соң Чехословакия җирендә безнең полкның өлкән офицерлары эш белән Брно шәһәренә еш кына баралар иде.

Хәтерем ялгышмаса, 1945 елның май азакларында иде бугай, штаб начальнигы белән миңа да Брнога барырга туры килде. Брнога җитәрәк безне бер хәрби машина куып узды да юл читенә туктады. Ул машинадан бер майор чыгып кулын күтәрде. Аның янына без дә килеп туктадык. Штаб начальнигы машинадан төшүгә, майор белән дусларча күреште. Ул шунда, безгә бер сүз дә әйтмичә, майор машинасына утырып китеп тә барды. Штаб шоферы моңа бер дә гаҗәпләнмичә юлын дәвам итте. Ул, шәһәр уртасына җитәрәк, нәни генә мәйданда машинасын туктатты да штаб начальнигын шушында көтәчәгебезне әйтә. Машинадан төшеп, көпчәкләренә типкәләгәч:

— Дускай! Миңа сакчы кирәкми, боегып утырма син, төш тә кызлар күзлә, начштаб тиз генә бушамас әле. Мин черем итеп алам, төнлә йокымның рәте булмады. Төшемдә хатынымның бер кибет мөдиренә кияүгә чыкканын күрдем, — диде. Мин, аңа татлы йокы теләп, машинадан төштем дә көрсенеп куйдым. Их, әгәр дә мин турист булсам, бу тарихи шәһәрне буеннан-буена йөреп чыгар идем бит! Шулай да мин, юк дигәндә, штаб машинасы яныннан йөз илле метр чамасы булса да китә алам ич әле. Шул форсаттан файдаланып, үзәк урамга чыктым. Сирәк-мирәк кенә безнең хәрбиләр дә очрый, мин офицерларга честь бирәм, ә солдатлар — миңа. Як-якка карап бара торгач, архитектура бизәкләре белән чуарланган зур бинага күзем төште. Биредә, һичшиксез, музей булырга тиеш дигән уй белән урамның икенче ягына чыктым. Бу йортның имән ишекләре шыр ачык иде. Өскә мәрмәр баскычтан менәсе. Баскычның як-ягында бронзадан коелган нечкә билле кызлар басып тора. Бу күркәм фигураларны да күргәч, биредә музей икәненә тәмам ышандым. Ишек янындагы киндер пумала белән итекләрдәге тузанны сөрткәч, баскычтан менә башладым. Каршыма муенына автомат аскан бер чех егете төшеп килә иде. Аның башында каска, бер кулында — сары буяу тулы чиләк, икенчесендә — зур гына пумала. Ул миңа якынлашкач, пумаласы белән ымлап, бирегә керергә ярамаганлыкны аңлатты. Ярар, ярамагач ярамый инде. Мин борылып урамга чыктым. Чыгуга бу бинада нинди оешма төпләнгәнлеген чамалап булмасмы дип, чех телендә язылган күрсәткечкә күз йөртә башладым. Минем арттан ул чиләкле егет тә чыккан икән. Ул миңа, тагын ымлап кына, биредә торырга ярамаганлыкны аңлатты, нәрсәдер булачагын сиздерәсе килеп күзен кысты. Мин тиз генә урамның икенче ягына чыгып тротуарга бастым. Озак та үтмәде, автоматлы чех патриотлары бер төркем кешеләрне алып чыктылар да, аларны урамга каратып, бер рәткә тезеп бастырдылар. Бу кешеләр миңа кинофильмнарда күргән симез банкирларны, фабрикантларны хәтерләтте. Өсләрендә бостон костюм, аякларында ялтырап торган лаклы туфлилар. Патриотларның берсе команда биргәч, алар урамга аркалары белән борылды. Икенче мәртәбә команда булгач, кулларын күтәрделәр. Өченче командадан соң, миңа күз кыскан егет пумаласын сары буяуга батырды да бу капкорсакларның аркаларына фашистлар эмблемасы— свастика сурәте ясый башлады. Бу тамашаны күрүгә, авызымны ачып таш булып каттым! Мин дөньяда мондый мәсхәрәле җаза барлыгын белми идем бит! Бу капкорсаклар башта үзләрен дәрәҗәләре белән масайган турәләр сыман тоттылар. Ә менә аркаларына хурлык тамгасы чәпи башлагач, сыгылып төштеләр, йөзләреннән кан качты. Тамга салынып бетүгә, аларны урам буйлап алып киттеләр.

Мин башта хурлык тамгасына дучар булган әфәнделәрне немецлар дип уйлаган идем, алар чехлар икән: шәһәр идарәсенең фашистларга сатылган чиновниклары булып чыктылар.

Миңа монысын чал чәчле пехота капитаны әйтте. Ул да, минем кебек, чех дусларның Гитлер ялчыларына карата булган нәфрәтләренә сокланып карап торган иде.

**СӘЕТ КАЛЬМЕТОВ.**

Бакый Урманче

# АРХИТЕКТОР ИСМӘГЫЙЛЬ ГАЙНЕТДИНОВ



Бөек Октябрь кояшының бәрәкәтле нурлары астында татар халкының талантлы уллары һәм кызлары арасыннан күп санлы сәнгать осталары үсеп чыкты. Шуларның берсе — архитектура профессоры Исмәгыйль Гайнетдинов. Ул инде житмеш яшен тутырып килә[1]. Бөтенсоюз һәм Татарстан архитектура сәнгатендә күренекле урын тоткан бу корым-төзем[2] остасының иҗаты хакында житди бер монография язарга да күптән вакыт инде дип беләм. Бу мәкалә әнә шул кимчелекне әз булса да төзәтү теләгеннән чыгып, дөньядагы иң могтәбәр архитектура институтларыннан берсе — Мәскәү архитектура институтында шәһәр төзү кафедрасы мөдире булып эшләүче профессор Исмәгыйль Гали улы Гайнетдиновның архитектура мәйданында майтарган зур хезмәтен тәкъдир итү, укучыларны аның белән кыскача таныштыру максаты белән язылды.

Революциягә кадәр хәлле гаиләләрдән чыккан татар яшьләренең бик азы югары уку йортларын тәмамлый алсалар да, аларга, потенциаль сәләтләре нинди генә зур булмасын, фән һәм гыйлемнең биек үрләренә күтәрелү мөмкин түгел иде. Ә инде Исмәгыйль кебек ярлы эшче гаиләсендә туып үскән яшьләргә югары белем институтларының бусагасыннан атларга да мөмкинлек булмый.

Аның эшләрен күзәтеп, иҗади әсәрләрен бәяләгәнче, Исмәгыйль төземчелек мәйданына килеп чыкканга кадәр татар халкының архитектура эшләре ни хәлдә булганлыгын кыскача гына күз алдына китерик. Шул вакытта гына останың бу өлкәдәге зур хезмәтен тәкъдир итү иплә булачак.

Татар халкының элекке чорда төзү-төзүчелек, калалар һәм салалар кору мәйданындагы активлыгы хакында сүз ачсак, уналтынчы гасырга кадәрге һәм унсы-

---

[1] Профессор И. Г. Гайнетдинов үткән елның 21 октябрендә вафат булды. Бу мәкалә шушы аянычлы вакыйгага кадәр үк язылган булганлыктан, без аны үзгәртмичә дөньяга чыгаруны тиешле таптык.— Редакция.

[2] Корым — сооружение мәгънәсендә, төзем — зодчество.

гезенче гасырның икенче яртысыннан соңгы чор турында сөйләргә туры килә. Татар халкының борынгы корылыш әсәрләреннән бик азлары гына сакланган. Мәсәлән, Казанда Сөембикә манарасыннан башка бер әсәр дә юк. Тарихи әсәрләрдә, фәндә Сөембикә манарасы дип аталып йөрүе аның Сөембикә ханша заманында корылган булуын күрсәтә. Каюм Насыйри да шулай ди. Моннан башка шәһре Болгарда, Касыйм каласында һәм Чулман-Идел, Агыйдел буйларының башка төбәкләрендә ярым хәрабә хәлендәге берничә таш корылышны әйтеп китәргә мөмкин.

Дөньяның корым әсәрләре күп заманнарда һәм күп илләрдә таш корым рәвешендә сакланган. Урта Азия, Иран, Мисыр, Рум һәм башка илләрнең корымнары таштан, кирпечтән салынган булган. Аерым игътибар белән корылмаганда агач өйләр тиз җимерeләләр, харап булалар. Идел буе халыклары, шулар җөмләсеннән татар халкының йорт-каралтылары күбрәк агачтан салынганлыктан, кыска гомерле булганнар. Хәер, өйләре агачтан булса да, җәмәгать биналарын, храмнарны халык таштан салырга тырышкан. Мәгълүм ки, Казан каласында элекtә дә таш сарайлар һәм мәчет-мәдрәсәләр булмаган түгел. Князь Курбский, мәсәлән, Казанның бик күркәм булуын, таш мәчетләр, сарайлар булуын язып калдырган. Боларга мәшһүр сәяхәтче Олеариның 1630 елда ясап калдырган рәсемнәре бер чама иллюстрация була ала. Шиһаб Мәрҗани башка чыганаклардан файдаланып, XVI йөздә «кала эчендә сигез манаралы бер җомга мәчете һәм таҗик ермагы дип аталган урында янә бер мәчет вә мәдрәсә» булуы турында яза.

Археологик казынулар күрсәткәнчә, татарларда кирпеч-силикат эшләре алга киткән булуы билгеле. Болгар заманында таштан кору осталыгы югары дәрәҗәдә булган. Болгар осталарының рус калаларына барып кору-төзү эшләрендә катнашулары, мәсәлән, Владимирда, Псковта чиркәүләр салышулары ышанычлы тарихи чыганакларда күрсәтелә.

XVI гасырдан соң, татарларда таш биналар салу, тимерчелек белән шөгыльләнү тыелган чорда, металл һәм тимердән ясау, таш пулатлар салу һөнәрләре җуела, онытыла башлый. Профессиональ таш корым-төзү осталыгы югала бара.

Бары 1767 елда гына, Екатерина II Казанда булган чагында, татарлар, патшага гариза биреп, Казанда таш мәчет салырга рөхсәт алалар. Таш пулатлар корылмауның башка сәбәпләре дә булгандыр: татар халкы гасырлар буе бик фәкыйрьлектә яшәгән. Шул ук Мәрҗани яза: «Мулла Габдерәшит мәчет мөһиме өчен Хаҗи Тархан (Әстерхан) шәһәренә кадәр мөзул итмеш», ди. Димәк, патшадан рөхсәт алынса да, Казан үз халкыннан таш мәчет салырлык мая җыя алмаган. Идел буенча Әстерханга кадәр төшеп акча җыеп кайтканнар. Болар ул вакытта татар халкы өчен корылыш-төзелеш эшләренең нинди авыр булганлыгын күрсәтә.

Шуннан соңгы заманда Казанда берничә таш мәчет салына. Боларның төзүчеләре һәм корымчылары кемнәр булгандыр, аныcын тикшеренүчеләр архивлардан ачыклар. Чөнки ул заманнарда инде архитектура һәм калачылык тәртипкә салына. Шәһәрләр алдан корылган план белән төзелә башлый. Биналарны да алдан хәзерләнгән проект белән сала торган булганнар. Хәтта авыл мәчетләре дә төземче ясаган проект белән корыла.

Татарларны чукындырырга тырышкан каратун-миссионерлар татар мәдәни хәрәкәтен бөтен көчләре белән юк итәргә омтылган заманда татар халкы бик мескенлеккә төшеп, архитектура үз эше түгел, аңарга омтылырга да кирәк түгел дип уйлау дәрәҗәсендә тора. XVIII—XIX гасырларда байтак таш биналар корылса да, татарлардан профессиональ архитекторлар чыкмаган.

Ләкин агач корылыш дәвам итә. Аның формалары да, стиле дә саклана. Агач корымның төземе, бизәкләре дә сакланып килгәнен хәзер дә күреп торабыз. Авыз иҗаты әсәрләре сакланган кебек, халык корымының төп үзенчәлекләре дә сакланып килә һәм һаман үсмәктә.

Бары тик Бөек Октябрь революциясе генә халкыбызның зур мәдәни көчләрен уятырга, аякка бастырырга һәм эшкә җигәргә мөмкинлекләр бирде. Талантларга олы юл капкалары ачылды.

Исмәгыйльнең биографиясендә гадәттән тыш берни дә юк. Атасы Гали абзый, фәкыйрьлек, җир азлыктан интегеп, 1912 елда бөтен гаиләсе белән Олы Мәңгәр авылыннан (Татарстан, Арча районы) Чиләбе шәһәренә күчеп китә. Бу вакытта Исмәгыйльгә бишенче яшь кенә була әле. Чиләбедә Гали абзый әле йөкче, әле ат караучы, әле урам себерүче булып эшли. Исмәгыйльнең әнисе байларда пешекче булып хезмәт итә. Унике яшенә кадәр Чиләбе татар мәктәбендә укыганнан соң Исмәгыйльнең үзенә дә эшләргә туры килә. Ул итек тегү һөнәренә өйрәнә һәм берничә еллар итекче булып эшли. Укуга һәвәслеге дә зур була. Революция биргән киң мөмкинлекләр яшүсмер егетне дәртләндереп тора. Ул, үзлегеннән укып һәм хәзерләнеп, 1925 елда җидееллык рус мәктәбенә укырга керә. Аны егерме яшендә тәмам итеп, шул ук елны Казан индустриаль техникумы рабфагында укый башлый. Күп тә үтми, шушы техникум нигезендә Казан коммуналь төзелеш инженерлары институты ачыла. Һәм 1931 елда ук инде Исмәгыйль Гайнетдинов институттан төзүче инженер дипломы алып чыга. Әүвәл ул прораб ярдәмчесе, аннан соң прораб булып Казан төзелешләрендә эшли.

Исмәгыйльнең күңелендә иҗади төзелеш эшләренә омтылыш нәкъ менә шушы елларда туа да инде. Айлар, еллар үтү белән аның бу теләге көчәя бара. Ниһаять, 1936 елда ул Казан шәһәр советы янындагы проектлау остаханәсендә архитектор булып эшли башлый. Останың гомерендә зур борылыш ясалган чак бу. Һәм аның моннан соңгы гомере бөтенләе белән архитектура, төземчелек эшенә багышлана.

1936 елның көзендә Исмәгыйль конкурс аша Мәскәүдәге СССР Архитектура академиясенең аспирантурасына уза. Аспирантура курсын тәмамлаганнан соң, академия президиумы карары белән аны калачылык (градостроительство) институтында эшкә калдыралар. Менә шушы институтта яшь архитекторның интенсив төземчелек эшчәнлеге киң колач ала.

1939 елда Исмәгыйль Гайнетдинов шунда ук кандидатлык диссертациясен яклый. Соңрак Мәскәү архитектура институтына гыйльми-педагогик эшкә күчә. 1965 елда Исмәгыйль Гайнетдиновка профессор дигән гыйльми исем бирелә. Педагоглык Исмәгыйль аганың табигатендә төп хасиятләрнең берсе дисәк ялгыш булмас.

И. Гайнетдинов Казан архитекторлары белән якыннан бәйләнешен һичкайчан өзми. Казан төзүче инженерлар институтында архитектура факультеты ачу буенча әзерлек эшләрендә актив катнашып, ул әлеге факультетның беренче яшь архитекторлары чыгарылышын хәзерләүгә күп көч куйды. 1977 ел чыгарылышында да имтихан комиссиясенең рәисе булып эшләде.

Исмәгыйль Гайнетдинов — күп санлы гыйльми һәм фәнни-популяр хезмәтләр авторы. Әле Казанда эшләгән елларында ук ул «Сызымнар, аларны сыза һәм укый белү», «Шрифт үрнәкләре» дигән ике китап язып Татарстан китап нәшриятында татар телендә бастырып чыгарган иде. Моннан соң төрле матбугат органнарында татарча һәм русча илледән артык китап һәм мәкаләләре дөнья күрде.

Исмәгыйль Гайнетдиновның кору-төзүдәге практик эшчәнлегенә килсәк, аның иң күркәм әсәрләре белән без республикабыз башкаласы Казанда көн саен диярлек очрашып торабыз. Әмма иң әүвәл 1938 елда Мәскәүдә — Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә корылган Татарстан павильонына тукталыйк. Ул хәзер сызымнарда гына сакланып калган. Бу павильон төземчелек мәйданына чыккан яшь һәм сәләтле останың егетлек дәрте белән ясалган беренче җитди әсәре була. Бу чорда ул инде — корым-төзем эшләрендә яхшы ук тәҗрибә алган, классик һәм милли төзем формаларын нык үзләштергән белгеч. Аңарга бары шул белемнәреннән тулы файдаланып, осталыгын күрсәтерлек бер объект кирәк була.

Шул вакыт хөкүмәтебез Мәскәүдә совет иленең уңышларын күрсәтерлек зур Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсен оештыру турында карар кабул итә. Татарстан павильоны проектына да махсус конкурс ачылып, анда күп кенә танылган архитекторлар катнаша. Исмәгыйльнең проекты беренче премияне ала һәм Татарстан павильонын төзү аның проекты буенча башкарылырга тиеш була.



*Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсендәге Татарстан павильоны. 1940 елгы фоторәсем.*

Оста бөтен җыйган тәҗрибәсен, сәләтен, күңелендәге хыялларын бергә туплап, җан-фәрманга эшкә керешә. Сызымнар берсе артыннан берсе кәгазьгә төшә, рулон-рулон калькалар киштәләргә өелә. Срок зур түгел, көннәрне төнгә ялгап эшләргә туры килә. Һәм, ниһаять, проект әзер. Исмәгыйль һәр детальнең, һәрбер кечкенә генә төзем кисәгенең дә үзе хыял кылганча ясалып чыгуын тели. Ул коручы инженерлар, һөнәрчеләр, металл осталары, агач осталары белән сәгатьләр, көннәр уздыра. Кадерле сәнгать әсәре, бигрәк тә архитектура әсәре төзер өчен төземче проект сызымнарыннан башлап, ишекләрне тупсаларына утыртканга кадәр һәр нәрсәне үзе карап, үзе күрсәтеп торып эшләтергә тиеш. Исмәгыйль шундый. Ул тәрәзәнең шпингалетын да үзе теләгәнчә ясата. Бу оригинал һәм нәфис төзем әсәрендә архитекторның бөтен иҗади хыялы, классик көнбатыш архитектурасы, көнчыгыш төзем стильләре һәм татар халкының төзелеш сәнгате хәзинәләре барысы да тиешле чагылышын тапкан иде. Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсе Советлар Союзында яшәүче халыкларның төзем сәнгате казанышларын да дөньяга танытты. Татар павильоны тамаша өчен күренекле урында һәм башка павильоннар янында төземчелек сәнгатенең иң җитди, иң камил ясалган әсәрләреннән берсе булып торды. Шул вакыттагы совет матбугатында бу бинаның гүзәл сыйфатлары хакында күп язылган. Чыннан да, павильон татар төзем сәнгатенең шедевры иде. Якын киләчәктә татар халык сәнгатенең музее, әлбәттә, корылса кирәк. Ул музей шул павильон проекты белән ясалса, татар төзем сәнгатендә зур казаныш булыр иде.

Илленче еллар уртасында Казан елгасы тамагы киңәйтелеп, Казан янында зур елга порты салынды. «Зур су» Казанның өйләренә тәмам орынып, Яңа бистәнең эченә килеп керде диярлек. Өчәр катлы пассажир теплоходлары Казанның кырыена килеп туктый башладылар. Портта мәһабәт кыяфәтле елга вокзалы ансамбле калкып чыкты. И. Гайнетдинов проекты белән корылган бу ансамбль менә ике дистә ел буе тирәюньгә ямь биреп, үзеннән нур таратып утыра. Элекке ике бистә арасы хәзер шәһәрнең иң матур төбәкләреннән берсе. Татарстан проспектының бу очы шушы ансамбль урнашкан мәйданга килеп терәлә. Кремль диварлары яныннан башлап елга портына, аннары Татарстан проспектына борылып киткән дуганың очы шәһәрнең иң күркәм паркларыннан берсе булып бара.



*Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры.*

Бу төбәктә яңа корылышлар булыр әле. Әшне дәвам иттерәчәк төземчеләр Исмәгыйль ага[1] салган идеягә төшенеп, ул төбәкнең архитектура бердәмлеген саклар-лар дип ышанасы килә.

Ерактан килә торган теплоходлар өчен якты маяк кебек ялтырап торган вокзал Идел ягыннан Татарстанның башкаласы Казанның парад капкасы булып тора. Шәһәрдән барганда да, су өстеннән шәһәргә килгәндә дә ансамбльнең үзәге булган вокзал шул кадәр җиңел тамаша кылына ки, гүя ул табигый рәвештә җирдән үсеп чыккан. Җиңел формалардан корылган бу бина шәһәрдән килгәндә уникe җыйнак, сылу колоннасы, төрле төстәге майолик паннолары белән күңелгә шатлык биреп каршы ала. Шәһәр белән зур елганы һәм портны тоташтырып баглаган бер алтын боҗра кебек ул. Вокзал бинасы берсе шәһәр тарафына, икенчесе елгага караган ике фасады белән табигать һәм зур корылыш арасында органик бердәмлек, уртаклык хисе тудыра. Бинаның урта бүлеме үтә күренмәле пыяла диварлардан ясалган. Бу бүлектә пассажирлар залы. Алар, урыннарыннан да кузгалмастан, бу ике витраж аша елга өстен һәм вокзал алды мәйданын тамаша кыла алалар.

Вокзалның бөтен ансамбле, сәяхәтчеләргә төрле уңайлыклар тудыра торган павильоннары — барысы да портның җир-су хосусиятләрен исәпкә алып планлаштырылган.

Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера-балет театры архитекторның әсәрләре арасында аерым бер урын тота. Әүвәл шуны әйтергә кирәк, театр бинасын проектлауның үзенә генә хас мәҗбүри шартлары бар. Ул шартлар аның конструкциясендә әһәмиятле роль уйный. Шунлыктан опера-балет театры биналары конструктив яктан берсеннән-берсе аз аерыла. Исмәгыйль өчен дә шул кысаларда эшләү зарур була. Шулай да останың төземчелек хыялы ашкыр булса, ул театр таләпләренә буйсынырга тиешле схема нигезендә дә үзенең иҗади кодрәтен күрсәтә ала.

Исмәгыйль ага опера театрын бер киң симфоник музыка кебек хыял кылгандыр төсле. Күләме дистәләрчә мең кубик метр булган бинаны тамашачының күзен ялык-

---

[1] «Ага» дип, остаңы хөрмәтләү йөзеннән әйтелә.— Автор.

тырмаслык, йөрергә уңайлы итеп, бизәкле маршлар, баскычлар белән җиһазлау тәҗрибәле остадан да гаять зур иҗади киренкелек, чиксез дәрт, илһам таләп итә. Ул баскычлардан сез гади көнкүреш мәшәкатьләрен, хафа-борчуларны тышта калдырып, сәнгать дөньясына керәсез. Оста аларны әнә шундый булырлык итеп ясаган да. Гардероб бүлегендә өске киемнәрегезне салып, мәрмәр баскычлардан күтәрелгәндә сезнең күңелне бер шатлыклы шаукым, якты бер хис биләп ала. Чыннан да, гади бер бинаның беренче катыннан икенче катына менү генә түгел, бәлки көндәлек тормыш дөньясыннан сәнгать дөньясына күчү бу. Хакыйкатән, тәзүченең ул әсәргә сарыф иткән иҗади кодрәте хәйран калырлык, һәр детальне үзе карап эшләткәнен искә алсаң, куйган хезмәте чиксез зур.

Бу дәү сәнгать бинасының эчләп-тышлап һәр почмагында, һәр деталендә пөхтәлек, нәзакәтле зәвык билгесе бар. Театрның музыка йорты икәнлеген истә тотып, оста бинаның бөтен почмакларындагы, түшәм һәм диварлардагы декорга музыкаль рух бирә, гүя аның һәрбер бизәге җырлый, моңлана, бии, уйный. Бина борынгы классик стильдә төзелгән, ләкин терәкләрен, капительләрен, тәрәзә яңакларын, башка кисәкләрен ясаганда татар декоратив бизәкләре хәзинәсе урынлы һәм мул файдаланылган. Моның өчен илһам һәм хыялыңа киң ирек бирү белән бергә, бик сизгер ритм тойгысына ия булырга, һәр нәрсәдә гармоник пропорциягә ирешергә кирәк. Останың бу шедевры шундый югары иҗади дәрт белән тудырылган да.

Казанның Карл Маркс урамыннан узганда химия-технология институтының садә дорик стильдә ясалган мәһабәт портал колоннадасы игътибарны җәлеп итә. Элекке эшләреннән берсе булган бу бинада ук инде И. Гайнетдинов иҗатына хас билгеләр күренә. Ул — җыйнаклык, тыйнаклык һәм пөхтәлек. Бина урамнан эчкә кертеп салынган. Маркс урамына аның бары кечкенә ян фасады гына чыга. Ләкин төземче ул бинаны К. Маркс урамы ягыннан күрсәтәсе килә. Һәм шул кечкенә мәйданлы фасадны ул ротон формасындагы дорик колонналар белән терәкләнгән портик рәвешендә хәл итә. Бу — бер иҗади тапкырлык. Зур уку йорты бинасын без шул мәһабәт портикка карап истә калдырабыз. Исмәгыйль шул ук утызынчы елларда Казанда янә берничә бина төзи. Шулар арасында мехчылар клубын һәм башкаларны күрсәтергә була.

Без төзем остасы Исмәгыйль аганың өч-дүрт әсәренә генә аерым тукталып уздык. Илле еллык иҗат гомере эчендә ул алтмыштан артык проект ясаган, конкурсларда аның унлап эше беренче премия белән билгеләнгән, илледән артык проекты эшкә ашырылган. Без әле аның монументлар корудагы хезмәтләре хакында әйтмәдек. Шуларның премияләргә лаек булганнары арасында Орджоникидзе шәһәрендә шагыйрь Коста Хетагуровка, Уфада Салават батырга салынган һәйкәлләрнең архитектура өлеше Исмәгыйль ага проекты белән төзелде.

Гали абый улының табигатендә аерым сирәк зәвык, камиллеккә омтылыш һәм талымсыз эшчәнлек тупланган икән. Казанга килеп, корымчылык институты рабфагына кергән вакытта аны җитәкләп йөргән кеше булмаган. Үзенә хас бер эчке сизем аны бу институтка китерә. Инде бу сукмакка кереп алгач, архитектураның олы урамына барып ирешергә аның дәрте дә, дәрманы да, теләге дә, тырышлыгы да җитә. Ул үз инициативасы белән борынгы татар корым һәм төзем әсәрләрен, җимерелгәннәренең хәрабәләрен тикшереп, татар архитектура формаларын табу юлында гыйльми эзләнүләр алып барды. Аңардан алда бу юнәлештә сукмак салган осталар юк иде. Тарихи әсәрләре начар сакланган безнең халыкның корым-төзем һәм, гомумән, материаль культурасын тикшереп өйрәнү өчен зур ашкыну һәм зур тырышлык, түзем кирәк. Шуңа күрә дә Исмәгыйль Гайнетдиновны яңа чорда милли архитектурабызга яңадан нигез салучы дип атарга хакыбыз бар. Ләкин бу гади реставрация түгел, реконструкция дә түгел, яңадан иҗади ясау иде.

Чын иҗади кодрәте булган сәнгатьче иҗатында, ул нинди генә тарихи әсәрләрдән файдаланып эшләмәсен, классик шедеврлар аның иҗатына нинди генә йогынты ясамасын, заман рухы, дәвернең эстетик үлчәме сизелеп торырга тиеш. Исмәгыйль

ага эшчәнлегендә һәр вакыт заман белән бергә атлады. Илле еллык иҗат гомерендә ул эзләнүдән һич туктамады, һаман яшь, һаман егет булып калды. Оста әүвәл үзенең белем, зәвык һәм акыл үлчәвенә салып, төзелештәге борынгы формаларның хәзерге заманга хас булган кыйммәтләрен билгели. Шуннан соң гына алардан файдалана.

Югарыда әйтеп киткәнебезчә, татар архитектура әсәрләре бик аз санда калган. Бу әсәрләрне кадерләп саклауны үзенең изге бурычы санап, шул хакта гамь чигеп йөрүчеләрнең берсе — Исмәгыйль ага. Сөекле Татарстанына, Казанга аны күп җепләр бәйли. Иң күркәм иҗат җимешләре дә Казанга баглы аның. Ул Казанда үзе сызган биналар — бигрәк тә күп дәрт вә дәрман сарыф иткән опера һәм балет театрының хәле белән һаман кызыксынып-хафаланып тора. Казанга килгән саен театрга барып, бинаның нинди хәлдә булуын тикшереп үтә. Бинаның тышкы һәм эчке күренешендә берәр чатаклык күрсә, борчыла башлый. Бу табигый. Иҗади эшләрендә җитди булган остага шулай тиештер дә. Иҗади намуслылык — аның төп сыйфатларыннан берсе.

Без аның белән 1957 елда Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында катнаштык. Мәскәүнең Зур театрында йомгаклау концерты эскизларын ясау өчебезгә — Исмәгыйль агага, рәссам Чыңгыз Әхмәровка һәм миңа тапшырылган иде. Байтак бәхәсләшергә туры килде. Ләкин бу тәмле иҗади бәхәс иде.

Исмәгыйль болай тыныч, тыйнак кеше булса да, эш өстендә кызып бәхәсләшеп, үзенең багымын каты яклый белә. Иҗат кешесе өчен бу һич тә яман сыйфат түгел. Дәртсез эшләнгән әсәрләрдә сүлпәнлек була. Аның әсәрләрендә сүлпәнлек юк. Барча эшләре дәрт һәм аерым пөхтәлек белән ясалган.

Халкыбызның профессор-төземче Исмәгыйль Гайнетдинов белән горурланырга хакы бар. Ул эшче халкы арасыннан чыккан, тырышлыгы, намуслы хезмәте һәм илһамы белән гыйлем һәм сәнгатьнең югары баскычларына ирешә алган. Аның тормышы яшь буынга чыннан да үрнәк булып торырлык.

**Вячеслав Воздвиженский,**
**Миләүшә Маннурова**
филология фәннәре кандидатлары

# МУСА ҖӘЛИЛ ҺӘМ КАРШЫЛЫК ХӘРӘКӘТЕ ПОЭЗИЯСЕ

Татар әдәбиятының бөтендөнья, шул җөмләдән Европа күләмендә тоткан урыны һәм роле әле тиешенчә өйрәнелмәгән. Безнең алда әнә шул кимчелекне бергәләшеп күпмедер күләмдә бетерү бурычы тора. Моның өчен исә гомуми характерда сүз йөртүләр генә җитми, ә бәлки конкрет материалларга таянып эш итү сорала. Укучыга тәкъдим ителә торган бу мәкаләнең төп максаты шундый конкрет материалга — Муса Җәлилнең героик лирикасы белән француз Каршылык хәрәкәте шагыйрьләре арасындагы бәйләнешкә тукталудан гыйбарәт.

Солдат поэзиясендә Муса Җәлилнең үз урыны бар. Ул вакытлыча дошман тозагында калып, чәнечкеле тимер чыбыклар белән әйләндереп алынган лагерьда фашистлар белән йөзгә-йөз очрашкан әсирләр исеменнән сөйли. Моабит шигырьләрендә үлемгә хөкем ителгән, әмма дошман каршында тезләнмәгән көрәшчеләрнең драматик язмышы, рухи ныклыгы тасвирлана. Шагыйрь һәм аның лирик герое бер генә минутка да язмышка буйсынмыйлар.

> ...мине синнән аера
> Чәнечкеле тимер коймалар.
> Аерса да тәнне, коллык сөймәс
> Мәгърур күңелем өчен юк алар.

Моабит циклына кергән шигырьләрдәге төп идеяләрнең берсе әнә шул. Геройның рухи көче фашизм дәһшәтеннән һәр вакыт өстен тора, тантана итә. Монда әсирлеккә төшсә дә кулыннан коралын ташламаган, каршылык күрсәтүен, көрәшүен дәвам иттергән сугышчы күз алдында тотыла. Муса Җәлил шигырьләренең дөньякүләм яңгырашка ия булулары нәкъ әнә шуның белән аңлатыла да.

Муса Җәлил иҗатын, бигрәк тә аның Моабит шигырьләрен француз Каршылык хәрәкәте поэзиясе белән янәшә куеп, чагыштырып карау кызыклы нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Билгеле булганча, 1940 елда Франция яулап алынгач, аның территориясенең шактый өлеше фашистлар кул астында кала. Француз әдипләренең күпчелеге бу чорда гитлерчыларга каршы җәелеп киткән бөтенхалык хәрәкәтенә кушыла. Антифашистик көрәш төрле формаларда алып барыла. Антифашистларның тәвәккәл эшчәнлекләре аркасында Франциядә дистәләрчә газета-журналлар чыга башлый, патриотик характердагы күп санлы әсәрләр басыла. Бу юнәлештә актив эшләүчеләрдән 1939 елда ук инде поэтик көчләрне бергә туплый башлаган шагыйрь һәм нашир Пьер Сегерсны күрсәтеп үтәргә була. Ул солдат поэзиясе үрнәкләрен «Каскалы шагыйрьләр» дигән исем астында аерым җыентыклар итеп чыгара башлый. Соңга таба Кар-

шылык хәрәкәтенең елга бер чыга торган «Поэзия» альманахын редакцияли, күп кенә яшерен нәшриятлар эшендә якыннан катнаша.

1941 елда ул илдәге башка яшерен басмалар янына француз язучыларының милли комитеты органы — коммунистлар партиясе инициативасы белән оештырылган атналык «Лэттр франсэз» газетасы өстәлә. Бу яшерен басманы хәзерләүне коммунист язучы, соңыннан гитлерчылар тарафыннан атып үтерелгән Жак Декур үз өстенә ала.

Франциянең үзендә яшерен эш алып баручылар үрнәгендә бу гомуми эшкә үлем лагерьларына куылган әсирләр, Алжир, Англия һәм башка илләрдәге француз сугышчылары зур өлеш кертәләр. Вакыйгаларның кайнар эзеннән барып, алар французларның авыр трагедиясен һәм халыкның киләчәккә булган өметләрен чагылдырган шигырьләр иҗат итәләр. Француз шагыйрьләренең авазы бөтен дөньяга тарала. Көрәшнең алгы сафына баскан бу поэзия сугышчыларның күңелләрен күтәрә, җиңүгә ышанычларын арттыра, дошманнар йөрәгенә курку сала.

Француз Каршылык хәрәкәте әдәбияты турында сөйләгәндә, аның яшерен шартларда басылуын һәм таратылуын, моның исә оперативлык, эчтәлекнең максималь дәрәҗәдә тыгыз булуын таләп иткәнлеген һич тә истән чыгарырга ярамый. Бу таләпләрне үтәү исә барыннан да элек лирик поэзиягә йөкләнә. Менә шуңа күрә дә оккупация чорында француз әдәбиятында лирик поэзия үзенең иң югары ноктасына күтәрелә. Француз поэзиясе тарихына бу чорда Поль Элюар һәм Луи Арагон, Робер Деснос һәм Андре Френо, Жан Кассу һәм башкалар менә дигән гүзәл сәхифәләр өстиләр. Бу хакта шагыйрь Жан Марсенак түбәндәгечә язды: «Иртәләрнең берендә кояш бөтенләй күренмәс булды, төн үзенең зур ачылган күзләре белән безнең йөрәкләргә кереп утырды, җыясы ризыгыбыз тамагыбыздан үтмәс булды... һәм шул вакыт шагыйрьләр калкып чыкты. Ярсуларын тыя төшеп, алар Францияне үз кулларына алдылар һәм... азатлык җырда коткарып калынды...»

Сегерс, Арагон, шулай ук башка шагыйрьләрнең тырышлыгы белән 1943 елның июлендә һәм 1944 елның маенда яшерен төстә «Шагыйрьләр намусы» исемле шигырь китаплары басылып чыга. Ул китапларда Поль Элюар, Луи Арагон, Робер Деснос, Андре Френо һәм шулай ук исемнәре билгесез башка шагыйрьләр катнаша.

«Антифашистик поэзия» төшенчәсе фашистларга каршы көрәшүче эмигрантлар поэзиясен, яшерен оешмаларда, төрмәләрдә, концлагерьларда, баракларда язылган шигырьләрне үз эченә ала. Сегерс үз альманахының 1940 елда чыккан беренче санында ук инде әсир шагыйрьләрнең әсәрләренә киң урын бирә. Ә 1943 елда тулысынча алар иҗатына гына багышланган махсус җыентык бастырып чыгара.

Концлагерьларның барлык михнәт-газапларын ватандашлары белән тигез бүлешкән әдипләр анда да чын шагыйрь булып калалар. Алар француз халкының һәм аның поэзиясенең тормышчанлыгын, яшәргә, көрәшергә сәләтле булуын раслыйлар. Әлеге җыентыкта Эдит Тома псевдонимы белән басылган бер шигырь укучы күңелендә аеруча тирән тәэсир калдыра:

**Әй, син тынлык, әй, син матурлык!**
**Ишетелә кошлар тавышы.**
**Ә үзәндә искән җилләргә**
**Килеп кушыла йөрәк сагышы.**
**Эшафотта элмәк тирбәлә,**
**Богау чыңы җанны сызлата.**
**Кул-аягым минем чылбырда,**
**Җәй һәм җырлар — авыр йозакта.**

Җыентыкка Андре Френо шигырьләре дә урнаштырылган. Бранденбург концлагеренда иңнәренә күтәреп цемент ташыган шагыйрьнең шигырьләре шул цементтан бушаган кәгазь кисәкләренә язылган. Концлагерьдан аларны Франциягә Луи Арагонның «элемтәчесе» алып кайткан.

1944 елның февралендә егерме алты яшьлек француз шагыйре Жак Лоран Германиядә үлем җәзасына хөкем ителә. Аны поездда кулга алалар. Чемоданыннан антифашистик поэмалар һәм листовкалар табыла. Бухенвальдта ул Либкнехт, Люксембург һәм Ленинга багышлап «Өч Л» дигән поэма иҗат итә. Лагерьда кемдер аның

өстеннән донос язый. «Азатлык, мин сине ялварып сорамыйм, чөнки үз йөрәгеңне, үз каныңны ялварып сорап булмый. Соңгы сулышыма кадәр син минем һәр күзәнәгемдә»,— дип яза ул үзен атарга алып китәсе төнне.

Яшь коммунист Мадлен Риффо француз Каршылык хәрәкәтендә унсигез яшеннән катнаша башлый. Фашист офицерларына көпә-көндез һөҗүм иткәне өчен кулга алына. Аны бик каты газаплыйлар һәм Френ төрмәсенә ябалар. Париж азат ителер алдыннан төрмәдәге барлык тоткыннарны төрле концлагерьларга озаталар, үлемгә хөкем ителгәннәрен аталар. Зур һәм буш төрмәдә өч кенә тоткын торып кала. Алар арасында Мадлен Риффо да була. Нинди дер могҗиза аркасында үлем тырнагыннан котылган Мадлен төрмәдә кулына каләм ала. Яшь шагыйрьнең «Йомарланган йодрык» исемле шигырьлр җыентыгына кереш сүзне Поль Элюар үзе яза.

Париждан Освенцим үлем лагерена озатылган еврей хатын-кызлары анда «Парижанкалар» дигән яшерен группа оештыралар. Аларның бердәмлеге, ирек хакына үзләренең тормышларын да корбан итәргә әзер торулары һәркемдә соклану һәм ышаныч тудыра. Бу группада катнашучылар берничә җыр язалар. Зур сәнгать әсәре югарылыгында тормасалар да, ул җырларда көчле пафос һәм эпик характер бар.

Авыр сынау елларында поэзия дошманга каршылык күрсәтүнең төп формасы була. Менә шуңа күрә дә Каршылык хәрәкәте шагыйре Жан Марсенок болай дип яза: «Икмәк паегыбыз һәм поэзия паегы бар иде, шулар безне үлемнән коткарып калды».

Поэзия әсәрләре ил-җирләреннән аерылган тоткыннарга рухи көч бирә, аларга ахырынача көрәшче булып калырга булыша. Моны раслау өчен «Моабит дәфтәрләре»нең Франциядәге концлагерьларда язылган шигырьләр белән бик нык аваздаш булуларын әйтеп үтү дә җитә. Муса Җәлилнең фашистлар әсирлегендә язылган шигырьләре дә коллыкка, дошманның вакытлы тантана итүенә каршы торган зур реаль көч. Поэзия Муса Җәлилгә һәм аның көрәштәшләренә батырлык чыганагы булып хезмәт итә, авыр шартларда аларга бетмәс-төкәнмәс көч бирә. Ул шигырьләрдә сүз һәм эшнең, поэзия һәм биографиянең тулы бердәмлеге, аерылгысыз булуы ачык чагыла. Шундый ук бердәмлекне без Каршылык хәрәкәте шагыйрьләре иҗатында да күрәбез. Луи Арагон «Хөкем вакытында җырлаган кеше турында баллада»сына эпиграф итеп реаль геройның — Франция коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты члены Габриэл Периның үләр алдыннан язып калдырган: «Яңадан яши башласам, мин шул ук юлымны кабатлар идем»,— дигән сүзләрен ала. Бу һич тә очраклы хәл түгел.

Гомуммилли хәрәкәттә турыдан-туры катнашу француз поэзиясе өчен социаль тәрбия һәм гражданлык тәҗрибәсе мәктәбе ролен үти. Анда халык белән, җәмгыять һәм аерым кешеләр белән тыгыз бәйләнештә булу кирәклеге кискен чагыла. 1943 елның июнендә Жан Тардье: «Поэзия, хәтта иң интим поэзия дә үз эченә бикләнә алмый. Дөресрәге, без бикләнә алмыйбыз, үзебез өчен генә бикләнергә безнең хакыбыз юк», — дип язды.

Һәм, чыннан да, француз Каршылык хәрәкәте поэзиясенә геройның халык белән, ватандашлары белән конкрет бәйләнештә булуы характерлы. Мондый бәйләнешне өзәргә берниндн төрмәләрнең дә, чәнечкеле тимер чыбык белән уратылган концлагерьларның да көче җитми.

Шул уңай белән үзен туган иленең, халкының бер өлеше итеп санаган Муса Җәлилне искә төшереп үтми мөмкин түгел. Моабитның ялгыз камерасында да Ватанына тугрылыклы булып калган герой-шагыйрь менә болай ди:

**Юк, кайгырма, дускай, безнең гомер**
**Ил гомеренең тик бер чаткысы,**
**Без сүнсәк тә, безнең кыюлыктан**
**Арта бары аның яктысы.**

Яшерен оешмаларда, концлагерьларда көрәшкән һәм иҗат иткән шагыйрьләрнең максат уртаклыгы аларның поэтик авазларын да бер-берсенә охшаш итә. 1944 елның 1 маенда Поль Элюар һәм Луи Арагон «Европа» исемле яңа антология бастырып чыгаралар. Анда Робер Десносның бер поэмасы да урнаштырыла. Шунысы характерлы, нәкъ шул көнне (1 майда) бу шагыйрьне Бухенвальд концлагерена китерәләр. Ул 1944 елның 22 февралендә кулга алынган була. Десносны хакыйкать җырчысы дип

атыйлар. Үзе өчен иң авыр вакытларда да ул дөреслекнең күзенә туры карый. Кулга алынганнан соң язган «Туган яклар» дигән шигырендә Деснос үзенең соңгы көннәре якынлашуын сизә. Ләкин рухи төшенкелеккә бирелми. «Моабит дәфтәрләре»ндә дә бу тема үзәк урынны алып тора. Муса Җәлил дә ачы чынбарлыктан йөз чөерми. Үлем көткән минутларында да совет иленең җиңәчәгенә ышана.

**Җырлап үттем данлы көрәш кырын,**
**Җырлап килдем тормыш языма.**
**Соңгы җырым палач балтасына**
**Башны тоткан килеш языла.**

Яңадан Робер Десноска әйләнеп кайтыйк. Лагерьдан яңа гына азат ителгән Деснос 1945 елның 8 июнендә тифтан үлә. Чех тәрҗемәчесе һәм тәнкыйтьчесе Адольф Крупа раславынча, гомеренең соңгы көннәрендә шагыйрь төрле кәгазь кисәкләренә карандаш белән нәрсәләрдер сызгалый. Бу аның хатынына багышлап язылачак поэмасының караламалары булырга тиеш.

**Синең хакта күпме хыялландым,**
**Синең хакта күпме сөйләдем.**
**Истәлегең булып шәүләң генә**
**Калачагын ник соң белмәдем.**

**Синең кояш тулы тормышыңда,**
**Кояш балкып торган көнеңдә**
**Бер кат түгел, йөз кат шәүлә булып**
**Калдым бугай инде үзем дә.**

Менә шушыңа охшашлы шигырьләр Десносның һәм аның лирик героеның кешелеклелек хисләрен тулысынча саклап калулары турында сөйлиләр. һәм без Муса Җәлилнең дә шундый ук поэтик позициядә торганлыгын яхшы беләбез. Иң авыр шартларда да ул интим кичерешләрдән ваз кичми. Җәлилнең Моабит, Тегель, Шпандау төрмәләрендә утырган көннәре турында мәгълүматлардан һәм аның үзенең лирик шигырьләреннән безнең күз алдына олы җанлы, тирән кичерешле кеше образы килеп баса. Аның герое — үз язмышы турында уйланып, җирдә эзем калырмыюкмы дип кайгыра һәм борчыла белә торган шәхес. Муса Җәлил һәм аның каләмдәшләре — француз Каршылык хәрәкәте шагыйрьләре өчен әнә шул нәрсә бик мөһим һәм кадерле.

1944 елның февралендә Луи Арагон «Яшерен рәвештә язылган 33 сонет турында» дигән мәкалә бастыра. Анда сүз немец төрмәсендә утырган Жан Кассу әсәрләре хакында бара. Л. Арагон аның чын мәгънәсендә интернационалист булуына басым ясый. Бу хакта сүз барганда без яңадан Муса Җәлилгә тукталып үтмичә булдыра алмыйбыз. Ул, немец милләтеннән булган фашист палачларының барлык кабәхәтлекләрен һәм мыскыллауларын үз башында кичергән совет шагыйре, Германиянең үзенә пычрак ыргытмый. һәркемгә билгеле булган «Алман илендә» шигырендә ул бөтен немец халкының кешелеккә дошман булуына ышанырга теләми, Гитлер Германиясенә Бетховен һәм Гейне, Маркс һәм Тельман Германиясен каршы куя.

Француз Каршылык хәрәкәтенең иң күренекле шагыйрьләреннән берсе Поль Элюар исемен яңадан бер тапкыр телгә алмыйча үтү мөмкин түгел. Бу зур шагыйрь коммунистлар партиясе сафына 1942 елда керә. Ватаны өчен иң авыр чакта ул Каршылык хәрәкәтенең күренекле вәкиленә әйләнә. Аның шигырьләре кулдан-кулга күчерелеп таратыла, листовкаларда басыла, чын халык поэзиясе үрнәкләре югарылыгына күтәрелә. Фашистлар тарафыннан «куркынычлы» кеше дип игълан ителгәч, ул ай саен торган урынын алыштырырга мәҗбүр була. Тыелган яшерен китапларны һәр очракта үзе белән алып китә һәм аларны ватандашлары арасында тарата. Үзе гестапо эзәрлекләвеннән качып йөргән хәлендә, төньяк һәм көньяк Франциядәге яшерен группалар арасында элемтә урнаштыра, кечкенә генә бер типография табып, аны яшерен әдәбият бастыру өчен җайлаштыра. Каршылык хәрәкәтендә актив катнашу аның иҗатына зур йогынты ясый. Элек катлаулы поэтик манерада язган лирик шагыйрь көрәшкә хезмәт итә торган шигырьләре өчен укучыга тиз барып җитә алыр-

лык яңа, реалистик алымнар таба. Үлемсез батырлык һәм дошманга нәфрәт турында һәркемгә аңлаешлы сүзләр белән яза башлый.

Җәлил һәм Элюар иҗатларын бер дәрәҗәгә куеп тикшерү монда бәлки ясалма да булып тоелырга мөмкин. Бу шагыйрьләрнең язмышлары төрлечә, биографияләре, иҗат ысуллары бер-беренә охшаш түгел. Әмма аларның сугыш елларында иҗат иткән шигырьләренең үзара якынлыгы тышкы охшашлыкта түгел. Бу якынлык — аларның нинди художество позицияләрендә торуында, фашизм белән көрәш чорында иҗатларының нинди роль уйнавында, иҗат тенденцияләренең тирәнлеге нинди булуында.

Элюар лирикасында гәүдәләнгән төп нәрсә — басып алынган, әмма көрәшүен дәвам иттергән Франциянең драматизмы. Шагыйрь үзе әсирлектә булмаган. Ләкин ул иленең, шуның белән бергә үзенең дә әсир икәнлеген ачык тойган. Менә ни өчен аның газаплары Муса кичергән газаплар белән аваздаш яңгырый.

Элюар һәм Җәлил кичергән трагедияләренең чыганагы вакытлыча булса да фашизм, изү, вәхшилек тантана иткән чынбарлыкка түзеп тора алмау. Бу трагедия — Җәлилдә «Бүреләр», «Вәхшәт» һәм башка шундый шигырьләрендә. Җиргә тере килеш күмдермәс өчен, ананы үз баласын пуля астына куярга мәҗбүр иткән фашистлар вәхшилегеннән дә зуррак тагын нинди явызлык бар?!

**Әйт син миңа, миллион еллар яшәп,**
**Син бакчалы, күлле, чәчәкле,**
**Күрдеңме тик бер кат үз гомереңдә**
**Мондый хурлык, мондый вәхшәтне!!**

Элюарның «Поэзия һәм дөреслек» җыентыгындагы шигырьләрендә дә халык кайгысын гәүдәләндергән образлар Франциядә оккупантлар кылган җинаятьләрне фаш итүче образлар белән чиратлашып килә. Әмма Җәлилдә дә, Элюарда да кара көчләрнең башбаштаклыгы, котырынулары кешеләрдә курку түгел — нәфрәт, өметсезлек түгел — каршылык күрсәтү өчен ихтыяр көче тудыра. Менә шуңа күрә дә аларның гитлерчыларга, палачларга каршы юнәлтелгән шигырьләре — дошманның чын йөзен фаш итү, аның идеалларын кире кагу ул. Фашизмның вәхшилегенә түзеп тора алмау хисе аны юк итү өчен турыдан-туры көрәшкә өндәүгә күчә. Авторлар нацизмның кешелеккә каршы асылын гиперболик формаларда ачып бирү өчен гротеск һәм фантастик образларга мөрәҗәгать итәләр. Муса Җәлилнең «Төрмә сакчысы» шигырендә эсэсчы кан һәм күз яшьләре белән туенучы үлем ялчысы итеп сурәтләнә. Бай метафораларга нигезләнгән «Таш капчык» шигырендә гитлерчылар режимы кеше мәетләрен тартучы тегермән белән чагыштырыла. «Сихерле йомгак» шигырендә фашистлар Германиясе безнең күз алдыбызга әкиятләрдә сөйләнә торган явыз көчләр патшалыгы булып килеп баса.

Үзләрен Франциягә хуҗа итеп санаучы гитлерчы вәхшиләрнең чын йөзен ачып салу өчен Поль Элюар да көчле, гади һәм укучыга аңлаешлы сурәтләү чаралары куллана. Аның сугышка кадәрге иҗатында явызлык еш кына реаль тормыштан ерак булган ниндидер мәңгелек көч итеп күрсәтелә. Хәзер исә шагыйрь әсәрләрендә бу абстракт көч мәкерле дошманны күз алдына китереп бастырырлык конкрет образлар белән алышына. «Хайваннар һәм явыз җаннар» дигән шигырендә Элюар үз Ватанын канга батырган илбасарлар турында ышандырырлык итеп сөйли.

**Килә алар штыкларын сузып,**
**Хәнҗәрләрен тагып киләләр.**
**Ранецларында тик үзләренең**
**Үлемнәрен алып киләләр.**

**Палачлары килә күкрәк киереп,**
**Алар өчен хисләр чит нәрсә.**
**Дагаланган пычрак итекләрен**
**Мактап җырлый алар, җитмәсә.**

Поль Элюар героик француз патриотларын әнә шуларга каршы куя. Ватандашларын ул һәлак булган көрәшчеләргә алмашка чакыра.

1942 елда Поль Элюарның «Хәбәр» дигән шигыре фашистлар тарафыннан атылуга хөкем ителгән француз көрәшчеләренең исемлеге янына Париж стеналарына ябыштырыла. Шигырьдә сүз Франциянең азатлыгы өчен фашист тоткынлыгында һәлак булган меңнәрчә исемсез геройларның берсе турында бара. Ләкин шагыйрь аны кызганып яшь түкми, ә үч алырга чакыра. Андый шигырьләр Каршылык хәрәкәте көрәшчеләрендә киләчәккә ышаныч һәм батырлык рухы тәрбияләделәр.

Муса Җәлилнең Моабит циклындагы шигырьләрендә дошман каршында тез чүкмәү, соңгы сулышкача кыю көрәшче булып калу кебек мотивларның өстенлек итүе турында сөйләп тә торасы юк. Әсирнең кайгы хисләрен аның каршылык күрсәтүгә юнәлдерелгән нәфрәте күмеп китә.

Ләкин Җәлил геройлары да, Элюар геройлары да бары тик көрәш белән генә яшәмиләр. Иң авыр минутларда да алар тормышны тулы килеш кабул итү сәләтен югалтмыйлар. Фашистларның кансызлыгына Элюар һәм Җәлил кешенең якты хисләр, кичерешләр белән тулы дөньясын каршы куялар. Кешенең матур сыйфатларыннан берсе төсендә һәр ике шагыйрь мәхәббәткә дан җырлыйлар.

Элюар мәхәббәтнең чын мәгънәсен кешеләрнең бер-берләре белән эчкерсез мөнәсәбәттә булуларында күрә. Чәнечкеле тимер чыбык эчендәге концлагерьларда һәм төрмәләрдә газап чигүче миллионнарча гади французларның язмышын күреп борчылган шагыйрь аларны юатырга, аларга көч һәм дәрт бирергә тели. Шулай ук ул, туганнарына, якыннарына, улларына ярдәм кулы сузарга чакырып, аларның сөйгәннәренә, хатыннарына, аналарына мөрәҗәгать итә.

**Миллион эшче… миллион тоткын монда**
**Көтеп тора фашист карарын.**
**Төрмәләрдән алып чыккан юллар**
**Төшләренә керә аларның.**

Муса Җәлил дә шул ук образны — тоткынлыктан иреккә алып чыгарга тиешле юллар образын куллана:

**Юллар, юллар! Мине илкәемнән**
**Аерып ерак алып киттегез.**
**Яңа дәртләр, яңа хисләр белән**
**Сөйгәнемә кире илтегез.**

Авыр сынаулар аша узган мәхәббәткә һәм сөйгән кешесенә тугрылык темасы «Моабит дәфтәрләре»ндәге байтак шигырьләрдә урын ала.

Муса Җәлил һәм Поль Элюар иҗатында лирик поэзиянең күп кенә үзәк, мәңгелек проблемалары — кешенең тормыштагы урыны, үлем һәм үлемсезлек, ирек турында язылган шигырьләр шактый күп. Муса Җәлилнең «Ирек» шигыре, мәсәлән, кеше тормышының, яшәешнең иң югары мәгънәсе булган ирекне, азатлыкны, бәйсезлекне раслый. Бары тик ирек кешене кеше итә, аның тормышын мәгънәле, тулы эчтәлекле итә.

**Нәрсә соң ул, иркем булмагач,**
**Бар булуым белән юклыгым.—**

ди шагыйрь бу хакта тирән уйланып.

1942 елда Поль Элюар да шул ук фикерне диярлек әйтә:

**Мин сине татыр өчен тудым, Азатлык!**

Әйтелгәннәрдән чыгып шундый нәтиҗә ясарга мөмкин: бер үк иҗат шартлары һәм көрәш максатларының уртаклыгы, беренче карашка бер-берләреннән ерак булып күренгән әдипләрнең поэтик позицияләрен үзара якынайта. Чагыштырганда алар арасындагы аермалыкларны да күрсәтергә мөмкин булыр иде, әлбәттә. Муса Җәлил социалистик реализм сәнгате вәкиле буларак иҗат итә. Ә француз Каршылык хәрәкәте шагыйрьләренең эстетик программасы шактый чуар, кайбер очракларда хәтта буталчык. Шуңа күрә күп кенә поэтик темаларны чишкәндә совет шагыйре һәм француз әдипләре арасында кайбер аермалы яклар да бар. Анысын инде махсус тикшерергә кирәк.

# МӘҢГЕЛЕК СӘЯХӘТ

Шагыйрь күпме генә алга, киләчәккә карап яшәмәсен, ул барыбер үткәннәренә борылып карамый булдыра алмый. Чөнки үткәннәрдә — аның тормыш һәм үсеш юлы, матди һәм рухи биографиясе, шигырь юлларына әверелгән уй-фикерләре, гамьнәре, кичерешләре. Әхсән Баянов үзенең чирек гасырдан артыграк вакыт эчендә язылган шигырьләр һәм поэмалар җыентыгын «Елларга сәяхәт»[1] дип атаган икән,. бу очраклы хәл түгел. Шагыйрь, әйтерсең, үткәннәренә караш ташлый, тормыш һәм әхлак тәҗрибәсен барлый, үзе белән бергә укучысын да узган көннәргә сәяхәткә чакыра. Сәяхәт исә кешенең кичерешләрен, рухи дөньясын баета, фикер офыкларын киңәйтә, аны өр-яңа серле киңлекләргә алып чыга.

Китап Сибгат ага Хәкимнең кереш сүзе белән ачыла. Өлкән шагыйрь үзенең өч битлек кенә кереш сүзендә гаять кыйммәтле, уйландыра торган фикерләр әйтә. Шагыйрь турында шагыйрь сөйли, монысы да кызыклы.

Чирек гасырлык иҗат... Шагыйрьнең иҗатын, үсешен, характерын билгеләүче китап. Бу поэзиядә генә әле. Әгәр проза, драматургия һәм башка жанрлардагы эшчәнлеген дә искә алсак, Әхсән Баяновның шактый актив һәм нәтиҗәле иҗат итүен танырга туры килә. Әйе, Ә. Баянов төрле жанрларда иҗат итә. Яхшымы бу, начармы? Кисеп кенә әйтү кыен. Әмма шунысы хак: Ә. Баянов проза һәм поэзия мәйданында да нык басып торган, сөлгесен кысып тоткан һәм күпләр белән бәхәсләшә, көч сынаша алырлык көрәшче егетне хәтерләтә. Җегәре бар, куәте, дәрманы бар... Җыентыкны укыган саен өнә шуңа ышана барасың.

[1] Әхсән Баянов. Елларга сәяхәт. Татарстан китап нәшрияты, Казан, 1977.

«Яшьлек дәфтәреннән» дип аталган беренче бүлектәге шигырьләр тын гына агып яткан, үз көе, үз моңы булган талгын чишмәне хәтерләтәләр. Нигездә алар табигать, мәхәббәт турындагы шигырьләр. Аларның саф сөю, ярату хисләре, камиллеккә, гүзәллеккә омтылыш белән сугарылган булуы куандыра.

Сине уйлап, ахры, табигатьне,
Бар дөньяны сөям, яратам.

Яки:

Бу дөньяда могҗиза юк, диләр.
Ә синең соң, синең күзләр?

Бу бүлектәге кайсы гына шигырьгә юлыкма, аларда бернинди сыкрау, зарлану, үксү, үкенү юк! Мәхәббәт хисләре бөтен, вакланмаган, чәчелмәгән.

Үрелеп яшен җыям кулга —
Барысы да сиңа, сиңа!..

Лирик геройның әнә шулай көчле итеп ярата алуына ышанам мин. Олы мәхәббәт олы хисләр таләп итә, әхлакый яктан көчле, ныклы шәхес булуыңны сорый. Шушы сыйфатларга омтылып яшәү үзе үк матур күренеш түгелмени? Дөрес, соңгы бүлектәге кайбер мәхәббәт шигырьләрендә шушы төп лейтмотивка ят булган авазлар да яңгырап китә (мәсәлән, «Тәрәзәң ачыла үткәнгә...» дип башланган шигырь һ. б.).

Мәхәббәт димәктән, аны тарайтып, кечерәйтеп аңлау зур хата булыр иде. Хатын-кызга мәхәббәт — тормышны, дөньяны яратуның бер өлеше генә әле ул. Шагыйрь үзенең йөрәгендә тормышка, дөньяга карата чиксез һәм олы мәхәббәт йөртергә тиеш. Әнә шундый олы мәхәббәт утларында өзгәләнсә, җирнең кичкенә генә кайгысын да, шатлыгын да уртаклашып яшәсә генә шагыйрь дигән бөек исемне йөртергә хакы бар аның.

Мәхәббәтем яши
Үзем белән бергә.
Ләкин калыр,
Шушы дөнья төсле шаулап калыр
Миннән соң да.

Ә. Баянов үзенең тыйнак, эчкерсез мәхәббәтен шушы юлларда ышандырырлык итеп мәңгеләштерә алган. Чыннан да, әгәр кешенең тормышны яратуы үзе белән бергә үлә, «теге дөнья»га китеп бара торган булса, яшәүнең һәм йөрәк тулы теләк-омтылышларның мәгънәсе калыр идеме икән?

Һәр буынның әйтер сүзе була, һәр буын җирдә үз эзен калдыра. Берәүләрнең эше яңа кала, яңа төзелешләр, икенчеләрнең исә әдәбият, культура, фән һәм техника өлкәсендәге ачышлар рәвешендә тарихка, чынбарлыкка кереп кала. 40—50 нче еллар... Бу буынның характеры нинди? Нинди уй-гамь, борчулар, идеаллар, теләк-омтылышлар белән яши алар? Тоткан кыйблалары нәрсә? «Елларга сәяхәт» китабында әнә шундый сорауларга җавап табарга мөмкин. Ә. Баянов үз исеменнән генә түгел, үз буыны исеменнән дә сөйли. Аның «мин»е сәнгатьчә гомумиләштерү көченә ия. Шагыйрьнең Кояш тирәсендә әйләнүче Җиребезгә карап:

— Юк, мин матрос,— ут кабыпса сиңа,
Сүндерермен яки янармын!

— дип ихластан әйтүендә тулы бер буын язмышы, иминлек хакына күкрәгән теләсә нинди утлар каршына куярга әзер торучы патриот характеры ярылып ята.

Шагыйрьнең башлангыч чор иҗаты тын гына агып яткан чишмәне хәтерләтә дигән идек. Әмма һәр чишмә, мәгълүм булганча, елгаларга, диңгезләргә барып кушыла. Ә. Баянов иҗаты да тора-бара мул сулы елга кебек гайрәтләнеп, киңәебрәк ага башлый. Аның инде хәрәкәте дә, дулкыннары да бүтән. Шагыйрьнең характеры, иҗат диапазоны поэмаларда аеруча калку чагыла. «Диңгез шавы» дигән поэманың исеме үк шау-шулы, давыллы дөньяга алып кереп китә. Мәхәббәт хисләре билгеле бер эшкә, хәрәкәткә үсеп әверелсә, хәлиткеч вакыйгалар фонында гүзәл сыйфатлары белән ачылса гына үзенең тылсымлы көче белән тәэсир итә ала — автор әнә шушы хакыйкатьне яклый, сөю-яратуга омтылган яшь йөрәкләр адресына әнә шундый олы чакыру ташлый. Кыска гына поэма. Ә шуңарда никадәр киеренкелек, яктылык, җылылык, кешелеклелек, никадәрле матурлык һәм рухи батырлык!

1957—1958 нче елларда язылган шушы поэмасында ук инде шагыйрь үзенең драматик киеренкелеккә корылган әсәрләр язарга сәләтле булуын раслаган икән.

«Сез аңларсыз мине» әсәрендә исә яшьлеге сугыш елларына туры килгән буынның язмышы бөтен тирәнлеге белән ачыла. Ятим калган малай... Унбер яшьлек кыз... Сугыш олыларны ут эченә суырып алган, зурлар эше әнә шушы сабыйлар кулына тапшырылган. Унбер яшьлек Әгъния яз-көзләрдә челтәр бозны ватып ялан аяк килеш бала кере юа. Малай үсә, тик кызның үз аяклары йөрмәс була. Яшь бер гомер белән хушлашасың. Фаҗига йөрәкнең кай җирендер өтеп ала... Җирән аткаен җигеп урманга йөрүче, өсләренә агач ауганда да Кояшка карый белүче малайны ничек инде яратмыйсың, аның көчле ихтыярына ничек сокланмыйсың ди!

Драматик киеренкелек бүлектән-бүлеккә арта бара. Тормыш буяулары куе һәм ышандырырлык итеп салынган. Ялган юк! Әсәрдә моң бар, моңсулык бар. Ялган кояш, ялган ай һ. б. булырга мөмкин, ләкин ялган моң була алмый — ышандыру көченең сере әнә шуңарда. Ә бит сәнгать әсәрендә моңга, моңсулыкка ирешү бик үк ансат түгел. Моның өчен тормышның үзәгендә торып сөйләү, катлаулы бәрелешләрне тирәнтен тоя һәм кичерә алу, олы җанлы була белү кирәк. Имән агачына кемдер элеп калдырган сабан калагы чыңлавыннан Җир авазын тыңлый алган, кояшны ячь-яшь кыз итеп күрә алган, табигатьтәге авазларны — чишмә чылтыравын, тәкәрлек һәм акчарлаклар тавышын изге көрәш юлында һәлак булган әтисенең сүзләре дип кабул итә алган шагыйрьнең исә олы җанлы, шәфкатьле булуына ышану кыен түгел.

Әсәрдә тагын бер кызыклы момент бар. Мич кырыена җылынырга дип кергән чегәннәр, авторның үз сүзләре белән әйтсәк:

Әни юып элгән керләрне һәм
Чалбарымны чәлеп сызганнар...

Авыр еллардагы шушы вакыйганы искә төшергәннән соң шагыйрь: «Нишлим, белмим, яши белмим һаман»,— дип үзенең йомшаклыгыннан «зарланып» ала. Кешеләргә ышану, янәшәдә явызлык, түпаслык, мәкер, хәйлә, әшәкелек бардыр

дип күз алдына да китерә алмау... Сабый җанлы мондый кеше чынлап та «яши» белмидер бәлки? Бәхәсләшмим, ләкин андыйларның яшәве тормышны бизи, аны матур итә, җирдә гаделлек һәм чисталык тантана итәчәгенә ышанычны арттыра.

«Сез аңларсыз мине» әсәре, үзенең эчке җепләре белән, яңа бер буынның өлгереп җитүе, совет кешесенең формалашуы мәсьәләләренә барып тоташа. Әлеге буынга хакыйкать эзләү, ялганны күрәлмау, дәреслеккә һәм әхлакый камиллеккә омтылу, гаделсезлеккә һәм вөҗдансызлыкка каршы көрәш, дөнья гаме белән яшәү кебек олы сыйфатлар хас.

Әткәйләр даны — килер буын өчен рухландыргыч үрнәк, яшәү нормаңны һәм идеалларыңны билгели торган изге биеклек. Лирик герой тормышны яңача үзгәртеп коручыларның язмышы хакында да уйлана, «үзенең йөрәк тибешен байракларда калдырган» әтисе белән горурлана. Илне, халкыңны, Ватаныңны яратуның чишмә башы әнә кайларга барып тоташа икән! Бу тема «Һәйкәл» исемле драматик поэмада тагын да үстерелә, эпик планда хәл ителә. Шартлылыкка мөрәҗәгать итеп, автор үткәннәр белән бүгенгенең бәйләнешен, намус һәм икейөзлелек, сафлык һәм мәкерлек, тугрылык һәм хыянәт, чын һәм ялган патриотизм арасындагы мөнәсәбәтләрне яңа югарылыкта, өр-яңа яссылыкта художникларча чишә алган.

Фәлсәфи тирәнлек... Шушы сыйфат җитешмәсә, әсәр тәэсир итү көченнән мәхрүм булыр иде. Шөкер, автор тирәннән алдыра, катлаулы һәм гыйбрәтле язмышлар дөньясына курыкмый керә. Тормышта үз-үзеңне, үткәнне, буыннар дәвамын — димәк, тарихны, хакыйкатьне исбат итәргә омтылу... Кешелекле, яхшы ниятле омтылыш бу! Югыйсә, яудан соң батырлар күбәя дигәндәй, фидакарь җаннарга ышыкланып үз-үзеннән «герой» ясарга теләүчеләр җай чыкканны көтеп көнә торалар. Чын батырлык рухы — мәңгелек, иртәме-соңмы, гаделлек барыбер өскә, кояш яктысына калкып чыга — «Һәйкәл» поэмасы әнә шундый кешелеккә аккорд белән тәмамлана.

Сүз уңаеннан әйтергә кирәк, поэмалар шикелле үк, «Төнге бәхәс» балладасы һәм «Букет-манара» легендасы да драматик киеренкелеккә корылган. Әгәр шулай әйтергә ярася, киеренкелек — сәнгать әсәренең йөрәге ул. Киеренкелек — көрәш, рухи яктан сыналу. Әнә шундый көрәш ноктaларын таба һәм күрә белгән, аларны художество көче белән сурәтли алган әдип кенә бай тарихлы әдәбиятта үзенең үзенчәлекле авазын яңгырата ала. Художество көче белән дип әйтүебез юкка түгел. Конкрет шигырьгә мөрәҗәгать итик: Төн. Тайга. Учак яна. Кыз егетнең белгәненнән: «Бәхет юк дөньяда» дигән сүзләрне укый. «Син чынлапмы? Шулай уйлыйсыңмы?» Егет җавап бирми, утлы кисәү белән белгәендәге сүзләргә баса... Менә сиңа җавап! Көтелмәгәнчә. Әгәр тайга уртасында шәһәр кадәр шәһәр салучы шушы егет телдән җавап биргән булса, валлаһи, ышанмас та идек!

...Күрә белгән, дидек. Әйе, шагыйрьнең бәхетле язмышы аның күрә белү «сәләтенә» дә нык бәйле. Асылда язучы яки шагыйрь ачкан күренешләр, вакыйгалар, хакыйкатьләр, ул тудырган дөнья — һәммәсе дә тормышта, тирә-ягыбызда тулып ята. Әдип әле шуларны «беренче булып» күрә алуы белән көчле! Юкса таныш һәм билгеле булган хакыйкатьләрнең шигырьдән-шигырьгә күчеп йөрүе укучыны дулкынландырмый, аңа эстетик ләззәт бирә алмый.

Олы поэзиядә беренче карашка бер-берсеннән шактый ерак шикелле тоелган ике сыйфат — лирика һәм фәлсәфи-публицистик агым һәр вакыт янәшә баралар. Кояш нурларында тып-тын оеп яткан мәһабәт диңгез кайчак шаулап, давыллап алган шикелле, лирика да киеренке һәм масштаблы фикерләр белән чиратлаша. Безгә калса, Ә. Баяновның иҗат үсеше дә шушы эздән күтәрелә. «Йоклый кошлар», «Йолдызлар җитә һәркемгә», «Баш иярге мөмкин» һ. б. шигырьләр шулай дип әйтергә нигез бирә.

> Тезләнергә мөмкин бары туган җиргә,
> Баш иярге — бары мәхәббәткә!

«Йоклый кошлар» исемле шигырьнең мәгънәсе укучы аңын актив эшчәнлеккә этәрә, уйлар ирексездән җир һәм халыклар язмышына, сугыш һәм тынычлык темасына килеп тоташа.

Фикер тирәнәя, сурәтләү колачы, масштаблылык киңәя. Шагыйрьнең шигъри байталы тора-бара традицион форма рамкаларын җимереп чыга, ирекенлеккә омтыла... Моның сәбәбен шуның белән аңлатырга кирәктер бәлки?

Шагыйрь — хакыйкать сакчысы. Хакыйкать ул үзенең капма-каршысы булган ял-

ган шикелле үк әрсез, талымсыз түгел, аны сакларга кирәк — поэзиянең тагын бер югары миссиясе әнә шул. Ә. Баяновның «Дөньяга ялвару» шигыре дәреслекне, табигыйлекне яклап чыгучылар тавышына үзенчәлекле аваз булып кушыла. Хисләрдә, мәхәббәттә һәм, гомумән, тормышта, күңел дөньябызда ясалмалылык булырга тиеш түгел. Бу исә укучыда теләктәшлек уята.

Шагыйрь — табигать сакчысы да. «Сәяхәтнамә» (Кама этюдлары) әсәрен укыганда шигырь юллары арасыннан гражданин йөрәкле шагыйрь күтәрелә. Табигатьне сакларга кирәклек турында чаң кагу безнең әдәбиятка соңгы елларда гына килеп керде. Бу юнәлештә әле яңа эзләнүләр, һичшиксез, булачак.

Кагылсалар ялгыш...
Парашюттан сикерә алмас Тормыш.

Сәнгатьчә төгәллек белән әйтелгән әнә шушы юлларда да шагыйрьнең гражданлык хисләре алгы сызыкка ургып чыга. «Берәүләр — бомба, икенчеләр кызга чәчәк сузган» заманда битараф яшәү мөмкин түгел. Равил Фәйзуллинның Мәскәүдә рус телендә чыккан «Саз» җыентыгына сүз башында тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин, хаклы рәвештә, болай дигән иде: «Гражданлык хисе — дөньяда барган барлык хәлләргә, үз халкың һәм барлык кешелек язмышына югары сизгерлек күрсәтү». Математик төгәллек белән әйтелгән бу фикер чын гражданлык хисен купшы һәм ялтыравык сүзләргә төренгән ясалма хисләрдән аера белүгә рәхәтләнеп хезмәт итә ала. Чыннан да, халкыңның, кешелекнең, ахыр чиктә, планетаның язмышы турында борчылып, тынгысыз җан булып яшәү генә гражданин йөрәкле икәнлегеңне раслауда — бәхәссез дәлил.

Әйе, бу дөньяда шагыйрьне дөрләтеп, аны тынгысыз җан итеп яшәткән ике нәрсә бар, болар — мәхәббәт һәм нәфрәт! Икесе ике полюстагы шушы төшенчәләр, ахыр чиктә, кешелеклелек һәм гражданлык хисе дәрәҗәсенә күтәреләләр.

Ә. Баяновка туктаусыз эзләнү хас. Үз моңын, үз юлын дип әйтүем түгел, алары инде күптән табылган. Һәр әсәргә яңа бер «ачкыч», көтелмәгән бизәкләр табарга омтылып эзләнә ул. Әмма шагыйрь иҗаты бар яктан да камил икән дип аңларга да ярамас. Аның байтак кына шигырьләрендә стиль кыенлыгы сизелә, урыны-урыны белән кайбер җөмләләр хис һәм акыл тарафыннан авыррак үзләштерелә. Әмма шунысы гаҗәп: аларда ихлас хисләрнең, тормышның, чынбарлыкның «тупырдап» торуы әлегә кимчелекне укучы күзеннән ерак яшерә.

Йолдызларың җыеп галәмеңдә,
Җиргә бүләк итсәм,
Шул җитә.

Шагыйрь алтмышынчы еллар башында ук биргән шигъри вәгъдәсе каршында тугрылыклы яши. Без, җир кешеләре, аңардан яңадан-яңа йолдызлар көтәргә хаклы. Иҗат — мәңгелек сәяхәт ул. Шагыйрьне, шул исәптән... укучыларны да киләчәктә якты киңлекләр, яңа биеклекләр көтеп тора дип ышаныйк.

**РАШАТ НИЗАМИЕВ.**

# ХИС ҺӘМ ФИКЕР БЕРЛЕГЕ

1976 нчы ел Равил Фәйзуллин өчен аеруча нәтиҗәле һәм истәлекле булды: шагыйрьнең «Аҗаган» исемле беренче китабы чыгуга ун ел тулды, бер елда аның татар һәм рус телләрендә ике җыентыгы дөнья күрде [1]. Асылда аларның һәр икесен сайланма әсәрләр дип санарга була.

Яшь тәнкыйтьче М. Вәлиев дөрес күрсәткәнчә, Р. Фәйзуллин әдәбиятка сугыштан соңгы буынның, рухи яктан 60 нчы елларда формалашкан буынның дөньяга карашын, тормышка мөнәсәбәтен алып килде. Бу буын үзеннән алда килгән буыннан киңрәк һәм тирәнрәк белемле булуы белән генә аерылмый, аның дөньяга карашы үк инде күп үзгә. Фәнни-техник революция, җәмгыять тормышында барган социаль һәм экономик характердагы кискен үзгәрешләр, фәннең яңа уңышлары, космосны үзләштерү — болар һәммәсе аның рухи йөзенә үз эзен салган.

[1] Р. Фәйзуллин. Шигырьләр һәм поэмалар. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1976 ел, 447 бит. Р. Фәйзуллин. Миг возвращенья. Рус телендә. Шигырьләр. Мәскәү, «Советский писатель» нәшрияты, 1976 ел, 159 бит.

Әлеге буынның әхлакый тәҗрибәсе һәм сәнгатьчә эзләнүләре, дөньяның матурлыгына соклануы, самимилеге һәм зирәклеге Р. Фәйзуллин иҗатында үзенчәлекле чагылыш һәм яңгыраш таба. Тормышка яшьләр күзе белән карау, яшьлек хисе — шагыйрь талантының төп сыйфаты. Р. Фәйзуллин поэзиясенең кайнарлыгы, шигырьләренең артык кискен һәм тәэсирчән булуы, ялганга, гаделсезлеккә һәм явызлыкка карата искиткеч дәрәҗәдә сизгерлеге, аның иҗатындагы яшьләргә хас максимализм, аерым алганда, нәкъ менә шуның белән аңлатыла. Аның иҗатында мәхәббәт темасының киң урын алуы да шуның белән бәйле. Шагыйрь иҗатында мәхәббәт якты һәм саф, кешегә зур ләззәт китерә торган, шул ук вакытта газап һәм әрнүләр дә алып килә торган хис итеп сурәтләнә.

Р. Фәйзуллин — яңа, яшь буынның гади бер вәкиле генә түгел, ә барыннан да элек, үзенчә фикер йөртә торган кызыклы шәхес тә ул. Басынкы, вакыты-вакыты белән хәтта бераз кырысрак та булган дәрт шагыйрь интонациясенең төп сыйфатын билгели. Аның лирик герое дөньяның бер генә хәленә дә битараф түгел. Шул ук вакытта, уттан качкандай, ул җебегәнлек һәм сентиментальлектән, коры шапырынулардан һәм арзанлы күз яшьләреннән качарга тырыша. Р. Фәйзуллин шигырьләрендәге лаконизм, хисләрне белдерүдәге саранлык, аның шигырьләрендәге прозаизм әнә шуннан килә.

Ул фикерләрен турыдан-туры «маңгайга бәреп» әйтүдән курыкмый. Мисалга авторның «Яшәсен!» исемле программ характердагы шигырен китерү дә җитә, анда ул фикерен ялангач лозунглар формасында бәян итә төсле. Әмма шагыйрьнең һәр сүзе шул хәтле саллы, һәр фикере шул хәтле оригиналь, ә иманы шул хәтле ихлас ки, хәтта иң ачык, иң ялангач лозунг та ахыр чиктә чын поэзиягә әйләнә. Ораторлык пафосы аның шигырьләренең стилистик төсмерләрен генә түгел, еш кына композицион төзелешен дә билгели. Мисалга «Телсез» исемле шигырьне алыйк:

> Дөньяда һәр нәрсәнең үз теле бар...

Шушы беренче фразага ук, бодай бөртегендәгедәй, кысылган, пресслаган хәлдә, шигырьнең төп образлы фикере салынган. Алдагы юллар шул фикерне ачу, үстерү хезмәтен үти:

> Агачлар серләшә,
> яфракларын лепердәтеп,
> дулкыннар ярсынып нәрсәдер даулаша,
> пәрәвез җепләре тибрәнеп моңлана,
> ажаганнар бәхәсләшә төнне ярып,
> комнар күчә пышын-пышын...

Әмма шул рәвешчә санап бару гади тасвир өчен генә китерелми, баналь төстә табигать күренешләрен җанландыру өчен генә хезмәт итми. Алга таба күренгәнчә, бу юллар авторга табигать күренешләрен кешенең эчке дөньясы белән янәшә куеп карау өчен кирәк:

> Шул шауларның бөтенесен басып
> ишеттерми генә
> каным шаулый,
> хисем кайный,
> җан өздергеч тавыш белән рухым дулый!..

Ахырдан көтелмәгән, шул ук вакытта шигырьнең алдагы бөтен агышы белән хәзерләнгән соңгы нәтиҗә килә:

> ...Азлар белә
> гарип моң көчен.

Игътибар беләнрәк күзәткәндә күрү кыен түгел, Р. Фәйзуллин шигырьләре ораторлык сәнгате кануннары нигезендә төзелгән (схемасы мондый: тезис — аның үсеше — нәтиҗә). Билгеле, бу коры риторика түгел, чөнки җанлы поэтик образ үзенең күп мәгънәле булуы һәм хисси конкретлыгы белән укучының фантазиясенә дә шактый җирлек калдыра.

Р. Фәйзуллин лирикасы — актив төстә, тормышка йогынты ясый торган, турыдан-туры укучыларга юнәлтелгән лирика. Шул ук вакытта бу зур дәрт белән чынбарлыкны өйрәнә торган, яшәешнең иң төп, хәлиткеч мәсьәләләре хакында киеренке итеп уйлана белә торган лирика.

Татарча басмада шагыйрь үз шигырьләрен ике бүлеккә бүлеп йөртә. «Сүз сораган уйлар» исемле беренче бүлеккә асылда авторның фәлсәфи лирикасы тупланган, «Мәхәббәтнамә» исемле икенче бүлек, исеменнән үк күренгәнчә, мәхәббәт шигырьләреннән тора. Фәлсәфи лирика — шәрык әдәбиятыннан ук килә торган бай һәм ныклы традицияләре булган, шуңа да карамастан, бездә тиешле дәрәҗәдә үсеп китә алмаган бик катлаулы һәм авыр жанр. Тормыш турында философларча уйлану — Р. Фәйзуллин талантының табигый сыйфаты. Шуңа да аның фәлсәфи шигырьләре буш үгет, коры акыл сату булып тоелмый. Аның фикере актив һәм хәрәкәтчән, шуңа күрә шагыйрь характерының һәм темпераментының табигый чагылышы буларак кабул ителә.

Һәр шагыйрь тормышны үзенчә күрә, тормыштан алган тәэсирләрен үзенчә гомумиләштерә. Р. Фәйзуллинның үзенчә-

леге шунда, ул табигатьне, теге яки бу вакыйганы коры тасвирлау белән чикләнми, ә аларның асылына төшенә, аларны яңабаштан ача. Бу аның шигырьләренең композициясендә дә чагыла. Авторның күпчелек шигырьләре контрастларга корылган. Мисалга «Ике күпер» шигырен алыйк.

Берсе:

Яңа күпер:
тимер-бетон.
Җимерелмәс
күк күкрәткән
алла төшеп бисә дә!

Икенчесе:

Иске күпер.
Мәет илткән
кабыкмыни...

Берсендә ыгы-зыгы, машиналар, юлаучылар. Ә икенчесе ташландык хәлдә, хәзер аннан беркем йөрми. Шул фикерен әйтеп тә бетерми, шагыйрь үз-үзен төзәтә башлый: «Юк! Ялгышам: төнлә монда бер чал чәчле ана йөри». Бу укучының кызыксынуын көчәйтеп җибәрә: карт ана ни өчен бер ялгызы иске күпердән йөри икән? Һәм шагыйрь фронтта югалган улын көтүче ананың үз сүзләре белән үк әлеге сорауга үтемле итеп җавап та бирә:

Белми бит ул
яңа күпер
салынганын!
Киткәне күк —
моннан кайтыр
минем балам...

Укучы ихтыярсыздан яңа белән искенең үзара мөнәсәбәте хакында уйлана башлый. Әйе, яңалык көчле, гүзәл, куәтле. Әмма кешеләр аңында, кешеләр хәтерендә әле үткәннәр дә яши, чөнки аның белән дә күп нәрсә — узган яшьлек, тормыштан киткән иптәшләр, бөтен бер дәвер бәйләнгән.

Яки менә тагын бер шигырь. Ул зур түгел, шуңа күрә тулысы белән китерик:

Кыз сынын ясады бер оста.
Ә кыз эчтән көлде, масайды.
«Җан өрсәң дә, оста, син ташка,
таш таш инде, тере мин — башка!»

Акты гомер. Оста күптән юк...
Ә таш сын шул — көләч, яшь һаман!
Бөкре карчык килгән янына.
Яшьлегенә — сынга яшь тама...

Бирелә сәнгать һәм тормыш, таш сын һәм гүзәл кыз янәшә куела. Беренче строфада шагыйрь бу янәшәлекнең бер ягын күрсәтә: тормыш сәнгатькә караганда, һичшиксез, баерак, күп төрлерәк һәм күп кырлырак. Яшь чибәр кыз салкын таш сынга көлеп, масаеп карый икән, ул хаклы. Икенче строфада исә шагыйрь ниндидер мәгънәдә сәнгатьнең тормыштан өстенлеген күрсәтә, ник дигәндә, ул «мизгелне туктата ала», шул бер хәлендә аны күп елларга, хәтта мәңгелеккә саклап кала ала.

Р. Фәйзуллинның күпчелек шигырьләре әнә шундый контрастка, капма-каршылыклар берлегенә корылган. Кайчак шигырьдә бер генә контраст була, кайчак һәр строфа, философия термины белән әйткәндә, тезис һәм антитезистан тора.

Философ булмаган эти.
Ә минем кирәкне белеп
өйләнгән минем эти...

Җырчы да булмаган эти.
Ә миңа бишек силәсен
зыңлап торганын ясарга
Өйрәнгән минем эти...

Асылда бөтен шигырь әнә шундый каршы куюлар теземеннән тора (галим дә булмаган эти, рәссам да булмаган эти, шагыйрь дә булмаган эти, герой да булмаган эти), һәр строфада тезис һәм антитезис чиратлашып бара. Иң ахырдан мондый нәтиҗә ясала:

Син алла да түгел, эти,
Фәрештә дә түгел, эти,
Син бары эти, эти!

Авторның төп фикере ачык: аның өчен әтисе галим дә, философ та, җырчы да, рәссам да, шагыйрь дә, герой да икән. Мондый композиция Р. Фәйзуллинның фәлсәфи шигырьләре өчен генә түгел, ә бәлки саф лирик шигырьләренә дә хас:

Мин сиңа йомшак таң җиле
юллаган идем.
Чәчләреңнән иркәләр дип
уйлаган идем.

Сәфәреңдә илләр кичеп,
тауларда кунып,
ул сиңа ирешкән икән
зилзилә булып.

Күрәсез, бу шигырь дә контрастларга корылган, геройның теләкләре белән ул теләкләрнең тормышка ашуы, кешедәге чын хис белән аның ничек кабул ителүе арасындагы каршылыкка корылган. Асылда биредә дә тезис белән антитезис чиратлашып килә:

Мин сине сагынып бер җыр
чыгарган идем.
Җан дуслар аны яратып
тыңлаган иде.
Җыр сиңа ошар дип йөрдем,
ваемсыз булып.
Ә ул сиңа барып җиткән
Авыр сүз булып.

Һәм шигырьнең соңгы строфасын асылда синтез дип кабул итәргә була:

...Хәзер җилләр дә юлламыйм,
чыгармыйм җыр да.
Әгәр теләсәң, җанымны
кил дә бер тыңла.

Авторның бүтән шигырьләрен дә анализлап карарга була, һәм аларның һәркайсында диярлек без бер үк композицион төзелеш белән (тезис — антитезис — синтез) очрашырбыз. Аларда шигырьне традицион схема нигезендә (экспозиция — төенләнеш — вакыйганың үсеше — кульминация — чишелеш) төзү бөтенләй юк диярлек. Автор сюжетлы яки тасвири шигырьләрдән качарга тырыша. Аның берәүнекенә дә охшамаган үз сюжеты бар. Монда фикер сюжеты, табигатьтәге, чынбарлыктагы, кеше күңелендәге капма-каршы көчләрнең бәрелешенә корылган сюжет күздә тотыла. Р. Фәйзуллин иҗатының көчле ягы да, көчсез ягы да шушы үзенчәлеккә бәйләнгән.

Шигырь нигезенә яңа һәм көчле хис, кызыклы һәм оригиналь фикер салынган очракта без аның композициясендәге әлеге бер төсле, кырыс конструкцияләрне сизмибез, әсәрне бөтен итеп, эчтәлек һәм форма берлегендә кабул итәбез. Инде шигырьнең төп фикере тапталган һәм баналь икән, композицион төзелешнең ясалмалыгы шунда ук күзгә ташлана. «Көмәч пешерүчеләр җыры» дип исемләнгән күп сүзле, озын шигырь, мәсәлән, шундый. Шигырьнең төп идеясе безне киендерүче, туендыручы кешеләргә, бу очракта икмәк пешерүчеләргә мәдхия җырлауга кайтып кала. Үзенең яраткан алымына турылыклы буларак, автор шигырьне биредә дә контрастлар алымына кора («Көмәч кебек йомшак түгел, үзебез каты куллыбыз», «Әйдә, кайчак он кунсын, куллар камырда булсын! Тик эшебез эшчәннәрнең хезмәте чаклы булсын, күзләрдә чаткы булсын, йөзебез якты булсын!»). Әмма ул контрастлар тышкы сыйфатлардан чыгып кына сайланганнар. Алар кеше җанының, һич югы, пешекче һөнәренең нинди дә яңа якларын ачмыйлар, шуңа күрә битараф калдыралар. Бу очракта бик озынга сузылган санап барулар да шигырьгә берни өстәми.

Болай да күптән билгеле нәрсәләргә укучыны ышандырырга тырыша торгач, автор ачык ишекне шакучыга охшап кия. Әйе, кызганычка каршы, аның кайбер шигырьләре тирән һәм оригиналь булулары белән аерылып тормыйлар. «Парикмахерда» шигыре дә авторның яраткан алымы — контрастларга корылган. Картлар парикмахерга яшәрү, сакалларын төзәтү өчен килә. Яшьләр, киресенчә, чәчләрен, матурлыкларын калдырып китәләр. Күрәсез, шигырь шактый ясалма, уйлап чыгарылган конфликтка корылган. Ләкин автор шул күренештән зур социаль мәгънәгә ия нәтиҗә чыгарырга тырыша:

Яшьләр килә монда
прическа өчен түгел,
компресс өчен түгел,
йомшак кул өчен түгел —
болай гына,
парикмахер машинасы чәчне төптән
ялмасын дип,
тик,
планета пеләш калмасын дип.

Мондый фикергә каршы килеп булмый. Тик тышкы ассоциацияләргә, ясалма контрастларга корылган шигырь безне әллә ни дулкынландырмый, безнең күңелгә барып җитми, димәк ки, авторның фикерләрен укучы үзенеке итеп кабул итми.

Хис һәм фикер бөтенлегенә ирешкәндә шагыйрь аеруча зур уңыш казана. Инде фикер хистән өскә чыкканда, алай гына да түгел, аны басып-изеп торганда (Р. Фәйзуллин шигырьләрендә мондый хәл дә еш очрый), шигырьләренең ясалмалылыгы да күзгә ташлангалый.

Шагыйрь иҗатында күз алдына китерерлек дәрәҗәдә җентекләп эшләнгән табигать күренешләре очрамый диярлек. Туган як табигатенең нинди дә аерым сыйфатлары саналып үтелсә дә, бу — туган табигатьнең конкрет-хисси, тулы канлы образы түгел. Әйтик, бер шигырендә автор юл йөрергә, сәяхәт итәргә яратуы турында сөйли:

Шулай туры килә,
читкә кителә;
әле уң якка, әле сул якка,
әле — төн ягына,
әле — көн ягына...

Тик кайда гына булмасын, күңел үз сөйгәне янына омтыла һәм кабат сөйгәне янына алып кайта. Шушы фикерне укучыга җиткерү өчен, автор көнбагыш образына мөрәҗәгать итә:

Көнбагыш чәчәкләре!
Көнбагыш чәчәкләре!
Очрыйлар һәркайда.
Син — үзәге аның,
сары чуклар —
юлларыма минем.

Күрәсез, көнбагыш монда үз исе, үз төсе булган табигать бизәге, тере чәчәк булудан бигрәк, авторның фикерен үтемлерәк, ачыграк итеп күрсәтергә тиешле абстракт символ буларак алынган. Менә шуңа күрә еш кына Р. Фәйзуллин шигырьләре шактый коры булып чыгалар. Аңарда җете, ачык эпитетлар, чагыштырулар,

метафоралар аз. Әмма бу аның шигырьләрендә поэтик образлар юк дигән сүз түгел. Асылда аның һәр шигырен киңәйтелгән метафора дип карарга була.

Биеккә мендем. Кояшка —
калды шундый якын!
Җиде кат күкнең быел мин
ачтым алты катын!

Бирсен әле калдырып тордым
алгы гомергә дип.
Бер бәхетле таңда икәү
ачарбыз бергә дип.

Бу шигырьдә бер генә эпитет, бер генә чагыштыру да юк дияргә була. Шигырь «җиде кат күк» дигән мәгълүм тәгъбирне уйнатуга корылган. Һәм ул эзләнү, иҗат итү, яңа ачышлар ясау бәхете турында сөйли, яныңда сөйгәнең булмаса, бәхетнең тулы булмаячагын искәртә...

Мин шагыйрьне корырак, фикерләренең ясалмарак булганы өчен гаепләргә җыенмыйм. Аның иҗат үзенчәлеге шундый. Өстәвенә, бу үзенчәлек аның матбугатка чыккан беренче шигырьләреннән алып бүгенге көнгә хәтле сизелеп килә. Билгеле, Р. Фәйзуллин поэзиясе күпмедер үзгәреш кичерде. Аның хисләре тагын да тирәнрәк һәм катлаулырак, фикерләре тагын да саллырак, әһәмиятлерәк төс алды. Шигырьләрендә очраклы, тәэсирсез юллар, буш тукымнар кимеде. Һәм авторның ун ел буе иҗат иткән иң яхшы шигырьләреннән төзелгән яңа җыентыгы белән танышканда тагын бер кат шагыйрьнең эчке шигъри дөньясы бердәм, бөтен булуга ышанасың. Үз-үзенә турылыклы калган хәлдә, шагыйрь үсә, үзгәрә бара. Аның төрле елларда иҗат ителгән шигырьләре арасында да үтеп булмаслык тирән чокырлар, төпсез упкыннар юк. Яңа җыентык бүгенге татар поэзиясендә Р. Фәйзуллинның өлгереп җитүе турында сөйли.

**РАФАЭЛЬ МОСТАФИН.**

# ӘНӘС КАМАЛГА 70 ЯШЬ

Татар театрының «атасы» исемен йөрткән күренекле драматургыбыз Галиәсгар Камал традицияләрен дәвам итүче һәм үстерүчеләр арасында аның үз улы Әнәс Камал да бар.

Әнәс Галиәсгар улы Камалетдинов 1908 елның 20 февралендә Казанда туа. Кече яшьтән театр һәм драматургиягә якын булган егет яшьли әдәбият һәм сәхнә мәсьәләләре белән кызыксына башлый. Бу исә аны Казан театр техникумына алып килә һәм кече яшьтән кулына каләм алырга мәҗбүр итә.

Әнәс Камалга үзенең беренче комедиясе «Хуҗа Насретдин әфәнде»не язганда әле 13 яшь тә булмый. Дөрес, аның тәүге әсәрләре әле матбугатта басылмый, шуңа да карамастан, аның өметле генә яшь драматург булуы күзгә ташлана. Ул әсәрләр үзешчәннәр тарафыннан сәхнәгә дә куела.

Әмма еллар узган саен үз өстендә өзлексез эшләүләр нәтиҗәсендә аның әсәрләре дә җитдиләнә, камилләшә баралар. Ул аеруча бер пәрдәлек пьесалар һәм комедияләр язучы драматург буларак танылa. Ә. Камалның 1931 елда «Ике көч» һәм «Давыл» әсәрләрен эченә алган беренче җыентыгы дөнья күрә. Ә бүген исә инде ул дистәләгән китап авторы. Аның әсәрләре бигрәк тә үзешчән театр коллективлары тарафыннан яратып сәхнәләштереләләр. Моны, беренчедән, Ә. Камал әсәрләренең кыска һәм оста язылулары белән аңлатсак, икенчедән, драматург үзенең әсәрләрендә халык өчен зур әһәмияткә ия мәсьәләләр, актуаль проблемалар күтәреп чыга. Аның әсәрләрендә совет кешеләренең иҗади хезмәте һәм аларның коммунистик киләчәккә омтылышы ачык чагылыш таба, искелек калдыклары һәм тормыштагы тискәре күренешләргә каршы аяусыз көрәш күрсәтелә.

Бер үк вакытта Ә. Камал эстрада өчен шигырьләр һәм интермедияләр авторы да. Аның ул әсәрләре шәһәр һәм авыл сәхнәләрендә аеруча зур уңыш белән яңгырыйлар.

Еш кына ул язучыларның аерым әсәрләренә, республикабыз театрларында куелган яңа постановкаларга карата тәнкыйть мәкаләләре белән дә чыга, рецензияләр яза. Бигрәк тә аның әтисе Г. Камал турындагы истәлекләре, очерклары, хикәяләре зур әһәмияткә ия. Бу әсәрләр әдәбиятыбыз классигының тормыш һәм иҗат юлын тагы да тулырак һәм бөтенрәк итеп күз алдына китерергә ярдәм итәләр. Әлеге тема исә Әнәс Камалны һаман да кызыксындыруында дәвам итә, якын елларда ул укучыларга һәм театр сөючеләргә үзенең яңа хезмәтен тәкъдим итәр дип ышанырга кирәк.

Әнәс Камал тәрҗемәче буларак та зур активлык белән эшләгән әдип. Аның Н. Островский, Л. Толстой, С. Маршак, А. Гайдар, С. Михалков, А. Барто һәм күп кенә башка рус язучыларыннан тәрҗемәләре шул хакта сөйли.

Татарстан Язучылар союзы, «Казан утлары» журналы һәм аның зур укучылар аудиториясе әдипкә ныклы сәламәтлек һәм иҗат уңышлары тели!

# В. Г. ВОЗДВИЖЕНСКИЙГА 50 ЯШЬ

Тәнкыйтьче, әдәбият галиме өчен илле яшь — иң өлгереп җиткән, тирән белем һәм тәҗрибә туплаган чор. Галим һәм педагог, әдәбият-сәнгать тормышын тирәнтен аңлап эш итүче тәнкыйтьче В. Г. Воздвиженский үз иҗат юлының нәкъ әнә шундый дәверен кичерә.

Ул Мәскәү университетының филология факультетында белем ала, шунда ук совет әдәбияты өлкәсендә фәнни эшкә керешә, академик Л. И. Тимофеев җитәкчелегендә аспирантура тәмамлый. Ә 1956 елдан башлап аның бөтен тормышы һәм гыйльми-әдәби эшчәнлеге Казан белән бәйле. Монда ул В. Маяковский, Л. Леонов кебек данлыклы рус совет әдипләрен генә түгел, иң күренекле татар язучылары һәм шагыйрьләре иҗатын да өйрәнүгә ныклап керешә. Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Җәлил, Ш. Усманов һәм башка каләм осталары мирасын өйрәнеп язылган әдәби тәнкыйть мәкаләләре белән татар әдәбияты һәм милли культурасы хәзинәләрен бөтенсоюз укучысына якынайтуга хезмәт итә.

Патриот-шагыйрь М. Җәлилнең тормыш һәм иҗат юлын фәнни өйрәнү өлкәсендә В. Воздвиженский аеруча тырышып эшли. 1969 елда Мәскәүнең «Наука» нәшрияты аның «Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» исемле китабын бастырып чыгарды. Авторның бу хезмәте М. Җәлил шигъриятен тикшерүдәге киң колачлылыгы белән аерылып тора. Филология фәннәре докторы Нил Юзиев сүзләре белән әйткәндә, «тикшеренүнең максаты, хезмәтнең кыйммәте һәм яңалыгы — М. Җәлил шигъриятенең тирән тамырларын, сәнгать нигезләрен ачуга омтылуда, бу шигъриятнең башка совет шагыйрьләре белән эстетик бердәмлек тәшкил итүен исбатлауда, «Моабит дәфтәрләре»н эпоха белән янәшә куеп, сугыш елларындагы әдәби үсеш фонында карый белүдә». Күп кенә катлаулы теоретик мәсьәләләр күтәрелүенә дә карамастан, Муса Җәлил турындагы бу китап әдәбият белгечләренә дә, киң катлау укучылар массасына да бердәй диярлек аңлаешлы.

В. Воздвиженский М. Җәлил иҗатын өйрәнүен һаман да дәвам иттерә. «Художественная литература» нәшриятында галимнең патриот-шагыйрь турында ике яңа күләмле хезмәте басылып ята. Беренче китапта автор шагыйрьнең кешелек сыйфатларын, аны дулкынландырган уй-тойгылар тирәнлеген, М. Җәлил шигырьләрендәге тормыш сөючәнлекне, кешелек горурлыгын бөтен тулылыгында күрсәтергә омтыла. Икенче хезмәте исә Җәлил шигърияте белән французларның Каршылык хәрәкәте поэзиясе арасындагы эчке бәйләнешләрне тикшерүгә багышланган. Моннан тыш, «Татар совет әдәбияты тарихы» дигән күмәк хезмәтнең герой-шагыйрьгә багышланган бүлегендә Воздвиженский М. Җәлил иҗаты буенча тупланган фәнни тикшеренүләрне гомумиләштереп, билгеле бер йомгак ясый. В. Воздвиженскийның бу хезмәтләре Муса Җәлил иҗатын өйрәнүгә сизелерлек өлеш кертә.

Соңгы елларда ул Идел белән Урал арасында яшәүче халыклар әдәбиятларының социалистик реализм юнәлешендә эстетик бердәмлек буларак үсешен һәм үзара йогынтысын өйрәнүгә багышланган хезмәт өстендә эшләде. Бу өлкәдәге тикшеренү совет әдәбият фәнендә беренче тәҗрибә дияргә мөмкин. СССР Фәннәр академиясе чыгара торган «Күп милләтле совет әдәбияты тарихы» исемле алты томлы хезмәттә Воздвиженский «Идел һәм Урал буе халыклары әдәбияты» бүлеге авторларыннан берсе буларак катнаша.

Воздвиженский күп еллардан бирле Казан университетында совет әдәбияты курсы буенча лекцияләр укый, ул шулай ук бүгенге әдәбиятның мөһим темалары буенча берничә махсус курс авторы да.

Партияле әдип В. Воздвиженский гыйльми һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендәге эшчәнлеген үзләренең партия оешмасында һәм Татарстан Язучылар союзында төрле җәмәгать эшләре белән бергә алып бара. Студент яшьләр, башлап язучылар арасында да, өлкән әдип һәм галимнәр арасында да хөрмәтле кеше ул. Илле яшен тутырган көндә хезмәттәшебез В. Г. Воздвиженскийга нык сәламәтлек, яңа иҗат уңышлары телибез.

**ГЕННАДИЙ ИВЛЕВ.**

# МӘСГУТ ШӘРИФУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 50 ЕЛ

Мәсгут Шәрифуллин кыска, ләкин иҗади яктан үзенчәлекле гомер кичерде. Ул 1928 елның 18 февралендә Башкортстанның Ярмәкәй районы Рәтамак авылында крестьян гаиләсендә туа. Бала чактан ук рәсем ясарга, китап укырга ярата. Стена газеталары чыгару, клубны бизәү кебек эшләрнең барысын да ул башкара. Шуның өстенә колхозда да эшли.

Армиядән кайткач, 1953 елда М. Шәрифуллин Казанга килә һәм заводта автоматлаштырылган станокларны көйләүче слесарь булып эшли башлый. Таләпчән егет үзлегеннән белемен күтәрә. Уку теләге аны Казанның художество училищесына китерә. Шунда ул партиягә алына.

1959 елга кадәр М. Шәрифуллин — Татар академия театрында рәссам, аннан Казан телевидениесында художество цехы башлыгы.

М. Шәрифуллинның хикәяләре матбугат битләрендә 1956 елдан күренә башлый. һәм бер ел да үтми, «Айлы төндә» исемле беренче китабы дөнья күрә. Авыл кешеләренә багышланган «Еллар үткәч» дигән повесте һәм «Туганнар» исемле пьесасы әле дә күпләрнең хәтерендә.

Мәсгут Шәрифуллин 1962 елда СССР Язучылар союзына кабул ителә.

Каты авыру әдипкә үзенең барлык мөмкинлекләрен, бай күңелен ачып салырга ирек бирми. Иҗаты бөтен киңлегенә ачылып китә башлагач кына, утыз сигез яшендә язучы вафат була.

Шушы елның 18 февралендә аның тууына 50 ел тулды.

**Гөр-Гөри**

# ПАРОДИЯЛӘР ҺӘМ ЭПИГРАММАЛАР

## КамАЗга бар

Бар шагыйрьләр җирдә купкан чакта,
Юл биргәндә бар да туктап чатта,
Бик аз гына шунда, бик аз гына,
КамАЗ белән бары намаз гына
Рифмалашмый калган заманда
Мин дә йөрдем, йөрдем КамАЗда.

*Сибгат Хәким, «Дәверләр капкасы»ннан.*

Сызылып-сызылып таңнар аткан чакта,
Шагыйрь халкы йоклап яткан чакта,
Мин дә йөрдем, йөрдем Кимедә[1].
«Хәкимеңә күпме җыр биргәнсең,
Лауреатка кадәр үстергәнсең,
Хет бер җырлат, Киме, мине дә!»

Шунда әйтте Киме: «Әйе,— диде,—
Кимесез ул Сибгат соң кем иде?!
Ләкин «Киме, Киме» дия торгач,
Миндә шигъри тема кимеде.

Шуңа бар шагыйрьләр купкан чакта,
Хәкимемә юл биргәндә чатта,
Бик аз гына, бары бик аз гына,
Илһам җыеп кына бераз гына
Йөрде Сибгат, йөрде КамАЗда...
... Син дә, егет, җырга бар анда!»

●

«Төн буе ятам, шигырьнең
Юлларын уйлап,
Моңнарын уйлап.
Начар шигырьләр язарга
Тукайдан оят,
Такташтан оят» [2].

Ә укучыдан оятмы?..
Кем торган уйлап?!

---

[1] Күлле Киме — С. Хәким туган авыл.
[2] Г. Афзал шигыре.

## Урманга бер сүз

Бөек Шелли җанын үзенә тарткан диңгез!
Синдбад үзенең сәер бәхетен тапкан диңгез!
Робинзонга яңа тормыш биргән диңгез!..
...Колумблар, куш йөрәкләр гизгән диңгез!..
...Авырса да тозлы җилдән, сусаудан җан,
Китә алмам, сездә калам, калам, диңгез.

*Рәдиф Гатауллин, «Диңгезгә бер сүз».*

Шүрәлеләр җанын үзенә тарткан урман!
Былтыр үзенә коры утын тапкан урман!
Л. Леонов язган русский куе урман!
Урманчылар өчәр норма куган урман!
Бөек Шишкин рухи азык тапкан урман!
Без пикникта йөзәр грамм капкан урман!

... Саф һавада күпме рәхәт чигә бу җан,
Китә алмам, синдә калам, калам, урман!

## Ертык җырлар

Кайбер шагыйрьләр шигырьләрендә
мәкальләрне кирәгеннән артык күп кулланалар.

Мәкальне күп куша, ләкин һаман
Образлары булмый өр-яңа.
«Җырның ертыгы юк» дигән саен...
Ямаулы җыр туа дөньяга.

## Ә син килдең...

*Элеккеге диңгезче*
*Миргазыян Юныска.*

Без гади авыл малае...
Зур дөньяга күтәрелдек
Без абзар артларыннан.
Ә син килдең ераклардан,
Ак канатлы корабларда —
Занзибар якларыннан.

Сәяхәтләрдән кайттың да,
Син каләм алдың кулга.
Сәнгатьтә дә, әдип, шул ук
Миргазыян булып кал син,
Тик миргә зыян булма!

Альберт Яхин

# КҮРГӘЗМӘ ӘСБАП

ХИКӘЯ

Күргәзмә әсбап, ниһаять, укучыларга аң-белем бирү эшендә алыштыргысыз коралга әверелде. Ул алыштыргысыз коралга мин үзем бер күрүдә үк менә болай гашыйк булдым. Шул җан кисәгем ярдәме белән без — алдынгы укучылар — класста иң катлаулы мәсьәләләрне дә тун әйләндергәндәй әйләндереп кенә салабыз, дөньяның иң ерак почмакларына да күз ачып йомганчы барып кайтабыз. Матур әдәбият турында әйтеп тә торасы юк. Күргәзмә әсбапларны файдалана башлаганнан бирле укучылар тарафыннан аны үзләштерү күп мәртәбәләргә артты. Шулар аркасында хәзер мин үзем матур әдәбият гыйлемен укучылар башына мичкәгә чиләкләп су тутыргандай тутырам. Ул суны келәт бикләгәндәй бикләп куям. Мактанып әйтә дип уйламагыз, бер мин генә алай итмим, әлбәттә. Яңалыктан баш тартмаучылар тагын да бар. Ә шулай да...

Мин менә бүген күргәзмә әсбаплар файдаланып дәрес бирәм, дәресемә тирә-юнь авылларыннан җыелган укытучылар кереп утырдылар һәм авызларын ачып, күзләрен шар итеп шаккатып торалар. Күргәзмә әсбапны шул аны ярата белү генә җитми. Аны алдан әзерләргә кирәк. Ә әзерләү өчен уйланырга кирәк. Ә уйлану өчен менә монда, кем әйтмешли, ул-бу булырга тиеш.

Мәсәлән, Тукаебызның «Гали белән Кәҗә» шигырен укып кына да чыгып була. Аннан соң Гали яшәгән заманның караңгылыгы, культурасызлыгы турында сөйлисең, клублар ачык булмау сәбәпле, мәдрәсәләрдә укытучылар булмау сәбәпле Галинең бердәнбер күңел ачу шөгыле кәҗә ашату кебек бик дөрес фикерне без барыбыз да әйтә-әйтә туеп беткән инде. Ә менә әдәбиятны тормыш белән күбебез бәйли белми әле. Шул максатны тотып кәҗә дигән мал иясенең, ягъни шигырьдәге икенче төп геройның, үзебезнең авыл ит һәм йон балансында торкан урынын авыл советыннан алган саннар белән исбат иткәч, күрше авыллардан җыелган укытучылар егылып китә яздылар. Ләкин күргәзмә әсбап дигәнемне, билгеле, закускасына калдырдым.

Кереш дип аталган өлешен сөйләп бетергәннән соң тамак кырып җибәрүем булды, ишектән иске ыштан, иске чикмән кигән малайның килеп керүе булды. Кунаклар, билгеле, кулында яшел үлән күреп ул малайның әлеге төп унай герой Гали икәнлеген абайлап алдылар. Ишек тагын ачылып китте. Бу юлы аннан озын сакаллы, кәкре мөгезле Минһаҗ завхозның кәҗәсе пәйда булды. Кәҗә Гали кулындагы үләнне тәмләп ашады, башта ни өчендер кычкырып куйды, башын чайкады. Шулай да сакалын селеккәч кенә чыгып китте.

Дәрес турында фикер алышкан чакта мин Гали булып киенгән күрше авыл малаеның үз исеме дә Гали икәнлеген әйткәч, төрле авыллардан җыелган укытучыларым бөтенләй телсез калдылар.

Наратлыдан килгән укытучы сорау биреп маташкан була:

— Тукай кәҗәсе тәрәзә аша сакалын селкетә, ә сезнеке ник класска керә? — имеш.

Алдан әзерләп куйган тирән иронияле җавабым белән авызын капладым куйдым тегенең:

— Кәҗәгез тәрәзә янына килерме, сакалын селкетерме, әгәр селкетсә, аны укучылар класста утырып күрерләрме? Ул кадәрен үзегез эшләп карарсыз, — дидем. Шуннан соң миңа сорау биреп маташучы булмады.

Фатих Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт» повесте буенча үткәрелгән ачык дәрестә күргәзмә әсбапларның тагын да хәтәррәген кулландым.

Кәҗә иясе Минһаҗ завхоз, Фәтхулла хәзрәт кебек киенеп, класска бер кәрҗин йомырка күтәреп керде. Менә шул эшләп утырган телевизорга шуларны берәм-берәм бәрә башлады. Үзе бәрә, үзе берөзлексез «аллаһе әкбәр, аллаһе әкбәр» дип сөйләнә. Анысын нәкъ әсәрдәгечә итә. Хәзерге телевизорлар бик нык бит алар, ай-һай, йомырка бәреп кенә бу карт вата алыр микән, дип уйлап утыралар бугай кунак укытучылар. Тыныч булыгыз, коллегалар, бар да исәпкә алынган, бар да алдан уйланылган. Минһаҗ завхоз, йомыркалар бәрелеп беткәч, телевизор янына килде дә — шап аягы белән экранга. Челпәрәмә китерде.

Бар да ах иттеләр. Әйтәм ич, күргәзмә әсбап әллә нинди могҗизалар эшли ала, дип.

Телевизор эченнән аягын тартып алгач, Минһаҗ алдан ятлаган сүзләрен менә дигән итеп кабатлап чыкты:

— Менә күрдегезме, мәсәлән, бабагыз карт ни эшләде? Сез булсагыз, бәлфараз, авызыгызны ачып торган булыр идегез әле...

Шундый матур итеп кабатлады, Наратлы укытучысы хәтта башын чайкап куйды, онытылмасын дип булса кирәк, блокнотына да нидер язып алды.

Язарлык та булды шул. Син ул бала-чагага элеккеге хәзрәтләрнең наданлыгын, вәхшилеген сәгатьләр буе аңлат — барыбер хәтерләрендә калдыра алмыйлар. Ник дисәң, безнең әдәбияттагы барлык хәзрәтләр дә шундый ук наданнар, шундый ук вәхшиләр. Ә үз күзләре белән иң кыйммәтле телевизорны да тибеп ватуын күргәч, ышанмый кая барсыннар. Гомерләренә онытмаячаклар.

Шуннан соң мин күренекле шагыйребез Һади Такташның «Мокамай» дигән шигырендәге идея эчтәлекне күргәзмә әсбаплар белән ачып салырга тиеш идем. Әйтергә кирәк, бу ачык дәрескә аеруча нык әзерләндем. Класска урманнан гына кисеп алып кайтылган юан-юан ике каен кертеп бастырдык. Аларны стеналарда махсус ясалган ыргакларга трослар белән тарттырып куйдык. Беркайда да булмагандай шаула-

сыннар өчен, район ашханәсенең вентиляторын ботакларына каратып урнаштырдык.

Бу эшләрне читтән чыраен сытып карап торган Наратлы укытучысы директорга ниндидер язу илтеп бирде. Мине директор кабинетына чакырттылар.

— Сез ике малайны югарыга, һаман яктыга, каен башына үрмәләтергә җыенмыйсыздыр бит? — дип сорады директор.

— Канцеляриядә чишенеп маташалар,— дидем.— Сигнал булгач та үрмәләячәкләр.

— Шигырьдәге үрмәләү урынын укып кына күрсәтерсез, — дип, фәрман бирде директор. Ни эшләмәк кирәк. Тыңламый булмый бит. Ничек итеп әзерләнгән дәрес харап булды! Бар да шул Наратлы укытучысы аркасында.

Ә шулай да яңалыкны кабул итә алмаучылар да очрый дип әйткән идем ич.

## ТАТАРСТАН КОМПОЗИТОРЛАРЫНЫҢ IV СЪЕЗДЫ

Узган елның ноябренда Казан консерваториясенең актлар залында Татарстан композиторларының IV съезды булып үтте. Съезд татар композиторларының симфоник әсәрләрен тыңлау белән башланды. Съезд барган көннәрдә актлар залына җыелган күп санлы музыка сөючеләр шәһәребезнең музыка училищесы, музыка мәктәпләре һәм консерватория студентларының әсәрләрен, композиторларыбызның яңа җырларын, инструменталь әсәрләрен зур игътибар белән тыңладылар. Кичләрен Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында Фәрит Яруллинның «Шүрәле», Әнвәр Бакировның «Су анасы» балетлары, Рәшит Гобәйдуллинның «Җиһангир», Хөснул Вәлиуллинның «Самат» опералары һәм Луиза Хәйретдинованың балалар өчен язылган «Мәкерле песи» операсы куелды.

Татарстан Композиторлар союзының ике съезд арасындагы эше турында отчет докладын ТАССР Композиторлар союзы идарәсенең элекке җитәкчесе Нәҗип Җиһанов ясады. Ревизия комиссиясе эше турында доклад белән комиссия председателе, композитор Исмай Шәмсетдинов чыкты.

Докладлар буенча фикер алышуларда композиторлардан Анатолий Луппов, Шамил Шәрифуллин, Леонид Любовский, музыка белгечләре Мәхмүт Нигъмәтҗанов, Роза Исхакова, Галина Касаткина, шагыйрь Илдар Юзеев, культура министры урынбасары, шагыйрь Ренат Харисовлар чыгыш ясады.

РСФСР Композиторлар союзының беренче секретаре, РСФСРның халык артисты А. Я. Эшпай, профессор Г. И. Литинский, РСФСР Композиторлар союзы секретаре В. Г. Агафонников, РСФСР Композиторлар союзы секретаре, Башкортстан Композиторлар союзы идарәсе председателе Заһир Исмәгыйлов, Удмуртия АССР Композиторлар союзының җаваплы секретаре Ю. Л. Толкач, Чувашия АССР Композиторлар союзыннан РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе В. А. Ходяшев, РСФСР Композиторлар союзының Урал бүлеге идарәсе члены профессор Б. Д. Гибалин иптәшләр дә фикер алышуларда катнашып, Мәскәүдә, күрше республикалар һәм өлкәләрдә яшәүче композиторларның дуслык сәламнәрен җиткерделәр һәм үзләренең фикерләре белән уртаклаштылар.

Съезд Мирсәет Яруллин, Бату Мулюков, Фасил Әхмәтов, Рафаэль Белялов, Хөснул Вәлиуллин, Ренат Еникеев, Алмаз Монасыйпов, Заһид Хәбибуллин, Рөстәм Яхиннар составында Татарстан Композиторлар союзының яңа идарәсен сайлады. Композиторлар союзы идарәсенең председателе итеп **Мирсәет Яруллин**, председатель урынбасарлары итеп **Бату Мулюков** һәм **Фасил Әхмәтов**, ревизия комиссиясенең председателе итеп **Исмай Шәмсетдиновлар** сайланды.

Биш көн барган бу зур иҗади сөйләшүдә Мәскәүдән, тугандаш республикалардан килгән кунаклар, КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре А. Г. Кадырова иптәшләр катнашты.

## ТАТАР РАДИОСЫНА 50 ЕЛ

Ноябрь аенда Татарстан Министрлар Советының Телевидение һәм радиотапшырулар комитеты эшчәнлегенә 50 ел тулды. Шул уңай белән шәһәребезнең Яшьләр үзәге йортында тантаналы кичә уздырылды. Анда радиотапшырулар, телевидение, радио-телеүзәк, элемтә работниклары, язучылар, журналистлар, партия, совет һәм җәмәгать оешмалары вәкилләре катнашты.

Җыелышны ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов ачты.

КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев КПССның Татарстан өлкә комитеты, ТАССР Верховный Советы Президиумы, ТАССР Министрлар Советы исеменнән котлау белән чыкты.

Татарстан радиосының илле еллык эше турындагы докладны ТАССР Министрлар Советының Телевидение һәм радиотапшырулар комитеты председателе Ф. Г. Надыйров ясады.

СССР Министрлар Советының Дәүләт телевидение һәм радиотапшырулар комитеты председателе урынбасары Г. З. Юшкявичус тантаналы җыелышта катнашучыларга котлау белән мөрәҗәгать итте һәм комитетка СССР дәүләт телерадиосының Почет грамотасын тапшырды.

Юбилярларны республикабыз журналистлары исеменнән «Социалистик Татарстан» газетасы редакторы Ш. Х. Хаммәтов, Казан радиотапшырулар станциясенең элекке техникы, хәзер СССР Элемтә министрлыгының Дәүләт проект институты баш белгече, техник фәннәр докторы, Дәүләт премиясе лауреаты В. М. Тимофеев, шагыйрь Заки Нури, РСФСРның атказанган артисткасы Рәшидә Җиһаншина, Чаллы шәһәренең ташчылар бригадасы бригадиры В. С. Мәүликов, «Әлмәтнефть» идарәсенең өлкән операторы Социалистик Хезмәт Герое А. Ш. Сафиуллин, Лаеш районы «Победа» колхозы председателе Д. Ж. Вәлиуллин, ВЛКСМ өлкә комитеты секретаре Ф. Ә. Илдарханова, Мордовия АССР Министрлар Советының Телевидение һәм радиотапшырулар комитеты председателе В. П. Бочкарев иптәшләр котлады.

Тантаналы утырышта Татарстан Министрлар Советы Председателе Г. И. Усманов, КПСС өлкә комитетының икенче секретаре Ф. И. Панин, ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары А. М. Котов, ТАССР халык контроле комитеты председателе М. М. Репеев һ. б. иптәшләр катнашты. Тантанага килгән кунаклар республикабызның сәнгать осталары концертын карадылар.

* * *

Татар радиосына 50 ел тулу уңае белән радио тапшырулар һәм радио-телевидение үзәге работникларыннан бер төркем иптәшләргә **РСФСРның атказанган культура работнигы, Татарстан АССРның атказанган культура работнигы** дигән мактаулы исемнәр бирелде, күп кенә работниклар **Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы, КПССның Татарстан өлкә комитеты һәм Министрлар Советының Почет грамотасы, СССР Дәүләт телерадиосының Почет грамотасы, «Телевидение һәм радио отличнигы», «Почетлы радист»** билгеләре белән бүләкләнделәр.

## КОММУНИСТЛАР КИҢӘШӘ

Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында Татарстан Язучылар союзы һәм китап нәшрияты партия оешмаларының берләштерелгән утырышы булды. Партия Үзәк Комитетының октябрь (1977 ел) Пленумы йомгаклары яктылыгында язучыларның һәм нәшрият работникларының бурычлары турындагы докладны нәшрият директоры Г. Н. Шәрәфетдинов сөйләде. Ул, әдәбиятыбыздагы соңгы еллар уңышын билгеләп үтү белән бергә, вакыйга булырлык зур әсәрләрнең азрак язылуын әйтте, кайбер язучыларның китапларын тәнкыйтьләде. Доклад буенча фикер алышуларда Геннадий Паушкин, Габдрахман Минский, Риза Ишморат, Шамил Рәкыйповлар катнашты.

Җыелыш язучыларның иҗат активлыгын үстерү һәм нәшрият эшен тагын да яхшырту буенча карар кабул итте.

## ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Чаллы шәһәренең «Энергетик» культура сараенда яшь һәм башлап язучыларның беренче зона конференциясе булып үтте.

Татарстан Язучылар союзы идарәсе һәм ВЛКСМ өлкә комитеты тарафыннан оештырылган бу конференцияне Чаллы шәһәр советы башкарма комитеты председателе урынбасары Г. М. Хәкимова ачты.

Чаллы шәһәре, Тукай, Түбән Кама, Зәй һәм Алабуга районнарының яшь әдәби көчләре Татарстан Язучылар союзының партоешма секретаре, драматург Туфан Миңнуллинның чыгышын һәм «Совет әдәбиятында — КамАЗ» дигән докладны (докладчы Рафаэль Мостафин) зур кызыксыну белән тыңладылар.

Чаллы әдәби берләшмәсе «Ләйсән» (җитәкчесе Р. Лотфуллин), Түбән Кама әдәби берләшмәсе «Кама таңнары» (җитәкчесе Р. Хисмәтуллин), Зәй әдәби берләшмәсе «Зәй энҗеләре»нең (җитәкчесе Р. Сәлимҗанов) эше турындагы отчетлар да игътибар үзәгендә булдылар.

Конкрет әсәрләрне тикшерү укучы балалар иҗатыннан башланып китте. Шуннан соң яшь язучылар ике көн буена проза, поэзия, драматургия, тәнкыйть секцияләренә бүленеп, җитди әдәби сөйләшүдә катнаштылар. Конференция җитәкчесе Илдар Юзеев, язучылардан Аяз Гыйләҗев, Туфан Миңнуллин, Шәүкәт Галиев, Шамил Рәкыйпов, Гәрәй Рәхим, Сажидә Сөләйманова, Габдулла Шәрәфи, Михаил Скороходов, Эдуард Касыймов, Татарстан Язучылар союзы секретаре, тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин һ. б. яшь көчләрнең әсәрләренә җентекле анализ ясадылар.

Конференция барган көннәрдә Тукай районының Биклән авыл мәктәбендә Габдулла Тукай музее ачылды. Бу тантанага катнашкан язучылар музейга, автографларын язып, китапларын бүләк иттеләр.

Конференциянең йомгаклау утырышында КПСС өлкә комитеты инструкторы И. К. Хәйруллин, КПССның Чаллы шәһәр комитеты секретаре Л. В. Шилова, партиянең Тукай райкомы секретаре Л. И. Пятибратова, ВЛКСМның Чаллы шәһәр комитеты секретаре Фәүзия Харисова, Алабуга педагогия институты ректоры, тәнкыйтьче Талгат Галиуллин, проза секциясе исеменнән Аяз Гыйләҗев, поэзия секциясе исеменнән Илдар Юзеев ике көн дәвам иткән конференциянең уңай нәтиҗәләре турында сөйләделәр.

Чаллы шәһәренең яшь язучылары Мәхмүт Газизов һәм Равил Вәлиев СССР Язучылар союзы членлыгына тәкъдим итәргә лаек дип табылдылар. Күп кенә яшь язучыларның әсәрләре Татарстан китап нәшриятына, республикабыз газета-журналларына басарга тәкъдим ителде.

Конференциянең эше Чаллы промышленность предприятиеләренә сәяхәт, мәктәпләрдә очрашулар һәм зур әдәби-музыкаль кичә белән тәмамланды.

## БАЛАЛАР һӘМ ТЕАТР

РСФСРның культура һәм Мәгариф министрлыклары, ВЛКСМ Үзәк Комитеты һәм Бөтенроссия театр җәмгыяте президиумы инициативасы белән өченче ел инде илебездә «Театр һәм балалар атналыгы» үткәрелә.

Республикабызда үткәрелгән бәйрәм ноябрь ахырында Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында тантаналы рәвештә башланып китте.

ТАССР культура министры урынбасары Р. М. Харисов, мәгариф министры урынбасары Р. В. Шакиров, ВЛКСМ өлкә комитеты секретаре Ф. Ә. Илдарханова, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге председателе Р. А. Җиһаншина балаларны театр атналыгы ачылу белән котладылар.

Тантанадан соң шәһәребезнең яшь тамашачылары Казан театрлары артистлары башкаруында спектакльләрдән өзекләр карадылар.

Атналык дәвамында республикабыз авылларында һәм шәһәрләрендә мәктәп балаларының спектакльләргә культпоходлары, яшь тамашачылар конференцияләре, күренекле артистлар, драматурглар, компо-

зиторлар белән очрашулар, караган спектакльләр турында фикер алышулар уздырылды.

Казан шәһәренең яшь хәбәрчеләре «Театр сәхнәсендә революция» дигән темага пресс-конференция үткәрделәр. Казан шәһәренең пионер активы сараенда «Октябрь тудырган сәнгать» темасына актерлар һәм укучы балаларның җанлы сөйләшүе уздырылды.

Октябрь революциясенең 60 еллыгына багышлап үткәрелгән театр бәйрәме балалар күңелендә дулкынландыргыч зур вакыйга булып калды.

## КҮРГӘЗМӘ ЗАЛЛАРЫНДА

Казан дәүләт университетында яшь В. И. Ульянов катнашкан студентлар сходкасына узган елның декабренда 90 ел тулды. Бу бөек датаны каршылап, республикабыз Художниклар союзы Татарстан сынлы сәнгать музеенда кызыклы күргәзмә оештырды. «Совет сәнгать осталары әсәрләрендә яшь Ленин образы» дип аталган бу күргәзмәдә Татарстан рәссамнарыннан тыш Мәскәү, Ульяновск, Чабаксар һ. б. шәһәрләрнең осталары да катнашты. Татарстан рәссамнарыннан К. Максимов, В. Кудελькин, Е. Киселева, С. Лывин, В. Маликов, Р. Нигъмәтуллина, В. Рогожин, Т. Зуева, Е. Зуев, И. Симбирин, Р. Имашев һ. б. әсәрләрен күргәзмәгә дип махсус атап яздылар.

Музейның 3 залын биләп торган күргәзмәгә 35 авторның 100 әсәре — сынлы сәнгать, графика, скульптурасы куелган иде. Алар арасында Харис Якуповның «Пролог», В. Скобеевның «М. Вахитов һәм Г. Ибраһимов В. И. Ленин янында», Х. Якупов һәм Л. Фәттаховларның бергәләп ясаган «В. И. Ленинның ТАССРны оештыру турындагы Декретка кул куюы» кебек рәсем сәнгатен сөючеләрнең яратып караган картиналары да бар.

В. И. Ленинның яшьлеген, университет елларын, Кокушкинода сөргендә булган вакытларын чагылдырган бу күргәзмә күп санлы тамашачылар күңелендә тирән эз калдырды.

* * *

Мәскәүдә СССР Сәнгать академиясе залларында яшь рәссамнарның Бөтенсоюз күргәзмәсе булып үтте.

Бу җаваплы күргәзмәдә беренче тапкыр катнашучылар арасында СССР Сәнгать академиясенең Казан остаханәсе (җитәкчесе РСФСРның халык художнигы Харис Якупов) рәссамнары З. Гимаев, С. Слесарский, Ш. Шәйдуллин, Ф. Якуповлар бар иде.

Иҗат алымнары төрле булган бу талантлы яшьләрнең «Дежур кыз Фәния» (З. Гимаев), «Студент рәсеме» (С. Слесарский), «Саша» (Ш. Шәйдуллин), «Җылы җил» (Ф. Якупов) дип исемләнгән әсәрләре башкала тамашачыларында зур кызыксыну уятты.

## РОССИЯ ФЕСТИВАЛЕНДӘ

Октябрьның 60 еллыгына багышлап, милли драматургия һәм СССР халыкларының театрлары фестивале игълан ителгән иде. РСФСР фестивалендә өч йөзгә якын театр катнашып, шулардан 44 спектакльгә I нче Дәрәҗә диплом бирелде. Алар арасында Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры (М. Кәрим трагедиясе буенча «Ташлама утны, Прометей» спектакле өчен), М. Гафури исемендәге башкорт дәүләт академия театры (Туфан Миңнуллинның «Үзебез сайлаган язмыш» драмасы буенча куелган спектакль өчен), Тува драма театрының рус труппасы (Илдар Юзеевнең «Сандугачлар килгән безгә» драмасы буенча куелган спектакль өчен) бар. «Сандугачлар килгән безгә» спектакле иң яхшы 12 спектакль белән бергә Ленинград шәһәрендә күрсәтеләчәк. Шулай ук автономияле республикаларның дүрт драматургы, пьесалары өчен, I нче Дәрәҗә дипломга лаек булды. Аларның икесе татар драматурглары — Туфан Миңнуллин һәм Илдар Юзеев.

## СОВЕТ ПОЭЗИЯСЕНӘ 60 ЕЛ

Бөек Октябрьның 60 еллыгына багышлап, Мәскәүнең «Художественная литература» нәшрияты ватанибыз шагыйрьләренең дүрт томлык шигырьләр китабын чыгарды.

«Совет поэзиясенә 60 ел» дип исемләнгән бу дүрт томлыкның өченче китабында татар поэзиясе вәкилләре Муса Җәлил, Һади Такташ, Гадел Кутуй, Фатих Кәрим, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Әхмәт Исхак, Әнвәр Давыдов, Нури Арсланов, Равил Фәйзуллин, Зәки Нури, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев һ. б. шагыйрьләрнең әсәрләре урнаштырылган.

## ЯЗУЧЫГА — РӘХМӘТ

Сентябрь азакларында Сәмәрканд шәһәрендә язучыларның республика конференциясе булып, анда «Яңа кеше шәхесен тәрбияләүдә хәзерге заман совет әдәбиятының бурычы» дигән темага зур сөйләшү уздырылды.

Октябрь революциясенең 60 еллыгына багышлап үткәрелгән бу конференциядә татар язучылары исеменнән тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин катнашты һәм ул «Совет әдәбиятларының үзара йогынтысы һәм бер-берен баетуы, яңа кеше образын иҗат итүдә гомуми һәм специфик зерымлык» дигән темага чыгыш ясады.

## СӘНГАТЬ ОСТАЛАРЫ ФИНЛЯНДИЯДӘ

Хельсинки шәһәрендәге Тукай җәмгыяте чакыруы буенча Татарстанның халык артисты, Тукай бүләге лауреаты Айрат Арсланов җитәкчелегендә, республикабызның бер төркем сәнгать осталары Финляндиядә булып кайттылар.

Хельсинки һәм Тампера шәһәре, Ярвенпяя эшчеләр поселогы тамашачылары РСФСРның атказанган, ТАССРның халык артисты, Тукай бүләге лауреаты Илһам Шакиров, Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе солисты Римма Ибраһимова, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Марат Әхмәтов (скрипка), Марат Сираҗетдинов (фортепиано), баянчы Рокыя Ибраһимова һәм сәхнә остасы Ай-

рат Арсланов башкаруында Г. Тукай шигырьләрен, аның сүзләренә язылган җырларны, татар совет композиторларының әсәрләрен дулкынланып тыңладылар.

### КИЧӘЛӘР, ОЧРАШУЛАР

Татарстан язучылары Куйбышев өлкәсе хезмәт ияләре белән әледән-әле очрашып торалар. Язучы Хәсән Сарьян, шагыйрь Галимҗан Латыйп һәм «Казан утлары» журналы хезмәткәре Абдулла Сәләхетдиновлар катнашы белән уздырылган әдәби кичәләр өлкәнең Келәүле районында зур күтәренкелек белән узды.

* * *

Куйбышев шәһәре металлургларының татар җыр һәм бию ансамбле «Ялкынлы яшьлек»кә халык ансамбле дигән исем бирелде. Бу бәйрәмдә Татарстан язучыларыннан Мәхмүт Хөсәен, Зөлфәт, Разил Вәлиев, матур әдәбиятны пропагандалау бюросының җитәкчесе Эльс Гаделев катнашты. Куйбышев шәһәре яшьләренең ялкынлы биюләре һәм җырларына кушылып, татар шагыйрьләренең шигырьләре яңгырады.

* * *

«Казан утлары» журналының бүлек редакторлары, шагыйрьләр Гәрәй Рәхим, Рәдиф Гатауллин һәм Роберт Миңнуллиннар Х. Ямашев исемендәге мех берләшмәсенең 1 нче тулай торагында журнал укучылары белән очраштылар, аларга редакциянең алдагы ел планнарын сөйләделәр, шигырьләр укыдылар.

* * *

Шагыйрьләр Рәдиф Гатауллин, Зиннур Насыйбуллин һәм Роберт Миңнуллин Чүпрәле районында булып, «Казан утлары» исемле әдәби кичәләр үткәрделәр. Укучыларны «Казан утлары» журналының планнары белән таныштырдылар, үзләренең яңа шигырьләрен укыдылар.

* * *

Язучы Нәби Дәүли Зеленодольск шәһәренең Куйбышев исемендәге клубында, Казан хәрбиләре янында булып, үзенең китаплары буенча үткәрелгән укучылар конференцияләрендә катнашты. Аларның күп санлы сорауларына җавап бирде, иҗат планнары белән уртаклашты.

Язучы Юдино тимер юлчылар клубында үткәрелгән яшьләр һәм остазлар кичәсендә дә катнашты. Хезмәт һәм сугыш ветераннарына, аларның яшь алмашчыларына әсәрләреннән өзекләр укыды.

* * *

Казан дәүләт университеты «Әллүки» әдәби берләшмәсенең элекке членнары, шагыйрьләр Фәннур Сафин, Роберт Миңнуллин, Җәүдәт Дәрзаманов һәм әдәбият галиме Нурмөхәммәт Хисамов Казандагы 10 нчы интернат-мәктәп укучылары белән очраштылар. Укучыларга «Әллүки» берләшмәсенең тарихы, аның язучылары турында сөйләделәр, шигырьләр укыдылар.

* * *

Казан педагогия училищесының актлар залында композиторлар Бату Мулюков һәм Әнвәр Шәрәфиевнең студентлар һәм укытучылар белән очрашуы булды.

Бу кичәдә сүз Татарстан композиторларының музыкаль әсәрләре турында барды, сәхнә осталары һәм Казан студентлары башкаруында концерт бирелде.

### ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Әлмәттә яшәүче язучылар, сәнгать вәкилләре һәм журналистлар Шашин исемендәге Ленин орденлы «Татнефть» берләшмәсендә очрашуда булдылар, әдәбият, сәнгать һәм производство яңалыклары турында фикер алыштылар.

Әдип Маликов, Рафаил Төхфәтуллин, Саҗидә Сөләйманова, Гамил Афзал, Юныс Әминов, Әлмәт татар дәүләт драма театрының баш режиссеры Гали Хөсәенов, музыка училищесы дирижеры В. Чепкасов һәм башка иптәшләргә, нефтьчеләрне коммунистик һәм эстетик тәрбияләүдә актив катнашканнары өчен, «Татнефть» берләшмәсенең һәм нефть-газ промышленносте профсоюзы өлкә комитетының **мактау грамоталары** тапшырылды.

Генераль директор урынбасары Үзбәк Саттаров «Татнефть» берләшмәсе һәм нефтьчеләр профсоюзы өлкә комитеты исеменнән бүләкләнүчеләргә яңа иҗат уңышлары теләде. Язучылар нефтьчеләргә китапханә бүләк иттеләр.

* * *

Лениногорск әдәби берләшмәсенең чираттагы утырышы әдәби осталык мәсьәләсенә багышланды.

Татарстан язучыларының Әлмәт бүлеге җитәкчесе Әдип Маликов, Тукай бүләге лауреаты Гамил Афзал, Шамил Бикчурин яшь авторларның иҗатлары турында сөйләделәр.

* * *

Бүлек язучылары нефть районнарындагы әдәби көчләр белән тыгыз элемтәдә яшиләр. Баулы әдәби берләшмәсендә Сәет Кальметов, Җәмит Рәхимов, Әлмәт һәм Азнакай әдәби берләшмәләре утырышларында Саҗидә Сөләйманова, Гамил Афзал, Рафаил Төхфәтуллин, Мәхмүт Хәсәнов иптәшләр яшь авторлар белән очраштылар, аларның әсәрләренә төпле анализ ясадылар.

* * *

Азнакай поселогындагы бораулау эшләре идарәсе клубында язучы Мәхмүт Хәсәновның иҗатына багышланган әдәби кичә уздырылды. Нефтьчеләр язучының әсәрләре турында фикерләрен әйттеләр. Яшь шагыйрь Нур Әхмәдиев үзенең яңа шигырьләрен укыды. Мондый кызыклы кичәләр Азнакайдагы 1 нче һәм 2 нче номерлы урта мәктәпләрдә дә үткәрелә.

* * *

Шагыйрә Саҗидә Сөләйманова КамАЗ төзүчеләре белән еш очраша һәм Чаллыдагы әдәбият берләшмәсе членнарына иҗади ярдәм күрсәтә. Аның композитор Әнвәр Бакиров белән иҗат иткән «КамАЗ җыры» Бөтенроссия конкурсы бүләгенә лаек булды. Шул хезмәтләрен искә алып, С. Сөләйманова **«КамАЗ төзелеше ударнигы»** дигән значок белән бүләкләнде.




*Архитектор ИСМӘГЫЙЛЬ ГАЙНЕТДИНОВ*

*Рәссам Б. УРМАНЧЕ рәсеменнән фоторепродукция*

## Хөрмәтле укучыбыз!

Сезне «Почет билгесе» орденлы «Казан утлары» журналының 3 нче саны белән таныштырабыз.

**Бу сан Шәйхи Маннурның «Чын сөю бармы?» дигән лирик повесте белән ачыла. Әсәр мәхәббәтнең сафлыгын, югары әхлак мәсьәләләрен яклап язылган.**

Нәбирә Гыйматдинова журналда әле беренче тапкыр катнаша. «Су хикәяте» дигән озын хикәясен ул «Замандаш» конкурсына дип җибәргән.

Бу санда хатын-кыз авторларга аеруча күп урын бирелә. Сез Саҗидә Сөләйманова, Фәния Чанышева, Клара Булатова, Флера Гыйззәтуллина һәм Чаллыда яшәүче бер төркем яшь авторларның шигырьләрен укырсыз.

Татар халкы элек-электән җыр яраткан һәм аның бик борынгыдан килгән бай мирасы бар, хәзерге заман җырлары күп. Фольклор галимнәре һәм музыка белгечләре бу байлыкны өйрәнеп, күп кенә гыйльми хезмәтләр язалар. В. Лукъяновның бу санда басылган «Халык җыры — тәрбия чарасы» дигән хезмәте дә шул байлыкка бер өлеш булачак.

Л. Җамалетдиновның «Энҗе чәчтем, энҗе җыйдым» дигән мәкаләсе исә халык җәүһәрләренең иkенче бер тәрәнә — әкиятләр дөньясына сәяхәт иттерәчәк.

Март аенда «Социалистик Татарстан» газетасының чыга башлавына 60 ел тула. Газетаның редакторы Ш. Хамматов шул уңай белән «Әдәбият һәм сәнгать елъязмасы» дигән мәкалә бастыра.

А. Литвинның «Революция солдаты» дигән мәкаләсе данлы сугышчы, генерал Якуп Чанышев тормышына багышлана. Җ. Кәлимуллинның «Егет булсаң — даның китсен» дигән очеркы республикабызның хезмәт алдынгылары турында сөйли.

Өченче саннан журналыбызда бүгенге татар поэзиясе турында зур сөйләшү филология фәннәре докторы Ибраһим Нуруллин һәм шагыйрь Равил Фәйзуллин әңгәмәсеннән башлана.

«Культурабыз тарихына материаллар» дигән бүлектә М. Әхмәтҗановның «Татар шәҗәрәләре һәм аларның төрләре» дигән кызыклы материалы бирелә.

Әдәбиятта инде үзләрен таныткан язучылардан Альберт Яхин, Лирон Хәмидуллин, Роберт Миңнуллин, Мансур Вәлиевләр үзгән ел СССР Язучылар союзына кабул ителделәр. Алар турындагы кыскача белешмәләрне сез шушы ук саннан укый алырсыз.

«Безнең календарь» бүлеге күп кенә язучыларның туган көннәрен билгеләп үтә.

«Китап күзәтү» бүлеге исә Т. Галиуллин һәм Р. Ягъфәровларның рецензияләрен урнаштыра.

Һәр сандагыча, әдәбият һәм сәнгать яңалыклары бирелә.

**Хөрмәтле укучыбыз!**

**Әгәр сез журналга бөтен бер елга язылмаган булсагыз яки аны әлегә алдырмый калсагыз, исегезгә төшерәбез:**

**«Казан утлары» журналының теләсә кайсы санына алдагы айның 20 числосыннан да соңга калмыйча язылырга мөмкин. Журналның индексы 73210, язылу бәясе бер елга 6 сум.**

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210